# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

## Тормыш
## һәм
## иҗат елъязмасы

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

УДК 01
ББК 91.9.83
Т72

**Редколлегия:**

Н.Г.Юзиев (*җаваплы мөхәррир*), Ә.Х.Алиева, З.З.Рәмиев
(*фәнни мөхәррирләр*)

**Төзүчеләре:**

Ә.Х.АЛИЕВА
Ф.И.ИБРАҺИМОВА

**Рецензентлары:**

Филология фәннәре докторы, профессор Р.К.Ганиева
Филология фәннәре докторы, профессор Ф.З.Яхин

Т 72 Габдулла Тукай: Тормыш һәм иҗат елъязмасы.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2003.— 271 бит.

Китапта классик шагыйребез Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы беренче тапкыр хронологик тәртиптә тәкъдим ителә. Укучылар шагыйрь турында моңарчы билгеле булмаган өр-яңа мәгълүматлар белән дә таныша алачаклар.

ISBN 5-298-00641-8

©Татарстан китап нәшрияты, 2003
©Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2003

## РЕДКОЛЛЕГИЯДӘН

Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлы күптәннән өйрәнелеп килә. Әдәбият галимнәре бу проблеманы игътибар үзәгенә куеп, күп кенә китаплар, монографик хезмәтләр яздылар. Берничә мәртәбә әсәрләренең күптомлы тупланмалары да басылып, киң катлам укучыга җиткерелде.

Тукайга багышланган мемуар әдәбият шактый бай. Үлгән көненнән алып 50—60 елларга кадәрге чорда аның турында йөзгә якын истәлек язылды. Шулардан кайберләре архивта саклана, күбесе матбугатта да дөнья күргән.

Ләкин Тукайның тәрҗемәи хәле әле тарихи эзлеклелектә өйрәнелгән дип булмый. Шагыйрь тормышына караган аерым вакыйгалар һәм иҗаты белән бәйле фактлар, бәхәсле детальләр хроникаль яктан якын килеп ачыклауны сорый. Шуңа да аның иҗат һәм тормыш елъязмасын төзү мөһим мәсьәлә булып калуын дәвам итә. Бу ихтыяҗны истә тотып, соңгы елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кулъязмалар һәм текстология бүлегеннән бер төркем хезмәткәрләр Тукайның иҗат һәм тормыш елъязмасын кабат күздән кичерү белән мәшгуль булдылар. Әдипнең шәхси тормышына кагылышлы фактларны, вакыйгаларны, иҗади хезмәтен, һәр әсәренең язылу, басылу даталарын аның иҗат юлына тәңгәл килерлек итеп укучыга җиткерү максаты куеп эшләнгән эшнең нәтиҗәсе буларак, шушы гыйльми хезмәт барлыкка килде.

Елъязманың 1886—1908 елларга караган өлешен өлкән фәнни хезмәткәр Фатыйма Ибраһимова, 1909—1913 еллар эчендәгесен өлкән фәнни хезмәткәр Әнисә Алиева төзеде.

Әйткәнебезчә, Тукайның тормышын һәм иҗатын тикшереп язган хезмәтләр байтак санда. Болар арасыннан елъязманы төзүчеләр төп чыганак буларак түбәндәге материалларны сайлап алдылар:

1) шагыйрьнең үзе исән чакта вакытлы матбугатта дөнья күргән хезмәтләре; аерым китап булып басылган әсәрләре һәм аларга карата чыккан рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре;

2) замандашлары, дуслары һәм туганнарының истәлекләре;

3) шагыйрь үзе язган һәм аңа атап язылган хатлар;

4) аның эшчәнлегенә мөнәсәбәте булган архивларда саклаиган материаллар;

5) әдипнең иҗатын, шәхесен өйрәнеп язылган монографияләр, юбилей җыентыклары.

Тукайның иҗатын яки тормышын яктыртуда кыйммәтле мәгълүмат биргән хатларның кайберләреннән өземтәләр дә китерелде, ә калганнарына кыскача аннотация бирү белән генә чикләнелде. Аеруча әһәмияткә ия булган яисә тормыштагы берәр истәлекле вакыйгага, теге яки бу сыйфатлары белән татар дөньясына билгеле шәхесләргә багышлап язылган әсәрләренең эчтәлеге, тарихы турында кыскача әйтеп үтелде. Тукайның дуслары, фикердәшләре, танышлары, алар арасындагы мөнәсәбәтләр, ул аралашкан даирә мөмкин кадәр тулырак күрсәтелергә тырышылды. Шулай ук шагыйрьнең иҗатына багышланган тәнкыйди хезмәтләр, рецензияләр турында мәгълүмат бирелде, кайберләреннән өзекләр дә китерелде.

Аерым көнгә, айга беркетелмәгән фактлар «кыш», «җәй» һ.б. диеп, ел фасылына туры килгән урында бирелде.

Бер үк көндә булган фактлар алдында дата бер генә тапкыр язылды.

Күрсәтелгән фактлар тарихи яктан төгәл булмаска да мөмкин, шуңа күрә бәхәсле моментларның да чыганаклары күрсәтелде. Бер үк вакытта берничә чыганакка таяну әлеге фикернең шуларга нигезләнүен күрсәтә.

Газета-журналларның чыгу даталары хронологик даталар белән туры килгәндә чыганакта күрсәтелмәде, калган очракларда күрсәтелеп барылды. Теге яки бу басылып чыккан әсәре астында имза буларак «Тукай», «Г.Тукай», «Г.Т.» дип язылган очракта елъязмада бирелмәде, псевдоним белән басылган әсәрләренең имзасы күрсәтелде.

Г.Тукайныкы булу ихтимал дип уйланылган имзасыз әсәрләре, Биш томлы «Әсәрләр»енә нигезләнеп, елъязмада урын алдылар.

Бик еш кабатлана торган чыганаклар шартлы кыскартылмалар белән бирелде, алар түбәндәгеләр:

1. «Г.Тукай шигырьләре», 1926 — Габдулла Тукай шигырьләре. Төзүчесе Ф.Бурнаш. Казан: «Гажур» нәшрияты, 1926.

2. Өч томлы «Әсәрләр» — Г.Тукай әсәрләре. Өч томда. Төзүчесе Ф.Сәйфи-Казанлы. Казан: «Яңалиф» нәшрияты, 1929—1931.

3. Биш томлы «Әсәрләр» — Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда. Төзүчеләре Р.Гайнанов, Л.Гайнанова (3 том). Казан: Татар. кит. нәшр., 1985—1986.

4. «Әдәбият», 1909 — Габдулла Тукай. Әдәбият («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр). Казан: «Үрнәк» матбагасы, 1909.

5. «Мәҗмугаи асарь» — Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре (Җамалетдин Вәлиди тарафыннан язылган Тукайның тәрҗе-

мәи хәле һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә). Казан: «Мәгариф» көтепханәсе, 1914.

6. «Балалар күңеле» — Габдулла Тукай. Балалар күңеле. Беренче җөзьэ. Ибтидаи мәктәпләр өчен шигырьләр мәҗмугасы. Казан: «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов литотипографиясе, 1909.

7. «3 нче дәфтәр» — Габдулла Тукаев шигырьләре («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр). Беренче кыйсем. Казан: Шәрәф матбагасы, 1907.

8. «4 нче дәфтәр» — Габдулла Тукаев шигырьләре («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр). Икенче кыйсем. Казан: Шәрәф матбагасы, 1907.

9. «Исемдә калганнар» — Габдулла Тукай. Исемдә калганнар. Казан: «Үрнәк» матбагасы, 1909.

10. «Замандашлары» — Тукай турында замандашлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

11. «Истәлекләр» — Тукай турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

12. «Хатирәләр» — Тукай турында хатирәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.

13. «Габдулла Тукай», 1948 — Габдулла Тукай. Шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары.Казан: Татар. кит. нәшр., 1948.

14. Нафигов Р. Тайны... — Р.И.Нафигов. Тайны революционного подполья (Архивные поиски и находки). Издатель-ство Казанского университета, 1981.

15. ТРМА — Татарстан Республикасы Милли архивы.

16. ПҮДТА — Петербург Үзәк дәүләт тарих архивы.

17. Мирасханә — Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Кулъязмалар һәм текстология бүлегенең мирасханәсе.

18. «КУ» — «Казан утлары» журналы.

19. «СӘ» — «Совет әдәбияты» журналы.

Җыйнап әйткәндә, бу хезмәт бөек шагыйрьне безгә тагын да якынайта төшәр, аның шәхесен ачыграк күрергә, иҗатын тулырак аңларга ярдәм итәр, дип ышанасы килә.

## 1886

**14 (26 апрель)** Габдулла Тукай Казан губернасы Казан өязе Кушлавыч авылында (хәзерге Татарстанның Әтнә районы) указлы мулла Мөхәммәтгариф* Мөхәммәтгалим** мулла улы белән Бибимәмдүдә*** Зиннәтулла**** мулла кызы гаиләсендә дөньяга килә.

Казан губернасы Казан өязе буенча 1886 елда туган, өйләнешкән һәм үлгән кешеләрне теркәү кенәгәсендә аны үз этисе Мөхәммәтгариф мулла «Габдуллаҗан» исеме белән теркәп куйган.

*ТРМА. 4-ф., 177-тасв., 237-эш, 353 б.; Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 149 б.*

**29 август.** Г.Тукайның этисе Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалим улы 44 яшендә кату зәхмәтеннән үлә. Кушлавыч авылы зиратына җирләнә. Әтисе үлгәндә, Габдуллага дүрт ай ярым була.

---

* Мөхәммәтгариф (1843—1886) — Татарстанның Әтнә районы Кушлавыч авылында туган, Кышкар мәдрәсәсен тәмамлап, 1864 елның 30 апрелендә муллалыкка указ алып, Кушлавыч авылында икенче мәхәлләдә мулла булып торган.

** Мөхәммәтгалим — Кушлавыч мулласы, аның җәмәгате Мәргубә Әтнә районы Җөлби авылыныкы булган. Аларның биш баласы: өчесе ир — Зариф, Мөхәммәтгариф, Шакирҗан, кызлары — Газизә һәм Файзә.

*** Бибимәмдүдә (1864—1890) — (әлеге документта, ни сәбәптәндер, Миңсафа дип язылган) Зиннәтулла мулла белән Камилә кызы. Өчиледә туган. Әнисе Камилә иртә үлеп, үги ана кулында үскән. Укымышлы булган, шигырьләр язган, кул эшләре белән шөгыльләнгән, калфак чиккән. Төскә матур булган. Истәлек авторлары Тукайда әнисе чалымнары күренүен әйтәләр.

**** Зиннәтулла — Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмиров (1829—1909) — Өчиле авылы имамы. Ул китап күчерү белән дә шөгыльләнгән, шигырьләр дә язган. Кызы Мәмдүдә үлгәннән соң чыгарган «Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән» дигән шигыре Тукайның Саҗидә апасы истәлегендә дә урнаштырылган. (М.Укмасый. Сайланма әсәрләр. Казан, 1958, 105 б.) Зиннәтулла Өчилегә (Татарстанның хәзерге Әтнә районы) Кышкар мәдрәсәсен тәмамлап килгән. Чыгышы белән хәзерге Пермь өлкәсенә керә торган Барда районы Коҗмакты исемле татар авылыннан булган. Ерак бабалары Түмән ягына Татарстан җиреннән күчеп киткәннәр.

Г.Тукайның шигъри таланты әнисе һәм бабасы Зиннәтулла ягыннан килә. Әтисе ягыннан туганнарының күбесе сәүдә эше белән шөгыльләнгән.

Мәмдүдә, ире Мөхәммәтгариф үлгәннән соң, этисе йортына кайткан. Монда кайту датасы билгеле түгел.

*ТРМА. 4-ф., 177-тасв., 237-эш, 349 б.;*
*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли.*
*«КУ», 1976, 3 нче сан, 147 б.*

## 1888

**22 декабрь.** Г.Тукайның әнисе Бибимәмдүдә Малмыж өязе (хәзерге Балтач районы) Сасна пучинкәсе авылының указсыз мулласы Мөхәммәтшакир Фәйзуллинга (1819—1916) икенче мәртәбә тормышка чыга. Мәмдүдәгә 23, Мөхәммәтшакирга 69 яшь була.

Никях мәҗлесе Өчиледә, этисе Зиннәтулла йортында үтә. Мөхәммәтшакир Мәмдүдә өчен 30 тәңкә мәһәр бирә.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли.*
*«КУ», 1976, 3 нче сан, 147 б.*

**22 декабрьдән соң.** Әнисе Мәмдүдә Сасна пучинкәсе авылына кияве йортына күчеп киткәндә, кечкенә Габдуллаҗанны Кушлавычка алып барып, Шәрифә исемле фәкыйрь бер карчыкка вакытлыча асрамага биреп калдыра. Бу вакытта Габдуллага ике яшь тә сигез ай була.

«Исемдә калганнар» исемле автобиографик очеркында ул үзе бу карчыкта үткән көннәре турында болай ди: «...мин бу карчык ханәсендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән; тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән».

*«Исемдә калганнар», 5 б.*

## 1889

**Март—апрель**. Әнисе Мәмдүдә Габдулланы үз янына Сасна пучинкәсенә алдырта.

«Исемдә калганнар»да бу турыда түбәндәге сүзләр язылган: «...анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк: ул бервакыт мине үзе янына Саснага алдыртырга атлар җибәрткән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән дәкыйкаләрдә миндә, бала булсам да, бер нәүгы шөгур хасил булганмы, нидәндер, мин хәзердә дә атта утырып Саснага бар-

---

Дәкыйка — минут.

Бер нәүгы шөгур хасил булганмы — бертөрле сизенү, аң ачылып китү барлыкка килгәнме.

ганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам. ...үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым биш минутлык төш шикелле генә әле дә булса хәтеремдә».

Тукай Сасна пучинкәсендә бер елга якын торган.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 148 б.;*
*«Исемдә калганнар», 7 б.*

## 1890

**18 гыйнвар.** Г.Тукайның әнисе Бибимәмдүдә Зиннәтулла мулла кызы 26 яшендә эченнән кан китү авыруыннан вафат була. Архив язмаларында «эч китү» авыруыннан диелгән.

Казан губернасы Казан өязе Сасна пучинкәсе авылы зиратына күмелә. Кабер урыны билгесез. 3 яшь тә 9 ай булганда, әти-әнисе үлеп, Габдулла тома ятим кала.

«Исемдә калганнар» автобиографик очеркында Тукай бу вакыйганы хәтерендә түбәндәгечә яңарта: «Мин монда әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, ялан-баш хәлендә капка астыннан үкереп җылый-җылый җөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» — дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне язамын».

*Вятка губернасы Малмыж өязе буенча 1890 елда туган, өйләнешкән һәм үлгән кешеләрне теркәү кенәгәсе. ТРМА. 4-ф., 1-тасв., 68-эш, 160 б.;*
*«Исемдә калганнар», 7 б.;*
*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 148 б.*

**Февраль—март**. Әнисе вафат булганнан соң Габдулла яңадан Өчилегә, бабасы Зиннәтулла йортына кайтарыла. Бу турыда Г.Тукай үзе болай дип яза: «Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле каръясендәге анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән».

«Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән» исемле язмада Габдулланың Өчилегә яңадан кайту елы итеп 1891 ел күрсәтелгән. Ләкин бу дата чынбарлыкка бик үк туры килми.

---

Тәхаттыр итү — хәтерләү.

Тукайның биографиясен архив чыганакларыннан өйрәнгән Р.Якупов фикере дөреслеккә якынрак тора.

«Нәни Габдулла исә Сасна пучинкәсенә 1889 елның март-апрель айларында килеп, 1890 елның февраль-март айлары тирәсендә аннан киткән булырга тиеш»,— ди Р.Якупов. Чөнки Зиннәтулла карт кызының вафаты турында бер ел ишетми торырга мөмкин түгел. Мәкаләдә Габдулланы Саснадан Өчилегә бабасы Зиннәтулла мулла алып кайткан, дип әйтелә.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 148 б.;*
*Укмасый М. Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән. «Сайланма әсәрләр», 1958, 107 б.;*
*«Исемдә калганнар», 7—8 б.*

**12 март.** Г.Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф ике мәртәбә өйләнә. Беренче хатыны — Бибигафифә, икенчесе — Бибимәмдүдә. Беренче хатыныннан Газизә белән Мөхәммәтшәриф исемле ике бала кала. Мөхәммәтшәриф Казанда Җамали хәрчәүнәсендә буфетчы булып эшли. Тиф белән авырып туган авылы Кушлавычта 12 мартта вафат була. Кушлавыч зиратына күмелә. Туган елы — 1873.

*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 96 б.;*
*Зәбирова Г. Тукай хакында истә калганнар. «Истәлекләр», 1986, 27 б.*

## 1891

**Ел урталары.** Зиннәтулла бабасы белән үги әбисе Латыйфә Габдулланы бер авыл ямщигына утыртып, Казанга озаталар. Сасна пучинкәсеннән 1890 елның февраль-март айларында кайткан Габдулла бабасы йортында 1891 елның урталарына кадәр торган булырга тиеш. Чөнки Тукай соңыннан бу вакытта каты ачлык булуын (ачлык 1891 елны була), бабасының ишле гаиләсе бик мохтаҗлыкта яшәвен искә ала. Казанга озатылу моменты турында ул болай ди: «Ямщик Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?!» — дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган.

...Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде».

Алар Яңа Бистәдә торганнар.

*«Исемдә калганнар», 9—10 б.*

**Ел башы.** Мөхәммәтвәли белән Газизә, каты авырып киткәнлектән, үзебез үлсәк, бу бала кемгә калыр, дип куркып, Габдулланы бер ямщикка утыртып яңадан Өчилегә, бабасы Зиннәтулла өенә кайтарып җибәрәләр.

Тукай «Исемдә калганнар» автобиографик очеркында: «Бу ата-анамда ике елмы, күпмедер торгач»,— дип әйтсә дә, ул монда бер елдан артык тормаган булырга тиеш. Р.Якупов аның 1892 ел урталарында Кырлайга килүен документлар белән исбат итә.

*«Исемдә калганнар», 11 б.;*
*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 150 б.*

**Июнь урталары.** Бабасы Зиннәтулла Габдулланы Кырлай авылы кешесе Сәгъдигә асрамага биреп җибәрә. «Исемдә калганнар» автобиографик очеркында шагыйрь үзе дә болай ди: «Кырлай исемле бездән җиде генә чакрым авылдан Сәгъди исемле бер ир баласыз кеше килеп, мине үзенә алып киткән». Апасы Саҗидә* бу моментны түбәндәгечә искә ала: «Габдулла өйдән чыгып киткәндә, Зиннәтулла карт: «Бер дә бирмәс идем, дөньясы шул»,— дип, яулык белән күзен сөртә-сөртә озатып кала».

Саҗидә апасы үзе дә Тукай турында истәлекләр язып калдырган. Ул истәлек «Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән» исеме белән М.Укмасыйның «Сайланма әсәрләр»ендә (Казан, 1958) басылган.

Булачак шагыйрьнең Кырлайга кайчан килүе турында төрлечә әйтелә. Хәлилрахман Гобәйдуллин (Тукайның Кырлайдагы беренче остазы Фәтхерахман мулла улы) аның бу авылга 1892 елда түгел, 1894 елда килүе турында сөйли.

Р.Якупов исә Габдулланың Кырлайга 1892 елда килүен архив документлары белән исбат итә.

Кырлай — Г.Тукай иҗатына билгеле бер эз салган авыл, үзе әйткәнчә, «минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным». «Шүрәле» поэмасында, «Туган җиремә», «Туган авыл» шигырьләрендә ул Казан артын аерым бер мәхәббәт белән сурәтли.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 150—151 б.;*

* Саҗидә (Бибисаҗидә Зиннәтулла кызы Хәбибуллина, 1877—1956) — Тукайның әнисе белән бертуган (ата бер, ана башка) иң яраткан апасы. Шагыйрь аны «Исемдә калганнар»ында «...ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә ап-ак саф бер фәрештә күренә»,— дип яза. Уральскида, Казанда яшәгәндә дә аңа җылы-җылы хатлар җибәрә.

**30 июль.** Сәгъди абзыйның Бибисабира исемле кызы 23 яшендә вафат була һәм Кырлай авылы зиратына күмелә.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 150 б.*

**Көз (якынча октябрь башы).** Үги әнисе Зөһрә абыстай Габдулланы укырга илтә. (Ул вакытларда укулар кыр эшләре төгәлләнгәч башланган) «...әни мине кулымнан җитәкләде дә үземездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды... Әни мине тапшырып, үзе киткәч, мин кызлар белән бергә: «Әлеб, би, ти, си, җымыкый»ны бер дә тарланмыйча кычкырып укый башладым»,— ди Тукай «Исемдә калганнар» автобиографик очеркында.

Димәк, Тукай гыйлем дөньясына беренче адымны 1892 елның көзендә Кырлайда ясый.

*«Исемдә калганнар», 20—21 б.*

## 1893

**Яз көне.** Сәгъди абзыйның Садретдин исемле ир баласы дөньяга килә. Кечкенә Габдулла бу җәйне шул баланы карап үткәрә. Кырлай картларының сөйләвенә караганда, Садретдин революциядән соң Кырлай авылында беренчеләрдән булып Кызыл Армиягә языла һәм Гражданнар сугышында һәлак була.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 151 б.*

**Көз (якынча октябрь башы).** Габдулла абыстайда укуын төгәлләп, мәдрәсәгә күчә. Мәдрәсәдә «Һәфтияк», «Бәдәвам», «Кисекбаш» китапларын бик җиңел үзләштерә. Сабакташы Ахун Сабирҗанов болай ди: «Ул авыл балаларына охшамаган, бик юка гәүдәле һәм чандыр иде. Укырга искиткеч зирәк иде. Беренче кышны ук ул «Һәфтияк» иҗеген, сүрәсен укып, «Коръән»гә керде».

Тукай бу мәдрәсәдә Уральскига киткәнче укый. Кырлай мәдрәсәсендә беренче остазы мулла Фәтхерахман Гатаулла улы Гобәев булса, беренче иҗек танытучы, «Иман шарты»н өйрәтүче кеше Фәтхерахман мулланың хатыны Маһруйбикә абыстай була.

*«Исемдә калганнар», 25 б.;*
*Сабирҗанов А. Күңелдә шулай саклана. «Истәлекләр», 17 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 264 б.*

# 1894

**30 апрель.** Сәгъди абзыйның Бибисаҗидә (1879 елда туган) исемле кызы унбиш яшендә үпкә авыруыннан вафат була. Кырлай авылы зиратына җирләнә.

Истәлекләрдә бу Саҗидә апасының Габдулланы җитәкләп мәдрәсәгә илтеп йөрүе турында әйтелә.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 151 б.; Гобәйдуллин Х. Кырлайга килгәндә. «Хатирәләр», 1976, 10 б.*

**Көз.** Уральскидагы җизнәсе Галиәсгар Госмановның чакыртуы буенча Кушлавыч крестьяны Бәдретдин абзый Габдулланы Кырлай авылыннан Уральскига алып китә.

Габдулла Кырлайдан турыдан-туры Уральскига китми. «Исемдә калганнар» автобиографик очеркында ул Бәдри абзый ниндидер эш белән Казанга киткәнлектән, бер ай кадәр аны көтеп, Кушлавычта торуы, берникадәр вакыт Кушлавыч мәдрәсәсенә сабакка йөрүе турында яза.

*«Исемдә калганнар», 22, 29, 33 б.*

**Көз ахыры.** Габдулланы Бәдри абзый ат белән Казанга алып китә. «Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән икән. Шул сәбәпле, Бәдри абзый белән без бер-ике атна кадәр шул кешене көтеп яттык»,— ди Г.Тукай «Исемдә калганнар» автобиографик очеркында.

*«Исемдә калганнар», 36 б.*

**Ел ахыры.** Габдулла Уральскига килеп җитә. «Унсигез көн булды дигәндә, кичкә таба Җаекка барып җиттек»,— ди ул «Исемдә калганнар» автобиографик очеркында.

Габдулланы Уральскига сәүдәгәр җизнәсе Галиәсгар Госманов, аның хатыны Газизә* чакыртып ала. Уральскига ул 1894 елның ахырында яки 1895 елның башында килеп җиткән. Тукай 27 еллык гомеренең зур өлешен шушы шәһәрдә үткәрә. Уральск — аның зур шагыйрь буларак формалашкан шәһәре.

---

* Газизә — Газизә Госманова Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф белән бертуган апасы. Уральскида яши. Тукай, Казанга күчкәч, аңа хатлар язып тора. Туган-үлгән елы билгесез.

Госмановлар Почиталин урамы, 66 нчы йортта яшәгәннәр. «Пионер» журналының 1952 ел 12 нче санында әлеге йортның фотосы да урнаштырылган.

*Якупов Р. Архивтагы язулар ни сөйли. «КУ», 1976, 3 нче сан, 152 б.;*
*Нәфыйгов Р. Тукай яшәгән урыннарда. «Пионер», 1952, 12 нче сан, 33 б.*

## 1895

**Сентябрь.** («Мотыйгыя»дә укулар шушы айда башланган.) Габдулланы җизнәсе Галиәсгар Госманов «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә укырга бирә.

«Шунда ук төркине яхшы укый иде... Сабакны бик күңел биреп укыды. Кайчакларны, сабакка соңга калам, дип, иртәнге ашны ашамастан китеп бара иде»,— ди Газизә апасы*.

«Мотыйгыя»дә иң әүвәлге хәлфәсе — Фәтхетдин хәлфә Рәхмәтуллин. Фәтхетдин хәлфә Габдуллага гарәп әдәбияты, Коръән, «Тәгълиме әс-салат» исемле гарәпчә китаплар укыта.

*Зәбирова Г. Тукай турында истә калганнар. «Истәлекләр», 23 б.;*
*Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 31—32 б.*

## 1896

**Сентябрь.** Габдулланы җизнәсе Галиәсгар Госманов өч еллык рус классына бирә. Булачак шагыйрь мәдрәсәдә дә, рус классында да бер үк вакытта укый. Рус классында беренче учителе Оренбургта Учительская школаны тәмамлаган Әхмәтша Сираҗетдинов (1850—1919). Учительнең бай китапханәсе булган. Габдуллага рус язучыларының әсәрләрен биреп укыткан. Пушкин, Лермонтов иҗаты белән ул беренче мәртәбә шушында танышкандыр, дип уйланыла. Әхмәтша учитель Тукайның сәләтле бала булуы турында сокланып сөйли торган булган. Рус классына кергәндә, Габдулла ун яшендә була. Сабакташы Ярулла Морадыйга үзе: «Мин школага кергәндә сигез яшьтә генә идем»,— дип сөйләгән.

---

* Газизә апасы — Газизә Зәбирова (1877—1963) — Тукайның әтисе бер, энисе башка булган бертуганы. Ул да кияүгә чыкканчы Уральскида Г.Госмановлар гаиләсендә яши.

Почиталин урамындагы 53 нче йортның икенче катында урнашкан бу рус классының «Пионер» журналының 1952 елгы 12 нче санында фотосы урнаштырылган.

Г.Тукайның талантлы шагыйрь булып җитешүендә Госмановлар гаиләсенең роле аз булмаган. Шәһәр мохитендә яшәү, «Мотыйгыя» кебек алдынгы мәдрәсәдә, шуның белән бергә рус классында уку Габдулланың дөньяга карашы, шагыйрьлек талантын формалашуга уңай йогынты ясамый калмаган.

*Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 32 б.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 52—53 б.;*
*Нәфыйгов Р. Тукай яшәгән урыннарда. «Пионер», 1952, 12 нче сан, 33 б.*

## 1898

**Ел дәвамында.** Габдулланы Кырлайдан (Сәгъди йортыннан) барып алып Уральскига озаткан Кушлавыч авылы крестьяны Бәдри абзый (Бәдретдин Хисаметдин улы Хисаметдинов) үзе дә Уральскига күчә. Башта балта остасы, соңыннан сәүдә эше белән шөгыльләнә. Ул Тукайның ерак туганы булган.

«Бәдри абзый гаиләсе минем өчен дә, Габдулла өчен дә туган агабызның йорты күк иде, бик аралашып йөри идек»,— дип сөйли апасы Газизә Зәбирова.

*Зәбирова Г. Тукай хакында истә калганнар. «Истәлекләр», 20 б.*

## 1899

**Яз көне.** Г.Тукай «Мотыйгыя» мәдрәсәсе каршындагы өч еллык рус классын тәмамлый.

*«Истәлекләр», 237 б.*

**26 май.** Уральскида Пушкинның тууына 100 ел тулу уңае белән «Пушкин йорты» ачыла. Бу тантаналы җыелышка Габдулланың катнашкан булуы бик ихтимал. Ул «Пушкин йорты»нда булган рус язучыларының юбилей кичәләренә бик яратып йөргән.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 53 б.*

**Ел дәвамында.** «Габдулла әфәнде сандыгында төрле хикәят китаплары да күренгәлиләр. Татар тормышыннан алып язылган «Рәдде бичара кыз» исемле бер театр китабын ул әл-

лә кайдан гына табып, бик тәмле генә иттереп укый вә тыңлаучыларны бик хозурландырып, дәрт кертә иде»,— ди сабакташы «Мотыйгыя» мәдрәсәсе шәкерте Ярулла Морадый.

*Морадый Я. Тукаев Уральскида. «Истәлекләр», 40—41 б.*

## 1900

**30 июль.** Г.Тукайның җизнәсе сәүдәгәр Галиәсгар Госман улы Госманов ашказаны авыруыннан вафат була. Уральск зиратына җирләнә (1845 елда туган). Булачак шагыйрь, җизнәсе үлгәннән соң, «Мотыйгыя»гә* торып укырга күчә. Ул монда 1906 елның декабренә кадәр яши.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 265 б.*

**Ел дәвамында.** Г.Тукай «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганда шагыйрь Мирхәйдәр Чулпаный белән таныша. Чулпаный «Мотыйгыя» мәдрәсәсен тәмамлаган яңа карашлы шагыйрь булган. Г.Тукайда шагыйрьлек дәрте уятуда билгеле бер йогынты ясаган.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 70—71 б.*

## 1901

**Ел дәвамында.** Габдулла «Мотыйгыя»дән авыру сәбәпле укуын ташлап киткән сабакташы Ярулла Морадый белән хатлар алыша. Хатларында үзенең фәкыйрьлегеннән, тормышының авыр булуыннан зарлана.

*Морадый Я. Тукаев Уральскида. «Истәлекләр», 41 б.*

Истәлекләрдә өч еллык рус классын тәмамлаган Тукай үзе дә Мотыйгулла хәзрәткә метрика дәфтәре язуда булышкан, дигән фикерләр очрый.

*Вәлиди Җ. Тукаев хакында берничә сүз (Вафатына бер ел тулу мөнәсәбәте илә). «Замандашлары», 260 б.; Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 34 б.*

---

* Габдулла «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең баш имамы Мотыйгулла хәзрәттән (Мотыйгулла Төхфәтулла улы Төхфәтуллин, 1846—1920) гыйльме гаруз (шигырь үлчәве турындагы белем) дәресләре ала. Мотыйгулла хәзрәт аңа үзенең бай китапханәсе белән танышырга да мөмкинлек бирә.

## 1902

**Ел башы.** «Мин Мисырдан әйләнеп кайтканда, ул тәмам зур егет кыяфәтенә кергән иде. Аннан соңра шул кыяфәт аңарда үлгәнчегә кадәр һич үзгәрмәде»,— ди К.Мотыйгый.

К.Мотыйгый 1900 елда Истанбулда, аннан Мисырда укый. 1902 елда Уральскига әйләнеп кайта. Монда шул вакытларын искә ала.

*Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 33 б.;*
*Төхфәтуллин Х. Камил Мотыйгый, 1992, 11 б.*

**Апрель.** Г.Тукай иптәш шәкертләре белән Җаек һәм Чаган елгасының кушылган урынына ял итәргә чыга. Иптәшләренә Җаекның балыкка бай булуын, казакъларның Җаектан ничек балык тотулары турында сөйли. Иптәшләренә кушылып җырлый. Әле генә чыгарган шигырьләреннән өзекләр укый. Менә бер өзеге:

Тәрәзә дә ишек, ачык та тишек,
Хәлфәсе кыйшык авыз, дусларым.
Шәһридә сөннәт тапканнар шөһрәт,
Ушбудыр гыйбрәт аңла, дусларым.

Димәк, Г.Тукайның 1902 елларда ук шигъри тезмәләре булган.

*Курамшин Ш. Габдулла Тукай хакында истәлекләрем. «СӘ», 1955, 11 нче сан, 83—84 б.*

**Җәй.** Г.Тукай Истанбул университетыннан алдынгы фикерләре өчен куылган, Уральскига килеп, «Мотыйгыя»дә бер җәй, бер кыш укып киткән төрек егете Габделвәли Әмрулла белән дуслаша, аңардан төрек телен өйрәнә. Баштагы шигырьләрендә төрекчелекнең көчле булуы, мәдрәсәдә укудан тыш, шушы Габделвәлинең азмы-күпме тәэсире белән дә аңлатыла. Габделвәли шигырьләр дә язган. «Габдулла әфәнде төрек романнарын, рус әдәбиятыннан Лермонтов һәм Пушкин әсәрләрен бик яратып укый иде»,— ди Г.Кариев.

*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 55 б.*

**Елның икенче яртысы.** ***(«Мөгаллим Нури...») исемле шигырен яза. Шигырь үз вакытында басылмаган, язылу датасы билгесез. Г.Тукай «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганда

шигырьләр чыгара башласа да, татар телендә көндәлек матбугат булмау сәбәпле, аларны яттан гына әйтеп йөргән.

Шигырьнең язылу датасы К.Мотыйгый истәлегеннән чыгып якынча билгеләнде. Ул Мисырдан 1902 елның ахырында кайта: «Бу вакытларда мәдрәсәбездә шактый үзгәрүләр бар иде. Мәдрәсәбезгә Оренбург вилаятеннән Нуриәхмәт исемле бер ысулы җәдит мөгаллиме килү сәбәпле иске хәлфәләрдә укый торган барча кечкенә шәкертләр шул мөгаллимгә күчкәннәр иде»,— ди.

Шигырь шушы Нуриәхмәт хәлфә турында.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 389 б.;*
*Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 33 б.;*
*Курамшин Ш. Габдулла Тукай хакында истәлекләрем. «СӘ», 1955, 11 нче сан, 83 б.*

**Ел ахыры.** ***(«Укыгыз, кызлар, укыгыз!..») шигырен яза. Шигырь үз вакытында басылмаган, язылу датасы билгесез. Ул Тукайның «Мотыйгыя» сабакташы Шәриф Каюмов истәлеге эчендә китерелә. Ш.Каюмов «Мотыйгыя»гә 1902 елның көзендә килә. Шигырьнең язылу датасы шуннан чыгып якынча билгеләнде. Әлеге шигырь турында Ш.Каюмов истәлегендә болай дип яза: «Бервакыт җәй көне мәдрәсәгә, Тукай янына Ярулла мәзин килә. Тукай тактадан бүленгән бер бүлмәдә тора иде. Ярулла мәзингә мин самовар кайнатып өлгертәм. Чәй янында мәзин Тукайга җырларга куша. Тукай, бер-ике җыр җырлагач, мулла кызларына карата болай җырлый башлый (шигырь китерелә).

Тукай Ярулла мәзиннең буйга җиткән ике кызы барын белеп җырлый. Кешене ул күз алдында тәнкыйть итә. Һич тайчанмый, оялмый, баш ими, тәрилкә тотмый».

*Каюмов Ш. «Истәлекләр», 65 б.*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 73-эш.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 389 б.*

**Ел дәвамында.** «Мотыйгыя» мәдрәсәсе сабакташы Гали Хикмәтуллин үзенең истәлегендә Г.Тукайның җырлар чыгаруын, ул җырларны шәкертләр белән бергә отып алып, нинди дә булса бер көйгә салып җырлаулары турында сөйли һәм шул вакытларда үзе ятлап калган түбәндәге тезмәне китерә:

---

Вилаять — өлкә.

Дөньяны болгар болгар, монкарыйз булды Болгар...
Муллалары — бүрәнә, мөәзиннәре — утыннар.

...Мулла максатка җитсен, мөәзин йөзтүбән китсен,
Мөәзингә ашарга юк, мулла шәраблап типсен.

...Бер бай кешегә очраса, мулла тезе калтырый,
Тычкан күргән песи кебек, күзе уттай ялтырый,

Ник аның күзе янмасын, разыйкы һәм рыйзыкы шул:
Бай аркасын кашыса да, мулла тизрәк суза кул.

Бай янында әйләнәдер утырып, торып, чүгәләп,
Ничек әйләнә кич белән ут янында күбәләк.

Бу тезмә Г.Тукайның «Әсәрләр»е җыентыгына кермәгән.

«Безне җыр якынайтты һәм дуслаштырды. Габдулла бик матур җырлар уйлап чыгара, аларны без нинди дә булса көйгә салып җырлый торган идек»,— ди тагын Г.Хикмәтуллин.

Замандашлары Тукайның йомшак кына матур тавыш белән җырлавын, кесәсендә шәкертләрнең уен коралы — кубыз булуын әйтәләр.

Шагыйрь үзе дә: «Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем»,— ди «Халык әдәбияты» (1910) исемле хезмәтендә.

Г.Хикмәтуллин Тукайның яшел күн читек, яшел башмак кигән бер шәкерттән көлеп чыгарган тагын бер җырын китерә:

Яшел башмаклар киминчә,
Юк сираттан ашмаклар,
Сираттан кичәргә кирәк
Яшел читек-башмаклар.
Мондый башмаклар киминчә,
Сираттан кичү кая!
Итек кисәң, шуа, имеш,
Шиблитле кеше тая.

Бу текст та Тукайның «Әсәрләр»е җыелмаларында урын алмаган.

*Хикмәтуллин Г. Тукай турында исемдә калганнар. «Истәлекләр», 46—48 б.*

Габдулла Мисырдан укып кайткан К.Мотыйгыйдан нәхү, мантыйк, хәдис, тәфсир, фикъһе, гарәп әдәбияты буенча дәресләр ала.

«Миннән ул ялгызы гына дәрескә утырып, тәфсире «Җәла-

---

Монкарыйз булды — юкка чыкты.
Разыйк — туйдыручы.

лин» вә хәдисе «Сәхихел-Бохари» һәм дә әдәбияты гарәбия укыды»,— ди К.Мотыйгый.

*Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 34 б.*

Г.Тукай Уральскида «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыганда «Рәкыйбия» мәдрәсәсе шәкерте Рәхмәтулла Хәйруллин белән дуслаша. «Ул үзенең шагыйрь икәнен шул 1902 елда белгертте»,— ди Р.Хәйруллин.

*Хәйруллин Р. Шагыйрь, сине оныта алмыйм. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 143-эш, 5 б.*

«Мотыйгыя» мәдрәсәсе имамы Мотыйгулла хәзрәт әдәбият белгече, телче Җамал Вәлидигә хат җибәрә. Хатында мондый юллар бар: «Шушы елларда (Кариевнең риваятенә күрә, 1902—1903 елларда) мәдрәсәбездә Габделвәли намында бер төрек шәкерте бер кыш, бер җәй торган иде. Тәсадефи уларак, Габделвәли әфәнде шагыйрь иде. Тукаев та берәр сәнә мөкатдәм генә үземнән «Мохтасарел-кяфифи кыйсмел гаруз вәлкавафи»* китабының кафия кыйсмен калдырып, фәкать гаруз кыйсмен генә укыган, гарәпнең уналты төрле шигырь вәзеннәрен, тәкътыйгларын кыскача гына укып, мәдхәле шигырьгә юл тапкан иде.

Шул араларда госманлы китапларыннан, шулай ук рус әдәбиятыннан бәгъзе нәрсәләр тәрҗемә итәргә башлады. Кулына каләм алса, һич тоткарсыз яза иде. Шул юл белән талантлы табигате илә көн саен шигырьләр чыгара башлады. Шулай да уңайлык өчен йә «Мөхәммәдия»,йә «Бакырган» кеби әсәрләрдән вәзен үрнәкләре ала башлады».

Мотыйгулла хәзрәт Тукайның шигъри таланты 1903 елларда ачыла башлавы турында әйтә.

*Вәлиди Җ. Тукаев хакында берничә сүз (Вафатына бер ел тулу мөнәсәбәте илә). «Замандашлары», 260 б.*

---

* Шигырь төзелеше турындагы китап исеме.
Риваятенә — хәбәр итүенә.
Тәсадефи — очраклы.
Вәзен — шигырь үлчәме: ритм, иҗек саны.
Тәкътыйгларын — бүлекләрен.
Мәдхәле шигырьгә — шигырь яза башларга.

**Ел ахыры.** Тукай Уральскидан Өчиледә яшәүче Сажидә апасына (Бибисажидә Зиннәтулла кызы Хәбибуллина) хат яза. Хатында ул үзенең «Мотыйгыя»дә ничек укуы турында сөйли: «Үземез хәзер дә мәдрәсәдә укыб торамыз. Дәресемез «Тәркиб»не чыгыб барамыз. Быел укырга акчамыз юк иде. Шулай булса да Аллаһы Тәгалә бер юл ачты. Гурьевтагы бай туганнарым унбиш тәңкә акча бирде һәм үземезнең ахун җизни биш кадак чәй бирде...»

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 67 б.*
*Мирасханә. 9-ф., 2-тасв., 13-эш.*

## 1903

**30 июнь.** Габдулла Уральскидан Өчиледәге Сажидә апасына хат яза. Хатында аның бу апасын ни рәвешле якын итүе чагыла:

«Синең сабый вакытта һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам. Анам дарелбәкайә рихләт иткәч, бабайлар өендә бәңа мәрхәмәт күзе илән карачы юк иде, мәгәр син бар иден»,— ди ул.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 том, 74 б.*
*Мирасханә. 9-ф., 2-тасв., 10-эш.*

**Июль.** К.Мотыйгый Г.Тукай һәм алдынгы шәкертләр хуплап каршы алган «Әл-мәгариф» исемле кулъязма газета чыгара. Аны «милләт юлында хезмәт итүче һәфтәлек газета» дип атый. Газетаның 1903 елгы 9, 16, 24, 31 июль (13, 17, 27, 33 һәм бер номерсыз) саннары Татарстанның Берләштерелгән дәүләт музеенда саклана.

Тукайның монда бер әсәре дә урнаштырылмаган, әмма аның бу газетаны укып баруы мәгълүм. Газета 1904 елда кулъязма «Әлгасрелҗәдит» журналы булып киңәеп китә.

*Яхин Ф. Кулъязма журналдан — әдәби-иҗтимагый басма сүзгә. «Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш», 1987, 55—56 б.*

**Көз башы.** ***(«Туйга бардым мин бүген, эчтем кымыз...») шигырен яза. Шигырь үз вакытында басылмаган, язылу датасы

---

«Тәркиб» — сүз тезмәсен өйрәтә торган китап.
Дарелбәкайә рихләт иткәч — үлгәч.

билгесез. Ул Тукайның «Мотыйгыя»дәге сабакташы Шәриф Каюмов истәлеге эчендә китерелә.

Бу шигырь миллионер Мортаза Гобәйдуллинның улы яшь сәүдәгәр Садыйк Гобәйдуллинның туена барып кайткач язылган. Туй исә 1903 елның көз башында булган, димәк, шигырь дә шушы вакыттагы вакыйганың кайнар эзеннән һәм экспромт буларак язылган. Шигырь беренче мәртәбә Биш томлы «Әсәрләр»нең 1 нче томында басылган.

*Каюмов Ш. Шәкертлек еллары хатирәсе. «Истәлекләр», 62 б.; Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 390 б.*

**Кыш.** Габдулла Төркия егете Габделвәли Әмрулланы туган иленә озатып җибәрә. Мәдрәсә тормышы турында сүз чыкканда, Тукай шушы егет белән үткән көннәрен сагынып сөйли торган булган.

*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 55 б.*

**Ел дәвамында.** «Мотыйгыя»дәге сабакташы Шәриф Каюмов үзенең истәлегендә Г.Тукайның «Кара урман», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» кебек татар халык көйләрен яратып җырлавы турында яза.

*Каюмов Ш. Шәкертлек еллары хатирәсе. «Истәлекләр», 61 б.*

## 1904

**26 апрель.** Г.Тукай Уральскидан Гурьевтагы туганнары Абдуловларга* хат яза. Хатында ул үзенә ярдәм иткәннәре өчен бу туганнарына рәхмәтен белдерә һәм болай ди: «...ун сум акчаңызны 22 апрельдә, ахшамнан соң юлыгып алдым. Безнең кеби ятим шәкерт никадәр шатланганы һәм никадәр сезгә рәхмәт укыганы сезләргә билгеледер. Иншаллаһ, бу изгелекеңезгә каршы изгелек кыла алырмын дип Аллаһдин өмидем бардыр». Хатка түбәндәге шигъри юлларны да өстәп куя:

И әфәндем, Хак сәни даимән мәсрүр әйләсен,
Кем сәңа дошман улырса, аны мәкъһур әйләсен;

---

*Абдуловлар — Әхмәди һәм Әүхәди — Тукайның әтисе ягыннан әбисе Мәргүбә белән бертуган Мөхәммәди балалары. Гурьев шәһәрендә тире белән сәүдә иткәннәр.

Даимән мәсрүр әйләсен — һәрвакыт шат кылсын.

Мәкъһур әйләсен — каһәр төшсен.

Һәм шәҗагать, һәм сәхавәт сәндә мәҗмугъ әйләсен,
Җөмлә галәм халкы үзрә сәни мәшһүр әйләсен.

Хат Тукайның шәхси тормышын гына түгел, шигырьләр яза башлавын күрсәтү ягыннан да әһәмиятле.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 75—76 б.*

**20 май.** Тукайны бала вакытында асрамага алган Кырлай крестьяны Сәгъди абзый (Сәгъдетдин Шәмсетдин улы Салихов) 67 яшендә фалиҗдан (параличтан) вафат була, Кырлай зиратына күмелә (1837 елда туган).

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 263 б.*

**Июнь ахыры.** Камил Мотыйгый Төхфәтуллин Уральскида атнага бер мәртәбә гыйльми, әдәби, хикми вә фәнни дип аталган кулъязма «Әлгасрелҗәдит» журналы чыгара башлый (1905 елның 12 маенда туктала).

Тукай — бу журналны язучыларның берсе, журнал идарәсендә редколлегия әгъзасы. Шигырьләре һәм мәкаләләре беренче шушында дөнья күрә. «Әдип» дип аңа беренче мәртәбә шушы журналда мөрәҗәгать ителә.

Тукайны киң тормыш юлына әзерләп чыгаруда, гомумән, Төхфәтуллиннар гаиләсе аерым урын тота. К.Мотыйгый газета-журналлар чыгарып аның шигъри таланты ачылуга этәргеч ясаса, этисе Мотыйгулла хәзрәт булачак шагыйрьгә поэзия серләренә төшенергә ярдәм итә. Моның бер сәбәбе Тукайның талантын күрү булса, икенчесе Мотыйгулла хәзрәтнең Кышкар мәдрәсәсендә Тукайның этисе Мөхәммәтгариф белән бергә укыган булуы да тәэсирсез калмагандыр.

**Июль.** ***(«Әхмәтсафа әфәнде — фазыйль әдибтер кәнде...») шигыре түбәндәге искәрмә белән урнаштырылган: «Мәдрәсәи Мотыйгыя» таләбәләрендән Габдулла Тукаев намында кәнҗ шәкерт Әхмәтсафа әфәнде хакында чыкарылмыш улдыгы назымы «Гасрелҗәдит»тә дәрҗ улынмасыны истигъдә әйләдегендән, мәгаттәшәккер кабул иделеп, бер вәҗһе ати асыл нөсхәсендин нәкыль улынды».

Тәрҗемәсе: «Мотыйгыя» мәдрәсәсе шәкертләреннән Габдулла Тукай исемле яшь шәкерт Әхмәтсафа әфәнде хакында язган тезмә әсәрен «Әлгасрел-җәдит»кә кертүне үтенгәнлектән, рәхмәт белән кабул ителеп, төп нөсхәсеннән күчереп алынды». Шигырь беренче мәртәбә «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә (1914) басылган.

---

Шәҗагать — батырлык, гайрәт.
Сәхавәт — юмартлык.
Мәҗмугъ әйләсен — туплансын (Ходай тарафыннан).

Әхмәтсафа Байтирәков — Уральскида Тукай белән бер чорда «Мотыйгыя»дә укыган шагыйрь, мөгаллим.

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 3 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 390—391 б.*

**Сентябрь.** Г.Тукай «Мотыйгыя»дә укыганда татарның булачак атаклы артисты, режиссеры, татар театрына нигез салучы Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйруллин, 1886—1920) белән дуслаша.

«Мин үзем Уральскида алты-җиде сәнәләр мәдрәсәдә үткәрдекемнән, Габдулла әфәнденең Уральскида вакытындагы мәгыйшәтеннән байтак хәлләрен үз авызыннан ишетеп, яхуд үз күзем берлә күреп беләдер идем. Чөнки ул вакытлар Габдулла әфәнде берлә бер мәдрәсәдә булмасам да, аның берлә бик якын таныш идек»,— ди Г.Кариев.

Г.Кариев Уральскида Гайнетдин хәзрәт мәдрәсәсендә укый.

*Кариев Г. (мәкаләләр, истәлекләр, документлар), 1976, 4 б.;*
*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы, «Истәлекләр», 53 б.*

**8 октябрь.** Г.Тукай «Оренбургский мөхәммәдинский духовный собраниенең дәүләтле казыйларына» хат яза. Хат Уральскида яшәүче Мәфтүхә Мөбин кызының ире сәүдәгәр Мортаза Гаделшиннан аерылырга соравы, Духовный собрание казыйларының моңа комачаулык итүе уңае белән язылган. «Мортаза Гобәйдуллин бай ишарәте илә хөкем итдекеңездән соңра Духовныеңыз илә курчак уены арасында нә фәрекъ калыр?» — ди хатында Г.Тукай. Нәтиҗәдә суд аларны аера, Мортазадан суд чыгымы түләтелә.

Хат шагыйрьнең «Җәһаләт вә сәфаләт» исемле мәкаләсе эчендә китерелә.

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 11 нче сан.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 275—276 б.*

**14 октябрь.** «Җәһаләт вә сәфаләт» мәкаләсе «Каилел хак» имзасы белән урнаштырылган.

Хараб итде бези, аһ, бу җәһаләт,
Нәләр ябды безә, аһ, бу сәфаләт,—

дигән эпиграф куелган.

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 11 нче сан.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 275 б.*

---

Фәрекъ — аерма.
Җәһаләт вә сәфаләт — наданлык һәм түбәнлек.

***(«Сәнгә хезмәтдер мәрамем язмадан журналымый...») һәм ***(«Аһ идәрсәм — яндырыр бу галәми...») икеюллыклары кулъязма «Әлгасрелҗәдит»тә имзасыз һәм исемсез урнаштырылган. Бу икеюллыклар беренче мәртәбә дүрттомлыкның 2 томында «Тукайныкы булуы ихтимал» шигырьләр бүлегенә кертелгәннәр.

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 11 нче сан.*

**4 ноябрь.** ***(«Тугъды, көн туар кеби, бер сахибе һиммәте гани...»)*. Шигырь «Мәҗлесе гыйльмия» исемле баш мәкалә эченә кертелгән. Мәкаләдә Г.Тукайның әлеге мәҗлестә чыгыш ясавы һәм шушы шигырьне укуы, мәҗлестәгеләрнең шагыйрьне бик яратып тыңлаулары турында әйтелә. Тукайның чыгышы тыңлаучыларны «Мәдрәсәия Мотыйгыя»дә гүзәл әдиб һәм шагыйрьләр бар» дигән нәтиҗәгә китерә. Шигырь «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең элекке назыйры миллионер Мортаза Гобәйдуллинны алмаштырган Вәлиулла Хәмидуллинга мәдхия формасында язылган:

Тасвир итде мәдрәсәйе гүя бер гәүһәр фишан,
Пакьлеге, гүзәллеге вирәдер оҗмахтан нишан,—

ди шагыйрь.

Тәрҗемәсе:

Бизәде мәдрәсәне ул асылташ кебек итеп,
Гүзәллеге оҗмахны искә төшерерлек итеп.

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 15 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 314—315 б.*

**9 декабрь.** Белдерү. Г.Тукайның киләчәктә чыгачак басма «Әлгасрелҗәдит» журналының язышучыларыннан берсе булачагы турында әйтелгән. Журнал эшенә катнашачак язучылар исемлегендә Тукай белән янәшә Г.Ибраһимов, Р.Фәхретдинов, Г.Исхакый, Ф.Кәрими фамилияләре китерелгән. Шунда ук Тукайның, Оренбургка барып, Ф.Кәрими матбагасында бер ай матбага гыйльменә, мөрәттиблеккә өйрәнәчәге турында язылган. Тукай Оренбургка бармаган.

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 20 нче сан.*

---

* Тугъды, көн туар кеби, бер сахибе һиммәте гани — бер бай, һиммәт иясе туар көн кеби туды.

Сәнгә хезмәтдер мәрамем язмадан журналымый — журналымны язудан максатым сиңа хезмәт итү.

Мөрәттиб — хәреф җыючы.

**11 декабрь.** Г.Тукай К.Мотыйгый исеменнән Пирмөхәммәт Ниязовка түбәндәге ачык хатны җибәргән: «Мөхтәрәм әфәндем! «Тәмәдден, яхуд Мәгарифе исламия»* ичун йибәрелмеш парәңез вакытында кәлмеш иде. Адресыңыз дәфтәрә каид улынмыш иде. Фәкать «Тәмәдден» китабының вәгъдәсендә чыксына бер кач гозер вә сәбәпләр улды. Шимди у китап цензура өченче дәфга уларак тәслим улынды. Без у китаби, инша Аллаһы Тәгалә, шөбһәсез бастырачагыз. Сезә һәм басылдыгы кеби эстәдеңеңез кадәр йибәрәчәңез.

Уральск шәһәрендә Мөхәммәткамил әл-Мотыйгый Төхфәтуллин өчен конторщик Габдулла Тукаев. 1904 ел, 11 декабрь».

Тәрҗемәсе: «Хөрмәтле әфәндем! «Мәдәниләшү яки Мөселманнарның мәгарифе» өчен җибәргән акчагыз вакытында килгән иде. Адресыгыз дәфтәргә теркәлгән иде. Тик «Мәдәниләшү» китабының вәгъдә ителгән вакытта чыкмавына кайбер сәбәпләр булды. Хәзер ул китап цензурага өченче тапкыр бирелде. Без ул китапны, Аллаһе Тәгалә боерса, һичшиксез, бастырачакбыз. Басылуы белән Сезгә дә теләгәнегез кадәр җибәрәчәкбез.

Уральск шәһәрендә Мөхәммәткамил әл-Мотыйгый Төхфәтуллин өчен конторщик Габдулла Тукаев.

1904 ел, 11 декабрь».

К.Мотыйгый 1902 елда Мисырдан кайтканнан соң китап бастыру эшләре белән шөгыльләнүче контора оештыра. Үзенең китапларын да, башка кешеләрнекен дә бастырып чыгарып тарата. Г.Тукай монда К.Мотыйгыйның конторщигы хезмәтен үтәп, шушы хатны яза.

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 21 нче сан; Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 77 б.*

**Ел дәвамында.** Г.Тукай «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә дүрт ай балалар укыта. Хәлфә Гомәр Хөсәенов кызыл мал белән сәүдә итүче Вәлиулла Апаков өчен ялланып хаҗга китә. Хәлфәнең унлап шәкертен Г.Тукай укыта. Ул класска моңа кадәр булмаган кара такта элеп куя, балаларны укытканда язуга, телгә, хисапка игътибар итә.

Тукайның кубыз уйнавы, һәрвакыт кесәсендә кубыз йөртүе турында да мәгълүмат бар.

*Каюмов Ш. Шәкертлек еллары хатирәсе. «Истәлекләр», 62 б.*

---

Тәмәдден — мәдәниләшү.

*«Тәмәдден, яхуд Мәгарифе исламия» — Уральск шәһәре янындагы Сеҗе (Чежинск) авылы имамы Әхмәтфәрит Ширвани язган китап.

Г.Тукай нашир һәм мөхәррир, соңыннан җырчы Камил Мотыйгый белән фоторәсемгә төшә.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 97 б.;*
*Габдулла Тукай. Альбом, 1978, 46 б.*

**Ел ахыры.** К.Мотыйгый кулъязма «Әлгасрелҗәдит»не басма журналга әйләндерү артыннан 1904 елның урталарыннан йөри башлый. Басма журналга катнашуларын үтенеп, 1904 елның ахырларында күренекле татар зыялыларына хатлар җибәрә. Бу хатларны язышуда Тукай актив катнаша.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 328 б.*

## 1905

**13 гыйнвар.** ***(«Безнең эти аягында җыермалы ал читек...»). Шагыйрь бу җырларны түбәндәге искәрмә белән урнаштырган: «Дәха бер мәгърифәтдин мәхрүм улан бай угылына килгән сылу кызлардан беренең ашагыдагы язылмыш бәетләри нәркиз, күзләрендә яшь акызыб җырлаганы мәсмугымыз улып, сынык күңелемезгә пәке тәэсир әйләдекендин ичун журналымызга дәрҗ әйләдек».

Тәрҗемәсе: «Надан бер бай улына чыккан кызлардан берсенең түбәндә китерелгән җырларны матур күзләреннән яшь агызып җырлаганын ишетеп, сынык күңелебезгә бик нык тәэсир иткәнгә күрә, журналыбызда бастырдык».

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 3 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 392—393 б.*

**26 гыйнвар.** ***(«Әхмәтсафа әфәнде — фазыйль әдибтер кәнде...»). Шигырь Тукайның «Мотыйгыя» сабакташы шагыйрь Әхмәтсафа Байтирәковка багышланган. Бу шигырьгә каршы Ә.Байтирәков Тукайны мактап хат язган. Аның хатына каршы Тукай журналда түбәндәге хатны урнаштыра: «Мөхәррир әфәнде! Габдулла Тукаевның язмыш бәетләрене затыңыза дугъры китереп укыдым. Чөнки у әбъяте мәргубәләренең бәгъзе сүзләре бәндәңезә дугъры килмәдегене аңладым. Ләкин килмәсә дә, килергә иҗтиһад кылмакым лязем улды. Иншаллаһ, дугъры киләчәгем...»

*Кулъязма «Әлгасрелҗәдит», 4 нче сан;*
*Беренче мәртәбә «Мәҗмугаи асарь»дә басылган.*

---

У әбъяте мәргубә — мактап әйтелгән.

**1 май.** Уральск эшчеләре Ханская рощада халыкара бердәмлек көне — Беренче майны билгеләп үтәләр. Тукай бу бәйрәмгә катнашкан булырга тиеш. Чөнки эшчеләр тарафыннан оештырылган демонстрацияләргә, митингларга ул актив катнашкан. Бу турыда мәкаләләр дә яза.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение,1986,с. 45.*

**12 май.** Г.Тукайның беренче шигырьләрен, мәкаләләрен урнаштырган, аның шигъри таланты ачылуга зур булышлык иткән кульязма «Әлгасрелҗәдит» журналы 1905 елның 12 май саны белән тукталып кала. Барысы 9 сан чыга.

*Яхин Ф. Кулъязма журналдан — әдәби иҗтимагый басма сүзгә. «Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш», 1987, 71 б.*

**Май.** К.Мотыйгый «Уралец» газетасы типографиясен арендага ала. Аның тәкъдиме белән Г.Тукай бу басмаханәгә өйрәнчек булып керә. Монда аны кассадагы хәрефләрне ничек урнаштыру, гомумән, хәреф җыю эшенең техникасына әлеге типографиядә эшләүче рус эшчесе Александр Гладышев өйрәтә. Ул үзенең истәлекләрендә, өч көн шөгыльләнгәннән соң Тукайның хәрефләрне ничек урнаштыру тәртибен белеп алуы, беренче эше итеп «Казанның Габдулла Тукаев» гыйбарәсен җыюы турында яза. Монда ул 1 сум 50 тиен хезмәт хакы ала.

А.Гладышев Тукайның матбагага өйрәнчек булып 1904 елның ахырларында — ноябрь яки декабрь аенда керүен әйтә. К.Мотыйгый, Р.Нәфыйгов күрсәткән даталар дөреслеккә турырак килә, чөнки К.Мотыйгый типографияне 1905 елның май аенда сатып ала.

**Май-июнь (якынча).** Г.Тукай ***(«Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран...»)*, ***(«Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый...») шигырьләрен яза.

*Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 34 б.; Гладышев А. Письмо А.Файзи с воспоминанием о Тукае. Мирасханә. 101-ф., 3 тасв., 100-эш.; Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986,с. 44.*

---

* «Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран» — гыйлемнең бакчасында күңел ачып йөрик.

Чөнанча — биредә: беркөнне.

**8 июнь.** К.Мотыйгый Г.Тукай актив катнашкан басма «Әлгасрелҗәдит» журналын чыгаруга рөхсәт ала. 4 июльдә журналның цензоры итеп Казан Учительская семинария укытучысы Н.И.Ашмарин билгеләнеп куела.

*Яхин Ф. Кулъязма журналдан — әдәби-иҗтимагый басма сүзгә. «Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш», 1987, 75 б.*

**Җәй.** Г.Тукай якшәмбе көннәрендә «Мотыйгыя»дәге сабакташы Ярулла Морадый белән бергә еш кына Ханская рощада үткәрелә торган халык гуляньесенә чыга. Табигать матурлыгына хозурлана, солдатлар тарафыннан уйнала торган музыканы бирелеп тыңлый, су коена.

Тукайның дусты, сабакташы Ярулла Морадый (соңыннан укытучы) истәлекләрендә шундый белешмә бар: «Беркөнне Тукай иптәш бөтенләй язу эшләренә бирелергә уйлады. Миннән ун тиен акча сорап алды да кәгазь вә карандаш сатып алып, мәшһүр Крыловның басняларын татарча тәрҗемә итәргә тотынды.

Бу басняларның кайсыларының безнең татар тормышына муафыйк урыннарын күрсәтә вә бу хакта үз тарафыннан күп сүзләр дә кушып куя иде. Шушы ук җәйне бер хатында үзенең Крылов басняларын тәмам итеп, «Мәҗмугаи мөфидә»* исеме илә Камил Мотыйгыйга нәзер өчен биреп, каләм хакына егерме биш тәңкә алырга муафыйк булганын бик куанып язган иде».

*Морадый Я. Тукаев Уральскида. «Истәлекләр», 43—45 б.*

Г.Тукай Лбищенскидан ун километрлар ераклыкта урнашкан казакъ авылы Дуанда кунак була. Авылда казакъ халык җырларын (үләң) җыйный. Кемгә һәм кем белән барганы билгеле түгел.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение,1986,с. 107.*

**29 август.** ***(«Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран...»), ***(«Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый...») шигырьләре язылган һәм «1906 нчы сәнәсе башында чыкмая башлаячак «Әлгасрелҗәдит» журналының мөфассал игъланы»нда басылган. Болар — Тукайның беренче басма шигырьләре. Бе-

---

*«Мәҗмугаи мөфидә» — «Файдалы җыентык» исеме белән «Әлгасрелҗәдит»нең 1906 елгы 2 нче саныннан басыла башлаган.

Мөфассал — тулы, җентекле.

ренчесе чыгачак басма «Әлгасрелҗәдит» журналына, икенчесе аның булачак нашире һәм мөхәррире К.Мотыйгыйга мәдхия-мактау формасында язылган. Шигырьнең беренчесе алдында Г.Тукайның түбәндәге мөрәҗәгать хаты урнаштырылган:

«Уральскида мәдрәсәи «Мотыйгыя»дән,

29 август, 1905 сәнә.

«Мөхтәрәм Мөхәммәткамил әфәнде!

Чүкдин бирү чыкарылмасы мәэмүл булынан «Әлгасрел-җәдит» журналының нәшеренә мәэзүн улдыкыңызы ишедеб, фәүкылгадә мәсрүр вә мәмнүн улдым. Әгәр безем кебиләрә журналыңыз сәхифәләрендә урын вирелсә, бән, бикадәри халь, назмән вә нәсрән журналыңызда язмакымы вәгъдә идәрем: шу вәгъдәми тәэкид юлында журналыңыз хакында ушбу әбъяте гаҗизанәләреми тәхрир әйләдем».

Тәрҗемәсе: «Күптән бирле көтелгән «Әлгасрелҗәдит» журналын чыгарырга рөхсәт алуыгызны ишетеп, чиктән тыш шатландым. Әгәр журналыгыз битләрендә безнең кебекләргә урын бирелсә, мин, хәлемнән килгәнчә, журналыгызга тезмә һәм чәчмә әсәрләр язып торырга вәгъдә итәм һәм, шул вәгъдәмне ныгыту өчен, журналыгыз турында шушы зәгыйфь кенә бәетләремне яздым. Журналыгызның бер почмагында басылуын өмет итәм».

*«1906 нчы сәнәсе башында чыкмая башлаячак «Әлгасрелҗәдит» журналының мөфассал игъланы». Оренбург, 1905, 11 б.; Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 328 б.*

**2 сентябрьдән соң.** Петербургта Татар телендә беренче газета «Нур»ны чыга башлавы белән котлап «Шигырь» («Шималь яктан...») исемле мәдхия-тезмә яза.

«Нур»ның беренче саны 1905 елның 2 сентябрендә чыга.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 332 б.*

**15 сентябрь.** К.Мотыйгый «Әлгасрелҗәдит» журналын чыгарганчы ук аның «1906 нчы сәнәсе башында чыкмая башлаячак «Әлгасрелҗәдит» журналының мөфассал игъланы»н бастырып чыгара. Бу игъланны бастырып чыгару өчен рөхсәт 1905 елның 15 сентябрендә алына һәм ул Ф.Кәрими матбагасында дөнья күрә.

*Яхин Ф. Кулъязма журналдан — әдәби-иҗтимагый басма сүзгә. «Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш», 1987, 75 б.; Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 328—329 б.*

**15 октябрь.** Г.Тукай «Шигырь» («Шималь яктан...») мәдхия-тезмәсен түбәндәге үтенеч белән Петербургка «Нур» газетасы редакциясенә җибәрә: «Шәһри Петербургта мөхәррире «Нур» әфәнде хәзрәтләренә:

«Безем шу ашагыдагы әбъяте гаҗизанәмези, косурына бакмайарак, җәридәнезең почмагына сыгъдырсаңыз, кәмале һиммәтеңездән гадь идәр идем».

Үтенеп: Уральскида мәдрәсәи «Мотыйгыя» шәкерте Габдулла Тукаев, тарих 15 октябрь, 1905 сәнә».

Тәрҗемәсе: «Петербург шәһәрендә «Нур» мөхәррире әфәнде хәзрәтләренә. Безнең түбәндәге зәгыйфь кенә бәетләребезне, кимчелекләренә дә карамастан, газетагызның почмагына сыйдырсагыз зур яхшылыгыгыздан санар идем».

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 332 б.*

**21 октябрь.** Г.Тукай Уральск типографиясе эшчеләре оештырган демонстрациядә катнаша. Демонстрация эш хакын күтәрүне, 8 сәгатьлек эш көне урнаштыруны таләп итеп оешкан була.

*Гладышев А. Шәкерт тә, остаз да. «Истәлекләр», 68 б.*

**26 ноябрь.** Уральскида Г.Тукай актив эшләгән «Фикер» газетасының беренче саны чыга. «Атнага бер чыгып, соңыннан атнага өч тапкыр чыгачак» дигән белдерү бирелгән (1907 елның 13 маенда туктала). Мөхәррире Камил Мотыйгый Төхфәтуллин.

«Фикер» исемле газета чыгара башлагач, аны (Г.Тукайны.— Ф.И.) шул газетага мөсаххих итеп куйдым. Габдулла әфәндедең хезмәтләре миңа бик ягымлы һәм дә үзе фәүкылгадә иҗтиһадлы булганга күрә, мин аның жалуньесен һәр ай саен арттыра бара идем. Шөйлә ки, иң әүвәл сигез сумга хезмәт итә башлап, соңыннан бик тиз айга егерме биш сум ала башлады»,— ди К.Мотыйгый.

Тукай газетада төп эшне алып бара, шигырь һәм мәкаләләре дә даими басылып тора.

*Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 34—35 б.*

Г.Тукайның әлеге газетаның 1 нче санында басылган бе-

---

Мөсаххих — корректор.
Фәүкылгадә — гадәттән тыш.
Иҗтиһадлы — эшлекле.

ренче шигыре «Мужик йокысы» «Мөтәрҗим Габдулла Тукаев» дигән имза белән чыга. Әсәр рус шагыйре А.В.Кольцовның «Что ты спишь, мужичок» (1839) шигыреннән ирекле тәрҗемә.

«Габдулла Тукаев» дигән имзаны шагыйрь беренче мәртәбә шушы шигырьнең ахырына куя.

*«Фикер», 1 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 329 б.*

**Ноябрь.** ***(«Бу көндә бер сарай ачты әһали...») мәдхиятезмәсен яза. Мәдхия 1905 елның ноябрендә Уральскида ачылган «Казан миһманханәсе»нә багышланган.

Шигырь «Фикер»дә басылырга тиеш булса да, үз вакытында басылмый калган. Беренче тапкыр «Г.Тукай. Академик басма»ның 1 нче томына (Казан, 1943) кертелгән.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 332 б.**

**4 декабрь.** «Шәһәр хәбәрләре» исемле мәкаләсенең беренче кисәге имзасыз басылган. «Фикер» газетасында «Шәһәр хәбәрләре» дигән бүлекне Г.Тукай алып барган. Мәкаләнең эчтәлегеннән чыгып караганда да ул шагыйрьнең ***(«Бу көндә бер сарай ачты әһали...») дигән Уральскида «Казан» миһманханәсе ачылуга багышланган мәдхиясе белән аваздаш, хәтта кайбер гыйбарәләр, сүзләр тәңгәл килә. Бу мәкаләне Тукай язган, дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

*«Фикер», 2 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 372 б.*

**6 декабрь.** «Шигырь» («Шималь яктан...») исемле мәдхия-тезмәсе редакциягә юллаган үтенече белән бергә басыла. Шушы ук санда «Хәят», «Тәрҗеман» газеталарына багышланган дүртъюллыклары да урнаштырылган.

Болар барысы да мәдхияләр. Г.Тукай иҗатының башлангыч чорында мәдхия язу белән сизелерлек мавыккан.

*«Нур», 16 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 332 б.*

**11 декабрь.** «Хөррият хакында» шигыре «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган.

Шигырь 1905 елгы «17 нче октябрь манифесты»н тәбрик итеп язылган.

---

* Имзасыз басылган, ләкин төзүче тарафыннан Тукайныкы дип исәпләнгән шигырь һәм мәкаләләрнең күбесе беренче мәртәбә Биш томлы «Әсәрләр» җыелмаларына тупланган.

Әһали — кешеләр.

«Шәһәр хәбәрләре» исемле мәкаләсенең икенче кисәге имзасыз басылган.

*«Фикер», 3 нче сан.*

**18 декабрь.** «Дустларга бер сүз» исемле шигыре чыга. Шигырь 1905 елгы «17 октябрь манифесты» уңае белән язылган.

Бу хөррият манифесте-государьдыр,
Кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк имди,—

ди шагыйрь.

*«Фикер», 4 нче сан.*

**25 декабрь.** «Иттифакъ хакында» исемле шигыре чыга. Шигырь дини китап «Бәдәвам»ның ритм-рифма үлчәменә нигезләп язылган.

*«Фикер», 5 нче сан.*

**Ел дәвамында.** Г.Тукай үз чорының мәдәни тормышында актив катнашкан журналист, укытучы Сәгыйть Кәримгә (1883—1939) хатлар яза. «Габдулла әфәнде Тукаев белән минем арадагы мөнәсәбәт 1905 елдан башлана. Ул вакыт мин Оренбургта, ул Уральскида иде. Шул вакыт мин «Фикер», «Әлгасрелҗәдит»кә язган нәрсәләремә карата аңардан өч-дүрт мәртәбә хат алдым»,— ди ул.

*Сәгыйть С. Тукай тормышыннан истә калганнар. «КУ», 1968, 4 нче сан, 115 б.*

**Ел ахыры.** «Фикер» газетасы чыга башлагач (27 ноябрь.— *Ф.И.*) Габдулла әфәнде, «Фикер» матбагасында бишәр сум вазифа алып, ике ай наборщик булып хезмәт итте.

Наборщик вакытында бәгъзе бернәрсәләрне үзлегеннән төзәтә башлагач, Камил әфәнде аңар ун сум жалунье биреп, мөсәххих итеп куйды»,— ди Г.Кариев үзенең истәлегендә.

К.Мотыйгый истәлегендә иң әүвәл айга сигез сумга хезмәт итә башлавы, тора-бара хезмәт хакын егерме биш сумга күтәрүе турында әйтелә.

*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 57 б.; Мотыйгый К. Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде хакында хатирәләрем. «Истәлекләр», 35 б.*

Истәлек авторларыннан К.Мотыйгый фикерләре дөреслек-

---

Иттифакъ — берләшү.

кәрәк туры килә. Тукай Казанга килгәч, Шәһер Шәрәф белән очрашкан вакытында Уральскида егерме-егерме биш сум кадәрле вазифа алып эшләве турында сөйли.

*Шәрәф Ш. Габдулла Тукай хакында бәгъзе хатирәләрем. «Истәлекләр», 103 б.*

## 1906

**1 гыйнвар.** «Фикер» игъланында Г.Тукайның «Әшгаре мәҗмуга»сы басылып чыгачагы әйтелгән. Бу план тормышка ашмаган.

***(«Рөшде вар, кауле гүзәл, наме Рәшид...») дүртъюллыгы «Төрле хәбәрләр» бүлегендә «Декабрьнең 22 көнендә Петербургта фазыйль Рәшид әфәнденең «Өлфәт» намендә улан гәзитәсенең икенче номеры чыкты. Мөндәриҗаты гүзәл вә фасих лисан үзрә язылмыштыр»,— дигән искәрмә белән имзасыз басылган. Дүртъюллык 1905 елның декабреннән башлап Петербургта татар телендә чыккан, мөхәррире һәм нашире Рәшид Ибраһимов булган «Өлфәт» газетасына, аның наширенә мәдхия.

***(«Мәгатыйль кылды милләтне...») икеюллыгы «Төрле хәбәрләр» бүлегендә: «Тәрҗеман» гәзитәсе декабрь уртасыннан бирле цензурасыз чыкмая башлады һәм урысча кыйсьмене ташлады. Хәзер «Тәрҗеман»ымыз, хәмед улсын, бик яхшы улды. Аның хакында диерез»,— дигән искәрмә белән имзасыз басылган.

Бу икеюллык 1883—1918 елларда Бакчасарайда (Кырымда) И.Гаспринский җитәкчелегендә чыккан «Тәрҗеман»га мәдхия. «Фикер»нең 1 нче санында имзасыз басылган бу мәдхияләр Г.Тукайның татар газеталары чыга башлавына шатлануын белдерүләре ягыннан әһәмиятлеләр. Бу мәдхияләр беренче мәртәбә биш томлы «Әсәрләр»нең беренче томына (1985) кертелгәннәр.

*«Фикер», 1 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 393 б.*

**15 гыйнвар.** Уральскида Камил Мотыйгый Төхфәтуллин наширлегендә һәм мөхәррирлегендә «Әлгасрелҗәдит» («Яңа гасыр») исемле айлык әдәби, фәнни һәм иҗтимагый эчтәлекле журнал чыга башлый. (1907 елның 20 маенда туктала). Г.Ту-

---

Әшгаре мәҗмуга — шигырьләр җыентыгы.
Рөшде вар, кауле гүзәл — зиһене бар, сүзе гүзәл.
Фазыйль — галим кеше.
Фасих лисан үзрә — матур тел белән.
Мәгатыйль кылды — азат итте.
Хәмед улсын — мактау булсын.

кай бу журналның җаваплы секретаре булып эшли, иҗаты белән дә актив катнаша.

Журналның бу беренче санында аның «Алла гыйшкына» һәм «Уральскида Габдулла Тукаев» имзасы белән «Хәзерге хәлемезгә даир» исемле шигырьләре урын алган.

*«Әлгасрелҗәдит», 1 нче сан.*

**22 гыйнвар.** «Шәкерт, яхуд бер тәсадеф» шигыре басылган.

*«Фикер», 3 нче сан.*

**15 февраль.** «Әлгасрелҗәдит»тә «Мәҗмугаи мөфидә» исеме астында мәсәлләре түбәндәге аңлатма белән басылган: «Рус мөхәррирләреннән әдибе нәҗиб Крылов шәһирнең асаре мәргубәләреннән мәалән тәрҗемә улынмыш вә госманлы әдәбиятыннан әхез иделмеш кыска-кыска гыйбрәтле хикәяләрдер. Мөмкин кадәр татар мәгыйшәтенә борыбрак язылмыштыр».

Тәрҗемәсе: «Зирәк һәм мәшһүр язучы Крыловның кызыклы әсәрләреннән һәм госманлы әдәбиятыннан алынган кыска-кыска гыйбрәтле хикәяләр. Мөмкин кадәр татар мәгыйшәтенә борыбрак язылмыштыр. Габдулла Тукаев әсәре».

«Мөхәррир һәм карак» («Сочинитель и Разбойник»), «Оракул» (Крыловның шул исемдәге мәсәленнән), «Гауваслар» («Водолазы»), «Сандугач» («Соловьи»), «Вагыйз» («Прихожанин»), «Мачы илә Сандугач» («Кошка и Соловей»), «Мәрхәмәтле Төлке» («Добрая лисица»). «Бер гөл». («Цветок»). «Ахыры бар», диелгән.

*«Әлгасрелҗәдит», 2 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 291 б.*

**Кыш.** Кариев үзенең истәлекләрендә болай ди: «Тукай дүрт ай чамасы сул партияләргә ихлас куеп йөрде вә шуның тәэсире илә язылган, сулрак рухта булган берничә шигыре «Тавыш» гәзитендә басылды».

Ләкин бу газетада аның «Тавыш хакында» исемле бер шигыре генә урын алган. Шигырь 1907 елның 23 апрелендә Казанда «Тавыш» газетасы чыгуы уңае белән язылган һәм шушы газетаның шул елгы 14 май санында басылган.

*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 59 б.*

---

Тәсадеф — көтелмәгән очрашу.
«Мәҗмугаи мөфидә» — файдалы җыентык.

**5 март.** «Уральск 5 март». Баш мәкалә урынында имзасыз басылган. Мәкаләдә Дәүләт думасы турында сүз бара. Шунда ук «Вакыт» газетасының беренче саны чыгуга багышланган «Яңа гәзитә» исемле мәкаләсе имзасыз урнаштырылган.

*«Фикер», 9 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 281—282 б.*

**12 март.** «Яз галәмәтләре» шигыре һәм «Уральск. 12 нче март» мәкаләсе баш мәкалә урынында имзасыз кертелгән. Мәкаләдә «Фикер» газетасының мәсләге турында сүз бара. Анда болай диелгән: «Фикер» гәзитәсенең мәсләге тугрылык илә милләткә файдалы хезмәт итү улганлыгы өчен, әтрафтан килгән, караңгы җирләрдә халыкны теләгәнчә алдап яткан ишан вә муллалар хакында улан язуларны гәзитемездә басмактан без асла кире тормаячакмыз».

*«Фикер», 10 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 283—284 б.*

**15 март.** Тукайның «И каләм!», «Ифтиракъ соңында», «Шагыйрь вә һатиф», ***(«Сәгадәт юк, фәкать наме сәгадәт...») шигырьләре «Әлгасрелҗәдит»нең 3 нче санында басылган. Соңгысы «Бер затә көфү улмайан Сәгадәтбану исемле бер кызый тәклиф итдекләрендә бу шигыри сөйләмешдер» дигән аңлатма белән имзасыз бирелгән. («Бер кешегә тиң булмаган Сәгадәтбану исемле бер кызны димләгәндә, кыз бу шигырьне сөйли».). Бу шигырьнең Тукайныкы икәнлеге Я.Морадыйның «Тукаев Уральскида» дигән истәлегендә әйтелгән: «Миңа үзем эстәмәгән бер кызны алырга тәклиф итүләрен сөйләгән идем, Тукаев иптәш бакчаның капусыннан кереп барган арада гына: «Тукта әле, мин аның хакында бер шигырь әйтим әле, дип:

Сәгадәт юк, фәкать наме сәгадәт,
Көфүне вирмәмәк безләрдә гадәт,—

дип, матур гына көйләп тә җибәрде».

*«Әлгасрелҗәдит», 3 нче сан.*

**15 март.** «Мәҗмугаи мөфидә» исеме астында түбәндәге мәсәлләре чыга (И.А.Крылов мәсәлләреннән ирекле тәрҗе-

---

Ифтиракъ — аерылышу.
Һатиф — яшерен тавыш, өн.
Наме сәгадәт — бәхетнең исеме генә бар.
Тәклиф итү — мәҗбүр итү.
Көфүне вирмәмәк — тигезлек, тиңлеккә юл куймау.

мәләр.): «Мут илә Карлыгач» («Мот и Ласточка»), «Бәхет» («Фортуна в гостях»), «Мөрид» («Напраслина»), «Вәзир» («Вельможа»), «Казлар» («Гуси»), «Җекет сайлаучы кыз» («Разборчивая невеста»), «Көтүче» («Пастух»). «Ахыры бар» диелгән.

*«Әлгасрелҗәдит», 3 нче сан.*

**15 март.** «Уральск, 12 нче март» мәкаләсе «Мөтәнәүвига» («Аннан-моннан») бүлегенә урнаштырылган.

*«Әлгасрелҗәдит», 3 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 283 б.*

**24 март.** Г.Тукай «Фикер» газетасының берничә санында аның исеме астына гриф куя торган урынга газетаның үз укучыларына мөрәҗәгате рәвешендә имзасыз һәм исемсез ике строфадан торган шигырьләр урнаштырган. Бу санда түбәндәге юлларны укыйбыз:

«Языңыз да фикереңезне, фикри фикрә багълаңыз,
Фикер идүбән халемезне «Фикр»ә языб агълаңыз».

Автор соңыннан бу шигъри тезмәләрне бергә җыеп, бербөтен шигырь рәвешендә «4 нче дәфтәр»гә (1908) «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел» исеме белән керткән.

*«Фикер», 11 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 65 б.*

**31 март.** Бу санда «Фикер» газетасының исеме астында басылган түбәндәге юлларны укыйбыз:

«Фикереңезгә юл вирермез, дәрҗ итәрмез «Фикр»ә без,
«Мәҗмәгыйль әфкяр» намене вирмеш идек «Фикр»ә без.

*«Фикер», 12 нче сан.*

**1 апрель.** «Әлгасрелҗәдит» журналына язылу өчен игълан бирелгән. Игъланда журналның «Русиядә беренче әдәби һәм сәяси вә гомуми файдалы журнал булуы әйтелгән. Язышучылары арасында Тукай исеме дә күрсәтелгән.

*«Вакыт», 11 нче сан.*

**9 апрель.** «Фикер» газетасының исеме астында басылган шигъри юллар бу санда да дәвам иткән:

---

Мәҗмәгыйль әфкяр — җәмәгать фикерләре җыелмасы.

Язмали, дәрҗ итмәли — гольянә кәлсен фикремез,
Бу гокамәтләр бетеб, дөньяя кәлсен фикремез.
Чөн тәвәллед итсә әфкяр, юлланыр һәр кяремез —
Фикремез будыр безем, мәгълүменез, дәфкярецез.

Тәрҗемәсе:

Язийк һәм басып таратыйк — күп фикерләр кузгалсын,
Бу кысырлык бетеп, дөньяга фикеребез юл алсын.
Чөнки фикерләр кайнаса, эшләр дә алга китәр, —
Бу мәгълүм булсын һәркемгә — шушындый безнең фикер.

*«Фикер», 13 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 64—65 б.*

**9 апрель.** Игълан. «Әлгасрелҗәдит» журналының 3 нче (15 март) саны чыкты. Бу санда Г.Тукайның «Мәҗмугаи мөфидә» исеме астында мәсәлләре басылган.

*«Фикер», 13 нче сан.*

**15 апрель.** «Әлгасрелҗәдит» журналының 4 нче саны дөнья күрә. Биредә Тукайның берничә әсәре урын алган.

«Гыйшык бу, йа!..», «Пушкинә», «Мөритләр каберстаныңдин бер аваз» исемле шигырьләре, «Мөхарәбә вә Государственная дума» исемле мәкаләсе. Мәкаләгә «Ахыры бар» дип куелган.

Мәкалә Л.Памиранцевның басылып чыгуы белән үк патша властьлары тарафыннан конфискацияләнгән «Война и Дума» дигән социал-демократик брошюрасыннан (С.-Петербург, «Молот» нәшрияты, 1905) ирекле тәрҗемә. Тәрҗемә иткәндә Тукай РСДРП Үзәк Комитетының Көнчыгыш бюросы шул ук 1905 елда бастырып чыгарган «Год войны» исемле брошюраны да файдаланган. Анда исә Л.Памиранцев брошюрасында булмаган урыннар да бар. Тукай аларын да тәрҗемә иткән. Брошюра шулай ук РСДРПның Казан комитеты тарафыннан да тәрҗемә ителеп, Казан губернасы өязләрендә халык арасына таралган.

Мәкаләдә Рус-япон сугышының башлану сәбәпләре, бу сугышта җиңелгән Россия дәүләте өчен аның авыр нәтиҗәләре, Беренче Дәүләт думасы турында сөйләнә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 334—335 б.*

«Кыямәт көне» мәкаләсе дә басылган. Тукай бу мәкаләсен Коръәннең күп сүрә һәм аятьләрендә (мәсәлән, 70, 79—82) шигъ-

---

Мөхарәбә — сугыш.

ри сурәтләнгән Кыямәт көне һәм Кадер киче күренешләреннән файдаланып язган.

*«Әлгасрелҗәдит», 4 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 333—335 б.*

**17 апрель.** «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» мәкаләсе чыга. Мәкаләдә Тукайның милләтне уяту фикере түбәндәгечә: «Без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, гәзитә мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихад вә иттифакъ сулары салыйк, җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик, тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын».

*«Фикер», 14 нче сан.*

**17 апрель.** «Фикер»нең бу саны исеме астына Тукай түбәндәге шигъри юлларны теркәгән:

Фикеремез улсын мөҗәддәд кыйл хәзәр! Искермәсен,
Һәм дә җәнҗалдан, җидальдән кыл кадәр ис кермәсен.
Фикремез тәфрикы өммәт йилләрен исдермәсен,
Исдереб, тәүхиде милләт юлларын кисдермәсен.

Тәрҗемәсе:

Фикеребез торсын яңарып гел — саклан! Искермәсен,
Үзара җәнҗал-ызгыштан кыл кадәр ис кермәсен.
Фикеребез халыкны таркаткыч җилләр истермәсен,
Истереп милләтнең берләшү юлын кистермәсен.

*«Фикер», 14 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 65 б.*

**23 апрель.** «Фикер»нең бу саны исеме астына Г.Тукай мондый шигъри юлларны тезгән:

Та әзәлдин бирле безләр фикремез мәхбүс идек,
Кем капамышдыр бези? Мәхбүс идек, мәэюс идек.
Кәлде форсат ул кафәсләрне дә вәйран итмәя,
Һәм алыб сәрбәст нәфәсләрне дә тайран итмәя.

Тәрҗемәсе:

Борынгыдан бирле безнең фикеребез тоткын иде,
Кем соң безне мескен итеп тоткында тоткан иде?
Килде форсат кысан читлекләрне итәргә тар-мар,
Килде, иркен сулыш алып, вакытыбыз канат кагар.

*«Фикер», 15 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 64—65 б.*

---

Иттихад вә иттифакъ — бер фикердә булып, бергәләшеп эшләү.

**23 апрель.** «Мөкяләмә, яхуд Мөсарәгате фикрәйн» («Әңгәмә яки ике кешенең кызу фикер көрәштерүе») исемле памфлеты басылган.

Памфлетта иске мәктәп-мәдрәсәләрдә дөнья өчен кирәкле булган фәннәрнең укытылмавы тәнкыйтьләнә.

*«Фикер», 15 нче сан.*

Русиядә беренче әдәби һәм сәяси яңа журнал «Әлгасрелҗәдит»нең дүртенче саны чыгуы турында белдерү бирелгән. Белдерүдә бу санда, башка авторларның әсәрләре белән бергә, Г.Тукайның «Мөхарәбә вә Государственная дума», «Кыямәт көне» исемле мәкаләләре басылуы әйтелгән.

*«Фикер», 15 нче сан.*

**30 апрель.** «Гәзитә мөрәттибләренә» шигыренең дүрт строфасы «Фикер» газетасының хәреф җыючыларына мөрәҗәгате рәвешендә имзасыз басылган һәм ул берничә санда дәвам итә.

Милләтең әфкярени тәртиб идәнләр сезсеңез,
Чарасыз дәрдә дәва тәркиб идәнләр сезсеңез.
Сезсеңез, йа, язия, язычыя гайрәт вирән,
Язмая тәшвикъ идән, тәргыйб идәнләр сезсеңез.

Тәрҗемәсе:

Сез — милләтнең фикерләрен тәртипкә салучылар,
Сез — дәвасыз авыруларга дару табучылар.
Язуга һәм язучыга көч өстәүчеләр дә — сез,
Язуга кызыктыручы һәм өндәүчеләр дә — сез.

*«Фикер», 16 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 84—85 б.*

**1 май.** Г.Тукай Уральскида типография эшчеләренең Беренче май демонстрациясендә катнаша. «1906 елның Беренче маенда типография эшчеләре тагын демонстрациягә чыктылар. Кызлар гимназиясе янына җыелдылар. Без Апуш белән икәүләп киттек. Демонстрациягә тимер юл эшчесе Николай Покатилов җитәкчелек итте. Иске собор янында кызыл байрак күтәрделәр»,— дип искә ала Тукай белән бер типографиядә бергә эшләгән Александр Гладышев. Гладышев Тукай белән бергә төрле урыннарга прокламацияләр таратып йөрүләре, Тукайның «Варшавянка», «Смело, товарищи, в ногу» кебек революцион җырлар белүе турында яза.

*Гладышев А. Шәкерт тә, остаз да.*
*«Истәлекләр», 68—69 б.*

---

Мөрәттиб — хәреф җыючы.

**4 май.** «Фикер» һәм «Әлгасрелҗәдит» басмаханәсе белән янәшә торган мунчага ут каба. Ут басмаханә бинасына да үрмәли. Шул вакытта Тукай белән аның иптәшләре хәреф басу машиналарын һәм бинаны янгыннан саклап калалар.

*«Фикер», 8 май, 17 нче сан;*
*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986,с.74.*

**6 май.** «Вакыт» газетасы хәбәр итә: «Уральскида нәшер ителмәктә улан «Әлгасрелҗәдит» журналының 4 нче саны идарәмезә килде. Г.Тукайның «Гыйшык бу, йа!» «Мөридләр каберстаныннан бер аваз» сәрләүхәле шигырьләре журналның чәчәгедер».

*«Вакыт», 22 нче сан.*

**8 май.** «Фикер»дә Тукайның «Уклар» журналында мөхбир уланлара тәнбиһ» шигыре, рәсемле айлык сатирик журнал «Уклар»ның чыгачагы турында белдерү урнаштырылган. «Уклар» журналының мөгайййән мөхәррирләре «Шүрәле», «Сөемсез», «Ишан мөнкире», «Каилелхак вә ма әшбәһе залик» дигән имзалар күрсәтелгән. «Шүрәле», «Ишан мөнкире» Тукайныкы икәне билгеле. Ул шушы имзалар белән күп шигырьләрен һәм мәкаләләрен бастыра. Кайбер әдәбият белгечләре «Сөемсез» имзасын да Тукайныкы итеп күрсәтәләр. Ләкин бу нигезләп исбат ителмәгән әле.* «Шүрәле» имзасы беренче мәртәбә шушы урында очрый.

«Фикер»дә «Гәзитә мөрәттибләренә» шигыренең дүрт строфасы басылган:

Сезсеңез вар гомереңезне милләтә тәхсыйс идән,
Раһе гафләттән бези тәхлыйс идәнләр сезсеңез.
Кәнде хөснендән хәбәрсез бер гүзәл чуҗык кеби,
Кадереңезне кәндеңез тәнкыйс идәнләр сезсеңез.

Тәрҗемәсе:

Бар гомерегезне милләт эшенә салучы да — сез,
Наданлык юлыннан безне йолып алучы да — сез.
Үз матурлыгын белмәгән гүзәл бала кебек сез —
Үз кадерегезне үзегез кайчак һич белмисез.

«Хикмәтле хикәя» әсәре урын алган.

*«Фикер», 17 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 84—85 б.*

**10 май.** «Әлгасрелҗәдит» журналының 15 апрельдә чыккан 4 нче саны идарәмезгә килде. Эчтәлегендә Г.Тукайның

---

* Яхин Ф. Сөемсез имзасы белән кем язган? «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар». Казан, 1989, 30—40 б.

Мөгайййән — билгеләнгән.

«Мөхарәбә вә Государственная дума», «Кыямәт көне» исемле мәкаләләре, «Пушкинә» исемле шигыре күрсәтелгән.

*«Бәянелхак», 15 нче сан.*

**17 май.** «Фикер»дә «Кечкенә генә бер көйле хикәя» поэмасы «Гъ» инициалы белән чыккан.

Апасы Газизә Зәбирова бу поэманы Тукайның беренче мәртәбә үзенә укып күрсәтүе һәм аның эчтәлеге чын тормыштан алынуы турында әйтә. «Миңа иң беренче укыган шигыре Сафый абзый белән Фатыйма апа турында иде. Ул шигырен укыгач, мин: «Моны син чыгардыңмы, әллә Камил чыгардымы?» — дидем. «Аларның тормышын Камил кайдан белсен, мин яздым. Мин аларга барып йөри идем ич»,— диде.

*Зәбирова Г. Тукай турында истә калганнар. «Истәлекләр», 25 б.*

«Фикер»дә «Гәзитә мөрәттибләренә» шигыренең дүрт строфасы урнаштырылган.

Чөн сәфаһәтләр мөрәттиблеккә һич лязем дәгел,
Шунлары, билмәм нәдән, тасвиб идәнләр сезсеңез.
Пәк мохалифдер мөбәззирлек мөрәттиб шәэненә,
На монасыйб ишләри тәнсиб идәнләр сезсеңез.

Тәрҗемәсе:

Хәреф җыючыга бозыклык бит һич тә төс түгел,—
Ник моны кыласыз? Аны бит өнәми һич күңел.
Акчаны әрәм-шәрәм итү хәреф җыючы эше түгел,
Ә сез шундый яраксыз эшне дә эшләп куясыз.

*«Фикер», 18 нче сан.*

Бу строфалар бергә тупланып, «Гәзитә мөрәттибләренә» исеме белән «Яңалиф» басмасының 1 нче томына (1929) кертелгән.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 84—85 б.*

**20 май.** «Дәрдмәнд дәгелмием?» шигыре, «Мөхарәбә вә Государственная дума» мәкаләсенең ахыры басылган. Мәкалә «Әсәре Габдулла Тукаев, беренче җөзьэ тәмам»,— дигән искәрмә белән урнаштырылган, әмма икенче кисәге чыкмаган.

*«Әлгасрелҗәдит», 5 нче сан.*

**25 май.** «Граф Лев Толстой җәнабләре язадыр» хикәясе чыга. Тукай бу хикәяне Л.Толстойның «Ильяс» (1885) исемле хикәясеннән тәрҗемә иткән. Ахырда: «Мөнасиб җирләренә үземнән дә кушып тәрҗемә иттем»,— дигән искәрмә биргән.

*«Фикер», 19 нчы сан.*

---

Мөнасиб — таләп ителгән.

**1 июнь.** Уральскида татар телендә беренче сатирик журнал «Уклар»ның беренче саны чыга. Айга бер мәртәбә чыккан бу журнал шул ук елның ноябрендә 6 нчы саны белән туктала. Рәсми нашире һәм мөхәррире булып К.Мотыйгый исәпләнсә дә, журналда төп эшне Тукай алып бара. Журнал укучыларына түбәндәгечә мөрәҗәгать иткән: «Ашыгыгыз!.. Ашыгыгыз!..»

Ничә сәнәләр гафләт йокысында йоклаучы адәмнәр, әгәр уянырга теләсәгез яңа айлык рәсемле сатирик журнал «Уклар»ны алып калырга ашыгыгыз!»

«Уклар» Тукайның сатирик таланты ачылуга зур этәргеч ясый.

«Татарда сатира-юмор әдәбияты яңа гына аякка басу чорында, журналга яраклы материаллар бирүчеләр аз булганлыктан, журналны (аеруча баштагы саннарын) Тукай үзе язып тутыра. Төрле шәһәрләрдән килгән хатларны да оста файдаланып, кызыклы һәм үткен әсәрләр урнаштыра. Тукай үз әсәрләрен төрле псевдонимнар белән, ә байтагын имзасыз бастыра»,— ди Тукай «Әсәрләр»е җыелмасының биш томлыгын (1985—1986) төзүче Р.Гайнанов.

*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 339 б.*

Журналның бу беренче санында Тукайның түбәндәге шигырьләре, мәкаләләре басылган:

«Хәтирәи «Бакырган» шигыре «Шүрәле» имзасы белән «Сүз башы» журналның програм мәкаләсе рәвешендә «Дугъры» имзасы белән, «Шәкерт илә надан ишан» «Тәртә башы» имзасы белән, «Сөаль», «Дөрест телеграм хәбәрләре», «Аракы кибетендә», «Әхбаре хариҗия», «Озын колак хәбәрләре» мәзәкләре, «Әйтәсем килә» шигыре имзасыз басылган.

*«Уклар», 1 нче сан.*

**3 июнь.** «Фикер»дә «Гәзитә мөрәттибләренә» шигыренең дүрт строфасы урнаштырылган:

Сезгә тәслим әйләмеш милләт бөтен әүракыны,
Анлары энҗү кеби мәнсүр идәнләр сезсеңез.
Чикмәңез гамь: безчә, сез мәмдухсеңез, мәкъбүлсеңез,
Иштә шигъри язмая мәҗбүр идәнләр сезсеңез.

Тәрҗемәсе:

Милләт сезгә барлык кәгазьләрен тапшырган,
Шулар өстенә сез энҗе кебек сүзләр тезәсез.
Кайгырмагыз: сез мактаулы һәм кирәкле, безнеңчә,
Сез бит бу шигырьне язарга да мәҗбүр итүче.

---

Гафләт — наданлык.
Әхбаре хариҗия — тышкы (чит ил) хәбәрләр.

«Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?» исемле шигыре чыккан.

*«Фикер», 20 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 84—85 б.*

**10 июнь.** «Мөхәммәтгали бабай» дигән хикәясе басылган. «Ахыры бар» дип куелган.

*«Фикер», 21 нче сан.*

**15 июньгә кадәр.** Г.Тукай Ф.Әмирханга хат яза, хатта болай диелгән: «Хөрмәтле Фатих әл-Әмирхан әфәнде! «Әлгасрелҗәдит» журналына махсус җибәрдекеңез «Коммуна» әсәре — заманыбызда табгы вә интишаре гаять мөһим бер әсәрдер. Шуның өчен Сездән риҗа итәмез, мәзкүр әсәреӊ дөрест басылмасы өчен беловойга язып җибәрәсез, бер бозып, бер сызып язган черновоеңызны аңламак, хосусән, мөрәттибләр өчен бик мөшкелдер. Мадәм ки, тәрҗемәсенә һиммәт итмешсез, бер дә беловойга язмага да иренмәңез».

Хат Ф.Әмирханның «Әлгасрелҗәдит» журналына «71 ел коммунасы» (Марек Конколь брошюрасы) исемле мәкаләсен тәрҗемә итеп җибәрүе уңае белән язылган. Мәкалә әлеге журналның 1906 елгы 6 нчы (15 июнь) һәм 8 нче (15 август) саннарында басылып чыккан. Димәк, Тукайның хаты мәкаләнең басылуыннан, 15 июньнән алдарак язылган һәм җибәрелгән булырга тиеш, басылуы гына соңрак, «Фикер»нең 1906 елгы 4 август (29) санында булган. Монда аның язылу датасы мәкаләнең басылу датасыннан чыгып билгеләнде.

*«Фикер», 29 нчы сан.*

**15 июнь.** «Әлгасрелҗәдит»тә «Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?» шигыре чыккан. Бу шигырь язылган елларда Япониядә мөселманлык тарала, япон патшасы (Микадо) ислам динен кабул итә. Шуның хөрмәтенә ул ислам галимнәрен Япониягә чакыра икән, дигән хәбәр тарала. Шигырь шул уңай белән язылган.

Рәсемле айлык сатирик журнал «Уклар»ның чыгуы турында игълан урнаштырылган.

Игълан астында Г.Тукайның:

И «Уклар» мөхбирләре! Кызганмагыз укларны,
Исраф итмәгез укларны, атамагыз сез юк-барны.
Бездән фәрман шул сезгә: патрон берлә не шалить!
Кирәк җиргә атканда, патроннарны не жалеть!
Атучыга әмеремез: укларны кызганмасын!
Атылмышка нәсихәт! Йөрәге сызламасын! —

---

Интишар — таралу.
Риҗа иту — үтенү.
Мәзкүр — югарыда әйтелгән.

дигән шигъри юллар, «Уклар» журналының мөгаййән мөхәррирләре: «Шүрәле», «Сөемсез», «Ишан мөнкире», «Каилелхак вә ма әшбәһе залик» дигән яшерен имзалар китерелгән.

*«Әлгасрелҗәдит», 6 нчы сан.*

**18 июнь.** «Мөхәммәтгали бабай» хикәясенең соңгы өлеше басылган. «Ахыры бар» дип куелган. Ләкин ахыры күренмәде.

*«Фикер», 22 нче сан.*

**25 июнь.** «Ялкаулык, яхуд Җиңел кәсеп», «Тугры җавап», ***(«Пушкинский домад...») мәкаләләренең соңгы икесе имзасыз басылган.

Мәкаләләр хиҗаб (хатын-кызларга битне каплап йөрү) мәсьәләсендә «Бәянелхак» газетасы белән бәхәскә кереп язылган.

*«Фикер», 23 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 64—65 б.*

**27 июнь.** «Вакыт»та Тукай шигырьләренә түбәндәге бәя бирелгән: «Без Тукаевны назымнары сәбәбеннән таныдык. Милли шагыйрьләремезнең даһиларыннан улачагыны өмид идәрез».

Димәк, шагыйрьнең иҗатын югары күтәреп, беренче бәяләүче «Вакыт» редакциясе булган.

*«Вакыт», 42 нче сан.*

**3 июль.** «Алай-болай» исемле мәкаләсенең беренче өлеше «Биик усал» имзасы белән чыккан. Мәкаләдә «Бәянелхак» мөхәррире Әхмәтҗан Сәйдәшев (1840—1912) тәнкыйть ителә.

*«Фикер», 24 нче сан.*

**10 июль.** «Уральск имамнарына ачык хат»ы «Идарә» имзасы белән басылган. Хатта «Фикер» матбагасын туздырырга йөрүчеләргә карата тәнкыйть сүзләре әйтелгән. Автор, Уральск имамнарына мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Ул матбага, әлхәмделиллаһ, ислам кулында булганлыкы ичун тәшәккерләр лязем иде, сез, әфәнделәр, киресенә барып, буның кеби матбаганың мөселман кулында булып, һәртөрле гәзитә, журнал, китап, рисаләләр язып торуына хәсәд итәсезме?»

«Погром» исемле мәкаләсе «Уральск кешесе» имзасы белән чыккан. Бу мәкалә дә Уральск сәүдәгәрләре һәм муллаларының «Фикер» матбагасын туздырырга йөрүләре турында.

*«Фикер», 25 нче сан.*

---

Назым — тезмә сүз.
Хәсәд итәсезме? — Көнләшәсезме?

**14 июль.** «Бу эш яхшымы?» («Ахыры бар» дип куелган, ләкин ахыры күренми), «Гайнижамал хәзрәтнең дәхи бер ялганы» исемле мәкаләләре имзасыз басылган. Мәкаләләрдә Уральскидагы иске фикерле кешеләрнең «Фикер» матбагасын туздырырга йөрүләре турында сөйләнә.

*«Фикер», 26 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 299 б.*

**20 июль.** «Әлгасрелҗәдит»тә «Сорыкортларга», «Кемне сөяргә кирәк?» шигырьләре чыккан. Соңгысы А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» шигъри романындагы дүртенче бүлекнең XXII строфасын файдаланып язылган.

«Мәҗмугаи мөфидә» исеме астында (И.А.Крыловтан ирекле тәрҗемә ителгән) түбәндәге мәсәлләре басылган: «Фил» («Слон в случае»), «Бала караучы» («Крестьянин и Змея»), «Алмас» («Булат»), «Кеше һәм Арыслан» («Лев и Человек»), «Бүре хакында» («Мирская сходка»), «Сәүдәгәр» («Купец»), «Куйлар вә этләр» («Овцы и собаки»), «Бүре илә Сычкан» («Волк и Мышонок»), «Ишәк» («Осел»), «Арыслан ауда» («Лев на ловле»), «Черки изгелеге» («Комар и Пастух»), «Җылан илә Куй» («Змея и Овца»), «Картайган Арыслан» («Лев состарившийся»), «Мөһәндис» («Механик»), «Ике бала» («Два мальчика»), «Аю» («Медведь в сетях»), «Ике эт» («Две собаки»), «Батыр Кырмыска» («Муравей»), «Бытбылдык» («Синица»), «Роща илә ут» («Роща и огонь»), «Тавыклар илә Каракош» («Орел и куры»), «Тәүбә иткән Төлке» («Крестьянин и Лисица»). «Ахыры бар» дип куелган.

*«Әлгасрелҗәдит», 7 нче сан.*

**21 июль.** «Фикер»дә «Алай-болай» исемле мәкаләсенең дәвамы чыккан.

«Үрдәк бирсәң, каз алырсың» фельетоны «Без» имзасы белән басылган. Фельетонда Уральскида тире-яры сәүдәгәре Хәсәнҗан Хөсәенов тәнкыйтьләнә.

«Шәһәремездәге зур тәмгылы муллалара бер-ике сүз» мәкаләсенең ахырына «Берничә кешеләрнең үтенүе буенча вәкил — «Уральск кешесе» дип куелган.

Мәкаләдә Уральск муллаларының «Фикер» мөхәррире К.Мотыйгыйны гаепләүләренә каршы гади халык фикере тупланган.

«Юк, хәзрәтләр, алай иттереп, сезнең шикелле тәмгыга нәфесне җибәрмәйүб, үзалдына бер хезмәт тапкан сәбәпле бер кешене кяфер дип йөрү бик зур кабахәтлектер»,— ди Тукай.

---

Гайнижамал — Гайнетдин Җәләлетдинов дигән мулла.
Тәмгылы (тамигъ) — ач күзле, нәфселе.

**21 июль.** «Хакны белеп инкяр кылу» — «Уральск кешесе» имзасы белән урнаштырылган. «Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренми. Мәкаләдә Уральск мулласы Гайнетдин Җәләлетдинов белән хиҗаб мәсьәләсе хакында сүз алып барыла. Бу мулла «Бәянелхак» газетасының 1906 елны 13 июль (41) санында хиҗаб турында язылган мәкаләсендә хатын-кызларга чит ирләрдән качу, битләрен каплап йөрү кирәклеген исбат итеп, озын фәтвалар бастыра. «Фикер» сахибе шәригатьне таптый»,— дип яза.

Тукай Гайниҗамал хәзрәт фәтваларын кире кага.

«Әйтелгән сүз кире кайтмас» исемле мәкаләсе «Каз» имзасы белән басылган.

Шушы мәкаләләрдән башлап «Фикер» белән «Бәянелхак» (нашире һәм мөхәррире Әхмәтҗан Сәйдәшев) газетасы арасында хатын-кыз азатлыгы, хиҗаб мәсьәләсендә озак вакытлар бәхәсләр барган.

*«Фикер», 27 нче сан.*

**28 июль.** «Петр бабайның хикәяте» әсәре «русчадан тәрҗемә» дигән искәрмә белән басылган. Кем әсәреннән тәрҗемә икәне билгеле түгел.

«Идарәдән» — баш мәкалә урынында имзасыз чыккан. Мәкаләдә искелекне яклаучы «Бәянелхак» белән прогрессив карашларны алга сөргән «Фикер» редакциясе арасындагы каршылыклар турында сүз бара.

*«Фикер», 28 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 345 б.*

**Июль ахыры.** «Татар кызларына» шигыре, «Уйламаган җирдә орган», «Урамда», «Казанда» фельетоннары «Шүрәле», «Идел буендагы шәһәрдә» фельетоны, «Тәртә башы», «Саратов» дигән кечкенә парчасы, «Черек күлдә» (ике хатын арасында), «Казан» фельетоннары имзасыз басылганнар.

Соңгы ике фельетонда Г.Тукай Ә.Сәйдәшевнең хатын-кызга булган карашын тәнкыйть итә. Ә.Сәйдәшев фикеренчә, хатын-кыз иренең колы булырга, чит ирләрдән качып, җилән ябынып йөрергә тиеш.

Тукай исә хатын-кызның ирекле булуын, чапанын ташлап, ачык йөз белән йөрүен яклый.

*«Уклар», 2 нче сан.*

---

Фәтва — берәр эшнең дөреслеген шәригать кануннарыннан чыгып раслау.

Сахиб — хуҗа.

**1 август.** Идарәдән «Габдулла әфәндея! Форсатыгыз улдыкында мөһим хәбәрләр язып торачагыңызга тәшәккер улынырۥ» дип, «Вакыт» газетасы Г.Тукайны үзләренә язышып торырга чакыра. Тукай «Вакыт»ка язышмаган.

*«Вакыт», 56 нчы сан.*

**4 август.** ***(«Ф.Әмирханга җавап») «Идарәдән җаваплар» бүлегендә басылган. Монда сүз Ф.Әмирханның поляк революционеры Марек Конкель әсәреннән тәрҗемә иткән «71 нче ел Коммунасы» исемле мәкаләсен «Әлгасрелҗәдит» журналында бастырып чыгару турында бара.

Әхмәтсафа Байтирәковка адресланган хаты басылган хатта болай диелгән: «Яңа Яндовкада гыйззәтлү Әхмәтсафа әфәнде! «Фикер»гә мөхбирлек итәргә дәртеңез булса, мөмкин кадәр файдалы вә хикмәтле нәрсәләр язарга тырышыңыз, мәктүбләреңезең арасында мөляхәзәсезрәк язылганнары да булганлыктан, сайлап вә чүпләп кенә басарга тугры киләдер».

Тукайның «Мотыйгыя»дә бергә укыган дусты, шагыйрь Ә.Байтирәков Саратов губернасы Хвалын өязе Иске Кулаткы волосте Яндовка авылында (хәзер Ульяновск өлкәсе) мөгаллимлек иткән вакытында «Фикер»нең үз хәбәрчесе дә булып торган.

*«Фикер», 29 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 346 б.*

**11 август.** «Тугры сүз», «Тәрҗеман»ның кязибе» мәкаләләре имзасыз, «Гүзәл бер хакыйкать» мәкаләсе «Һәйьәт идарә» имзасы белән басылган.

Мәкаләләр «Тәрҗеман» белән «Фикер», «Фикер» белән «Бәянелхак» газеталары арасында хатын-кыз азатлыгы, ислам шәригате кануннары турындагы каршылыкларны чагылдыралар.

*«Фикер», 30 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 348—349 б.*

**15 август.** «Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» исемле тәрҗемә мәкаләсе чыккан. Мәкалә академик А.Н.Бахның (1857—1946) «Царь-Голод, экономические очерки» (1906) дигән хезмәтеннән тәрҗемә ителгән. «Дәвамы бар» дип куелган.

«Мәхү идәрмисән?», «Мөхәррирргә» исемле шигырьләре басылган.

1905 ел ахырыннан Казанда чыга башлаган «Бәянелхак»

---

Мөляхәзәсезрәк — игътибарсызрак.
Кязибе — ялганы.
Һәйьәт идарә — редакция.
Мәхү идәрмисән? — Юк итәрсезме?

газетасында К.Мотыйгый турында явыз ниятле кискен мәкаләләр басыла. Демократик юнәлештәге газета-журналлар чыгарганы өчен аны динсез (дәһри) дип атыйлар. Шигырьнең соңгысы шул уңай белән К.Мотыйгыйны яклап язылган.

*«Әлгасрелҗәдит», 8 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 341 б.*

**17 август.** Г.Тукай Уральскида «Пушкин йорты» алдында уздырылган митингта катнаша. Хөкүмәт тәртипләренә каршы юнәлдерелгән бу митингны атлы казаклар куып тарата.

Г.Тукай «Пушкин йорты»на, анда уздырылган кичәләргә, мәҗлесләргә бик яратып йөргән. Бу хәл аның иҗтимагый карашлары үсешенә уңай йогынты ясамый калмагандыр.

*Вәзиева Җ. Габдулла Тукайның Уральск чоры турында. «СӘ», 1961, 4 нче сан, 72—73 б.*

**18 август.** «Заманымызның әдиб вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсенә гаид» дигән язмасы чыккан.

Язма Петропавловск мулласы Хөҗҗәтел-Хәким Мәхмүдевнең «Өлфәт» газетасында (1906, 2, 9 август, 33, 34 нче саннар) басылган «Заманымызның әдиб вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсенә каршы язылган. Х.Мәхмүдев үзенең мәкаләсендә Тукай исемен аерым атамаган, мөхәррир һәм журналистларны гомумән алып кына тәнкыйть сүзләре әйткән. Тукай аның фикерләрен кире кага.

«Өлфәт»кә җавап» дигән мәкаләсе «Идарә» имзасы белән урнаштырылган һәм Х.Мәхмүдевнең «Заманымызның әдиб вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсе уңае белән язылган.

Шунда ук «Мөхәрриргә» шигыре басылган.

*«Фикер», 31 нче сан.*

**20 август.** Г.Тукай Уральск эшчеләре үткәргән митингта матбага эшчесе А.Гладышев белән бергә, революцион прокламацияләр таратуда катнаша.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986, с. 50.*

**27 август.** Г.Тукай Уральск эшчеләре үткәргән митингта катнаша. Полиция митингта катнашучыларны нагайкалар белән кыйнап тарата. Соңыннан бу вакыйганы Тукай «Уральскида дума членын вә тәвабигын нагайкалау» исемле мәкаләсендә җентекләп тасвирлый.

*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 174—176 б.*

---

Гаид — карата.
Тәвабигын — иярүчесен.

**Август ахыры.** Түбәндәге шигырь һәм парчалары басылган: «Тәрҗемә вә тәшрих» шигыре «Шүрәле» имзасы белән. Бу әсәр А.С.Пушкинның 1824 елда язылган бер исемсез шигыреннән ирекле тәрҗемә. Шунда ук Пушкинның әлеге шигыре дә урнаштырылган. «Алырга ашыгыңыз» — «Һөд-һөд» имзасы белән, «Ишан кәрамәте» — «Җен» имзасы, «Бюрократлар нәсихәте» — «Кырмыска» имзасы, «Ахун хәзрәтләрнең сатылулары» — «Шәкерт угы» имзасы, «Фатиха базары, яки Макарья ярминкәсе» — «Г.Т.» имзасы, «Яңа дәгъвәт» — «Адвокат» имзасы белән, «Тимерчыбыксыз телеграмм хәбәрләре» — имзасыз, «Яңа камустан берничә лөгать», «Тиешсез эш», «Казый кем була?» — «Шәкерт угы» имзасы белән, «Карттан гакыллырак бала» — имзасыз, «Тәҗрибәле сүзләр» — «Кырмыска», «Куркынычлы эш» «Догачы» имзалары белән бирелгән.

*«Уклар», 3 нче сан.*

**2 сентябрь.** «Уральскида хөррият бәйрәме» исемле мәкаләсе басылган.

Мәкалә Уральскидан Икенче Дәүләт думасына сайланган сул карашлы В.В.Недоносковның сайлаучылары белән очрашуы, шәһәр жандармнарының бу очрашуны өзәргә омтылулары турында.

*«Таң йолдызы», 37 нче сан.*

**3 сентябрь.** «Уральскида Дума членын вә тәвабигын нагайкалау» исемле мәкаләсе имзасыз басылган. Бу мәкаләнең Тукайныкы булуы авторның «Уральскида хөррият бәйрәме» исемле мәкаләсеннән билгеле.

*«Фикер», 32 нче сан.*

**7 сентябрь.** Әстерханда чыккан «Борһане тәрәккый» газетасы, «Фикер»дән күчереп, Г.Тукайның «Мөхәрриргә» исемле шигырен бастырган.

*«Борһане тәрәккый», 26 нчы сан.*

**10 сентябрь.** Г.Тукай Чыгтайның (Галиәсгар Гафуровның) «Әлгасрелҗәдит» журналында (1906, 6, 8 нче саннар) басылган «Тутам» рисаләсенең икенче кисәген патша хөкүмәте тәртипләренә каршы язылган әсәр дип бәяли.

Уральскиның Хәлим ахун, Тукай катнашында чыккан «Фикер» газетасын яптыруны таләп итеп, Уфага мөфтигә хат яза.

---

Тәшрих — ачыклау, шәрехләү.
Камус — сүзлек.
Тәвабигъ — иярүчеләр.

Таләбе үтәлмәгәндә шул турыда Эчке эшләр министрлыгына шикаять җибәрәчәген белдерә. Ләкин шикаять нәтиҗәсез кала.

*«Фикер», 33 нче сан;*
*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986, с. 73.*

**11 сентябрь.** «Алданмаңыз!» исемле мәкаләсе «Һәйьәт идарә» имзасы белән басылган. Мәкаләдә «Бәянелхак» һәм аның нашире Ә.Сәйдәшев тәнкыйть ителә.

«Габдеррәкыйп хәзрәтнең вәгазе» исемле мәкаләсе имзасыз чыга.

Уральск мулласы Габделрәкыйп Тулбаев халыкны «Фикер» газетасын укымаска котырта. Мәкалә шуңа каршы язылган.

*«Фикер», 33 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 353 б.*

**15 сентябрь.** «Борадәранә нәсихәт» шигыре «63 нче номер «Вакыт» җәридәсендә мөндәриҗ яшь төрекләрнең бәгъзе әшгаренә каршы»* дигән искәрмә белән чыккан.

«Хур кызына» шигыре М.Ю.Лермонтовның «К деве небесной» исемле шигыреннән файдаланып язылган. Тукай бу шигырьне ирекле тәрҗемә итә, киңәйтә, яңа тасвирлар өсти.

«Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» тәрҗемә мәкаләсенең икенче-өченче бүлекләре басылган. «Ахыры бар» дип куелган.

*«Әлгасрелҗәдит», 9 нчы сан.*

**17 сентябрь.** «Хиссияте миллия» исемле мәкаләсе басылган. Мәкаләдә Г.Тукайның мәгърифәтчелек карашлары чагыла. Ул болай ди: «Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәкъкыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, бардакханәдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ». «Җавабә җавап» мәкаләсе урын алган.

Г.Тукайның «Заманымызың әдиб вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсенә гаид» исемле мәкаләсенә каршы Х.Мәхмүдев «Җавап» яза («Фикер», 1906, 11 сентябрь, 33 нче сан).

«Җавабә җавап» шушы мәкалә уңае белән язылган.

*«Фикер», 34 нче сан.*

---

* Яшь төрекләрнең «Вакыт» газетасына кергән кайбер шигырьләренә каршы.

Бардакханәдән чыкмаган — фахешханә белән бәйләнеше булмаган.

**24 сентябрь.** «Фикер»дә «Төрле хәбәрләр», ***(«Шәһәремездә театр фәненә...») исемле мәкаләләре «Уральск хәбәрләре» рубрикасы астында информация рәвешендә имзасыз басылганнар. Шунда ук игълан-реклама китерелгән: «Русиядә беренче әдәби вә сәяси гомуми файдалы яңа «Әлгасрелҗәдит» журналына 1907 ел өчен мөштәри дәфтәре ачылды.

1907 сәнәдә мөштәриләргә һәр ай саен бер рисалә шәкелендә әдәби китаплар күндереләчәк. Габдулла әфәнде Тукаевның милли әшгаре мәҗмугасы һәдия ителәчәктер».

Г.Тукайның мөштәриләргә вәгъдә ителгән бу шигырь-җыентыгы чыкмаган булса кирәк.

*«Фикер», 35 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 381 б.*

**24 сентябрь.** «Муллалар» исемле мәкаләсе чыккан.

Мәкаләдә муллаларга хөкүмәт тарафыннан законлы рәвештә хезмәт хакы түләүне кертү таләп ителгән. Әгәр шулай булса, алар халык җилкәсендә яшәмәсләр иде, дигән фикер үткәрелә.

«Казан» чәйханәсендә голяма җәмгыяте» исемле мәкаләсе имзасыз басылган.

Мәкаләдә Тукай «Бәет» исеме белән түбәндәге юлларны китергән:

Карагыз сез безем хәзрәт миенә,
Миендә мәгърифәт дәрде биимә?..
Бөтенләй мөртәсәм фикре миендә —
Кымыз, шурпа, бәлеш, тәңкә, тиен дә.

**24 сентябрь.** Идарәдән игълан. «Русиядә беренче әдәби вә сәяси яңа журнал «Әлгасрелҗәдит» мәҗмугасының 9 нчы саны (15 сентябрь) чыкты». Эчтәлегендә Г.Тукайның «Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» исемле русчадан тәрҗемәсе, «Хур кызына», «Борадәранә нәсихәт» исемле шигырьләре күрсәтелгән.

*«Фикер», 35 нче сан.*

**30 сентябрь.** «Төрки журналлар» исеме астында «Әлгасрелҗәдит» журналының 9 нчы санына күзәтү ясалган. Күзәтүдә Г.Тукайның шушы санда басылган «Борадәранә нәсихәт», «Хур кызына» шигырьләренә югары бәя бирелгән, «Бер чук гүзәл шигырьләр» диелгән.

*«Вакыт», 80 нче сан.*

---

Әшгаре мәҗмугасы — шигырьләр җыентыгы.
Мөртәсәм — рәсемләнгән.
Чук — бик.

**Сентябрь.** «Уклар»да «Бай кызы илә кучер», «Мәүлед», «Жандармски офицер хатыны илә» исемле памфлетлары «Тәртә башы» имзасы белән басылган. Памфлетлар Г.Тукай «Әсәрләре»нең җыелмаларына кермәгән. Әмма шагыйрьнең биш томлы «Әсәрләре»н (1985—1986) төзүче Р.Гайнанов «Тәртә башы» имзасының Тукайныкы булуын күрсәтә. Кара: Г.Тукай. Әсәрләр, биш томда. 1 нче том (1985), 347 бит. Әлеге имза белән басылган башка әсәрләрен дә Р.Гайнанов биш томлыкка урнаштырган. Димәк, бу памфлетлар Тукайныкы булуы ихтимал. «Пыяла баш», «Рәсемгә ишарә» шигырьләре, «Татар диненчә мөселман булу» памфлеты «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шигырьләргә карата журналда рәсемнәр дә ясалган. Усал итеп күрсәтелгән ир кеше рәсеме төшерелгән. Шул рәсемгә аңлатма рәвешендә, рәсем астына түбәндәге сүзләр язылган: «Уклар өйдә һәм эштә каты булырга мәслихәт бирәдер, әмма мәҗлестә һәм усал муллалар алдында юаш булсалар да ярый, Ахмакҗан бабай кеби». Имзасыз басылган әлеге аңлатманы да Тукайныкы булырга тиеш дип уйларга нигез юк түгел, чөнки Ә.Сәйдәшевне «Ахмакҗан» дип күп урында Г.Тукай атый. Бу соңгысы да Тукай томнарына кермәгән.

**Сентябрь.** «Яңа камустан берничә лөгать» памфлетының дәвамы «Җен» имзасы белән басылган.

*«Уклар», 4 нче сан.*

**1 октябрь.** «Алла гыйшкына» дигән шигыре, «Уральскида дарелмөгаллимин» исемле мәкаләсе имзасыз чыга.

«Мөхәммәдински духовный» собраниегә Уральскида 3 нче мәсҗед мәхәлләсендин гаризалар» урнаштырылган.

Гаризада бер байның 3 нче мәсҗедкә вакыф итеп калдырган бинасын дарелмөгаллимин ачу өчен бирелүе сорала. Гаризага утыз сигез кеше кул куйган. Тукай имзасы 6 нчы урында тора.

«Сырой егет» исемле фельетоны «Мәкәрҗәдә булучы» имзасы белән чыккан.

*«Фикер», 36 нчы сан.*

**6 октябрь.** «Фикер»дә «Казан» миһманханәсендә мәҗлес» исемле мәкаләсе имзасыз басылган. Мәкаләдә Уральск шәһәрендә дарелмөгаллимин ачу турында сүз бара. Г.Тукай мәҗлестә түбәндәгечә чыгыш ясый: «Юк, Фатыйх абзый! Безнең ул мәдрәсәләремез генә җитми, башка милләтләрдәге кеби безгә дә 3—4 этажлы мәдрәсәләр кирәк. Син, Фатыйх абзый, әле күптән түгел генә ярлы идең, син шул ярлылыгым җитәр дип тормадың, кибет ачтың, сәүдә иттең, һәрничек баерга тырыш-

Д а р е л м ө г а л л и м и н — ир укытучылар хәзерли торган уку йорты.

тың. Инде мәдрәсә ачу хосусына килгәндә, җитәр дип әйтәсең. Вәхаләнки, мөселман кешегә милләт файдасын үз файдасыннан өстә тотарга кирәк. Юк, җитмәс, җитәр дип әйтмә. Безнең мәдрәсәләремез рус мәдрәсәләренең тәрәтханәсеннән дә шакшырак. Китәбез, алга китәбез, канәгать итмибез бу мәдрәсәләргә!» — ди ул дарелмөгаллимин ачуга каршы сөйләүче Фатыйх Шәриповка.

*«Фикер», 37 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 382 б.*

«Дәхи бер фетнә», «Уральск хәбәрләре» имзасыз басылган. Соңгысына «Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренмәде. Мәкаләнең азагына («Тугъды, көн тугар кеби... ») шигыреннән:

Мортаза бай! Син төзәлмәссең бугай,
Син нигә бигрәк саран булдың болай?! —

дигән өзек китерелгән.

«Дәхи бер фетнә» мәкаләсендә вакыфны ничек файдалану кирәклеген шәригать кануннарыннан чыгып аңлата.

«Хаҗи» исемле тәрҗемә хикәясе басыла. Ул К.Мотыйгый наширлегендә Уральскида чыккан «Уральский дневник» газетасында бирелгән «Хаджи» исемле хикәядән ирекле тәрҗемә.

*«Фикер», 37 нче сан.*

**10 октябрь.** «Казан» миһманханәсендә Уральск «Җәмгыяте хәйриясе»нең мәҗлесе була. Мәҗлестә җәмгыятьнең эш тәртибе карала. «Җәмгыяте хәйрия» әгъзаларының исемлегендә Г.Тукай фамилиясе дә бар. Моннан Г.Тукайның Уральскидагы «Җәмгыяте хәйрия» әгъзасы булганлыгы күренә.

*«Фикер», 39 нчы сан.*

**15 октябрь.** «Әлгасрелҗәдит»тә «Көз», «Милләтә» шигырьләре һәм «Бик кыйбат» хикәясе басылган. Хикәясенең ахырында автор: «Бу хикәя асыл Мопассан исемле француз мөхәрриренеңдер. Аннан граф Лев Толстой җәнабләре алмыш. Аннан бән алып тәрҗемә иттем»,— дигән аңлатма биргән.

Бу — Г.Мопассанның «Су өстендә» («На воде») исемле хикәясе. Аны 1890 елда кайбер үзгәртүләр белән Л.Н.Толстой тәрҗемә иткән.

«Мәҗмугаи мөфидә» исеме астында (И.А.Крыловтан ирекле тәрҗемә ителгән) түбәндәге мәсәлләре басылган: «Тычканнар киңәше» («Совет мышей»), «Нәүхәчеләр» («Похороны»), «Чабак» («Плотичка»), «Чүлмәк илә Казан» («Котел и Горшок»),

---

Вәхаләнки — һәрхәлдә.

«Күл» («Ручей»), «Кәгазь змея» («Бумажный змей»), «Аю мәҗлесе» («Обед у Медведя»), «Дуңгыз» («Свинья»), «Мосафирлар һәм этләр», («Странники и собаки»), «Тиен» («Белка»), «Ике күгәрчен» («Два голубя»), «Файдасыз җумартлык» («Туча»), «Күке илән Күгәрчен» («Кукушка и Горлинка»), «Җөкче илә Җул кисүче» («Разбойник и Извозчик»), «Яшь агач» («Дерево»), «Сукыр тычкан һәм Каракош» («Орел и Крот»), «Ике күрше» («Музыканты»).

*«Әлгасрелҗәдит», 10 нчы сан.*

**15 октябрь.** Уральскида «Казан» миһманханәсендә 2 нче мәҗлес». Мәкаләдә Уральск шәһәрендә «Җәмгыяте хәйрия» оештыру җыелышыннан хисап бирелгән.

«Төрле хәбәрләр», «Игълан» мәкаләләрендә «Фикер» газетасы, «Уклар», «Әлгасрелҗәдит» журналлары мөштәри дәфтәре һәм «Фикер»не көндәлек, «Уклар»ны атналык, «Әлгасрелҗәдит»не айга ике мәртәбә чыгарырга күчү турында сүз бара.

«Чит мәмләкәт хәбәрләре» мәкаләсе төрек солтаны Габделхәмит турында.

«Яңа гәзитә вә журналлар һәм мәкаләләр» имзасыз басылган һәм «Уральскида «Җәмгыяте хәйрия» башлануы» «Уральск җәмгыяте хәйриясе»нең бик усал бер члены» имзасы белән, «Дәхи ниләр күрермез икән?» «Мөсафир» имзасы белән чыккан.

*«Фикер», 38 нче сан.*

**15 октябрь.** Г.Тукай И.Жилкинның «Уральский дневник» газетасында басылган «Тормыш юллары» исемле мәкаләсен укый. Мәкаләдә Беренче Дәүләт думасының халыкка бернәрсә дә бирмәве турында язылган була.

*Вәзиева Җ. Габдулла Тукайның Уральск чоры турында. «СӘ», 1961, 4 нче сан, 73 б.*

**Октябрь.** «Уклар»да ***(«Кыямәт якын килде — җир сораучы ярылды...») шигыре «Хәсрәт» имзасы белән басылган.

1906 елның 16 сентябрендә «Азат халык» газетасы (мөхәррире Г.Камал) «Йолдыз» газетасы белән бергә кушыла. Г.Камал «Йолдыз»га секретарь булып күчә. Г.Тукай бу хәл белән риза булмый. Ризасызлыгын берничә шигырендә белдерә. Әлеге ***(«Кыямәт якын килде...») шигырендә дә:

«Фикер»дән көлгән иде — һич сәбәпсез бер «Азат»,
Инде ул китте назад — Аллаһ дигел, бәдәвам» —

дип, тәнкыйть сүзләре әйтә.

---

Мөштәри дәфтәре — абүнәче дәфтәре.

«Дөнья бу, йа!» шигыре «Шүрәле» имзасы белән чыккан. Бу шигырьдә дә ул:

Социал «Азат халык»ны черносотенный ясап,
Һади абзый* мәсләген мәсләк дидерткән дөньядыр,—

ди.

*«Уклар», 5 нче сан.*

Тел белгече Бәкер Яфаров «Тукай сатира һәм пародияләренең әдәби антиподларына карата» дигән мәкаләсендә Тукай «Дөнья бу, йа!» шигырен Көнчыгыш шагыйре Колшәрәфинең (Кашани) «Дөнья» турындагы тезмәсенә пародия итеп язган дигән караштa тора һәм һәр ике шагыйрьнең шигырьләрен чагыштырып, мисаллар китерә. Колшәрәфидә:

И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дөньядыр.

Тукайда:

И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу тәдавел ширбәтен халыкка эчергән дөньядыр.

Автор бу ике шагыйрь арасындагы аерманы да күрсәтә. Колшәрәфидә төп идея кеше дөньядан аерылырга, бизәргә тиеш. Тукайда исә татар халкының үсүенә ысулы кадимче байлар, панисламист укымышлылар комачаулык итәләр.

*Яфаров Б. Габдулла Тукай, 1948, 130 б.*

**Октябрь.** «Куркынычлы хәбәр» («Кыямәт») фельетоны — «Хәсрәт» имзасы белән, «Макарьядәге җыелыш», «Казан хәбәрләре» — «Тәртә башы» имзасы белән, «Тимерче», «Авылда», «Ике кеше арасында», «Гаҗаиб!» фельетоннары — «Шүрәле» имзасы белән, «Телсез телеграф хәбәрләре (гәзитәләр)» фельетоны имзасыз басылганнар.

*«Уклар», 5 нче сан.*

**22 октябрь.** «Государственная думага» («Ай бәгърем, Нәгыймә» көенә) шигыре басылган.

Шигырь Беренче Дәүләт думасын патша хөкүмәтенең куып таратуы (1906 ел, 9 июль) уңае белән язылган.

«Уральский листок» газетасының 1906 елгы 15 октябрь санында И.Жилкинның «О пароходе и песне о думе» исемле шигыре басылган. Тукай иҗатын өйрәнүче галим Р.Нәфыйгов «Государственная Думага» шигырен И.Жилкинның әлеге шигыре тәэсирендә язылган, дигән караштa тора.

---

* Һади абзый — Һади Максуди — «Йолдыз» газетасының мөхәррире һәм нашире.

Тәдавел ширбәте — бүтән холыкка кертә, үзгәртә торган эчемлек.

«Әдәбият ахшамы яки литературно-музыкальный вечер» исемле мәкаләсе чыккан.

*«Фикер», 39 нчы сан;*
*Нафигов Р. Поиски нового о Тукае. «Татарстан», 1995, № 5—6, с. 118.*

**29 октябрь.** «Интересный тормыш» исемле фельетоны «Бән» имзасы белән дөнья күрә. Әсәр Уральск миллионеры сәүдәгәр Мортаза Гобәйдуллин турында. Үзенең «И каләм!» шигырендәге:

Яз тәгаллемләргә тәргыйб, әйлә тәкъдир кадрене:
Ит наданлыкларны тәгъриф, зәһрене яз, гадрене.

Тәрҗемәсе:

Чакырып яз укырга, уку кыйммәтен тәкъдир ит,
Наданлыкның начарлыгын аңлат агу икәнен. —

дигән ике юллыкны берникадәр үзгәртеп, әлеге фельетонына түбәндәгечә кертеп җибәрә:

Мәгърифәт, хикмәт нәдер — белсенме җаһил кадрене,
Шәкъвәте җәһленә сабикъ, күр нифакъ вә гадрене.

Тәрҗемәсе:

Мәгърифәт, гыйлем нәрсә — надан беләмени кадрен,
Әшәкелеге аннан да артык — күр икейөзлелеген, зәһәрен.

«Сайлау хакында» исемле мәкаләсе имзасыз баш мәкалә урынында басылган. Мәкаләдә Икенче дәүләт думасына сайлауларны оештыру хакында сөйләнә.

*«Фикер», 40 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 383 б.*

**Октябрь.** Уральскида «Казан» миһманханәсендә әдәби-музыкаль кичә оештырыла. Кичәне оештыруда Г.Тукай, Г.Кариев, К.Төхфәтуллин башлап йөриләр.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986, с. 34.*

**5 ноябрь.** «Вакыт» газетасы Г.Тукайның «Әдәбият ахшамы, яки литературно-музыкальный вечер» исемле мәкаләсенә карата әдәби тәнкыйть мәкаләсе урнаштырган, авторы күрсәтелмәгән. «Гәзитәләрдән» дигән мәкаләдә «Фикер» гәзитәсендә (номер 39) яздыкына күрә, Уральскида яшь мөселман зыялылар әдәбият ахшамы (литературно-музыкальный вечер) ясамак булалар икән. Бу хосуста Тукаев әфәнде, озын бер мәкалә

язып, әдәбият ахшамының нә улдыгын вә аның кирәклегени һәр кешенең башына сыймаслык рәвештә бәян итә. Фәкать һәрнәрсәдән курыккан вә һәрнәрсәдән өреккән безнең мөселман халкына буйлә тәгърифләр яхшы тәэсир итә алырмы икән?.»

...Ләкин мәкаләнең ахырында: «Яшәсен әдәбият ахшамы!» — дип кычкыра. Иншаллаһ, яшәр!» — диелгән.

*«Вакыт», 95 нче сан.*

**5 ноябрь.** «Кемне сайларга кирәк?» — баш мәкалә урынында имзасыз басылган.

Мәкаләдә Икенче Дәүләт думасына сайлаулар турында сүз бара.

«Аю һәм Ссыльный» исемле хикәясе «Мөтәрҗим Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Кемнән тәрҗемә икәне билгесез.

*«Фикер», 41 нче сан.*

**12 ноябрь.** «Габдулла карый» исемле мәкаләсе «Уральск хәбәрләре» бүлегендә имзасыз басылган.

Мәкалә татарның танылган артисты, режиссеры, профессиональ татар театрына нигез салучы Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйруллин) турында.

*«Фикер», 42 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 364 б.*

**15 ноябрь.** «Сөеклемнең кабер ташында», «Үз-үземә» шигырьләре. Соңгысының исеме астына «Пушкинның бер шигырьчегеннән мөкътәбәс» дип куелган.

Тукай «Әсәрләре»нең биш томлы җыелмасын төзүче Р.Гайнанов аны А.С.Пушкинның «Про себя» шигыреннән файдаланып язылган дип күрсәтә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 349 б.*

Һәм мәнзум, һәм мәнсур «Кичке азан» шигыре: «Русларда вә башка мөтәмәддин милләтләрдә һәр сәтыры ике сүздән гыйбарәт, ләкин гаять мәгънәле шигырьләр бардыр. Мин монда, нәмунә өчен Лермонтовның бер шигырен алып, шул ук мотивка «Кичке азан» сәрләүхәсе или гаҗизанә бер шигырь яздым»,— дигән автор искәрмәсе белән басылган. Һәм журналда М.Ю.Лермонтовның «Звезда» исемле шигыре китерелгән.

---

Буйлә тәгърифләр — мондый аңлатулар.
Мәнзум һәм мәнсур — тезмә һәм әсәр.
Мөтәмәддин — алга киткән.
Сәтыр — юл.
Нәмунә — үрнәк.

«Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» тәрҗемә мәкаләсенең дәвамы бирелгән. «Дәвамы бар» дип куелган.

*«Әлгасрелҗәдит», 11 нче сан.*

**19 ноябрь.** «Кызыкка очрау» фельетоны «Тиктормас» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренмәде. «Ләтыйфа» исемле памфлеты имзасыз чыккан. «Мактанышу» («Бакырган»нан) шигыре «Вак-төяк» дигән гомуми баш астында имзасыз басылган. «Ахыры бар» дип куелган.

Тукай «Вак-төяк» дигән гомуми баш астында һәм «Мактанышу» дигән темага «Бакырган китабы»на назирә-охшату юлы белән бер серия сатирик шигырьләр язарга уйлаган булса кирәк. Моннан соңгы «Дөнья көенә» шигыренең дә шул ук баш астында чыгуы, «мактанышу» сүзенең яңадан кабатлануы, шул ук ишан диалогы һәм «Дөнья көенә» шигыре астына да «Ахыры бар» дип куелган булуы шуны раслый. Ләкин Тукай бу серияне дәвам иттерә алмаган.

*«Фикер», 43 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 350—351 б.*

**26 ноябрь.** «Фикер»дә «Тәрҗеман»ның татарларга галякасе» мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән урнаштырылган. Мәкаләдә Г.Тукай И.Гаспринский наширлегендә һәм мөхәррирлегендә чыккан «Тәрҗеман» (1883—1918) газетасына тискәре бәя бирә: «Минем уемча, «Тәрҗеман»ның без татарларга галякасе (бәйләнүе) бөтенләй юктыр. Чөнки, әүвәлән, аның теле безнең телемезгә бөтенләй кире бер Кырым теледер. Икенче, ул хәзерге хөррият диңгезе ташыган вакытта да һаман черносотенный мәсләк тотып, һәммә бюрократларның, хәтта ишаннар вә муллаларның хәерхаһыдыр»,— ди. Ләкин «Тәрҗеман» газетасын укып, татар зыялылары ул вакытта күп мәгълүмат алганнар.

«Лично почетный, потомственный» мәкаләсе «Уральск хәбәрләре» бүлегендә имзасыз басылган.

Шунда ук игълан-реклама бирелгән. «Әстерханда ушбу көннәрдә генә әдәбият ахшамы булып, Г.Тукайның «Мөридләр каберстаныңдин бер аваз», «Сорыкортларга» дигән шигырьләрен музыка белән җырлаганнар. Әдәбият ахшамы әһали өчен дә, яшь интеллигентлар өчен дә маддәтән вә мәгънән файдалы булган, әдәбият ахшамын күреп, күзләре нурланган.

---

Ләтыйфа — мәзәк.
Галяка — бәйләнеш.
Хәерхаһ — теләктәш.
Әһали — халык.
Маддәтән вә мәгънән — матди һәм мәгънәви.

һәм мәнзум, һәм мәнсур «Кичке азан» исемле шигыре кабат урнаштырылган.

*«Фикер», 44 нче сан.*

**Ноябрь.** «Уклар» журналы туктала. Бу соңгы 6 нчы санда түбәндәге памфлетлары басылган: «Чүкеч»тән, «Ике пьянчук», «Җен илә убыр», «Фатыйма илә Хәтимә», «Гаҗәп түгелме?», «Мосаләхә», «Телеграммнар», «Казанда никях мәҗлесе», «Шартлар» памфлетлары, «Уклар» шигыре — «Шүрәле» имзасы белән, «Сәдәхә» — «Уклар»ның лөгать мөтәфтише» имзасы белән, «Шәкерт илә мажик» — «Тәртә башы» имзасы белән («Фемида»), «Кайчан бетәр икән?» парчасы имзасыз чыккан.

*«Уклар», 6 нчы сан.*

**3 декабрь.** «Янә «Тәрҗеман»га мәкаләсе «Ш» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренмәде. Мәкаләдә шулай ук «Тәрҗеман» газетасы тәнкыйтьләнә.

«Уральск хәбәрләре» (2) мәкаләсенең бер өлеше «Ш», соңгы өлеше «Партия» имзасы белән басылган.

«Дөнья көенә» шигыре «Вак-төяк» дигән гомуми баш астында имзасыз чыккан.

*«Фикер», 45 нче сан.*

**5 декабрь.** «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә» шигыре «Ахыры бар» дигән искәрмә белән басылган, ләкин ахыры күренми.

«Әлгасрелҗәдит»ә маддәтән вә мәгънән иштиракъ идәнләрең лисане хале нә диер?»* шигыре басылган. Әсәр «Әлгасрелҗәдит»нең чыга башлавына бер ел тулуга багышланган.

*«Әлгасрелҗәдит», 12 нче сан.*

**9 декабрь.** «Вакыт»та Морад (Р.Фәхретдинов) «Ике әсәрләр» исемле рецензиясендә (рецензия Г.Тукайның «Әлгасрелҗәдит»нең 1906 елгы саннарында чыккан әсәрләре, М.Гафуриның «Яшь гомерем» шигырьләр җыентыгы турында) Г.Тукайны гарәп шагыйре Мәгарригә тиңли.

«Төрки журналлар» исемле имзасыз чыккан мәкаләдә «Әлгасрелҗәдит» журналының 1906 елгы 11 нче санына күзәтү ясала. Күзәтүдә Г.Тукайның әлеге санда басылган «Кичке азан», «Үз-үземә», «Сөеклемнең кабер ташында» исемле шигырьләре-

---

* «Әлгасрелҗәдит»кә матди һәм мәгънәви катнашкан кешеләрнең хәл телләре (күңеле) нәрсә әйтә?

Мосаләхә — килешү.

Лөгать мөтәфтише — сүзләрне тикшерүче, тел белгече.

нә, «Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» исемле мәкаләсенә югары бәя бирелә, журналны бизәүче әсәрләр итеп күрсәтелә. Үрнәк өчен «Сөеклемнең кабер ташында» шигыре тулысынча китерелгән.

*«Вакыт», 108 нче сан.*

**10 декабрь.** «Мөселманнарны ни өчен особый группага бүләләр?» исемле мәкаләсе басылган. Мәкаләдә Дәүләт думасына мөселманнардан выборщиклар сайлау турында сүз бара.

«Мөһим эш — имамнар җәмгыяте» мәкаләсе чыга. Мәкалә Пенза губернасы Чембар өязе Мучали волосте муллаларының мөфти Мөхәммәдъяр Солтановтан муллаларга дәүләттән хезмәт хакы билгеләтүне таләп итеп язган гаризалары турында.

Тукай «Фикер»дә муллаларның бу таләпләрен хуплый.

«Чөнки сез, жалуньегыз булмаганга күрә, милләтемезне төрле хәйләләр илә алдап, тәмам изденез...

...Үзенезне вә сезгә ияргән мәхәллә халкыны төзәтмәкнең чарасы үз кулыңыздадыр»,— ди. Шушы фикерен кабатлап, «Интернационал»дан бер куплет китерә.

Мәкаләләр имзасыз чыккан.

*«Фикер», 46 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 370 б.*

**13 декабрь.** «Уральскида сайлаулар» — баш мәкалә урында имзасыз басылган.

Мәкаләдә Дәүләт думасына выборщиклар сайлау турында сүз бара.

*«Фикер», 47 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 3 т., 260 б.*

**17 декабрь.** «Җәмгыяте хәйрия» исемле мәкаләсе «Төрек» гәзитәсеннән татарлар хәленә борыбрак, «Мөтәрҗим Г.Тукаев» дигән аңлатма белән басылган, кемнән һәм кайсы мәкаләдән тәрҗемә икәне билгеле түгел. «Ахыры бар» дип куелган. Мәкалә Уральск шәһәрендә «Җәмгыяте хәйрия» оешмасының төзелүе турында. Тукай бу оешманың төзелүен уңай яктан бәяли.

«Театрунын файдасын халыкка ничек төшендерәмез һәм хәзрәтләрдән ничек дөрестләтәмез» исемле мәкаләсе чыккан. Тукай мәкаләдә татар театрын мәйданга чыгару юллары турында уйлана.

*«Фикер», 48 нче сан.*

**24 декабрь.** Педагог, шагыйрь, публицист Насретдин әл-Хуҗашиның «Әлгасрелҗәдит» журналы хакында» исемле мә-

каләсе басылган. Мәкаләдә ул, Г.Тукайның әлеге журналда урын алган иҗатына югары бәя биреп, болай ди: «Г.Тукаев җәнабләренең әшгаре миллиясе бу журналга аеруча зиннәтләри вирде. Бу журналда иң зийадә бәнем һушыма килән Тукаевның әшгаре миллиясеدер ки, гаять ләзиз һиссияте миллияләр уйгатты. Бу әшгардән дә иң зийадә хушыма киләне «Мөридләр каберстаныندин бер аваз» сәрләүхәсе илә язылган шигырьләр иде ки, бу әшгарнең эченә алдыгы мәгънәләри, хакыйкатьләри шигырь илә мәйданә куйган ялгыз Тукаев улдыгы кеби, иң дәртле, иң монтазам, иң гүзәл шигырьләр дәхи Тукаевның агызыннан сөйләнде».

*«Фикер», 49 нчы сан.*

**31 декабрь.** «Җәмгыяте хәйрия» исемле мәкаләсенең ахыргы өлеше басылган.

«Һәркимиң кәндинчә вардыр ля мөхаль эндишәси»* исемле мәкаләсе «Бер фикерче» имзасы белән чыккан. Бу соңгы мәкаләдә мәгърифәт һәм социализмның үзара мөнәсәбәте турында сүз бара. Тукай болай ди: «Халыкның, укый торгач, үткенләнә торгач, шул социализм фикеренә барып төшмичә хәлләре юктыр. Социализм кеби бер мөкатдәс мәзһәбкә кергәндә, матурланып, кеше булып, галим вә мәгърифәтле булып керик. Без надан көенчә социалист булып мәйданга чыксак, койрыгына тутый кош җоннары кыстырган ала карга төсле, бөтен дөньяны көлдерербез».

*«Фикер», 50 нче сан.*

**Декабрь.** Г.Тукай, «Мотыйгыя» мәдрәсәсеннән чыгып, яңарак кына ачылган «Казан» миһманханәсенә күчеп килә, монда ул аена унбиш сум түләп, татарның атаклы артисты һәм режиссеры Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйруллин) белән бергә 7 нче номерлы бүлмәдә 1907 елның октябренә кадәр яши, шагыйрь Казанга шушы миһманханәдән күчеп китә.

*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 175-эш.*

**Ел дәвамында.** Тукай «Мулла Насретдин» журналын тотып, ялгыз фотога төшкән. Фотога «Тукай «Уралец» типографиясендә эшләгәндә» дигән аңлатма бирелгән.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 96 б.*

---

* «Һәркемнең, һичшиксез, үзенчә фикере, төшенчәсе бардыр».
Әшгаре миллиясе — милли шигырьләре.
Зийадә — артык.
Ләзиз — ләззәтле.
Сәрләүхәсе — исеме.
Монтазам — тәртипкә салынган.
Мәзһәб — дөньяга караштa тоткан юл.

Тукай, Уральскида яшәгәндә, азәрбайҗан сатирик журналы «Мулла Насретдин» белән таныша, шуннан соң аны даими укып бара. «Мулла Насретдин»ны тотып фотога төшүе дә (1906 елда Уральскида ялгызы төшкән фотосы) шул турыда сөйли.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 96 б.*

Азәрбайҗан газетасы «Хәят»та Г.Тукайның «Японияне мөселман идәчәк голяма нәрсәдә?» дигән шигыре басылган. «Как самобытный и талантливый художник слова Г.Тукай быстро завоевал признание в Азербайджане, стал самым современным поэтом современности, как и Сабир...» — ди В.М.Кулиев.

*Кулиев В. Г.Тукай и азербайджано-татарские литературные взаимосвязи начала XX века. «Поэт свободы и правды», 1990, с.57.*

**Ел ахырында.** Тукай Уральскида танышлары белән фоторәсемгә төшкән. Фоторәсемдә: Нәҗип Нигъмәтуллин («Казан» миһманханәсе буфетчысы), Рәхмәтулла Хәйруллин (М.Гобәйдуллинның приказчигы), Сираҗи шәкерт.

Фоторәсемнең төп нөсхәсе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кулъязмалар бүлегендә саклана.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 18-эш.*

## 1907

**6 гыйнвар.** Тукай, үзенең адресын күрсәтеп, газетада игълан урнаштыра:

«Мин бу көннәрдә генә «Мәдрәсәи Мотыйгыя»дән чыктым. Бинаән галәйһи, дустларым вә якыннарыма игълан итәмен ки, бу көннән ары миңа язачак мәктүбләренең адресын болай язсыннар: Уральск. Гостиница «Казань». А.Тукаеву.

Бакый ихтирам белән Г.Тукаев.

Шушы вакыттан башлап Г.Тукайның рәсми белем йортына кереп укуы тәмамлана, ул шагыйрьлек, публицист-журналистлык юлыннан китә.

«Төш күрдем!» мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән басылган.

«Казан миһманханәсендә мәҗлес» исемле мәкаләсе имзасыз чыккан.

Һәр ике мәкаләдә Уральскида «Казан» миһманханәсендә «Җәмгыяте хәйрия» мәҗлесе турында сүз бара.

*«Фикер», 1 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 291, 341 б.*

---

Бинаән галәйһи — шуңа күрә.

**12 гыйнвар.** «Ахырзаман галәмәте» исемле шигыре «Мөәррих» имзасы белән чыккан. Шигырь «Бакырган» китабындагы (XII йөз) «Килең, дустлар, бу дөнья кичде — ахыр булдыя» дип башланган шигырь калыбына салынган.

*«Фикер», 2 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 394 б.*

**21 гыйнвар.** «Кечкенә генә С.-Петербург гәзитәсеннән» дигән мәкаләсе имзасыз чыккан. Мәкалә Петербургта 1728—1917 елларда чыккан «С.-Петербургские ведомости» (Халык мәгарифе министрлыгы органы) газетасыннан алып тәрҗемә ителгән. Анда Дәүләт думасына сайлаулар турында сүз бара.

**25 гыйнвар.** «Чыккан шәкертләр ни диләр?», «Сөальләр» шигырьләре басылган.

Шагыйрь Кәшшаф Патии «Әлгасрелҗәдит» журналына» дигән шигырендә, Тукай талантына югары бәя биреп, болай ди:

Дәхи анда каләм тарткан Тукаевтыр,
Ул тарафта аның кеби шагыйрь юктыр,
Язылган шигырьләрен үлчәр исәк,
Һәр шигыре уйланырлык дәкыйктыр.

*«Әлгасрелҗәдит», 1 нче сан.*

**27 гыйнвар.** «Чыккан шәкертләр ни диләр?» шигыре (шигырь Г.Тукайның «4 нче дәфтәр» (1908) исемле җыентыгында «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» исеме белән урнаштырылган.), «Тәшәккер» исемле мәкаләсе басылган. Мәкалә «17 октябрь партиясе»нә каршы язылган. Икенче Дәүләт думасына сайлауларда халыкның алар артыннан китмәвенә рәхмәт белдерелә.

*«Фикер», 4 нче сан.*

**4 февраль.** «Уральск хәбәрләре» исемле мәкаләсе имзасыз чыккан. Мәкаләдә Хәсәнҗан Хөсәенов дигән кешенең «Бәянелхак фи хаккыл хиҗаб» («Хатын-кызны качыру турында дөрес сүз») исемле китабы тәнкыйтьләнә.

*«Фикер», 5 нче сан;*
*Биш томлы әсәрләр, 4 т., 293 б.*

Г.Тукайның «Мактанышу» исемле шигыре басылып чыккач («Фикер», 1906, 19 ноябрь), «Тылмач» имзасы белән «Татар теле» исемле мәкалә басыла. Мәкаләдә автор «Мактанышу»

---

Мөәррих — тарихчы.
Дәкыйк — төгәл, анык.
Тәшәккер — рәхмәт.

шигыре татар телендә язылган булуын хуплап, аны И.Гаспринский чыгарган «Тәрҗеман» газетасы теленә каршы куя. Гаспринский яклаган төрек теле фәкать өстен катлауларга гына аңлашыла, Тукай яклаган тел хезмәт ияләренең сыйнфый, иҗтимагый аңын ачуга ярдәм итә, дигән фикер әйтә. «Мактанышу» шигыренә уңай бәя бирә.

*«Фикер», 5 нче сан.*

**8 февраль тирәсе.** Хезмәт хакын арттыруны сорап матбага эшчеләрен эш ташларга котырта, дип, К.Мотыйгый Тукайны эшеннән чыгара. «Матбагам ябылмастан борын, ике атна әүвәл бөтенләй хезмәттән чыгарырга туры килде»,— ди К.Мотыйгый «Мәшһүр шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев хакында хатирәләрем»ендә.

*«Истәлекләр», 36 б.*

К.Мотыйгый аны эштән чыгардым дисә дә, Г.Тукай «Фикер» һәм «Әлгасрелҗәдит»тә бу матбугат органнары ябылып беткәнче эшли. Башта хәреф җыючы, аннан корректор, соңыннан бөтен эшләрне үзе башкара. Аның Уральск чоры иҗаты нигезендә «Фикер» газетасында, «Әлгасрелҗәдит» һәм «Уклар» журналында тупланган.

**11 февраль.** «Яңа әсәрләр» дигән рецензиясе имзасыз басылган. Рецензиядә «Чапан илә пальто гаугасы», «Карт хәлфә», «Әхмәт агай вә гаиләсе» исемле авторлары күрсәтелмәгән китапларга уңай бәя бирелгән.

«Мөселманнар хәмер эчмиләр» исемле мәкаләсе имзасыз чыккан. Мәкалә «Товарищ» газетасында (газета 1906—1908 елларда Петербургта чыга) басылган. «Мөселманнарның мәктәп, мәсҗед вә мәдрәсәләренә хәзинәдән ярдәм бирелмәскә тиеш, аның өчен мөселман халкы аслан аракы эчмиләр. Алар бу эшләре берлән һәр сәнә казнага 70 миллион зарар китерәләр. Әгәр мөселманнар үзләренең мәктәп вә мәдрәсәләренә пособие, муллаларына жалованье бирелүен теләсәләр, йә аракы эчсеннәр яки христиан динен кабул итсеннәр, чөнки христиан диненә чыккач, алар аракыны да эчәчәкләрдер»,— дигән фикерләренә каршы язылган.

Мәкаләләр «Тукайныкы булуы ихтимал» бүлегенә кертелгәннәр.

*«Фикер», 6 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 341—342 б.*

**15 февраль.** «Шагыйрьгә» (Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләренең бер нәсихәте) шигыре басыла. Шигырь М.Ю.Лермонтовның «Г-ну Павлову» исемле эпиграммасыннан файдаланып язылган.

«Хөррияттә» («Мөхәммәдия»дән) шигыре чыккан. Шунда ук И.А.Крыловтан иркле тәрҗемә мәсәлләре урнаштырылган: «Арыслан илә Тычкан» («Лев и Мышь»), «Этләрнең дуст булышуы» («Собачья дружба»), «Тычкан илә Күсе» («Мышь и Крыса»), «Умарта корты вә чебеннәр» («Пчела и мухи»), «Мактанчык куян» («Заяц на ловле»), «Бер гөл» («Василек»), «Күке» («Кукушка и Орел»), «Бүре этләр оясында» («Волк на псарне»), «Плитва» («Бритва»), «Кыр кәҗәләре» («Дикие козы»), «Арыслан илә Төлке» («Лев и лисица»), «Бала козгын» («Вороненок»), «Җумарт дуст» («Волк и Лисица»), «Җылан» («Змея»), «Аш пешерүче» ( «Кот и повар»), «Әтәч илә Күке» («Кукушка и Петух»), «Ташбака һәм Куян», «Җил илә кояш», «Тимерче вә эте», «Локман хәким сүзләре», «Каз». «Ахыры бар» дип куелган. Журнал чыгудан туктаганлыктан, ахыры басылмаган.

Ахырда Тукай үзе: «Бу рисаләнең хәзерге заманымыз өчен ул кадәр әһәмиятле булмаса да, яшь вакытта тәртип итдекем өчен ядкяр калсын» дип мәйдан интишарә куйдым»,— дигән искәрмә биргән.

*«Әлгасрелҗәдит», 2 нче сан.*

**18 февраль.** «Уральскида Думага сайлаулар» исемле мәкаләсе «Һәйьят идарә» имзасы белән баш мәкалә урынында басылган.

Мәкаләдә карагруһ таифәсенең К.Мотыйгыйны Дәүләт думасына сайлауларда выборщиклар исемлегеннән төшереп калдыруга ирешүләре турында сүз бара. Автор үзенең сөйләме эченә «Марсельеза»дан:

Торгыл, күтәрел, эшче кешеләр,
Каршы тор дошманга, ач кешеләр!
Яңгыра дөньяга, үч авазы!
Алга, алга, алга!.. —

дигән өзекне кертеп җибәргән.

*«Фикер», 7 нче сан.*

Шушы санда «Уральск яңалыклары» бүлегендә басылган хәбәрне дә Р.Нәфыйгов стиле, сүзләренең сайланышыннан чыгып, Тукайныкы булуын исбат итә. Мәкаләдә 14—15 февральләрдә өч депутатны Дәүләт думасына озату турында сүз бара.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение,1986,с.101.*

**22 февраль.** «Хәсәнҗан бине Әхмәтҗан әл-Хөсәенинең хиҗаб хакында улан мәзһәбе» исемле рецензиясе «Ул» имзасы белән басылган.

---

Интишарә куйдым — чыгарып куйдым.

Рецензия шушы кешенең «Бәянелхак фи хаккыл хиҗаб» («Хатын-кызны качыру хакында дөрес сүз», Оренбург, 1907) исемле китабында тулып яткан каршылыклы фикерләрне ача.

«Кешегә казыган чокырга үзе төшү» исемле мәкаләсе имзасыз басылган. Мәкалә Уральскида Хәйрулла Гаделшин дигән кешенең бер мәҗлестә җәнҗал чыгаруы турында. Мәкаләнең ахырына автор:

Какма кеше капкасын,
Үз капкаңны кагарлар,
Кешеләрне хурлап торсаң,
Төрмәгә дә ябарлар,—

дигән шигъри юллар урнаштырган.

*«Фикер», 8 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 342 б.*

**22 февраль.** «Кайгыру» исемле шигыре «Болгар» имзасы белән басылган. «Г.Тукайның «Государственная думага» әсәре дөнья күргәннән соң («Фикер», 1906, 22 октябрь) төгәл дүрт айдан соң басылып чыккан бу шигырь алдагысына формасы, аерым сүзләре һәм гыйбарәләре белән генә түгел, бәлки, бөтен рухы, мәгънәсе белән бик якын тора. «Государственная думага» патша Дәүләт думасына караштa беренче этап, «Кайгыру»ны икенче этап дип карарга мөмкин. Беренче этапта Думага пассив кына булса да, ышаныч бар, икенче этапта исә ышаныч сулларга гына»,— ди Р.Гайнанов.

*«Фикер», 8 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 394—395 б.*

**1 март**. «Өлфәт» газетасы редакциясе Г.Тукайның «Әлгасрелҗәдит» журналының 15 февраль (№ 2) санында басылган «Хөрриятә» шигырен алып, түбәндәге искәрмә белән бастырып чыгара: «Бу көнне «Фикер», «Әлгасрелҗәдит», «Уклар» хөкүмәт әмирләре тарафыннан туктатылдылар, дигән телеграмма алдык. Бу күңелсез бер вакыйгадыр. «Әлгасрелҗәдит»нең 15 февраль санын (№ 2) алдык. Бәлки, бу журналның соңгы номерыдыр. «Әлгасрелҗәдит»нең һичбер нөсхәсе юк иде ки, яңа шагыйремез Г.Тукаев җәнабләренең гүзәл шигырьләре илә зиннәтләнмеш улмасын... Без, ядкяр улсын өчен, Г.Тукаев җәнабләренең бу соң номерында (15 февраль) дәрҗ ителмеш «Хөрриятә» гонванлы шигырен бу йирдә нәкыш идиерез».

Чынлыкта исә «Уклар»дан кала, «Әлгасрелҗәдит», «Фикер» моннан соң да чыгуларында дәвам итәләр әле.

*«Өлфәт», 62 нче сан.*

---

Гонванлы — исемле.
Нәкыш идиерез — бастырабыз.

**8 март.** «Кабергә киткән «Фикер» яңадан терелеп кайтты» мәкаләсе имзасыз басылган.

«Шәһре Уральск, 22 февраль, 1907 сәнә» дип куелган белдерүендә К.Мотыйгый болай дип яза: «Шәһәремездәге администрациянең хөкеме буенча бәндин нашир вә мөхәррирлек хокуклары бу көн алынды. Бундин соңра якында икенче кеше тәхте идарәсенә күчәчәктер. Һәфтәлек «Фикер» гәзитәсе, «Әлгасрелҗәдит» вә «Уклар» журналлары һәм дә көндәлек «Уральский дневник» гәзитәләре әүвәлгечә дәвам итәчәктер: фәкать икенче кеше исеменә күчерелгәнче, бик күп булса, бер-ике атна гына узар».

Нашир вә мөхәррир Камил Мотыйгый Төхфәтуллин.

*«Фикер», 9 нчы сан.*

Шушы белдерү нәтиҗәсендә «Вакыт» газетасы 1907 елның 24 февраль санында (№139) Уральскида «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдит» һәм «Уклар» журналларының тукталулары турында хәбәр бирә.

Г.Тукайның әлеге мәкаләсе «Вакыт» хәбәре уңае белән язылган. Мәкаләдә К.Мотыйгый белдерүеннән чыгып, бу матбугат басмаларының дәвам иттереләчәкләре турында әйтелә.

*«Фикер», 9 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 293 б.*

**11 март.** Уральскида, «Казан» миһманханәсе залында әдәби-музыкаль кичә үткәрелә. Тукай, Хәкимҗан Йосыфов исемле бер егетне хәерче киеменә киендереп, үзе шул егетнең өстенә карап, «Теләнче» шигырен укый. Бу шигырьне укыганда, көлмичә, нәсер шикелле итеп, җөмләләрен аерып, калын тавыш белән әйтә. Соңыннан «Төрек маршы» дигән җырны җырлый.

*«Фикер», 18 март;*
*«Вакыт», 31 март;*
*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 59 б.*

**11 март.** «Тартар кошы сайрый» (яки «Татарский марш») шигыре чыга.

*«Фикер», 10 нчы сан.*

**15 март.** «Син булмасаң», «Теләнче» шигырьләре чыга.
«Идарәдән» исемле мәкаләсе басыла. Мәкаләдә мондый юллар бар: «Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин җәнабләренең кулыннан администрация тарафыннан мөхәррирлек вә наширлек хокуклары алынгач, табигый, «Әлгасрелҗәдит» мәҗәлләсе-

нең мөхибләре кайгырдылар... Шуңгар күрә без бәян итәбез ки, «Әлгасрелҗәдит»нең мөхибләре вә дустлары күңелләрен хуш тотсыннар. Вә дошманнары да куанмасыннар: без «Әлгасрелҗәдит»нең ушбу 3 нче нумирыны мәйданга куйдыкымыз кеби, аны һаман да дәвам иттерәчәкбез».

1907 елның 22 феврапеннән, К.Мотыйгый наширлек һәм мөхәррирлек хокукыннан читләштерелгәннән соң, ул матбагасын сәүдәгәр Мортаза Гобәйдуллинга сата. М.Гобәйдуллин матбаганың эшен дәвам иттерергә үз өстенә алса да, вәгъдәсен үтәми. 1907 елның 25 маеннан (№ 5) «Әлгасрелҗәдит» тукталa. Тукайның әлеге мәкаләсе М.Гобәйдуллинның вәгъдәсенә ышанган вакытта язылган.

**Март, апрель.** «Ай, бат!» (Кавказ тормышыннан!) исемле тәрҗемә хикәясенең беренче өлеше басылган. «Ахыры бар» дип куелган.

Тукай үзенең искәрмәсендә әрмәнчәдән русчага тәрҗемә ителгән бу хикәяне «Мир божий» журналыннан алып тәрҗемә итүе турында әйтә. Һәм болай ди: «Бу вакыйга «Мир божий» журналындагы ана Жавинар, угыллары Сипо вә Сироп, вә кыз Соналарның башына күп вакыт килдеки кеби, ничәничә Фатыйма, Фоад, Шәүкәт, Бакирәләрнең дә башыннан үткән эштер. Хәзерге заманнарда Кавказда мондый вакыйгалар алмаш-тилмәштер».

*«Әлгасрелҗәдит», 3 нче, 4 нче саннар.*

**2 апрель.** «Күрдегезме?» исемле шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган.

1906—1918 елларда Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» журналы хатын-кыз азатлыгына каршы чыгып, аларның ирләрдән качуларын таләп итеп, мәкаләләр бастыра. Шигырь шуңа каршы юнәлдерелгән.

*«Фикер», 13 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 356 б.*

**15 апрель.** «Әлгасрелҗәдит»тә «Бишектәге бала» шигыре басылып чыккан. Шигырь М.Ю.Лермонтовның «Дитя в люльке («Из Шиллера») шигыреннән файдаланып язылган.

Шунда ук «Мөтәшагыйрьгә», «Шиллердән» исемле әсәрләре урнаштырылган. «Яз!» (Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз, яз!) шигыренә «Ахыры бар» дип куелган булса да, ахыры күренми.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 357 б.*

---

Мәҗәлләсенең мөхибләре — журналны сөючеләр.

«Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» исемле мәкаләсенең дәвамы басылган.

«Тәкрар әйтәмез». Бу кечкенә генә язма Мисырда чыккан «Төрек» газетасыннан алып урнаштырылган «Мәгариф-хәяттыр» дигән мәкалә астына редакция исеменнән аңлатма рәвешендә бирелгән.

«Ай, бат!» исемле хикәясенең ахыры урнаштырылган.

*«Әлгасрелҗәдит», 4 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 295 б.*

**22 апрель.** «Шигырьләремез» исемле мәкаләсе басыла. Биредә татар шигырендәге кимчелекләр турында сүз бара.

*«Фикер», 15 нче сан.*

**Апрель.** «Тәрбиятел-этфаль»гә» исемле шигырен яза.

«Тәрбиятел-этфаль» — Мәскәүдә 1907 елның 1 январеннан алып март аена кадәр барысы биш сан чыккан беренче татарча балалар журналы. Шигырь әлеге журналның тукталуы уңае белән борчылып язылган, аның безгә билгеле булган соңгы саны март ае белән тәмамлана. Ләкин журналның март аенда әле тукталуы билгеле булмаска мөмкин. (Журналның җаваплы секретаре Ф.Әмирхан 1907 елның 8 апрелендә Р.Алушига язган хатында (5 нче саннан соңгы номерлары турында сүз бара): «Соңгы номерларда бәгъзе мәкаләләремне имза белән язмакчы булам»,— ди.

Шуннан чыгып караганда, бу шигырь апрель аенда язылган булырга тиеш.

Шигырь беренче мәртәбә «Габдулла Тукаев шигырьләре»ндә («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. Беренче кыйсем, Казан, Шәрәфләр матбагасы, 1907) басылган.

**4 май.** «Ана мәктүбләре» исемле педагогик язмасы басыла башлый. «Дәвамы бар» дип куелган.

Г.Тукайның биш томлы «Әсәрләр»ен төзеп чыгаручы Р.Гайнанов аны Л.Н.Толстойның «Педагогик хатлар»ын хәтерләтә дигән фикер әйтә.

*«Фикер», 16 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 296 б.*

**6 май.** «Ана мәктүбләре»нең дәвамы басыла. «Ахыры киләсе санда» диелгән.

«Пар ат» шигыре чыга. Шигырь Г.Тукайның Казанга килү хыялларын чагылдыра һәм «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә (Казан, 1914) «Лермонтовның «Тройка» шигырен уку тәэсиреннән» дигән искәрмә белән басылган.

«Фикер» хәбәре: якын көннәрдә безнең типографиядә Г.Тукайның шигырь җыентыгы басылып чыгачак. Бу җыентык басылып чыкмаган булса кирәк.

«Партияләр» әсәре баш мәкалә рәвешендә имзасыз чыга.

*«Фикер», 17 нче сан.*

**13 май.** Уральскида Г.Тукайның актив катнашлыгында 1905 елның 26 ноябреннән чыгып килгән «Фикер» газетасының соңгы саны дөнья күрә.

Соңгы санда Тукайның «Ана мәктүбләре», «Думаның хәле», «4 нче май — җомга» исемле мәкаләләре урнаштырылган.

*«Фикер», 18 нче сан.*

**14 май.** «Тавыш хакында» шигыре басыла. Казанда «Тавыш» газетасы чыга башлау уңае белән язылган. Бу газетаның гомере кыска була. Беренче саны 1907 елның 23 апрелендә чыкса, май азагында инде ул яшәүдән туктый.

*«Тавыш», 4 нче сан.*

**16 май.** «Фикер»нең 1907 елгы 22 апрель санында басылган «Шигырьләремез» дигән мәкаләсе уңае белән «Йолдыз» газетасы, аңа үз мөнәсәбәтен белдереп, түбәндәгеләрне яза:

«Фикер» гәзитәсендә мәшһүр шагыйрьләремездән Габдулла Тукаев әфәнде милли шигырьләремездәге косурлар хакында язган мәкаләсе шаян моталәгадер. Әфәнде мәкаләсенең ахырында диер: «Ник соң безнең татарлар дөньяда шулкадәр гасырлар гомер итеп, бер җүнлерәк шигырь яза алмаганнар? Әллә шифаһән сөйләүчеләр булып та, язып алучылар булмыйча, ул шигырьләр шагыйрьләре берлә бергә кабергә күмелдеме?»

*«Йолдыз», 120 нче сан.*

**25 май.** «Әлгасрелҗәдит» журналы чыгудан туктый. Бу соңгы санда Г.Тукайның «Пар ат», «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» Г.Исхакыйга багышланган «Кем ул?» шигырьләре, «Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» дигән тәрҗемә мәкаләсенең дәвамы басылган. Мәкаләгә «Ахыры бар» дип куелса да, журналның чыгудан туктавы сәбәпле, ахыры басылмый калган.

*«Әлгасрелҗәдит», 5 нче сан.*

**25 май.** «Казан мөхбире» газетасы игъланы: «Шагыйрьләремез дикъкатенә. «Тәрәкъкый пәрвәрләремездән Мөхәммәт-

---

Косур — җитешсезлек.
Шаян моталәга — игътибар белән карауга лаек.
Шифаһән — телдән.

гали әфәнде Газизов җәнабләре Н.Думави, Г.Тукаев, М.Гафури, З.Һади шигырьләрене аерым рисалә итеп нәшер кылырга теләге барлыгын хәбәр итте. Мәзкүр әфәнделәр төрле вакытларда гәзитәләрдә басылмыш шигырьләрене түбәндәге адрес илә җибәрсеннәр: Петровск, Сыр-Дарьинская обл., М. Гали Газизову».

Бу план тормышка ашмаган булса кирәк. Г.Тукайның күрсәтелгән адрес буенча чыккан җыентыгы очрамый.

*«Казан мөхбире», 235 нче сан.*

**Май.** Г.Тукай хат аркылы Казан матбагачысы Гыйльметдин Шәрәф белән таныша. Аңа хат яза. Хатында: «Сез могтәбәр татар шагыйрьләренең шигырьләрен нәшер итә башлагансыз икән. Мин дә үземнең берәр мәҗмугамның шулар арасында булуын телим»,— ди. Хатның төп нөсхәсе сакланмаган.

*Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар. «Истәлекләр», 106 б.*

**Май ахыры.** К.Мотыйгыйның матбагасын сатып алган сәүдәгәр Мортаза Гобәйдуллин «Фикер» газетасын, «Әлгасрелҗәдит» журналын чыгаруны дәвам иттерәчәге турында вәгъдә итсә дә, вәгъдәсен үтәми, матбаганы туктата. Тукай эшсез кала. Шушы вакыйга уңае белән «Матбага берлә уйнаган бер байга» шигырен М.Гобәйдуллинга багышлап яза.

*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 58 б.*

«Китмибез!» исемле шигырен яза. Дәүләт думасының 1907 ел май аенда булган унбишенче мәҗлесендә, мәсәлән, Уфа губернасыннан сайланып килгән депутат мөгаллим Кәлимулла Хәсәнов (1878—1949) мөселман мәктәпләренең хәле начарлыгыннан, хөкүмәтнең моңа бер чара да күрмәвеннән зарланып сөйли. Суллар кул чабалар, ә уңнар (Пуришкевич, Созонович һ.б. карагруһлар) урыннарыннан сикереп торып, йодрыкларын төйнәп, ораторга ташланалар һәм: «Төркиягә китеңез!» — дип кычкыралар. «Китмибез!» шул уңай белән иҗат ителгән һәм аның язылу вакыты да шушы вакыйга эзеннән, ягъни 1907 елның май ахырларында булырга тиеш».

*«4 нче дәфтәр», 1908, 16 б;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 365 б.*

**Җәй.** Г. Тукай Г.Кариевка 1902—1903 елларда «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә бергә укыган Истамбул шәкерте Габделвәлидән отып калган шигырьләрен сөйли.

*Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 55—56 б.*

**Җәй.** Әтисенең йортын сатудан Тукайга берникадәр мирас калган була. Гурьевтагы әтисе ягыннан туганнары сәүдәгәрләр Әхмәди һәм Әүхәди Абдуловлар шул акчаны (кайбер мәгълүматларга караганда 100 сум) Тукайга җибәрәләр. Тукай туган якларына солдатка каралырга һәм Казанга шушы акча белән кайткан булырга тиеш, дип фараз ителә.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 120 б.; Кариев Г. Габдулла Тукаевның Уральскидагы тормышы. «Истәлекләр», 60 б.*

**1 июнь.** «Дөньяда торыйммы?» — дип киңәшләшкән дустыма» шигыре чыккан.

*«Таң мәҗмугасы», 2 нче сан.*

**7 июнь.** Казандагы матбага хуҗалары Шәрәфләрдән Г.Тукайга хат килә. Алар Тукайның моңа кадәр «Фикер»дә, «Әлгасрелҗәдит»тә басылган шигырьләрен мәҗмуга рәвешендә бастырып чыгарырга рөхсәт сораганнар. Тукай риза була.

*Г.Тукайның 1907 елның 9 июлендә Гыйльметдин Шәрәфкә язган хаты; Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 78 б.*

**9 июнь.** Г.Тукай Уральскидан Казан матбагачысы Гыйльметдин Шәрәфкә хат яза: «Тарафыңызга, заказной бандероль уларак, «Әшгаре мәҗмуга»мны йибәрдем. Шигырьләрнең мөкаддәм-моаххир басылуын рәкымнәр илә яздым. Үзеңез аерырсыз. Зинһар, яхшылап тәсхих итеп басыңыз. Азсынсаңыз ушбу арада тагы бәгъзе тәхрират йибәрермен. Үзеңез дикъкатьләп карап чыгыңыз да нәшер итәргә разый булсаңыз, миңа тизлек берлә 50 тәңкә акча йибәреңез... Адресым: г.Уральск, гост. «Казань», А.Тукаеву».

Хатта җыентыкны бастырып сату хокукын Шәрәфләргә гомерлеккә бирүе турында әйтә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 78 б.*

**Җәй.** Тукай үзенең «Шигырьләр җыентыгы»н бастырып чыгару турында Уральскидан Казанга биш-алты хат җибәрә. Хатларның кайберләрен төрек, кайберләрен татар телендә яза.

«1907 сәнәнең әүвәлге яртысына кадәр Габдулла әфәнде шигырьләрен төрекчә язу белән татарча язу арасында йөреп,

---

Әшгаре мәҗмуга — шигырьләр җыентыгы.
Мөкаддәм-моаххир — нинди тәртиптә.
Рәкым — сан.
Тәсхих иту — карау, дөресләү.
Бәгъзе тәхрират — кайбер шигырьләр, язмалар.

бер катгый фикергә килмәгән. 1907 сәнәнең соңгы яртысының башларында ул үзенең «Шүрәле»се белән нәкъ татар теленә әйләнеп китә. Аннан соң язган шигырьләренең бөтенләен диярлек татарча яза»,— дип укыйбыз истәлекләрдән.

*Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар. «Истәлекләр», 107 б.*

**15 июнь.** «Нур» газетасы «Фикер»дән (1907 ел, 6 май) алып Тукайның «Пар ат» шигырен кереш сүз белән бастыра. Керештә «Пар ат» халык телендә язылган әдәбиятыбызны баетучы уңышлы шигырьгә мисал итеп китерелә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 359 б.*

**27 июнь.** Вафа Бәхтияров («Әл-ислах»ның мөхәррире) «Әл-ислах» газетасын чыгарырга Казан губернаторыннан рөхсәт ала. Уральскида чыккан «Фикер» газетасы, «Әлгасрелҗәдит» һәм «Уклар» журналлары аркылы танылган Г.Тукайга «Әл-ислах» газетасында катнашырга чакырып хат яза.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. «Истәлекләр», 76 б.*

**Июнь, 5 июльгә кадәр.** «Шүрәле» поэмасын, «Бездә истигъдад бар» шигырен яза. Шигыренең исемен Г.Тукай соңыннан «Безне урынсыз яманлыйлар» дип үзгәртә.

*Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар. «Истәлекләр», 106 б.*

**5 июль.** Г.Тукай Казан матбагачысы Г.Шәрәфкә Уральскидан хат җибәрә. «Тарафыгызга тагы да «Шүрәле» вә «Тәрбиятел-әтфаль»гә сәрләүхәле шигырьләремне күндердем. Шуларны «Китмибез» вә «Бездә истигъдад бар» шигырьләре белән бергә рисаләнең башына куярсыз. «Кечкенә генә бер көйле хикәя» (бу әсәр тиздән матбугатыбызда чыкса кирәк) сәрләүхәле шигырь басылмый калса да зарар итмәс зан итәм»,— ди шагыйрь.

Монда «Г.Тукаев шигырьләре»нә («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр, 1907) керәчәк шигырьләр турында сүз бара.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 79 б.*

**12 нче июльгә кадәр.** Дәрдмәнднең «Шагыйрьгә» шигыре Г.Тукайның «Мөтәшагыйрьгә» (1907 ел, 15 апрель) исемле шигыренә җавап рәвешендә язылган. Сәбәбе: «Мөтәшагыйрь-

---

Мөтәшагыйрь — шагыйрь булып маташучы.

гә» шигырендә «вакыт» сүзе ялгыш куштырнаклар эченә алынган була. «Вакыт» газетасы наширләреннән берсе Закир Рәмиев (шагыйрь Дәрдмәнд, 1859—1921) шигырьне үзенә каршы юнәлтелгән дип уйлый һәм «Вакыт» газетасына кушымта сыйфатында чыккан «Әдәбият мәҗмугасы»ның 12 нче санында (Оренбург, «Вакыт» матбагасы, 1907) «Шагыйрьгә» исемле шигырь бастыра.

Ничөн бу хиддәт, и шагыйрь,
Нәдер бу ярганың ярма?
Эчеңдә бармы йә бер чир,
Вә йә синдә күңел тарма?

Әдиплек шәэнеңи саклап,
Әдәпле сирәт эзләп тап,
Бигүк түрләргә уздырма
Катаңны да хата мактап.

Бирелмә ул кадәр зарга,
Сиңа көндәш түгел карга;
Вәли бик калкынып очма,
Сакын, тап булма шоңкарга!

Яңылма, и яңа былбыл,
Тикәннән гөлне аерып бел,
Телеңдә хар вә хөсса булса,
Вафаи васләт итмәс гөл.

Ала кошларга бакмача,
Газизем, булма такмакчы;
Матур гөлләргә бул былбыл,
Нәзакәт багына сакчы!

*«Әдәбият мәҗмугасы», 1907, 12 нче сан;*
*Дәрдмәнд. Исә җилләр, 1980, 31 б.*

**12 июль.** Г.Тукай Дәрдмәнднең «Шагыйрьгә» шигыренә җавап итеп, «Йолдыз» газетасында аңлатма бастыра.

**«Аңлашу»**

Мөхтәрәм «Вакыт» гәзитәсенең 12 нче номер «Әдәбият мәҗмугасы»ның ахыргы сәхифәсендә һич мөнәсәбәтсез вә хаксыз ударак, минем «Мөтәшагыйрьгә» дигән шигыремә каршы мине тәхкыйрь юллу язылмыш шигырьләр дәрҗ ителмеш.

---

Хиддәт — ачу, кабарыну.
Шәэн — дәрәҗә.
Сирәт (сиярәт) — гадәт, холык.
Вәли — ләкин.
Хар вә хөсса — чәнчү һәм дошманлык хисе.
Вафаи васләт — тугрылыклы аралашу.
Тәхкыйрь юллу — кимсетү максаты белән.

Бәнем «Мөтәшагыйрьгә» шигыреме язуым асла «Вакыт» гәзитәсенә юнәлтеп түгелдер. Шул шигырене язганда, «Вакыт» гәзитәсе минем хәтеремә дә килгәне юктыр.

Беләм ки, минем шигыремдә «вакыт» ләфзының мөгътәриза эченә хатамы, йә үземнең синтаксик кагыйдәсенә мөсаһәлә итүемнәнме төшүе мөхтәрәм «Вакыт» мөхәррирләрен шөбһәгә төшермештер. Миңа «Вакыт» гәзитәсен кимсетергә бер дә юл юктыр. Чөнки «Вакыт» гәзитәсе әшгар мәҗмугасы түгелдер ки, мин аны тәнкыйть итеп «Мөтәшагыйрь» исемен бирим.

Икенчедән, мин һәммә ислам гәзитәләрен җаным кадәр сөямен, һичберсенә тел озату минем шәэнем түгелдер.

Минем бәгъзе вакытта, дөрест, «Борһане тәрәккъкый» дә бер дә кирәкмәгәнгә урын алган бәгъзе шигырьләргә эчем пошадыр. «Мөтәшагыйрьгә» шигыре, ихтимал, шундый эч пошулар сәбәпле ихтыярсыз язылган булыр.

Инде «Вакыт»тан түбәнчелек белән үтенәмен ки, Хода хөрмәте өчен, бу яңлыш уларак киткән фикерне кайтып алсын. Мин бу кадәр нахак сүзләрне тәхәммел итә алмыйм.

*Газиз Габдулла Тукаев.*
*«Йолдыз», 143 нче сан.*

**17 июль.** «Вакыт» редакциясенең Тукай «Аңлашу»ына карата җавабы басылган. Анда мондый юллар бар: «Шимди сез үзеңезнең шигырьләрегездә безне ирадә әйләмәдекеңезне сөйләрсез вә сезләрә хитаб иделмеш шигырьләрнең кире алынмасыны эстәрсез. Без дә мәмнүният илә морадыңызга муафикъ итеп, 12 нче номер «Әдәбият мәҗмугасы»ның соң битендә сезләрә хитаб иделмеш шигырьләрне тәмам алдык. Вә сезнең шигырeңез нә хөкемдә калмыш исә, бездә язылмыш шигырьләр бигайниһи шул хөкемдә калыр».

*«Вакыт», 196 нчы сан.*

**20 июль.** Тукай, Уральскида М.Мусин, К.Төхфәтуллин белән бергә, «Яңа тормыш» газетасын чыгару турындагы килешүгә кул куя. Газетаны чыгару аерым кешеләрдән җыелган керемгә нигезләнгән.

Газета Уральскида «Яңа тормыш» исеме белән 1907 елның ноябреннән 1908 елның мартына кадәр чыга. Редакторы Мө-

---

Мөгътәриза — җәя.
Мөсаһәлә иту — игътибарсызлык күрсәтү.
Шәэн — эш, шөгыль.
Тәхәммел иту — күтәрә алу.
Ирадә әйләмәдекеңезне — безне күздә тотмавыгызны.
Хитаб иделмеш — төбәп әйтелгән.
Мәмнүният илә — бик куанып.
Бигайниһи — нәкъ.

хәммәтгали Мусин. Тукай бу вакытта Казанда инде. Газетада басылган әйберләре күренми.

Килешүнең рус телендә язылган күчермәсе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының Мирасханәсендә Кулъязмалар бүлегендә саклана.

## Домашнее условие

*(Копия)*

Мы, нижеподписавшиеся, решили издавать в г.Уральски газету на татарском языке под названием «Яни тормыш» («Новая жизнь») на паях, пай стоит 100 рублей, желающие могут принимать на себя 2 или 3 и более паев, условия об открытии и движении этого дела нами будут написаны своевременно после сбора денег от пайщиков. Главным руководителем этого общества является гр. Казанской губернии Камиль Мотыгулович Тухфатуллин, который будет вести все дела этого общества, касающиеся издания названной газеты «Яни тормыш», давая отчеты пайщикам по каждому их требованию.

Камиль Мотыгулович Тухфатуллин (подпись) 500 рублей.
Мухамед Гали Фазлиевич Мусин (подпись) 100 рублей.
А.Тукаев (подпись) 100 рублей.
Город Уральск, июля 20 дня 1907.
Төп нөсхәсе К.Төхфәтуллинда саклана, диелгән.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 4-эш.*

**24 июль.** «Җуаныч» исемле шигыре чыга.

*«Бәянелхак», 197 нче сан.*

**27 июль.** «Идарәдән җаваплар» дигән белешмә басылган. Анда болай диелә: «Мөхтәрәм шагыйрь Габдулла әфәнде җәнабләренә: «Җуаныч» басылды, ләкин мәгаттәэссеф, күрдекенезчә, кыскартылмыштыр, шигырьләренез мәгальмәмнүният дәрҗ ителәчәктер». Шигырьнең соңгы юллары басылмый калган. Тукай «Бәянелхак»ка да, «Казан мөхбире»нә дә шуннан соң шигырьләр бирмәгән.

*«Казан мөхбире», 234 нче сан.*

**Июль ахыры.** В.Бәхтияровның тиздән чыга башлаячак «Әл-ислах» газетасына язышуын үтенеп сораган хатына каршы Г.Тукай: «Берничә номер гәзитәгез чыкмыйча торып, берни дә әйтә алмыйм. Үзем көзгә таба Казанга барып чыгачакмын,

---

Мәгаттәэссеф — үкенечкә каршы.

Мәгальмәмнүният дәрҗ ителәчәктер — шатланып басылачактыр.

шунда сезнең белән сөйләшермен»,— дигән җавап хаты җибәрә. Хат сакланмаган.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. «Истәлекләр», 76 б.*

**9 август.** Г.Тукай Г.Шәрәфкә язган хатында үзенең озакламый туган якларына солдатка каралырга кайтачагы, аннан соң Казанга киләчәге турында әйтә. Хат сакланмаган.

*Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар. «Истәлекләр», 107 б.*

**4 сентябрь.** «Казан мөхбире» газетасы игълан итә: «Тиздән Шәрәфләр (Казан) матбагасында Г.Тукаев, Н.Думави һәм башкаларның шигырь китаплары нәшер ителәчәк».

Бу хәбәрдә «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. Казан, Шәрәф матбагасы, 1907») күздә тотыла.

*«Казан мөхбире», 264 нче сан.*

**Сентябрь.** Г.Тукай Уральскида берьялгызы фоторәсемгә төшкән. Фотоның күчермә нөсхәсе Г.Ибраһимов исемендәге институтның Кулъязмалар бүлегендә саклана.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 22-эш.*

**20 яки 25 сентябрь.** Г.Тукай Уральскидан Казанга чыгып китә. Туган якларына кайтуның максаты һәм бер сәбәбе солдат хезмәтенә каралу өчен дә була. (Тукайның тормыш юлын өйрәнүчеләр аның Казанга 10 октябрьдә килеп җитүен әйтәләр. Күрсәтелгән датадан чыгып караганда, бу килү вакыты озак кебек тоела. Ул вакытта Җаектан Казанга поезд белән йөрмәгәннәр, күбрәк ат белән килгәннәр. Тукайның Казанга нинди транспорт белән килүе мәгълүм түгел, бу турыда төрле фаразлар йөри. Ат белән дә, су юлы белән дә, диючеләр бар. Хөсәен Зәбиров күрсәткән шагыйрьнең Казанга чыгып китү датасы да документаль расланмаган, бәлки, автор фаразы гына. Тукайның Казанга килеп җитү датасы да якынча гына алына.)

*Зәбиров Х. Казанда Тукай урыннары. «КУ», 1986, 4 нче сан, 106—108 б.*

**3 октябрь.** Казанда демократик яшьләр, шәкертләр органы «Әл-ислах» газетасының беренче саны чыга (ул 1909 елның 22 июлендә туктала). Редакциясе «Болгар» номерлары, 12 нче бүлмәгә урнаша. Мөхәррире Вафа Бәхтияров. Газетада төп эшне Ф.Әмирхан алып бара. Казанга килгәч, Г.Тукай монда башта әдәбият бүлеген, соңыннан хатын-кызлар бүлеген алып бара, иҗаты белән дә актив катнаша.

**10 октябрь.** Г.Тукай Казанга килеп җитә. «Болгар» номерының (Татарстан һәм Киров урамнары кисешкән чат 14/59 нчы йорт) өченче катында Кабан күленә таба карап торган почмактан өченче тәрәзә, 40 нчы бүлмәгә урнаша. Кыска вакытлы күченүләрне исәпләмәгәндә, ул бу номерда 1912 елның декабренә кадәр яши. Тукайның Уральскидан алып килгән әйберләре бер кәрзингә сыеп беткән. Бу фактлар якынча гына әйтелә, төгәл документлар сакланмаган. «Болгар» номеры Тукайның иң озак яшәгән урыны.

*Г.Тукайның 1907—1913 елларда Казандагы тормышы һәм эшләгән урыннарын күрсәткән альбом, 1948. Төзүчесе Тукайның якын иптәше В.Бәхтияров.*
*Мирасханә. 9-ф., 3 тасв., 6-эш*.*

**10 октябрь.** «Әл-ислах» газетасы мөхәррире В.Бәхтияров иртән «Әл-ислах» идарәсендә («Болгар» номеры, 12 нче бүлмә) Г.Тукай белән таныша. «Ул өстенә пальто сыман бернәрсә кигән. Башында начар гына кепка, аягында искерәк итек, итек өстеннән чалбарын чыгарган, күгелҗем пыялалы күзлек кигән. Бу кеше, шул көн генә чыккан «Әл-ислах»ның икенче номерын алып, утыргычка утырды да: «Бу номер газетаны мин алып чыгам, мин «Болгар»ның 40 нчы номер бүлмәсендә торам, дип чыгып китте»,— ди В.Бәхтияров.

Мөхәррир белән әңгәмә вакытында Тукай «Әл-ислах»та эшләргә вәгъдә бирә.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. «Истәлекләр», 76 б.*

**10 октябрьдән соң.** Г.Тукайны журналист Борһан Шәрәф Ф.Әмирхан белән таныштыра. Бу танышу Ф.Әмирхан фатирында, хәзерге Мәҗит Гафури урамы, 35 нче номерлы йортта (элекке Яңа бистәдәге Кече Сембер урамы) була. Бу ике зур әдип арасындагы эчкерсез дуслык гомерләре буенча дәвам итә.

*Әмирхан Ф. Тукай тугрысында искә төшкәннәр. «Истәлекләр», 118—119 б.*

Г.Тукай «Йолдыз» газетасы редакциясендә ул вакытта әлеге газетаның җаваплы секретаре булып эшләгән Г.Камал белән таныша. Бу ике зур әдип арасындагы дуслык гомерләре буенча дәвам итә.

*Камал Г. Габдулла Тукай турында истәлек. «Истәлекләр», 70—71 б.*

---

* Алга таба: В.Бәхтияров. «Альбом», 1948. Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш дип биреләчәк.

Г.Тукай «Әл-ислах»чылар белән фоторәсемгә төшкән: Г.Тукай, И.Әмирхан, Ф.Әмирхан, К.Бәкер, В.Бәхтияров. Фотоның төп нөсхәсе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Кулъязмалар бүлегендә саклана.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 24-эш.*

**17 октябрь.** «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» исемле мәкаләсе басыла. Мәкаләне «Әл-ислах» газетасының төп хезмәткәре һәм оештыручысы Ф.Әмирхан редакцияләп бастыра.

В.Бәхтияров истәлегенә караганда, «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» — Тукайның Казанга килгәч язган һәм бастырган беренче мәкаләсе. Г.Тукай бу мәкаләне язганда, В. фон Поленцның «Крестьянин» романына Л.Н.Толстой язган кереш сүздән файдаланган. Бу роман 1902 елда басылып чыккан.

*«Әл-ислах», 3 нче сан;*
*Әмирхан Ф. Тукай тугрысында искә төшкәннәр. «Истәлекләр», 119—120 б.;*
*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. «Истәлекләр», 77 б.;*
*Карлова Т. Роль русской литературы в творческом развитии Габдуллы Тукая. «Поэт свободы и правды», 1990, с.51.*

**17 октябрьдән соң.** Г.Тукай солдат хезмәтенә каралу өчен туган авылы Кушлавычка кайта. Кайтышлый Каенсар, Кырлай авылларына туктала. Каенсар авылында яшәүче Саҗидә апасының әйтүенә караганда, Казаннан кайтканда Габдулла, Күәм авылы кешесенең атына утырып, аягына күн ботинкалар, кулына күн перчатка, өстенә кыска гына кием киеп кайткан. Юлда бик туңган булган, чөнки искечә октябрьнең 25 ләре булганга, көннәр салкынайтып торган. Өйгә кергәч тә, кулларын уа-уа «туңдым, апай» дип сөйләнеп торган.

Казанга кире киткәндә, Саҗидә апасы аңа бер пар киез итек һәм бияләй биргән.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 124 б.;*
*Усал (Туктаров Ф.). Габдулла Тукаевның Казанда үткән еллары. «Ялт-Йолт»,1913,55 нче сан;*
*Укмасый М. Шагыйрьнең тормыш сәхифәләреннән. Сайланма әсәрләр, Казан, 1958, 109 б.*

**24 октябрьгә кадәр.** Г.Тукай, солдат хезмәтенә каралу өчен туган якларына кайтканда, Югары Масра авылына, әтисе белән бертуган Файзә әбиләргә туктала.

*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 42 б.*

**24 октябрь.** Г.Тукай солдат хезмәтенә каралу өчен жирәбәне Олы Әтнәдә ала.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 125 б.*

**24 октябрьдән соң.** Г.Тукай солдатка каралу өчен чират, жирәбә алгач, Олы Мәңгәргә, Габделвәли исемле туганына барып, ике-өч көн кунак була.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 125 б.*

**26 яисә 27 октябрь.** Буйга кечкенә һәм чандыр гәүдәле, бер күзенә әзрәк ак төшкән Тукай солдатка каралу бүлмәсеннән ак билет алып чыга. Ул, Олы Әтнәдә каралып, солдатка алынудан азат ителә.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 127 б.*

**Октябрь ахыры.** Г.Тукай, Казанга кайткач, Шәрәфләр матбагасында Гыйльметдин Шәрәф белән очраша. Бу турыда Г.Шәрәф болай ди: «Менә шул минуттан без Габдулла әфәнде белән күреп таныш һәм соңгы көннәренә кадәр икебез дә Казанда булган вакытта бик еш-еш күрешә торган, Казан теле белән әйтсәм, «кашыклы аштан калышмый торган» дус, иптәш булып китәбез*.

*Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар. «Истәлекләр», 108 б.*

Г.Тукай «Таң йолдызы» газетасы мөхәррире шагыйрь С.Рәмиев белән очраша. Сөйләшү вакытында: «Сәгыйть әфәнде, мин Сезгә «Царь-Голод...»ның тәрҗемәсен җибәргән идем. Сез аны басмадыгыз да һәм идарәдән бер җавап та бирмәдегез»,— ди. Аннары «Гаяз әфәндене күрә алмам микәнни инде?» — дип сорый. С.Рәмиев Г.Исхакыйның шушы көннәрдә генә Архангель губернасына өч елга сөргенгә озатылуы турында әйтә. Г.Исхакый сөргенгә 1907 елның 24 октябрендә озатыла.

«Царь-Голод, яхуд Ачлык-Падишаһ» беренче мәртәбә «Әлгасрелҗәдит»нең 1906 елгы 8 нче, 9 нчы, 11 нче, 1907 елның 4 нче, 5 нче саннарында басыла. Тукай, күрәсең, хезмәтне Казанда икенче мәртәбә бастырырга уйлаган.

*Рәмиев С. Беренче очрашулар. «Ил», 1914, 23 нче сан. «Истәлекләр», 115—116 б.*

---

* Тукай Г.Шәрәфләрнең өенә дә барып йөргән. Шунда ул утырган урындык хәзерге көндә Казанда, Тукай музеенда саклана.

**5 ноябрь.** «Бер манигы тәрәкъкыйгә» исемле шигыре басыла. Шигырь турында В.Бәхтияров болай ди: «Тукай Казан яшьләре арасында Ишми Ишан турында төрле сүзләр ишетә. Аның яңалыкка каршы икәнен аңлый. Аны яңалыкның чын дошманы итеп санап, «Бер манигы тәрәкъкыйгә» исемле шигырен яза. Бу — Тукайның Казанга килгәч язган беренче, шуның белән бергә «Әл-ислах»та басылган беренче шигыре».

*«Әл-ислах», 5 нче сан;*
*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 26-эш.*

**15 ноябрь.** Г.Тукайның беренче шигырь җыентыгы чыга: Г.Тукаев шигырьләре («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр), беренче кыйсем. Казан, Шәрәф матбагасы, 1907.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 88-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

Җыентыкта басылган: «Шүрәле» поэмасы. Поэманың ахырында мондый юллар язылган: Ихтар. «Мин бу «Шүрәле» хикәясен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуына истинадән яздым. Өмид юк түгел әле: ихтимал, бара торгач, үз арамыздан маһир рәссамнар чыгып, шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кылынган урманнарны — һәммәсен тәрсим кылып чыгарырлар. Авыл җирендәге хыялый хикәяләрнең һәммәсен язып чыгуда файдадан башка бернәрсә дә булмас зан идәрем».

Шигырьләре: «Хур кызына», «Пар ат», «Шагыйрьгә» (Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләренең бер нәсихәте), «Мөтәшагыйрьгә», «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?», «Бишектәге бала» (Лермонтовтан), «Шиллердән», «Япунияне мөселман идәчәк голямә нәрәдә?», «Тәрбиятел-этфаль»гә» (Бер тыйфел мөслим лисаныңдан), «Пушкинә», «Кемне сөяргә кирәк?», «Теләнче», «Син булмасаң», «Дәрдмәнд дәгелмием?», «Пушкин ислам хатыннары хакында» (Шигырь рус телендә, ахырына «Пушкин» дип куелган), «Тәрҗемә вә тәшрих», «Мөхәррирләр вә карак», «Аллаһ гыйшкына», «Ифтиракъ соңында», «Дөньяда торыйммы?» —

---

Манигы тәрәкъкый — алга баруга комачаулык итүче.
Ихтар — искәрмә.
Истинадән — таянып, үрнәк алып.
Тәрсим кылу — сынландыру, сурәтләү.
Зан идәрем — уйлыйм.
Тыйфел мөслим — мөселман баласы.
Ифтиракъ — аерылышу.

дип киңәшләшкән дустыма», «Алтынга каршы», «И каләм!», «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Сөткә төшкән тычкан» (Бер Америка гәзитәсеннән), «...гә» (Лермонтовтан икътибас), «Утырышу», «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре», «Шагыйрь вә һатиф», «Гыйшык бу, йа!», «Туган җиремә».

**26 ноябрь.** «Әл-ислах»та «Театр» исемле шигыре басыла. Шигырь турында В.Бәхтияров болай ди: «Ноябрь аеның ахырларында «Сәйяр» труппасы тарафыннан Г.Камалның «Бүләк өчен» комедиясе уйнала. Тукай да театрга бара. Тукайның татар театрын беренче күрүе була. Уен шагыйрьгә ошый, яратып кайта. Шул тәэсир йогынтысында ул «Театр» шигырен яза. 26 ноябрьдә шигырь «Әл-ислах»ның 8 нче номерында басылып чыга.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 26-эш.*

**Ноябрь.** Г.Тукай «Әхбар» газетасына даими эшкә чакырыла. (Газетаның беренче саны 10 декабрьдә чыга. Баштарак ризалык күрсәтеп йөрсә дә, газета чыгар алдыннан Тукай, башка эшкә керешкәнен сылтау итеп, газетага бармый һәм соңыннан моның сәбәбен Г.Шәрәфкә болай дип сөйли: «Мине «Әхбар»га чакыралар. Мин анда кирәк нинди нәрсә бирсәләр дә, телим-теләмим тәрҗемә итәргә тиешле булам һәм һәр номерга ике-өч йөз юл нәрсә язарга тиешле. Минем русчам Уральскидан килгәндә зәгыйфь иде. Үзем теләгән нәрсәләрне тәрҗемәгә куәтем җитсә дә, ни бирсәләр, аны тәрҗемә итәргә үземдә икътидар хис итми идем. Бу минем фәкать күңелемдә саклангaн, ул вакыт беркемгә дә белдерү ихтималым булмаган бер сер иде. «Әхбар»га кереп, үземне сынатырга бер дә теләми идем...»

**Ноябрь ахыры.** Г.Тукай Габдрахман Дәүләтшин оештырган «Китаб» нәшриятына экспедитор булып урнаша. Монда эшкә кергәч, ул «Болгар» номерларыннан нәшрият контора итеп алган «Мәскәүский номерлар»ның берсенә, анда берәр ай чамасы торгач, контора белән бергә, «Уральское подворье»га күчә. Тукай нәшриятта әзерләнгән китапларның корректурасын карый, китаплар әзерләп, посылкаларны тегеп, аларны почтага илтә. Китапларны кирәк кадәр Казан китапчыларына илтеп тапшыра. Моның өчен ул айга 25 сум хезмәт хакы ала.

*Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар. «Истәлекләр», 109—110 б.*

---

Һатиф — яшерен тавыш, өн.
Икътидар — көч, куәт.

**Кыш.** Г.Тукай «Әл-ислах» редакциясендә күренекле галим-фольклорчы Хуҗа Бәдигый белән таныша. Аңардан халык иҗаты әсәрләрен ничек җыюы турында сораша.

*Бәдигый Х. Исемдә калганнар.*
*«Истәлекләр», 100 б.*

Мәхмүт Дулат-Алиевлар йортында (элекке Большая Симбирская урамы, 37 нче йорт, хәзерге М.Гафури урамы) Г.Тукай беренче мәртәбә М.Дулат-Алиев һәм Х.Ямашев белән очраша. Шуннан соң алар арасында фикри дуслык урнаша.

*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 58 б.*

Г.Тукай «Болгар» номерында китапчы, язучы Хәбибрахман Зәбири белән таныша. Истәлекләрендә Зәбири Тукай белән гомере буе дуслык мөнәсәбәтендә торуы турында яза.

*Зәбири Х. Шагыйрь Г.Тукай турында истәлекләр.*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 61-эш.*

**1 декабрь.** «Габдулла Тукаев шигырьләре». «Габдулла Тукаев шигырьләрене тәкъдир итүчеләрнең иң элеккесе, ихтимал ки, «Вакыт» улмыштыр. Бик күп кемсәләр ялгыз назыйм улдыклары хәлдә, Габдулла әфәнде һәм назыйм, һәм шагыйрьдер».

Бу бәя Габдулла Тукаев шигырьләре («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр, 1907) чыгу уңае белән әйтелгән.

*«Вакыт», 251 нче сан.*

**3 декабрь.** Ф.Әмирханның «Габдулла Тукаев шигырьләре» исемле рецензиясе «Дамелла» имзасы белән басыла.

Рецензия «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр, 1907) җыентыгы дөньяга чыгу уңае белән язылган.

Ф.Әмирхан, җыентыкка уңай бәя биреп, укучыларга тәкъдим итә: «Бу мәҗмугада Габдулла әфәнденең халис татарча — һәр татар рәхәтләнеп укырлык язылган бик гүзәл шигырьләре вә халис татар мәгыйшәтеннән алынган тасвирлары янында, иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, азәрбайҗанча, тагы әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер».

*«Әл-ислах», 9 нчы сан.*

---

Назыйм — тезмә әсәр язучы.
Халис — саф.

**5 декабрь.** Г.Камалның «Габдулла Тукаев шигырьләре» исемле рецензиясе басылган. Рецензия «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр, 1907) чыгу уңае белән язылган.

Г.Камал җыентыкның авторын түбәндәгечә бәяли: «Минем каршымда Габдулла әфәнде илә Габделмәҗит әфәнделәр алга чыктылар. Хәзерге көндә шагыйрь исемен итлак кылырга шул икесе лаектыр. Габдулла әфәнденең язган нәрсәләре арасында хакыйкатән шигырь итлакына мөстәхикъ булган гали тасвирлар, гүзәл тәрсимнәр күренәдер».

*«Йолдыз», 201 нче сан.*

**8 декабрь.** Г.Тукайның «Бер манигы тәрәккыйгә» шигыренә югары бәя биреп, «Яңа тормыш» газетасында «Г.Тукаевның 5 нче номер «Әл-ислах»та язган әшгаренә» тәкъриз басылган. Авторы күрсәтелмәгән. (Уральск татар матбугатын өйрәнгән Ф.Яхин «аны К.Мотыйгый язган», дигән фикердә тора.) Тәкъриздә мондый юллар бар:

Яза тор безгә шундый яхшы җырлар,
Ачып хаклыкны кал у кыйльгә каршы,
Кыйраәт бозучы карчыктай булып,
Авазы моңлы хуш тәртилгә каршы,
Белер-белмәс мыгырдап, юкны сөйләп,
Бозыклык сатмасыннар илгә каршы.

*«Яңа тормыш», 5 нче сан.*

**10 декабрь.** «Безне урынсыз яманлыйлар» (М.Һади Ширвани артыннан) шигыре «Шүрәле» имзасы белән чыккан. «Ахыры булачак» дип куелган. Бу шигырьне Тукай башта «Бездә истигъдад бар» исеме белән язган. Матбугатта бастырганда, аның исемен «Безне урынсыз яманлыйлар» дип үзгәрткән. Азәрбайҗан шагыйре Һади Мөхәммәтһади Ширвани (1880—1920) шигыреннән файдаланып язылган.

«Әл-ислах»та «Хатын-кызлар бүлеге»н алып баручы Тукай мөгаллимә һәм шагыйрә Маһруй Мозаффариянең «Мәшһүр хатыннар» исемле шигырен редакцияләп бастырып чыгара.

*«Әл-ислах», 10 нчы сан;*
*Укмасый М. Тукай турында истәлекләр. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 130-эш.*

---

Итлак кылырга — бирергә.
Мөстәхикъ — хаклы.
Тәрсимнәр — сурәтләүләр.
Тәкъриз — мактаулы бәя, рецензия.
Кал у кыйль — юк-бар сүз.
Кыйраәт — уку.
Тәртил — Коръән уку.
Истигъдад — сәләтлелек, булдыклылык.

**10 декабрьдән соң.** «Шәрекъ» клубында бер кичәдә шагыйрьнең «Безне урынсыз яманлыйлар» (1907) шигыре игълан ителде. Халык шагыйрьнең чыгышын түземсезлек белән көтеп алды. Номерны әйтеп торучы Тукай номерын әйткәннең соңында шагыйрь, кыюсызлыгыннан булса кирәк, кыстатып кына чыкты. Язылган шигырьне кулына тоткан килеш, ярым күңелдән, ярым карап, шактый көчле тавыш белән укыды. Кичәдә булган шәкертләр, шигыре бик матур, ләкин укуы көткәнчә үк булып чыкмады, дип сөйләделәр.

Ә шуннан соң бу шигырь мәдрәсәдә әдәбият кичәләренең программаларында еш кабатланды».

*Сафин Д. Г.Тукай турында минем истәлекләр.*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 122-эш.*

**12 декабрь.** «Мәхбүс» (Пушкиннан) исемле шигыре чыга. А.С.Пушкинның «Узник» шигыреннән ирекле тәрҗемә.

*«Әхбар», 2 нче сан.*

**17 декабрь.** «Вәгазь» (Лермонтовтан) исемле шигыре басылган. Ул М.Ю.Лермонтовның «Описание» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

*«Әл-ислах», 11 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 366 б.*

**24 декабрь.** «Бер гәзитә идарәсе хәленнән» шигыре басыла. В.Бәхтияров «Тукай турында кайбер истәлекләр»ендә шигырьне «Бәянелхак» нашире Әхмәтҗан Сәйдәшевтан көлеп язуы турында әйтә. Ә.Сәйдәшев — Мәскәү байларыннан бурычка мал алып, түли алмыйча, банкротлыкка чыккан сәүдәгәр. Акча юк дигән сылтау белән ул «Бәянелхак»та басылган күп мәкаләләргә гонорар түләми торган була.

*«Әл-ислах», 12 нче сан;*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 26-эш.*

**30 декабрь.** Г.Тукай Казаннан Уральскига апасы Газизә Госмановага хат яза. Шул хаттан бер өзек: «Әле бу арада бик яхшы гына авырып алдым. Хат яза алмадым. Кәефем вә тормышым яхшы. Дуст-ишләр күп. Казанда тору күңелле, Уральск бик сирәк искә төшә. «Шүрәле» китабы җибәрдем. Монда кечкенә вакытымда тәрбия иткән энкәмне дә таптым. Иртәгә күрешмәкче булдым».

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 80 б.*

**30 декабрь.** Тукай Казаннан Уральскига дусты артист Г.Кариевка хат яза. Хатта мондый юллар бар: «Казанны вә туган җирем булган Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр

вә хиссиятләр алдым. Мин хәзер Казанда инде. Уральскида вакыт шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетдеге вә шунда бару хакында шигырьләр яздыкым Казанда инде.

...Үзем теләп кенә «Әл-ислах»та хезмәт итәм. Жалунье башка җирдән алам». Тукай «жалунье» дигәндә Дәүләтшинның «Китаб» нәшриятыннан алган хезмәт хакын күздә тотса кирәк.

«Шигырьләр яздыкым» дигәндә, ул Уральскида язылган «Пар ат», «Туган җиремә» шигырьләрен күздә тота.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 81 б.*

**Декабрь.** Г.Тукай Париж коммунасы урамы, 9 нчы йортта, элекке «Сарай» номерларының ишегалдына караган ягында, 2 нче катта, 9 нчы бүлмәдә В.Бәхтияров белән бергә яши.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

**Ел ахыры.** Г.Тукай Казанга килгәч, Казанда үзен сабый чакта асрамага алып, берникадәр вакытлар тәрбияләгән үги әнисе Газизә апаның адресын эзләп таба һәм Гарәфә (бәйрәм алды) көнне әнисенә кеше аркылы бүләкләр җибәрә.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 173 б.*

Г.Тукай матбагачы Гыйльметдин Шәрәфнең туганы Шәһер Шәрәф (гарәп мәдәнияте белгече) белән таныша. Бу турыда Ш.Шәрәф болай ди: «Беркөн «Казан мөхбире» гәзите идарәсендә беренче мәртәбә Тукай берлә очраштым. Ул вакытта Тукай, солдатка каралдыкыннан соңра, Казанда торып калырга уйлаган иде.

Беренче сүз Уральскида дәвам иткән «Фикер», «Әлгасрелҗәдит» хакында булды. Ул бу газет вә журналларның күбрәк эшләре үз кулыннан, үз планы буенча эшләнгәнен сөйләдектән соң, мин анда күпме вазифа алганын сорадым. Егерме-егерме биш сум кадәрле, диде. Буңар каршы: «Казанда шулкадәр эшләсәң, сиңа аның кадәрле ике-өч өлеш вазифа бирерләр иде»,— дидекемдә: «Тамак туярлык, бер дәрәҗә мәгыйшәт итәрлек булгач, акчаның нигә кирәге бар, миңа шул акча җитә иде, газеталар яхшы барса, һаман шунда хезмәт итүне уйлап тора идем»,— диде».

*Шәрәф Ш. Габдулла Тукай хакында бәгъзе хатирәләрем (Вафатына биш ел тулу мөнәсәбәте илә искә төшерү). «Истәлекләр», 103—104 б.*

Г.Тукай В.Бәхтияров белән бергә Ф.Әмирхан фатирында була. Алар кайтышлый әдип белән бер күршедә генә яшәүче

Камчылы Ишан йортына керәләр. Бу вакыйганы В.Бәхтияров болай тасвирлый: «Без кергәндә, өйнең залында мөритләр идәнгә түгәрәкләнеп утырганнар. Түгәрәк уртасында зур чалма кигән Камчылы Ишан утыра. Шау килеп: «Яһу, яһу, яһу...» — дип кычкырып, тавышлап утыралар иде. Берничәсе сикереп торып, шул түгәрәк эчендә сикереп, кычкырып йөри башладылар. Бу күренеш Тукайны шомландырды булса кирәк: «Әйдә, чыгабыз»,— диде, без чыгып киттек. Бу хәлдән соң озак та үтмәде, «Бер шәехнең мөнаҗәте» исемендәге шигырен язып чыгарды».

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр, 82 б.*

«Тукай турында истәлекләр» китабын төзүчеләрнең берсе И.Нуруллин әлеге шигырьгә биргән аңлатмасында «Бер шәехнең мөнаҗәте» шигыренә карата С.Рәмиев версиясенең дөреслеккә якынрак булуын әйтә.

*Рәмиев С. Беренче очрашулар. «Истәлекләр», 116—117 б.*

**Ел дәвамында.** Г.Тукай Казанга Уральскидан үпкә авыруы алган килеш килә. Казанда табиб аңардан икенче стадия үпкә авыруы таба. Ләкин шагыйрь авыруына әллә ни илтифат итми, дәваланмый.

«Күп вакыт шагыйрь, иртә йокыдан торып, карават өстендә ике тезен кочаклап йөткерә торган иде. Йөткереп арыгач, йоклап китә яки йокламый түшәмгә карап дәшми, сөйләшми, моңаеп, тирән уйга батып, ятып карап тора торган иде»,— ди В.Бәхтияров.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 34-эш.*

Тукай шигырьләре Өфе өязе Кара Якуп волосте (хәзерге Чишмә районы) Келәш авылына да килеп җитә. «Һичбер көтмәгәндә, 1907 елда безнең авылга Тукай шигырьләре килеп чыкты. Тукай безгә аңлаешлы телдә, ләкин әлегә чаклы ишетелмәгән яңа бер тавыш белән:

Ник йоклыйсың, мужик?
Яз җитте һәм үсте
Чирәмнәр йортында,
Тор, уян, күтәрел! —

дип, безне гасырлык йокыдан тарткалап уятты,— ди шагыйрь Сәйфи Кудаш.

*Кудаш С. Безнең Тукай. «Тукай Башкортстанда», 1966, 145 б.*

**Гыйнвар.** Г.Тукай «Сарай» номерында икенче катта, 9 нчы бүлмәдә (Париж Коммунасы урамы, 9 нчы йорт) В.Бәхтияров белән бергә яшәвен дәвам иттерә.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

«Чүкеч» журналы Г.Тукайның «Безне урынсыз яманлыйлар» шигырен «Әл-ислах» сүзен имза урынына куеп, бастырып чыгарган. Бу — «шигырь «Әл-ислах»тан алынды» дигәнне аңлатса кирәк, чөнки шигырь беренче мәртәбә әлеге газетаның 1907 елны 10 декабрь санында чыккан.

*«Чүкеч», 37 нче сан.*

«Бәйрәм, без вә руслар» мәкаләсе «Шүрәле», «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» шигыре «Г.Т.», «Фөрьяд (Бер хатын авызыннан)» шигыре «Феакут» имзасы белән басылган. Соңгысының «Ахыры бар» дип куелган. Ләкин ахыры табылмады.

*«Әл-ислах», 13 нче сан.*

З.Бәшири «Дустыма (Тукаевка назыйрә)» исемле шигырь бастырган. Кайсы шигыренә назыйрә икәне әйтелмәгән.

*«Әхбар», 10 нчы сан.*

**2 гыйнвар.** Купеческое собрание залында шәкертләр катнашында әдәбият кичәсе була. Өч бүлемнән торган кичәнең икенче бүлемендә Г.Тукайның «Безне урынсыз яманлыйлар» исемле шигыре укыла. «Безне урынсыз яманлыйлар» шигыре дә бик акрын тавыш вә бөтенләй бер генә төрле тон вә жестларсыз, вә хәтта бәгъзе галәмәтләргә дә игътибарсыз укылып, бөтен хөсненнән гари булып чыкты, дияргә мөмкиндер»,— дип яза Ф.Әмирхан.

*Әмирхан Ф. Әдәбият кичәсе.*
*«Әл-ислах», 14 нче сан.*

**3 гыйнвар.** Тукай үги әнисе Газизә апа белән күрешә. Шагыйрь бу вакыйганы түбәндәгечә тасвирлый: «Яңа бистәдә, җимерек кенә җир астындагы бер өйдә бер карчык бар икән. Көннәрдән бер көн мин, ничектер, шул өйгә чакырылдым. Анда мине әнкәем көтеп торачак иде. Вакыт төн иде. Мин әллә нинди баскычлардан төшеп, караңгыда шул өйгә барып кер-

Назыйрә — икенче бер шигырьгә охшатып, шигырь язу.
Хөсненнән гари — матурлыгыннан мәхрүм.

дем. Кергәч тә, түрдә яше кырыклардан узмаган диярлек, кара кашлы, кара күзле, тулы гәүдәле бер хатын күренде. Моның әни икәнлеген танып: «Исәнме, әни»,— дип күрештем. Ул кулын бирде дә: «Син дә сәламәтмени соң әле?» — дип егълап җибәрде. Минем дә күңелем йомшарды, ничек тә үземне тота алдым».

*Апасы Газизә Госмановага язган хаты (1908 ел, 27 март); Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 82—83 б.*

Гает 1908 елның 1 гыйнварында булган («Әл-ислах», 24 декабрь). Тукай хатында Газизә әнисе янына Корбан гаетенең өченче көнендә баруын әйтә, дата шуннан чыгып куелды.

**6 гыйнвар.** «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр. Икенче кыйсем. Казан. Шәрәф матбагасы, 1908. Титул битендә «1907» диелгән) исемле китабы чыга. Бу — Тукайның басылып чыккан икенче җыентыгы. Казан губерна жандарм идарәсенең дөньяга чыккан китапларны теркәү дәфтәрендә җыентыкның басылып чыгу вакыты итеп 1908 елның 6 гыйнвары күрсәтелгән.

Җыентыкның эчтәлеге: «Мәхбүс» (Пушкиннан), «Театр», «Гыйлавә», «Байроннан», «Борадәранә нәсыйхәт»*, «Кем ул?», «Китмибез», «Иттифакъ хакында», «Ишек бавы»**, «Мөхәммәдия»дән», «Хөррият хакында», «Сөальләр», «Милләттә», «Бер манигы тәрәккыйгә», «Бер шәехнең мөнаҗәте», «Мөридләр каберстанындин бер аваз», «Тавыш хакында», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?», «Матбага берлә уйнаган бер байга», «Кичке азан»***, «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел», «Рәсемгә ишарә»****, «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә»,

---

* 23 нче номер «Вакыт» җәридәсендәге мөндәриҗкә, яшь төрекләрнең бәгъзе әшгарләренә каршы (*Г.Тукай искәрмәсе*).

** Безнең Урал тарафында бер гадәт бар: кыз янына керәсе кияүне ишек төбендә балалар, туктатып, акча сорыйлар. Балаларга акча бирмәсәләр, ишек ачылмыйдыр. Бәгъзе бер усал кияүләр, балаларга кәгазьгә төреп, бер тиенне күнә (көмеш) суына манып, 20 тиен сурәтендә бирәләр. Мин башка җирләрне белмим, безнең тарафларда шулай (*Тукай искәрмәсе*).

Җәридә — газета.

Мөндәриҗ — эчтәлек.

Әшгар — шигырьләр.

*** Русларда вә башка мөтәмәддин милләтләрдә һәр сәтыры ике сүздән гыйбарәт, ләкин гаять мәгънәле шигырьләр вардыр. Мин монда нәмүнә өчен Лермонтовның бер шигырен алып, шул ук мотивка «Кичке азан» сәрләүхәсе илә гаҗизанә бер шигырь яздым.

Мөтәмәддин — алга киткән.

Сәтыр — юл.

Нәмүнә — үрнәк.

Сәрләүхә — исем.

**** «Уклар»дагы рәсемгә карап язылган иде (*Г.Тукай искәрмәсе*).

«Көз», «Вәгазь» (Лермонтовтан), «Бер гәзитә идарәсе хәленнән», «Утырышу», «Ислахчыларга», «Мужик йокысы» (шагыйрь мәшһүр Кольцовның шигыреннән тәрҗемә вә икътибас ителмештер), «Үз-үземә», «Сөеклемнең кабер ташында», «Мәхү идәрмисән?», «Яз галәмәтләре», «Мөхәрриргә», «Әлгасрелҗәдид»ә маддәтән вә мәгънән иштиракъ идәнләрең лисаны хале нә диер?», «Шәкерт, яхуд бер Тәсадеф».

Тукай монда Лермонтовның «Звезда» исемле шигырен китергән.

Вверху одна
Горит звезда,
Мой взор она
Манит всегда.
Мои мечты
Она влечет
И с высоты
Меня зовет.
Таков же был
Тот светлый взор,

Что я любил
Судьбе в упор.
Мук никогда
Он зреть не мог,
Как та звезда,
Он был высок.
Усталых вежд
Я не смыкал,
И без надежд
К нему взывал.

*Лермонтов*

Тукай бу җыентыгына «Фикер»нең 24, 31 март, 9, 17, 23 апрель саннарында газетаның исеме астына укучыларга мөрәҗәгать рәвешендә имзасыз басылып барган икешәр юллык шигырьләрен туплап, «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел» исеме белән «Әлгасрелҗәдит»нең 1907 елны 1 нче санында басылган «Чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырен «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» исеме белән урнаштырган.

Г.Тукай Казан губерна жандарм идарәсе язмаларына шушы «4 нче дәфтәр»дәге шигырьләре белән 1908 елның февраль аенда килеп керә. Ул гади шагыйрь генә түгел, сәясәткә катнашучы хөкүмәт өчен шикле кеше булып исәпкә алына. Милли азатлык идеяләренә аеруча бай булган, сәяси яктан көчле яңгырашлы «Ислахчыларга», «Китмибез», «Иттифакъ хакында», «Милләтә», «Тавыш хакында», «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырьләре хөкүмәт өчен зарарлы дип бәяләнә.

**8 гыйнвар.** «Безне урынсыз яманлыйлар» шигыренең соңгы өлеше, «Бер шәехнең мөнәҗәте» исемле шигырьләре «Шүрәле» имзасы белән басылган. Соңгысының язылу тарихы турында С.Рәмиевнең «Беренче очрашулар» дигән истәлегендә мондый юллар бар: «Мин аңар бер остазым Габдеррәхим әфәнде Дәмини җәнабләреннән ишетдекем «Кафате хәмсә»не сөйләдем. Ягъни «Муллаларның сөйгәне — казы, кузый, каз, кыз, кымыз гына инде, үзләре боларны бергә җыеп «Кафате хәмсә» дип атыйлар икән»,— дидем.

Бу сүзне Тукай бик яратты да: «Туктале, мин моңардан бернәрсә эшлим»,— дип, үз номерына чыгып китте һәм бер ун-унбиш минуттан соң кулына:

«И Ходай! Мәгълүм сиңа тик яхшылыкта касдымыз,
Зикремездер: казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз,—

дип язылган бер кәгазь күтәреп керде».

*«Әл-ислах», 14 нче сан;*
*«Истәлекләр», 116—117 б.*

**9 гыйнвар.** «Әхбар» газетасы берничә санында «4 нче дәфтәр» турында игълан биреп бара: «Бу көн Шәрәфләр матбагасында «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр, 1908) басылып чыкты». Белдерү газетаның 16, 17, 18, 19, 20, 21, 22, 51 саннарына кадәр дәвам итә.

*«Әхбар», 12 нче сан.*

**13 гыйнвар.** Әстерханда булган әдәбият ахшамында Г.Тукайның «Теләнче», «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» шигырьләре ике шәкерт тарафыннан инсценировка рәвешендә башкарыла. «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре» шигыре укыла. Ахшамнан килгән җыем шәһәр мөселман кыйраәтханәсе файдасына тәгаен ителә.

*«Әхбар», 19 нчы сан;*
*«Яңа тормыш», 14 нче сан.*

**21 гыйнвар.** «Тәэссер» (Лермонтовның «Молитва» сәрләүхәле шигыренә тәкълид), «Төрекчәдән», «Янә» исемле шигырьләре чыга.

*«Әл-ислах», 16 нчы сан.*

**2 февраль.** Ф.Әмирханның «Габдулла Тукаев шигырьләре (4 нче дәфтәр)» исемле бәяләмәсе басыла. Автор җыентыкка уңай бәя бирә: «Габдулла әфәнденең моннан әүвәл бер шигырь мәҗмугасе нәшер ителеп, бөтен татар матбугаты тара-

фыннан иң гүзәл тәкъризләр белән каршы алынган иде. Бу икенче мәҗмуга да шулай ук гүзәл шигырьләр белән тутырылган вә рус мәшһире шөгарәсеннән бик муаффәкыять белән тәрҗемә ителгән шигырьләр белән зиннәтләнгәндер»,— дип, шагыйрь иҗатын мактаганнан соң, җыентыкның кимчелеге итеп «Мужик йокысы» шигырен күрсәтә. «Мал юк, дип зарланма, үзеңнән күр аны» дигән шигырьләрнең мәгънәләре берлә Русия җир тарихын вә сәясәтен белгән кешеләр канәгать итмәячәктер»,— ди. Бу әсәр иске карашы сәбәпле Тукаев шигырьләре арасында урын алырга тиеш түгел, дигән фикер әйтә.

Хәбәр: «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр. Икенче кыйсем, 1908) басылып чыкты».

*«Әл-ислах», 17 нче сан.*

**15 февраль.** Әстерханда үткәреләчәк «Әдәбият ахшамы»ның программасы басылган. Программада Г.Батыров тарафыннан Г.Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигыре укылачагы күрсәтелгән.

*«Идел», 27 нче сан.*

**15 февраль.** Галиәсгар Алтынбаев дигән кешенең «Шигырь» исемендә назымы басыла. Назымнан бер куплетны китереп үтәбез:

Рәхәтлек бу татарда дәхи юк дип иманлылар,
Намаз, руза барын сатып тыныч ятканымыз бардыр.
Исме чыккан кеше юк дип сөйләсәләр дә шагыйрьдән,
Үз исемен «Шүрәле» куеп, посып ятканымыз бардыр.

Бу шигырь язылган чорда «Шүрәле» имзасы белән Тукай гына басылган. Шуннан чыгып караганда, автор шигырьдә Тукайны истә тоткан, дип әйтергә кирәк.

*«Дин вә мәгыйшәт», 7 нче сан.*

**19 февраль.** Әстерханда әдәбият кичәсе үткәрелә. Кичәдә Г.Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырен Г.Батыров декламация итеп сөйли.

*«Идел», 28 нче сан.*

**23 февраль.** Соңгы көннәрдә идарәмезгә «Габдулла Тукаев шигырьләре («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр, Казан, Шәрәф матбагасы, 1908) килде».

*«Вакыт», 285 нче сан.*

---

Тәкъриз — мактау.
Мәшһире шөгарәсеннән — мәшһүр шагыйрьләреннән.
Муаффәкыять — уңыш.

«Егет илә Кыз (Авылда)», «Урланган мәгънә» шигырьләре басыла. Соңгысы «Шүрәле» имзасы белән чыга.

*«Әл-ислах», 20 нче сан.*

**Февраль.** В.Бәхтияров хатирәсенә караганда, Тукай «Сарай» номерларында яши. Шагыйрьнең 1907 елның ахыры, 1908 елның башларында кайда яшәве турында төрле фаразлар бар. В.Бәхтияров аның 1907 елның декабреннән алып, 1908 елның февраленә кадәр үзе белән бергә «Сарай» номерларында торуын әйтә.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

Журналист Гариф Латыйпов исә: «1908 ел башларында Г.Тукай Мәскәүский урамда аптека каршындагы йортның (хәзерге Киров урамы, 53 нче йорт) ишегалдына караган караңгы бүлмәсендә торды»,— дип яза.

*Латыйпов Г. Тукай турында истәлекләр.*
*«Истәлекләр», 92 б.*

Г.Тукай үзе 1908 елның 27 мартында апасы Газизә Госмановага җибәргән хатында бу вакыттагы адресын түбәндәгечә күрсәтә:

В гор. Казань, книгоиздательство «Китаб»,
*Абдулла Тукаеву.*

Г.Шәрәф истәлекләрендә «Китаб» нәшрияты урнашкан контора бүлмәсендә («Мәскәүский номерлар», «Уральское подворье») торуы, «Китаб» нәшриятыннан киткәч, яңадан «Болгар»га кайтуы әйтелә. Соңгылары дөресқәрәк туры килә, чөнки Тукайның үз сүзләре дә шуны раслый.

Г.Тукай, В.Бәхтияров, Г.Шәрәфләр белән бергә, Казанның Зур театрында француз композиторы Ш.Гунонның «Фауст» операсын карый.

В.Бәхтияровның истәлекләрендә Тукайның опера арияләренә караганда халык җырларын күбрәк яратуы турында әйтелә. Яраткан җырлары итеп «Уел», «Ашказар», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Порт-Артур», «Әминәкәй гүзәлем» кебек халык җырлары китерелә.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр.*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 26-эш.*

Казан губерна жандарм идарәсенә «Перс» яшерен имзасы белән ялланган шымчы Г.Тукай турында донос кертә. Шагыйрь-

нең хөкүмәткә дошманлык белән сугарылган шигырьләре Чистай мәдрәсәләренә таратылуы, шәкертләрнең шуларны укулары турында яза. «Китмибез» шигырен мисал итеп китерә.

*ТРМА. 199-ф., 1-тасв., 3458-эш, 43—44 б.*

**Яз.** Г.Тукай Ф.Әмирхан белән бер очрашу вакытында аңа эч серен ача: «Мин үзем килеп эләккән кругымнан разый түгел. Мин Казанга килгәннән бирле соң дәрәҗәдә эшлексезләндем. Минем бүлмәдә көне-төне буе вакытларыны кайда куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар...» «вә сүзенең хатимәсендә үзенең эш эшлисе килгәнене, бу эшсез, «идеалсыз», «чиле-пешле» кешеләр тирәсеннән котылырга теләгәнене... бәян итте».

*Әмирхан Ф. Тукай тугрысында искә төшкәннәр. «Истәлекләр», 121 б.*

**7 март.** «Сабах» нәшрияты җитәкчесе Хәбибрахман Зәбири Оренбургка «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәримигә хат яза. Хатында ул, мохтаҗлыкта яшәүче Г.Тукайга ярдәм итәргә, әгәр дә аңа матди һәм мәгънәви ярдәм ителмәсә, татар халкы үзенең бер шагыйрен югалтырга мөмкин, дигән фикер әйтә.

*Таҗетдинов Н. Яңа табылган бер хат турында. «СӘ», 1964, 1 нче сан, 138—140 б.*

**7 март.** Яңа клубта Шәрык музыкасы кичәсе була. Казан зыялы яшьләре оештырган бу кичәдә татар, башкорт, казакъ, үзбәк көйләре башкарыла.

Икенче бүлектә Г.А.Трейтер ханым борынгы татар көйләрен җырлый. Трейтер ханымның онытылган татар көйләрен яңгыратуына рәхмәт белдереп, бер төркем татар зыялылары имза җыялар. Имза куючылар арасында Тукай фамилиясе беренче урында тора.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение,1986, с. 179.*

**8 март.** Ф.Әмирхан дусты Исмәгыйль Аитовка язган хатында Г.Тукай турында сүз кузгата. Аның, костюмлык материя алып, костюм тегәргә бирүе турында сөйли.

*Ф.Әмирханның Ялтага И.Аитовка җибәргән хаты, 1908, 8 март. Мирасханә. 16-ф., 3-тасв., 4-эш.*

**15 март.** Х.Зәбири киңәше белән Ф.Кәрими, Тукайның бер иптәшенә хат язып, шул хат аркылы шагыйрьне «Вакыт», «Шу-

---

Хатимәсендә — ахырында.

ра» редакциясендә эшләргә чакырган. Хатында шагыйрьгә түбәндәгеләрне вәгъдә иткән: «Ашау-эчү, фатир үземнән булып, 40 сум жалунье бирелер».

40 сум ул вакытта иң югары хезмәт хакы булып исәпләнгән. Г.Тукай Оренбургка бармаган.

*Таҗетдинов Н. Яңа табылган бер хат турында. «СӘ», 1964, 1 нче сан, 138—140 б.*

**17 март.** «Шагыйрь», «Шәйтанның муенына» исемле шигырьләре басылып чыккан.

*«Әл-ислах», 23 нче сан.*

**27 март.** Г.Тукай Казаннан Уральскидагы апасы Газизә Госмановага хат яза. Ул болай ди: «...дус-иш күп. Күңелле, укыган кызлар белән дә танышырга туры килде. Гәзитәләр күп, китаплар һәркөн яңадан-яңа чыгып тора. Укыймыз, үземез дә язамыз. Әле бу арада тагы бер зур гына шигырь китабы яздым**. Монысы, һәртөрле матур буяулы сурәтләр илә зиннәтләнеп, балаларга бүләк өчен язылды. Тиздән басылып чыгачак. Чыккач та Сезгә җибәрермен.

<>...Әхмәт байның угылы [Габдрахман Дәүләтшин] илә бергә «Китаб» нәшрияты** исемле бер ширкәт ясадык. Һәртөрле яңа китаплар сатып алып, үземез бастырып сатабыз. Һәркөн һәр тарафларга җибәрәбез. Мин китапларның хаталарын төзәтәм. Хак куям. Сораган кешеләргә җибәрәм. Контора минем номерымдадыр. Бу эштән дә яхшы гына акча алам... Әле Оренбурдан да мине чакырып хат килде. «Вакыт» гәзитәсендә, «Шура» журналларында эшләргә, айга 40 тәңкә жалунье бирәләр. Ләкин мин хәзергә анда бара алмыйм. Оренбур язучылары илә гәзитә аркылы бераз чәкәләшеп алган идек. Шуңа күрә алар хатны минем үземә язмыйча, бер иптәшемә язып, мине чакырганнар***.

---

* «Зур гына шигырь китабы» дигәндә Г.Тукай «Җуаныч» исемле җыентыгын күздә тота.

** В.Бәхтияров төзегән альбомда (Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш) «Китаб» нәшриятының хәзерге Профсоюз белән Куйбышев урамнары кисешкән чатта 52/15 нче йортның бер бүлмәсен алып торуы әйтелгән. В.Бәхтияров күрсәткән бу адрес элекке Уральское подворье — кече Проломный белән Балык мәйданы кисешкән чат — Степанов дигән бай йорты булган.

*** Х.Зәбири «Вакыт» газетасының 1914 елгы 19 апрель санында биргән кечкенә генә аңлатмасында: «Жәй көне булганлыктан, Г.Тукайның Ф.Әмирхан һәм В.Бәхтияровлар белән бергә дачага чыгып торасы килде. Шунлыктан Оренбургка бармады»,— дип яза. Шагыйрьнең үз сүзләреннән чыгып караганда, Х.Зәбири фикере дөреслеккә туры килми. Кәрими хатны да Зәбиригә җибәргән булуы ихтимал, чөнки ул Тукай турындагы истәлекләрендә шагыйрь белән гомере буе якын дуслык мөнәсәбәтендә торуы турында сөйли. Тукайны чакырырга кушып, Кәримиләргә дә хатны үзе яза.

«Иртәгә Казанда әдәбият кичәсе була. Анда Казанның барча мөселманнары, хатын-кызлары — һәммәсе җыела. Мин шунда үземнең «Утырышу» атлы шигыремне җырларга өстемә алдым».

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 82, 84 б.*

**28 март.** Казанда, Купеческое собрание залында, Биржа йортында үткәрелгән әдәби кичәдә Г.Тукайның «Теләнче» шигырен В.Бәхтияров, «Утырышу» шигырен Тукай үзе укый.

«Г.Тукайның укуы начар булса да, әсәре матур гына язылганга күрә, халыкка ошады»,— диелә кичә турында басылган хәбәрдә.

*«Казан мөхбире», 273 нче сан;*
*«Йолдыз», 244 нче сан.*

**3 апрель.** Ф.Әмирхан «Әдәбият кичәсе» дигән мәкаләсендә болай ди: «Утырышу»ны да мөхәррире укып, халыкның бик озак кул чабуын җәлеп итте һәм, чыгып, икенче бер кыска шигырен укырга мәҗбүр булды».

*«Әл-ислах», 25 нче сан.*

**Апрель.** Г.Тукай Г.Дәүләтшинның «Китаб» нәшриятында экспедиторлык һәм корректорлык эшен дәвам иттерә.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

**27 апрель.** «Чын вә ялган», «Күңелсез минутта» исемле шигырьләре чыга. Соңгысы «Все говорят» көе белән җырлана» дигән искәрмә һәм «Шүрәле» имзасы белән басылган. («Яшен ташлары», икенче җөзьә, Казан, «Өмид» матбагасы, 1912 исемле җыентыгында шигырьнең исеме «Бер кайгы көнендә» дип үзгәртелгән.)

*«Әл-ислах», 28 нче сан.*

**Апрельнең соңгы көннәре.** Г.Тукай якын иптәшләренең тәкъдиме белән Унъяк Кабан урамы, 15 нче йортка, бер бүлмәле фатирга күчә. Монда ул ике ай чамасы тора. Шушы фатирда аның барлык әйберләре югала. Беркөнне фатир хуҗасы, Тукайның әйберләрен җыеп алып, каядыр чыгып китә.

*Бәхтияров В. «Альбом»,1948,*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

**Май урталары.** «Әл-ислах» идарәсенә Троицки кунаклары Бибиҗиһан һәм Зәйтүнә Мәүледовалар килеп йөри. Ф.Әмирхан бу кызларны Тукай белән таныштыра.

З.Мәүледова Чистай шәһәрендә заманы өчен шактый культуралы гаиләдә үскән кыз. Г.Тукайның язганнарын яратып укы-

ган, шагыйрьнең үзе белән танышырга теләгән. Бу чибәр туташ Тукайның күңелендә яшерен мәхәббәт хисләре уяткан.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. «Истәлекләр», 79—80 б.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 150 б.*

**19 май.** «Саташкан» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басыла. Шигырь С.Рәмиевнең «Алданган» («Әл-ислах», 1908, 4 май) исемле шигыренә пародия рәвешендә язылган.

*«Әл-ислах», 30 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 371 б.*

**21 май.** «Волжско-Камская речь» газетасында А.Пинкевич имзасы белән «Очерки новейшей татарской литературы» исемле мәкалә басыла. Мәкаләдә автор, Тукаев шигырьләре форма ягыннан тел тидererлек түгел, чын шигърият тә байтак, әмма морализм һәм вәгазьчелек күп кенә шигырьләренең кыйммәтен юкка чыгара, дигән фикер әйтә.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 157 б.*

**27 май.** «Үпкә», «Истамбул шагыйрьләре», «Шекспирдан да бер сүз» исемле шигырьләре чыга. («Истамбул шагыйрьләре», «Габдулла Тукаев» диваны «Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр» (1909) дә «Мәддахе Истамбул шагыйрьләре», «Шекспирдан бер сүз» «Шекспирдан» дип үзгәртелгән.)

«Бичара Бибиҗиһан» (Дүрт пәрдәле драманы бер дә ярым шигырь белән тәнкыйть) исемле шигъри рецензия «Тәнкыйть сөюче» имзасы белән басыла. Тукай иҗатын өйрәнүче кайбер галимнәр бу псевдонимны Тукайныкы итеп күрсәтсәләр дә, ул әле нигезләнеп исбат ителмәгән. Әмма артист Касыйм Шамилнең «Тукай һәм татар театры» исемле мәкаләсендә мондый юллар бар: «Закир Сәетзадә «Бичара Бибиҗиһан» исемендә бер театр әсәре яза. Ул 1908 елның апрель аенда Казанда уйнала. Уен йомшак чыга. Тукай спектакльне карый, ләкин канәгатьләнми. Бу спектакльдән соң, 1908 елның 27 маенда «Әл-ислах» газетасының 31 нче санында «Бичара Бибиҗиһан» исемле көлке шигырен бастырып чыгара. Бу шигъри рецензия биш томлы «Әсәрләр» җыелмасына кермәгән.

*Шамил К. Тукай һәм татар театры. «Габдулла Тукай», 1948, 103 б.*

---

Мәддахе Истамбул шагыйрьләре — мактап кына язучы Истамбул шагыйрьләре.

**Җәй.** Г.Тукай, Уңъяк Кабан урамы, 15 нче йорттагы фатирында әйберләрен югалтканнан соң, Ботан бакчасына* каршы Лозовский урамындагы йортка күчеп килә. Бу Ф.Әмирхан белән В.Бәхтияровның җәйге дача өчен алган йортлары, вакытлыча «Әл-ислах» газетасы редакциясе дә шушында күчә. Җәйне Тукай әлеге йортта үткәрә, көзен яңадан «Болгар»га кайта. «Альбом»да бу йортның фоторәсеме урнаштырылган.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

**3 июнь.** «...гә (Мәслихәт)», «...гә (Бай баласы бит...)», «...гә (Очраган юлда...)» шигырьләре «Шүрәле» имзасы белән басыла. Истәлек авторлары һәм әдәбият белгечләре бу шигырьләрнең З.Мәүледовага багышланган булуы турында әйтәләр.

*«Әл-ислах», 32 нче сан;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 151 б.*

**9 июнь.** Г.Тукай «Китаб» нәшрияты хуҗасы Габдрахман Дәүләтшинга хат яза: «Сезгә актык мәртәбә мөрәҗәгать итәм: әгәр Сездә миңа тиешле акча, үзеңез әйткәнчә, беткән булса да, пожалуйста, Сез хәзер 25 сум акча биреп йибәреңез әле. Мин Сезгә, вәгъдәм буенча, тиздән бер китап бирермен».

Хатыннан күренгәнчә, Г.Тукай «Китаб» нәшриятында июнь аенда эшләмәгән инде, ул моннан апрель ахырларында ук чыккан булырга мөмкин. В.Бәхтияров истәлекләреннән шул аңлашыла.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 85 б.*

**10 июнь.** «Волжский листок» газетасы сәхифәсендә Касыйм Уралец дигән берәү «О татарских поэтах» исемле мәкалә язып, А.Пинкевичка каршы чыга, А.Пинкевичны татар әдәбиятын белмәүдә гаепли. Тукайны тәрҗемәче генә, дип бәяли. Ун-унбиш оригиналь шигыре булып, калганнары Пушкин, Лермонтовтан тәрҗемә генә, шигырьләрендә рус һәм урам сүзләре күп, ди. Касыйм Уралецның кем икәне мәгълүм түгел.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 157 б.*

«Алдандым» (Лермонтовка тәкълид) исемле шигыре «Шүрәле» имзасы белән чыга. Шигырь М.Ю.Лермонтовның «К...» (Я не унижусь...) шигыреннән файдаланып язылган.

*«Әл-ислах», 33 нче сан.*

---

*Казандагы «Ботанический сад» күздә тотыла.

**12 июнь.** Г.Тукай «Кызык гыйшык» исемле шигырен яза. Матбугатта басылган нөсхәсенең ахырында «12 июнь, 1908» датасы тора.

**17 июнь.** «Кызык гыйшык» исемле шигырен «Мәҗнүн» имзасы белән бастырып чыгара. Бу имзаны Тукай шушы шигырендә генә куя, шигырь ахырына «12 июнь, 1908» дип куелган һәм ул яратып йөргән кызы З.Мәүледовага багышланган дигән караш яши.

*«Әл-ислах», 34 нче сан;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 151 б.*

Ф.Әмирхан «Дамелла» имзасы белән басылган «Татар шагыйрьләре» исемле мәкаләсендә, татар шагыйрьләре тирәсендә барган бәхәскә кушылып, Тукай шигырьләре турында А.Пинкевич фикерләренә теләктәшлек итә. Тукайны халык шагыйре итеп бәяли. Касыйм Уралецны татар поэзиясен белмәгәне, Тукай иҗатына дөрес бәя бирмәгәне өчен тәнкыйтьли.

*«Әл-ислах», 34 нче сан.*

**18 июнь.** «Волжско-Камская речь» газетасында «Татарин» имзалы берәү «Невежество или глупость?» исемле мәкаләсендә Касыйм Уралецка каршы чыга, А.Пинкевичны яклый, Тукайны чын шагыйрь дип таный. «Татарин»ның кем имзасы икәне билгеле түгел.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 158 б.*

**21 июнь.** «Чүкеч»тә З.Бәширинең Г.Тукайга багышланган «Мөтәрҗим шагыйрь» дигән шигыре басыла.

Түбән зәвыклы шигырьләр язганы өчен, З.Бәшири Г.Тукай һәм Ф.Әмирханнардан шактый тәнкыйть сүзләре ишетә, ул бу тәнкыйтьне кичерә алмый.

З.Бәшири «Чүкеч» журналының җаваплы секретаре булып торганда (1908 ел, 57 саныннан, октябрь аеннан), Ф.Әмирхан, Г.Тукай эшләгән «Әл-ислах» газетасы белән «Чүкеч» арасында бер-берсен чеметеп алулар еш кабатлана. Әлеге шигырьдә дә З.Бәшири Тукайны «тәрҗемәче» генә дип атый, аның шагыйрьлек дәрәҗәсен төшерергә тырыша.

Син дә Пушкин, Лермонтовның
Бозгалап шигырьләрен,
Шатланасың, түшне киереп,
Мин дә бит шагыйрь, диеп,—

дигән кимсетү сүзләре әйтә.

*«Чүкеч», 50 нче сан.*

Тукайның биш томлы «Әсәрләр»ен төзүче Р.Гайнановның язуына караганда, Г.Тукайның «Җавап» шигыре (1908) З.Баширинең шушы сүзләренә җавап рәвешендә язылган.

**23 июнь.** Г.Тукай Казаннан Серноводскида дәваланучы Ф.Әмирханга хат яза.

Хатта: «Әл-ислах»та «Кызык гыйшык» шигырен яраттыңызмы? Керпе үзенең кабыгына яшеренгән төсле, мин дә сөю хакында бернәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам».

«...Торам-торам да: «Рабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәләрендә черүләр арасында да саклап килдекем истигъдад очкыны шушы исереклекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?» — дим. Тәмам бер сәнә җон агызып йөрим бит!

Бу хәл туйдырды инде тәмам. Оренбургка Фатыйх Кәримов чакырган иде. Анда барсам, бәлки, үземә мөгаййән эш булуы һәм серьезный кешеләр тирәсе файдалы булыр иде, дим. Нишлим? Барыйм микән?

Монда «Әл-ислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем»,— дигән юллар бар. (Тукай Оренбургка «Вакыт» гәзитәсендә эшләргә бармаган.)

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 87 б.*

**28 июнь.** «Өмид» исемле шигырен яза. Шигырьнең матбугатта басылган нөсхәсенең ахырына «28 июнь, 1908 сәнә, Г.Тукаев» дип куелган.

**2 июль.** «Өмид» исемле шигыре басылып чыккан.

*«Әл-ислах», 36 нчы сан.*

**13 июль.** «Тормыш», «Тешләре ямьсез бер матурга» исемле шигырьләре басыла. Соңгысы «Шүрәле» имзасы белән чыга.

*«Әл-ислах», 37 нче сан.*

**13 июль.** Ф.Әмирхан «Татар шагыйрьләре» исемле мәкаләсенең соңгы өлешендә дә Касыйм Уралецның Тукай иҗатын бозып күрсәтүенә ризасызлык белдерә.

*«Әл-ислах», 37 нче сан.*

---

Истигъдад — талант.
Мөгаййән — билгеләнгән.
Калеб — күңел.

**20 июль.** «Кулын» (Мактый беләм микән, дип кенә мактаган) исемле шигыре басылган.

В.Бәхтияровның язуына караганда, шигырь Зәйтүнә Мәүледовага багышланган.

«Мөхәммәдия»дән» дигән шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган.

Тел галиме Бәкер Яфаров «Тукай сатира һәм пародияләренең әдәби антиподларына карата» исемле мәкаләсендә «Бу шигырь Мөхәммәд Чәләбинең (XV йөздәге төрек шагыйре) «Мөхәммәдия» китабындагы Ифтитах рисаләи «Мөхәммәдия» бүлеге тезмәсенә пародия» дип яза.

*«Әл-ислах», 38 нче сан;*
*Бәхтияров В. «Истәлекләр», 80 б.;*
*Яфаров Б. Тукай сатира һәм пародияләренең... «Габдулла Тукай», 1948, 132 б.*

**27 июль.** «Күк сыер» шигыре «Ахыры бар» дигән искәрмә белән чыккан, ләкин ахыры күренми.

*«Әл-ислах», 39 нчы сан.*

**Июль ае.** Демократик яшьләр органы «Әл-ислах» газетасы редакциясе «Болгар» номерларыннан хәзерге Тукай урамы, 63 нче йортка күчә (Ф.Әмирханның җизнәсе Шәкүр Аппаков йорты). Тукай бу йортка һәр көн килә, кайвакыт бөтен көнен диярлек идарәханәдә үткәрә. Газетада эшләү өстенә, кайсы вакытта идарәханәгә кесәсенә кузна тутырып килә дә, йорт хуҗасының балаларын алып чыгып, кузна уйный.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш;*
*Әмирхан Ә. Тукай турысында искә төшкәннәр. «Истәлекләр», 122 б.*

**Июль ахыры.** Тукай Кабан күле буендагы йортта яшәүче руслашкан немец хатыны Мария Карловадан унбиш-егерме көннәр немец теле дәресләре ала. Рус һәм Көнбатыш әдәбиятыннан киң мәгълүматлы булган бу хатын йортында С.Рәмиев кебек яшьләр катнашында әдәбият кичәләре дә үткәрелә, бәхәсләр оештырыла.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

**3 август.** Казанда Г.Тукайның сатирик таланты үсүгә зур этәргеч ясаган рәсемле сатирик «Яшен» журналының беренче

---

Ифтитах рисаләи «Мөхәммәдия» — «Мөхәммәдия» китабына кереш.

саны чыга (1909 елның июнь аенда туктала). Нашире һәм мөхәррире — Г.Камал. Секретарьлык эшен Г.Тукай алып бара. «Журналның беренче номерында башыннан ахырына кадәр Тукайның каләме йөри»,— ди Г.Шәрәф.

Бу беренче санда Тукайның түбәндәге шигырь һәм мәкаләләре басылган: «Яшен» журналы хакында» шигыре журналның чыга башлавын котлап язылган.

«Тотса мәскәүләр якаң» («Бакырган»нан) шигыре «Гөмберт» имзасы белән чыккан. Бу имзаны Тукай беренче мәртәбә шушы шигырендә куллана.

Тел галиме Бәкер Яфаров «Тотса мәскәүләр якаң» шигырен «Бакырган» китабындагы бер тезмәгә пародия, әлеге санда «Шүрәле» имзасы белән басылган «Осуле кадимче» поэмасын Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабындагы «Сәбәбе тәэлифе китабы «Мөхәммәдия» исемендәге тезмәсенә пародия рәвешендә язылган, дип күрсәтә.

Имзасыз урнаштырылганнары:

***(Руслар эш күрәләр...) шигыре — «Яшен»нең беренче битендә рәсем астында тора. «Яңа гәзитәләр» «Казан хәбәрләре» бүлегендә басылган.

«Гәзитәләрдән» (1), «Казанда базар бәһаләре», «Август башы». Бу мәкаләчекләрдән соңгысының ахырына «1908 ел, август» дип куелган. Ул «Яшен» журналы чыга башлау белән аның программасы рәвешендә язылган: «Яшен»нең сугуыннан милләт җилкәсене кимерүче профаннар, үзене шәп кеше итеп йөрүче саламторханнар, җәмәгать хакына кул сузган куштаннар, һәрбер сорыкорт дошманнар, мәктәп-мәдрәсәләрне бикләп, ялкауланып ятучы муллалар, эшсез ятучы мирзалар, хыянәтче байларның һичберсе имин дәгелләрдер»,— диелгән.

«Дөньяда ахмаклар күпме?» «Ләтыйфа» бүлегендә басылган.

«Сыбызгы» «Карамзин (Франклиннан)» дип куелган. Хикәячек Н.М.Карамзинның «Свисток» дигән әсәреннән ирекле тәрҗемә. Карамзин исә аны инглиз сәяхәтчесе һәм Котыпны өйрәнүче Джон Франклинның бер хикәясеннән файдаланып язган.

*Шәрәф Г. Тукай тугрысында истә калганнар. «Яшен», 1 нче сан;*
*«Истәлекләр», 111 б;*
*Яфаров Б. Тукай сатира һәм пародияләренең әдәби антиподларына карата. «Габдулла Тукай», 1948, 132—133 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 296 б.*

---

«Сәбәбе тәэлифе китабы «Мөхәммәдия» — «Мөхәммәдия» китабының язылу сәбәбе.

**5 август.** Г.Тукай Г.Камал белән бергә Мәкәрҗә (Нижний Новгород) ярминкәсенә бара. «Сәйяр» труппасы белән берлектә ярминкәдә урнашкан «Двухсветная» дип йөртелгән кунакханә залында концерт куюга катнаша. Хор чыгышында капельмейстер-дирижер ролен үти. Ул бу концертлардан ризасыз кала. Соңыннан анда катнашуы өчен үкенә.

*Кариев Г. Тукай Мәкәрҗәдә. «Истәлекләр», 93—95 б.;*
*Камал Г. Габдулла Тукай турында истәлек. «Истәлекләр», 73—74 б.*

**6 август.** «Кемнән ярдәм эзләргә?» (Майковтан тәрҗемә) шигыре басылган. Шигырь А.Н.Майковның «Советы» (немец шагыйре Һ.Һейне буенча) исемле шигыреннән файдаланып язылган.

*«Әл-ислах», 40 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 378 б.*

**14 август.** Ф.Әмирхан «Авырулар галәмендә (Посвящаю г-же Э.К.)» исемле мәкаләсе эченә Г.Тукайдан алынган:

Уянды хандра күңлемдә инде,
Караңгылык күңелдә нурны җинде, —

дигән юлларны керткән. Бу шигъри юллар Г.Тукайның Ф.Әмирханга 1908 елның 23 июнендә язылган хатында әйтелгән.

*«Әл-ислах», 41 нче сан.*

«Әл-ислах» газетасы игъланнар бүлегендә хәбәр итә: «Гәзитәмезнең даими язышучыларыннан Габдулла әфәнде Тукаев августның 5 еннән бирле Нижнийда (Нижний Новгород) торып, августның 17 ләрендә Казанга кайтачак».

*«Әл-ислах», 41 нче сан.*

**18 августтан соң.** Г.Тукай Казанда «Сәйяр» труппасы куйган «Бәхетсез егет» (Г.Камал) спектаклен карый. «Кариевның Кәрим бай, Сәхипҗамал Гыйззәтуллинаның Гайни, Фәйзуллин-Болгарскийның Мәгъри карчык ролендә уйнауларын һәрвакыт искә алып сөйли иде»,— ди артист Касыйм Шамил.

*Шамил К. Габдулла Тукай һәм татар театры. «Габдулла Тукай», 1948, 202 б.*

**31 август.** Гыйльметдин Шәрәф туганы Борһан Шәрәфкә (Оренбургка) язган хатында Г.Тукайның Мәкәрҗә ярминкә-

сеннән әйләнеп кайтуы һәм «Болгар» номерларында яшәве турында хәбәр итә.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1985, с. 174.*

**Сентябрь башы.** Казанга, Никитин циркына Карахмәт дигән көрәшче килә. Ул «Болгар» номерында Тукайдан берничә номер аркылы гына тора. Аны күрү Тукайга мәдрәсәләрдә укылып йөргән «Иске Кисекбаш» китабын искә төшерә. Китапны яңадан укып чыгу «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын язуга этәргеч ясый. Поэма язылып беткәч, Тукай аны «Яшен» журналында бастырырга уйлый. Ләкин иптәшләре аңа бу зур поэманы журналда бүлеп-бүлеп чыгармаска, башта ук аерым китап итеп бастырырга киңәш итәләр. «Тукайның әлегә кадәр басылган егермегә якын әсәрләре эчендә беренче чыгуында ук иң күп таралганы «Печән базары...» булды»,— ди Г.Шәрәф.

*Шәрәф Г. Тукай турысында истә калганнар. «Истәлекләр», 111—113 б.*

**8 сентябрь.** «Бер рәсемгә (Төрекләргә тәкълид)» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган.

*«Әл-ислах», 44 нче сан.*

**10 сентябрь.** «Яшен»дә «Мулланың зары («Мелла Насретдин»нән)» исемле шигыре чыккан.

Тукай аны азәрбайҗан әдәбияты классигы Сабирның «Мелла Насретдин» журналында басылган «Шикаять» (1908) шигыреннән файдаланып язган.

Мәскәү дәүләт университеты профессоры Азиз Шәриф «Абдулла Тукай и Сабир» исемле мәкаләсендә болай ди: «По характеру своего поэтического творчества и по индивидуальному жизненному пути Сабир и Тукай очень близки друг к другу. Они не встречались, но не подлежит сомнению, что знали друг-друга по печатавшимся в те годы в газетах и журналах стихотворениям».

«Авыл җырлары» (һәртөрле көйгә килә. Беренче көлтә) «Шүрәле» имзасы белән басылган. Ахырга «Беренче көлтә тәмам. Киләчәк номерларда икенче вә өченче көлтәләр дә бәйләнеп басылсалар кирәк» дигән искәрмә бирелгән.

«Хикәя» исемле әсәре («Ахыры булачак» дип куелган булса да, ахыры күренмәде), «Сөальләр» мәкаләсе, «Кирәкле игъланнар», «Төрлечә дөнья тану», «Кирәкле нәсихәтләр» фельетоннары имзасыз чыккан. Соңгы фельетонда: «Әгәр бервакытта берәр төрле начар эш эшләнгән, дип язарга тугры килсә, зинһар, «вакытта» дип яза күрмә, «заманда» дип яз, чөнки «вакыт» дисәң, мәшһүр «Вакыт» гәзитәсе, мине язган икән дип, әти булып вәгазьләр бирә башлар».

Бу — Тукайның Дәрдмәнд шигыреннән («Шагыйрь») һәм «Вакыт» редакциясенең «Аңлашуның җавабы»ннан алган тәэсирләрен һаман оныта алмавы турында сөйли.

*«Яшен», 2 нче сан;*
*Шариф А. Абдулла Тукай и Сабир. «Габдулла Тукай» (Сборник статей), 1968, с. 77.*

**15 сентябрь.** «Киңәш» исемле шигыре чыга.

*«Әл-ислах», 45 нче сан.*

**20 сентябрь.** «Ай башы», «Мөһим игъланнар» исемле кечкенә мәкаләләре имзасыз басылган.

*«Яшен», 3 нче сан.*

**23 сентябрь.** «Ташмөхәммәд» имзасы белән басылган «Зыялы шәкерт» исемле фельетонда Ф.Әмирхан Г.Тукайның «Дөньяда торыйммы?» — дип киңәшләшкән дустыма» (1907) дигән шигыреннән түбәндәге өзекне китерә:

Эчтән динсез булып, тыштан «дин», «дин» дисәң,
Ярлыларны дошман күрмәк диндин дисәң,
Мин мәсләкле, мин мәзһәбле, мин эшлекле,
Һәр артыклыкның чишмәсе «мин», «мин» дисәң.

*«Әл-ислах», 46 нчы сан.*

**23 сентябрь.** «Әл-ислах»та «Шатлык вә хәсрәт» (Плещеевтан)» дигән шигыре чыга. «Шигырь рус шагыйре А.Плещеевның «К чему мечтать о том, что после будет с нами» дип башланган шигыреннән файдаланып язылган булса кирәк»,— ди биш томлы «Әсәрләр» җыелмасын төзүче Р.Гайнанов.

«Улмы? — Ул...» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басыла. Соңгысы турында В.Бәхтияров болай ди: «...Бәянелхак» (Тукай «Бәянел-шап» дип атый иде) газетасының секретаре, тырышып-тырышып шагыйрь булырга йөрүчеләрнең берсе, яшьләр арасында яхшы танцевать итүе белән атказанган Рәкыйпов* (Урал ягыннан килгән) турында Тукай үзенең «Улмы? — Ул...» шигырен яза».

*«Әл-ислах», 46 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 382—383 б.;*
*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. «Истәлекләр», 82 б.*

**30 сентябрь.** Шагыйрь Габдулла Биги (Мостакаев)нең «Г.Тукаев җәнабләренә тәкълид» диелгән «Кечкенә фельетон»ы

* Рәкыйп Габдерәкыйпов, Рәкыйп Рәкыйби (1887—1963) — журналист.

басылган. Шигъри тезмә Г.Тукайның «Дөньяда торыйммы?» — дип киңәшләшкән дустыма» (1907) исемле шигыренә ияреп язылган. Мисал өчен бер строфа:

Һәр укыган нәрсәләргә риза булсаң,
Сүзләренә иярсәң дә бозау булсаң,
Намаз укып, тәмам иткәч, кул күтәреп,
Егълый-егълый анлар өчен дога кылсаң.

*«Әл-ислах», 47 нче сан.*

**30 сентябрь.** «Яшен»дә «Авыл җырлары (икенче көлтә)» «Шүрәле» имзасы белән басылган. Ахырга: «Өченче вә дүртенче көлтәләре дә бәйләнмәктә. Идарә»,— дип куелган, ләкин болары чыкмаган.

«Лөгатьләр», «Чыбыксыз телеграм хәбәрләре» имзасыз, «Йокы» (Сәгыйть Рәмиевтән үзгәртелде) исемле шигыре «Сәгыйть» имзасы белән басылган.

Соңгы шигырьгә түбәндәге аңлатма бирелгән: «Идарә. Югарыдагы шигырьләрдә яңлышлык илә «уку» диясе урыннарда «йокы» дип язылган. Яңадан дөреслəп укуыңызны риҗа итәмез. Әгәр дә йокы шулкадәр яхшы эш булса иде, безнең татарлар күптән алга киткән булыр иде».

Шигырь С.Рәмиевнең «Уку» («Әл-ислах», 1907, 30 октябрь) исемле шигыренә пародия рәвешендә язылган.

«Нәҗип Ломовой шигырьләре» исемле мәкаләсе «Бичура» имзасы белән басылган.

Тукай иҗатын өйрәнгән мәрхүм галим Рөстәм Башкуров «Тукай иҗатына караган материаллар» исемле мәкаләсендә «Бичура» псевдонимын һәм бу мәкаләнең Тукайныкы булуын исбат итә.

Мәкалә «Нәҗип Думави шигырьләре» (6 нчы дәфтәр. Казан, 1908) исемле җыентык турында язылган. «Мәкаләдә Думави шигырьләрендә чагылган төшенкелек, пессимизм, тормыштан ваз кичү идеяләре, ул шигырьләрдәге формалистик күренешләр тәнкыйть ителә»,— ди Р.Башкуров.

*«Яшен», 3 нче сан;*
*«СӘ», 1956, 4 нче сан, 102—104 б.*

«Нәҗип Ломовой шигырьләре» Г.Тукай «Әсәрләр»е җыелмаларына кермәгән. Соңгы биш томлы «Әсәрләр»не төзүче Р.Гайнанов «Бичура»ны Тукайның яшерен имзасы түгел дигән карашта торган. Библиограф М.Бурнашева «Псевдонимнар турында» исемле мәкаләсендә («СӘ», 1960, 8 нче сан, 152 б.) «Бичура» им-

---

Риҗа итәмез — үтенәбез.

засын Тукай псевдонимнары рәтендә саный. Бу хезмәтне төзүче үзе дә Р.Башкуров, М.Бурнашева фикерләренә кушыла.

**13 октябрь.** «Төлке һәм Йөзем җимеше» исемле мәсәле чыккан. Әсәр И.А.Крыловның «Лисица и Виноград» исемле мәсәленнән файдаланып язылган. Шунда ук «Бәйрәм бүген» шигыре урнаштырылган.

*«Әл-ислах», 48 нче сан.*

«Әл-ислах»ның 48 нче санында Купеческое собрание залында 14 октябрьдә булачак әдәбият кичәсенең программасы басылган. Кичәдә Г.Тукайның «Кызык гыйшык» һәм «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын укыячагы әйтелгән.

*«Әл-ислах», 48 нче сан.*

**14 октябрь.** Г.Тукай «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын Купеческое собрание залында «Әл-ислах» газетасы файдасына уздырылган әдәби-музыкаль кичәдә укый.

«Халык, җөмлә тәмам булганын да көтә алмыйчан, самими бер көлкегә тотылып, бөтен залны тутырып кул чабалар һәм, укучыны бүлеп, әллә никадәр вакытлар туктап торырга мәҗбүр итәләр иде»,— ди Ф.Әмирхан «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» исемле мәкаләсендә.

*«Әл-ислах», 52 нче сан.*

Г.Шәрәф тә «Тукай тугрысында истә калганнар» дигән истәлегендә тамашачыларның кичәдән канәгать булып калулары, поэманы бик яратулары турында яза.

*«Истәлекләр», 113 б.*

**22 октябрь.** «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасы аерым китап булып басылып чыга («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 7 нче дәфтәр). Казан, И.Н.Харитонов лито-типографиясе (тышлыкның 4 нче битендә Шәрәф типографиясе, 1908).

Поэма XIII йөз шигъри ядкярләреннән «Кисекбаш китабы»на назыйрә (охшату) рәвешендә язылган.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 109-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

«Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасының типографиядә басылган данәләре цензура аркылы үтә.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 177—178 б.*

**26 октябрь.** Ф.Әмирхан Оренбургка дусты Исмәгыйль Аитовка Казаннан хат җибәрә. Хатында әдәбият кичәсе булуы

турында яза. «Әдәбият кичәсендә Тукаевның «Кисекбаш»ы укылды (үзе укыды). Халыкның көлә-көлә эчләре катты һәм Тукаевны да бүлә-бүлә кул чабу белән сыйладылар».

Хат иясе 14 октябрьдә Купеческое собрание залында булган кичәне искә ала.

*Әмирхан Ф. Әсәрләр.*
*Дүрт томда. 4 т., 1986, 259 б.*

**2 ноябрь.** «Йолдыз» газетасы берничә санда түбәндәге игъланны урнаштырган: «Г.Тукайның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» китабы басылып чыкты».

*«Йолдыз», 324 һәм 326 нчы саннар.*

**5 ноябрь.** «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» нам мәшһүр шагыйрьләремездән Габдулла Тукаевның әсәре бу көннәрдә басылып чыкты».

*«Әл-ислах», 50 нче сан.*

«Яшен»дә «Төрле хайваннар тугрысында бераз мәгълүмат («Хәятел хайван»нан)» фельетоны «Хәятел хайванаттан күчерүче» имзасы белән басылган.

«Хәятел хайван» — «Хайваннар тормышы» 1900 елда Казан университеты типографиясендә басылган китап.

Фельетонда шагыйрь З.Бәшири, дин галиме, «Өлфәт» газетасын оештыручы Р.Ибраһимов, Һинди Минһаҗ һ.б. тәнкыйть ителә.

«Төшемдә күргәннәрем» исемле фельетоны «Шүрәле» имзасы белән чыга. «Ахыры киләчәк номерда» дип куелган. Ахыры күренмәде.

Фельетонда Г.Тукай З.Бигиевнең «Катилә» һәм «Мөртәт» исемле әсәрләренең үз вакытында басылмый калуларына борчылу белдерә һәм болай ди: «Аһ, әдәбият бәһарымызның иң әүвәлге чәчәкләре! Ник алай кояш төшмәгән җирдә яталар икән!»*

«Мин шушылар илә милләтче» фельетоны «Милләтче» (бу имзаны Тукай шушында гына куллана), «Мәкальләр» фельетоны имзасыз басылган.

*«Яшен», 4 нче сан.*

«Кисекбаш»ка гыйлавә» шигыре басыла. «Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренмәде.

*«Әл-ислах», 50 нче сан.*

---

Б ә һ а р ы м ы з н ы ң — языбызның.

* Соңгы вакытта татар әдәбияты галимнәре бу әсәрләрнең «Зур гөнаһлар» романының икенче төрле исемнәре генә булуын ачтылар. (Кара: Хафизов С.Х. XIX йөз татар прозасы. Уфа.— 1979.)

**8 ноябрь.** «Җуаныч» исемле китабы басылып чыга («Мәктәп мөкяфәте»ннән беренче китап). Казан, «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы, 1908. Эчтәлеге: «Су анасы (Бер авыл малае авызыннан)», «Таз (Бер авыл малае авызыннан)», «Ата илә бала (Кара такта янында)», «Яхшы хәбәрләр», «Тургайлар ашыймыз» (Хикәя).

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 109-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

**14 ноябрь.** «Алтын әтәч» исемле китабы басылып чыга («Мәктәп мөкяфәте»ннән икенче китап). Казан, «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы, 1908 (тышлыкта 1909). Китапның тышлыгында искәрмә рәвешендә «Пушкин хикәясеннән алынды», титул биттә (өстә) «Пушкинның хикәясеннән алынмыш», беренче битнең астөшермәсендә «Пушкинның «Сказка о золотом петушке» нам хикәясеннән алынмыш» дип язылган.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

**24 ноябрь.** Ф.Әмирханның «Печән базары, яки яңа Кисекбаш» исемле бәяләмәсе «Дамелла» имзасы белән басыла. Ул поэманың аерым китап булып басылып чыгуы уңае белән язылган.

«...бу әсәр татар әдәбиятында шигырь белән язылган көлкеләрнең иң мөкәммәл вә максудына иң муафыйк чыкканыдыр. Тукаев монда Печән базары мәгыйшәтенең иң садә вә иң горфи генә эшләрен дә шулкадәр көлкеле итеп тасвир итә»,— ди Ф.Әмирхан һәм Тукайны «татар галәменең иң оста юмористы» дип атый.

*«Әл-ислах», 52 нче сан.*

**24 ноябрь.** «Соңра (Лермонтовтан үзгәртелгән)» исемле шигыре басыла. Шигырь М.Ю.Лермонтовның «Ответ» шигыреннән файдаланып язылган.

*«Әл-ислах», 52 нче сан.*

**29 ноябрь.** «Вакыт» газетасы игъланнар бүлегендә хәбәр итә: «Басылып чыкты: «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш», Г.Тукаев әсәре, Харитонов матбагасы».

*«Вакыт», 401 нче сан.*

**Ноябрь.** «Кемгә нинди һөнәр җитә?» исеме астында Казанның атаклы кешеләренә шаржлар басылган. Авторы күрсәтелмәгән. Анда: «Шүрәле» әфәндея Уральскидан алып килгән агач аты илә Казанда, Болак күпере астында Сабан туе ясап,

---

Горфи — гадәти.

Печән базарына мәрсия яза белсә, шул җитә»,— дигән юлларны укыйбыз. «Шүрәле» имзасы белән бу вакытта Тукай гына язган. Шуннан чыгып караганда бу шарж юлларын Тукайга багышланган дип әйтергә кирәк.

*«Чүкеч», 59 нчы сан.*

**7 декабрь.** «Габдулла әфәнде Тукаевның мәктәп балалары өчен «Җуаныч» исемле рисаләсе Харитонов матбагасында басылып чыкты».

*«Йолдыз», 339 нчы сан.*

**11 декабрь.** Г.Камалның «Яңа әсәрләр» (Балалар дөньясы...) исеме белән чыккан рецензиясендә Г.Тукайның «Җуаныч» исемле китабы турында: «...шәкертләрнең һәм ибтидаи мәктәпләрдә укучы яшь балаларның мәгълүматларын арттыру өчен хили гүзәл әсәрдер»,— диелгән.

*«Йолдыз», 341 нче сан.*

**13 декабрь.** Г.Тукайның «Җуаныч» исемле җыентыгы һәм Исмәгыйль бәк Гаспринскийның 25 еллык хезмәтенә ядкяр буларак, З.Бәшири төзегән шигырь («Язгы кояш», 1908) мәҗмугасы турында «Ике әсәрләр» исемле имзасыз кечкенә рецензия басылган. Рецензиядә «Җуаныч»ка мондый бәя бирелгән: «Теле йиңел, мөндәриҗәсе кызык вә шул сәбәпле балаларга укырга муафыйктыр.

Мәдәни милләтләрдә балаларның зиһен вә фикерләрен ачуга, әхлак вә табигатьләрене төзәтергә хезмәт итүче, анларга махсус тәртип иделмеш йиңел вә кызыклы хикәя вә кыйраәт китаплары бик күптер. Бездә исә ушбу «Җуаныч» рисаләсе бу юлга керергә капу ачдыкы өчен «Сабах» көтепханәсенә тәшәккер улыныр». Имзасыз басылган.

*«Вакыт», 407 нче сан.*

**17 декабрь.** «Нәрсәдән?» шигыре «Кырмыска», «Фәләннең фәләне» шигыре һәм «Словарьдан фал ачу» фельетоны «Гөмберт» имзасы белән басылганнар. «Фәләннең фәләне» шагыйрьнең «Әсәрләр» җыелмаларына керми калган.

*«Яшен», 5 нче сан.*

**Декабрь урталары.** «Хөсәен Әбүзәров («Таң мәҗмугасы»ның мөхәррире) үзенең квартирасында (Дегтярный урамын-

---

Мәрсия — мактау шигыре, ода.
Ибтидаи — башлангыч.
Хили — шактый.
Кыйраәт — уку.
Тәшәккер улыныр — рәхмәт әйтелер.

да, хәзер ул йорт урынында бакча) яшьләр мәҗлесе ясый. Мәҗлестә Ф.Әмирхан, Г.Тукай, С.Рәмиев, В.Бәхтияровлар була. Матур тавышлы С.Рәмиев мәҗлестә «Әминәкәй гүзәлем», «Ашказар», «Әллүки» һ.б. борынгы татар көйләрен җырлый. Тукай бик бирелеп тыңлап утыра. С.Рәмиевнең җырлавын бик ярата, аны «татарның Шаляпины» дип атый иде. С.Рәмиев җырлаган моңлы көйләр тәэсирендә Г.Тукайның «Милли моңнар» (1909) шигыре туа. «Тукай искиткеч зиһен иясе иде. Ул бер әсәрне укыса яки күз генә йөртеп чыккан кебек күренсә дә, ул аны (бигрәк тә шигырьләрне) күңеленә алган, ул аны ятлаган була.

Кабатлап уку, яхуд ятка алу өчен берничә мәртәбә карап чыгу аңарда юк иде»,— дип искә ала В.Бәхтияров.

Истәлек иясе тагын шуны өсти: «Тукай халыкка үз вакытында әдәби тәнкыйть аша түгел, ә шигырьләренең телдән-телгә күчеп йөрүе аша танылды».

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 29 — 34-эшләр.*

**21 декабрьгә кадәр.** «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасының икенче басмасы чыга («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 7 нче дәфтәр). Казан, И.Н.Харитонов литотипографиясе (тышлыкның 4 нче битендә Шәрәф типографиясе), 1908.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 109-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

**21 декабрь.** «Бу көннәрдә мәшһүр шагыйремездән Г.Тукаевның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» әсәре басылып чыкты. (Игълан поэманың икенче басмасы чыгу уңае белән бирелгән.)

*«Әл-ислах», 54 нче сан.*

**Ел дәвамында.** Г.Тукай «Тәүлек» исемле шигырен «Бәянелхак» газетасы чыгарган «Мәгълүмат» (1908) исемле игълан-рекламалар җыентыгында «Кәрван чәй» фирмасының рекламасы рәвешендә бастырган. Әлеге чәй фирмасын мактап язган бу шигырь өчен ул «Бәянелхак» газетасыннан 25 сум акча алган.

*Бәхтияров В. Тукай турында кайбер истәлекләр. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 26-эш.*

Галиәсгар Гафуров-Чыгтай «Галинең алтмыш еллык истәлеге» дип аталган очеркында түбәндәге фикерне әйтә: «Гасыр» нәшрияты «Тутам» рисаләсенең икенче кисәген чыгарганда, бу рисаләне Тукай тәкъдиме белән сатып ала». (Хикәянең беренче кисәге 1907 елда Оренбургта, икенче кисәге 1908 елда Казанда дөнья күрә.)

*Гайнуллин М. Татар әдипләре, 1978, 135 б.*

«Сабах» көтепханәсе хуҗалары В.Әхмәдуллин, Х.Зәбири, Ш.Әхмәровлар китапчылыктан файда аз дип, сабын остасы алып, сабын кайнатып, аны көтепханәнең бер почмагында сата башлыйлар. Тукай моны күрә дә:

Япуннар туп атмыйдыр, төтене җиргә ятмыйдыр,
Ялган сүздер, ышанмагыз, «Сабах» сабын сатмыйдыр,—

дип җыр чыгара.

*Бәхтияров В. Тукай турында истәлекләр. Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 35-эш.*

Г.Тукай Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә атнага яки унбиш көнгә бер мәртәбә җыела торган әдәбият түгәрәге утырышларына катнаша.

*Шакиров З. Мин география укытканда. «Тукай Башкортстанда», 1966, 36 б.*

Г.Тукай фоторәсемгә төшкән:
а) Тукай Ф.Әмирхан белән;
б) Тукай берүзе;
в) Тукай «Әл-ислах» идарәсендә. Уңнан сулга: Г.Тукай, И.Әмирханов, Ф.Әмирхан, К.Бәкер, В.Бәхтияров;
г) Г. Тукай С.Рәмиев, Ф.Агиев белән.

*Габдулла Тукай. Фотоальбом, 1966;*
*Габдулла Тукай. «Альбом», 1978, 60, 62, 64, 67 б.*

Г.Тукай Купеческое собрание залында (хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасы) «Сәйяр» труппасы куйган «Кызганыч бала» (төрек язучысы Нәмикъ Кемаль драмасы, Г.Камал тәрҗемәсе) спектаклен карый.

*Шамил К. Тукай турында кайбер истәлекләрем. «Истәлекләр», 83 б.*

## 1909

**6—24 гыйнвар.** «Вакыт» газетасы берничә санда рәттән түбәндәге игъланны биреп барган:

«Шигырьләр көтепханәсе». 7 нче дәфтәр. Г.Тукай. «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш». Үткен телле, милләтемезнең мәшһүр шагыйрьләреннән Габдулла әфәнде Тукаев әсәре. Күпләп соратучыларга адрес: Казан, «Үрнәк» матбагасы.

Назик вә гали хисләр җырлаучы шагыйремезнең иң соңгы гүзәл шигырьләре бу мәҗмугададыр.

Назик вә гали — гүзәл һәм олы, бөек.
Мәҗмуга — җыентык.

Казан гавамына мөһим саналган хәбәрләр вә мәсьәләләр бу китапта бик килешле сурәттә җәмигъ ителеп, бик кызык көленмештер».

*«Вакыт», 415—423 нче саннар.*

**8 гыйнвар.** «...гә» (Ядкяр) шигыре басылып чыга.

Тукайның замандашларыннан К.Мостакаевның (1883—1974) истәлегенә караганда, бу шигырь Сәгыйть Рәмиевнең «Бәянелхак» газетасы хуҗалары сәүдәгәр Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләргә хезмәткә керүе уңае белән язылган.

*«Әл-ислах», 56 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 389 б.*

**14 гыйнвар.** «Габдулла Тукаев диваны» исеме белән шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр. 3 нче кыйсем, Казан, «Гасыр» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы, 48 б., 6000 данә.)

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

**15 гыйнвар.** «Вакыт» газетасында яңа китапны пропагандалап игълан-реклама урнаштырылган: «Шигырьләр көтепханәсе»ннән Г.Тукаев диваны» басылып чыкты. 8 нче дәфтәр. Назик вә гали хисләр җырлаучы шагыйремезнең иң соңгы гүзәл әсәрләре бу мәҗмугададыр».

*«Вакыт», 419 нчы сан.*

**20 гыйнвар.** «Әл-ислах» газетасы хәбәр итә:

«Гасыр» көтепханәсе ачылды! Казанда, Екатерининский урамында, Ибраһимовлар йортында*.

Хөрмәтле укучылар!

Без, ике сәнәгә якын дәвам иткән нәшрият эшемезне тагын да мөкәммәл сурәттә тәрәккый иттерергә иҗтиһад итеп, «Гасыр» көтепханәсе исемендә бер китап мәгазәсе ачарга мөвәффәкъ улдык. Нәшриятымызга матди вә мәгънәви ярдәм-

---

* Хәзерге Г.Тукай урамы, 74 нче йорт.

Г а в а м — халык.
Җ ә м и г ъ   и т е л е п — бергә тупланып.
Д и в а н — җыентык, китап.
С ә н ә — ел.
Т ә р ә к ъ к ы й   и т ү — алга китү.
И җ т и һ а д   и т ү — тырышу.
М ә г а з ә — кибет.
М ө в ә ф ф ә к ъ   у л д ы к — ирештек.

че булган мөхтәрәм укучыларга тәшәккер итеп, көтепханәмезнең ачылганыны белдерәмез.

Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкәсе».

*«Әл-ислах», 58 нче сан.*

«Гасыр» көтепханәсе Тукайның китаплары дөнья күрү һәм аның катнашында үткәреләчәк әдәби кичәләр турында игъланнарны еш бастырып торган.

«Әл-ислах» газетасы хәбәр итә: «Габдулла Тукаев диваны» басылып чыгып сатыла башлады. Киләчәк номерда мөхакәмә дәрҗ ителер».

*«Әл-ислах», 58 нче сан.*

**31 гыйнвар.** «Ахыр көрешүләр» баш мәкалә урынына имзасыз урнаштырылган.

Ул, Төркиядә буржуаз революция өчен көрәшкән «Яшь төрекләр» (чын исеме «Иҗтиһад вә тәрәкъкый») партиясе (1860—1918) илдәге барлык милләтләргә тигез хокук биреләчәк, дип вәгъдә итсә дә, 1908 елның июлендә власть башына килгәч, демократик вәгъдәләреннән ваз кичеп, буржуаз милләтчелек, пантюркистик юл белән китүеннән көлеп язылган.

«Бер яшь төрек «Хөррият игълан кыйлынды» хәбәрен ишеткәндә: «Төркиядә һәр милләтнең хокукы мөсави улыр; әрмәннәр, юнаннар, болгар — һәпсе төрекләрлә бер хокукда улачаклар; һичкемнең диненә, лисанына вә миллиятенә тәгадди иделмәз»,— дигән сүзләр илә тулы мәкалә язып утыра иде. Хәбәрне ишеткәч: «Юк, юк, мәктәбләрдә гайре мөслимләрә төрек лисани илә укыдылсын!» — диде».

*«Яшен», 6 нчы сан.*

«Яшен» журналында «Актык сүзләр» фельетоны («Гөмберт» имзасы белән), «Ну-ну-ну»* шигыре (имзасыз), «Килештерүче» дигән мәкаләсе («Шүрәле» имзасы белән) басылып чыккан.

«Актык сүзләр» 1906—1908 еллар аралыгында чыгып килгән «Милләт», «Азат», «Өлфәт», «Әхбар», «Ватан хадиме», «Азат

---

* Г.Тукайның биш томлы «Әсәрләр»ен тикшерүгә багышланган бер җыелышта И.Нуруллин бу әсәрне Г.Тукай шигыре дип басуга каршы чыкты.

Тәшәккер итү — рәхмәт белдерү.

Мөхакәмә дәрҗ ителер — рецензия басылыр.

Мөсави улыр — бертигез булыр.

Юнан — грек.

Һәпсе — һәммәсе дә.

Лисан — тел.

Тәгадди иделмәз — гаделсезлек, хаксызлык кылынмас; җәбер итү булмас.

Гайре мөслимләрә — мөселман булмаганнарга.

халык» һәм башка исемдәге татар газета-журналларының яшәүдән туктаулары уңае белән язылган.

«Ну-ну-ну» шигырендә исә татарлар арасындагы мәгълүм шәхесләрнең («Чүкеч» журналының нашире һәм редакторы Тимершаһ Соловьев, татар әдибе Зариф Бәшири, Казан сәүдәгәре Гыйльметдин Ибраһимов һ.б.ның) кайбер сыйфатлары көлкеле рәвештә тасвирлана.

«Гучков» исемле мәкаләсендә Октябристлар партиясенең җитәкчесе, III Дәүләт думасында бөтен хөррият һәм иркенлекләргә каршы чыгучы эре капиталист А.И.Гучковтан көлгән.

*«Яшен», 6 нчы сан.*

**Февраль.** «Алтын әтәч» әкият-поэмасының икенче басмасы («Мәктәп мөкяфәте»ннән икенче китап, «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов литотипографиясе) дөнья күрә. Рәсемле. 18 б., 5000 данә.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

**3 февраль.** «Сәгъди»нең (Борһан Шәрәфнең) «Габдулла Тукаев» исемле мәкаләсе басылып чыга. Анда Тукай иҗаты шактый тәфсилле тикшерелә, аңа югары бәя бирелә. Автор Тукайның һәр шигыре басылып чыгу белән халык массасы тарафыннан яратылып укылуы, ятлануы, телдән-телгә күчеп йөрүе, «Тукаев диваны» дигән җыентыгы белән исә шагыйрьнең поэзиядә тагын да югарырак менүе, аның «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш»ның күп вакытларга кадәр әдәбият дәреслеге булып хезмәт итә алуы һ.б. турында яза.

«Һәркемгә мәгълүм ике елга якын булып килгән олугъ вә кечек әдәбият кичәләренең һичберсе Г.Тукаев шигырьләреннән башка үтмидер. Шуларның һәрберсендә Тукайның берничә әсәре укыла. Бәгъзе кичәләрдә аның әллә ничә әсәре укыла һәм җырлана. Аның яңа чыккан шигырьләрен яшьләр тиз кабул итәләр».

*«Вакыт», 427 нче сан.*

**3—4 февраль.** Тукай Казанга килгәч аралашкан чордашы, язучы һәм гарәп мәдәнияте тарихы белгече Шәһер Шәрәф (1878—1938) белән очраша. Араларында булган сөйләшүне Шәрәф түбәндәгечә тасвирлый: «Тукай үзенең, табган, шагыйрь булып яратылуына, үзендә шагыйрьлек таланты фәүкыльгадә куәтле булуына бик нык иманлы иде.

---

Бәгъзе — кайбер.
Табган — табигый рәвештә.
Фәүкыльгадә — гадәттән тыш.

Бервакыт 1909 ел «Вакыт» газетасының бер номерысын «Сәгъди» имзасы берлә Тукайның шигырьләре вә шагыйрьлеге хакында озын бер фельетон язылган иде. Миңа, очрашканда, шул газет яңа гына килгән, Тукай да яңа гына укыган иде. Мин: «Бу фельетонны укыгач, берәр вершок үсеп киткәнсеңә»,— диюемә каршы Тукай, бер дә исәпләп тә тормаенча: «Балыкка: син оста йөзәсең, дисәләр, күтәрелеп китәр идеме?» — диде...

Соңра шул сүзләрне гыйлавә итте: «Мин шагыйрьлекне күп иҗтиһад итеп, күп вакытлар сарыф итеп тәхсил иткәнем юк. Бу шагыйрьлек миңа Аллаһ тарафыннан бирелгән бер куәт. Шунлыктан аның берлә мактанырга хакым юк»,— диде».

*Шәрәф Ш. Габдулла Тукай хакында бәгъзе хатирәләрем. «Замандашлары», 106 б.*

**6 февраль.** «Гасыр» көтепханәсе түбәндәге игъланнарын бастыра:

«Бу көннәрдә басылып чыккан китаплар... «Тукаев диваны».

«...Әдәбият вә музыка кичәсе була. Габдулла әфәнде үзенең әсәрләрен укыячак. Билетларны «Сабах», «Гасыр» көтепханәсендә һәм «Шәрык» клубында алырга мөмкин».

*«Йолдыз», 360 нчы сан.*

**7—12 февраль.** «Вакыт» газетасы «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» китабы дөньяга чыгу турында кат-кат хәбәр итә.

*«Вакыт», 429—431 нче саннар.*

**10 февраль.** «Күңел» һәм «Васыятем» исемле шигырьләре дөнья күрә.

*«Әл-ислах», 60 нчы сан.*

«Васыятем» турында Р.Гайнанов болай ди: «Шигырь 1909 елның гыйнвар ахырында, Тукайның «Актык сүзләр» дигән фельетоны белән бер үк вакытта язылган; аларның матбугатта чыгу аралары ун көн генә.

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар, юнәл, кит Тәңреңә!
Бирдең арканны моңарчы, инде бир бит әмренә,—

дип, фельетонда китерелгән газета-журналларның актык сүзләре рәтеннән бу ике юлны үзенең актык сүзе итеп белдерә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 341 б.*

---

Вершок — карыш.
Гыйлавә итте — кушты, өстәде.
Иҗтиһад итү — тырышу.
Тәхсил итү — хасил итү, биредә: язу.
Нәфсе мотмәиннәм — тынычлык тапкан күңелем.

**14 февраль.** «Вакыт» газетасы хәбәр итә: «Г.Тукаев әсәре «Җуаныч» («Мәктәп мөкяфәте»ннән беренче китап) басылып чыгып сатыла башлады».

*«Вакыт», 434 нче сан.*

**15 февраль.** «Шура» журналы шагыйрьнең «Габдулла Тукаев диваны» дигән китабына, «гүзәл вә үрнәк әсәрләрдән гыйбарәт мәҗмугадыр» дип, уңай бәяләмә биреп, рецензия бастырып чыгара.

*«Шура», 4 нче сан.*

**18 февраль.** «Әл-ислах» газетасында «Тәрәддед вә шөбһә» шигыре басыла. Шунда ук «Габдулла Тукаев диваны» (Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр) басылып чыгуы турында игълан бирелгән.

*«Әл-ислах», 61 нче сан.*

**26 февраль.** «Дамелла» имзасы белән Ф.Әмирхан «Яңа китаплар» исеме астында рецензия бастырып чыгара. Бу мәкалә-бәяләмә шагыйрьнең «Габдулла Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. 1 нче кыйсем. Икенче табгы) исемле китабына карата язылган.

Автор, Тукай иҗатына югары бәя биреп, болай ди: «Әл-ислах» кариэләре Габдулла әфәнденең шигырьләре белән «Әл-ислах» сәхифәләрендә бик яхшы танышканнар вә аларда никадәр нәфасәт вә никадәр хиссият барын үз күңелләрендә хис итеп белгәннәр.

Габдулла әфәнденең шигырьләре хакында мин «Әл-ислах»-та бер-ике мәкалә язган идем. Бу көннәр «Вакыт» газетасында «Сәгъди» (Борһан Шәрәф) әфәнде дә шагыйремезнең соңгы диваны мөнәсәбәте белән озын бер мәкаләсендә Тукаев шигырьләре вә алардагы фикер алмашынуны әсас сурәттә яктырта. Мин Тукаев шигырьләренә икенче яктан карамакчы булам.

Һәрбер талант зурая һәм акрынлап үсә.

Мөстәкыйль шагыйре булган бер әдәбият бәхетле әдәбияттыр».

*«Әл-ислах», 62 нче сан.*

**Февраль — март.** «Җавап» шигыре язылды*.

---

* Р.Гайнанов бу шигырьне 1908 елның июнь — июль айларында язылган дип саный. Кара: Биш томлы «Әсәрләр», 1 т., 376 б.

Мөкяфәт — бүләк, яхшылык.

Тәрәддед вә шөбһә — икеләнү вә шикләнү.

Кариэ — укучы.

Сәхифә — бит.

Нәфасәт — гүзәллек, нечкәлек.

Әсас сурәттә — нигезле, ышандырырлык итеп.

Шигъре Лермонтов вә Пушкин — олуг саф диңгез ул,
Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай — өч йолдыз ул.
Син дә шул диңгез ярында, и агу йоткан көчек!
Телләрең сузган буласың,— җитми, җитми, кит көчеп.
Кит хәзер, ләкин китәрдә сал колак бу сүзгә бер:
Барчы, эт, гомрең буе шул күктә өч йолдызга өр!

*«Г.Тукай шигырьләре», 1926, 113 б.*

Бу шигырьнең язылу датасына мөнәсәбәтен белдереп, И.Нуруллин түбәндәгеләрне әйтә: «Тукайның «Җавап» шигыре үзенең эчтәлеге белән З.Бәширинең «Мөтәрҗим шагыйрьгә» («Чүкеч», 1908, № 50) һәм «Ул дисезме?» («Чүкеч», 1908, № 63) шигырьләренә турыдан-туры җавап булганлыктан, аның язылу датасы 1909 елның февраль — март айларыннан да соң булмаска тиеш дияргә нигез бар».

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 208 б.*

**Кыш.** Г.Дәүләтшинның «Китаб» нәшриятында* экспедитор һәм корректор булып эшли. Вафа Бәхтияров язуынча, нәшрият урнашкан йортның ишегалдына карап торган ягында, икенче катта, караңгы, салкын, юеш бүлмәдә яши. Монда торганда «Хатыннар хөррияте», «Номерга төшкән искеләр», «Хәзерге өйләнүчеләр» һ.б. шигырьләрен яза.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948;*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

**2 март.** «Хатыннар хөррияте» исемле шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

*«Яшен», 7 нче сан.*

«Әдәбият»та (1909) Тукай, астөшермә ясап, бу шигырьгә түбәндәге аңлатманы бирә: «Сатирикон» журналында бераү, хатыннар тарафдары булып, идән буенда: «Хатыннар! Атлаңыз алга!» — дип гайрәтләнеп йөргән бер кешенең, фәкать чалбарын тазартмаган өчен, үз хатынын эт итеп сүккәненнән көлә.

Миңа килгәч, ул шигырь, табигый, миллиләште. Күп кешеләр бу шигырьдән морад нәрсә икәнен бөтенләй аңлап җитмәгәнгә, азрак изах иттем. «Мөтәрҗим».

*«Әдәбият», 1909, 19 б.*

Әсәр В.В.Князевнең «Либерал средней руки перед банкетом» дигән шигыреннән «Сатирикон» (1909, № 24, с.15) файдаланып язылган.

*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 343 б.*

---

* Казанның хәзерге Киров урамы, 53/6 нчы йорт.
Изах иттем — аңлаттым.
Мөтәрҗим — тәрҗемәче.

«Авыл җырлары» (Өченче көлтә) «Шүрәле» имзасы белән һәм шунда ук «Юк, маташма, и каләм!..» дип башланган исемсез шигыре «Идарәдән җаваплар» эчендә имзасыз басыла.

Юк, маташма, и каләм! — калсынчы, шундый юк белән;
Борчак атмак көлкедер тау-таш ватарлык туп белән.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Сипмә конфетти аның төсле сәфилләр өстенә:
Ул хәзерләнгән атарга йөзгә каршы чүп белән.

*«Яшен», 7 нче сан.*

Тукай бу шигырен уйлап чыгарылган «Шома» әфәндедән килгән хат рәвешендә яза. Соңгы юлдан соң өстәлгән «Чүкеч»кә тиебрәк язучы «Шома» әфәндегә: «Шигыреңездә ачу вә артык кызу галәмәтләре булганлыктан, һәммәсе дә басылмый»,— дигән сүзләр шуны аңлата. Шигырь «Яшен»гә, «Әлислах»ка, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камалга каршы әшәке «һөҗүмләр» белән чыккан «Чүкеч»чeләргә, аерым алганда «Чүкеч» журналы секретаре шагыйрь З.Бәширигә нисбәтән язылган.

*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 345 б.*

**6 март.** «Габдулла Тукаев шигырьләре» җыентыгы басылып чыга. («Шигырь көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. 1 нче кыйсем. Икенче табгысы. Казан, «Үрнәк» матбагасы, 48 б., 4000 данә).

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.*

Китап беренче басмасыннан эчтәлеге белән аерылмый, фәкать басып чыгаручыларның кереш сүзләре генә өстәлгән. Китапның икенче битендә түбәндәге текст китерелгән: «Наширләрдән:

Милләтемез әфрадының гомумән тәрәкъкыйга хәрәкәтләре арту нисбәтендә шигырьгә һәвәсләре арта барадыр.

«Бакырган», «Мөхәммәдия» илә канәгатьләнмәй торган яшьләремез яңадан-яңа шигырьләр телиләр.

Бинаән галәйһи, без газим итдекемез «Шигырьләр көтепханәсе»не дәвам иттереп, бу 3 нче дәфтәрдә үткен телле сөекле шагыйремез Габдулла Тукаевның шигырьләрен укучыларга тәкъдим итәмез».

Наширләр икенче басмага керештә: «3 нче дәфтәрнең бу икенче табгысы, Габдулла әфәнде Тукаев җәнабләренең телә-

---

Тәрәкъкый — прогресс, алга китеш.
Бинаән галәйһи — шуңа күрә.
Без газим итдекемез — без уйлаган.
Табгы — басма.

ве белән, элекке табгысыннан бераз үзгәртелде. Элекке табгысында дәрҗ ителгән бәгъзе шигырьләре калдырылып, урыннарына шагыйремезнең соңгы әсәрләреннән бәгъзеләре дәрҗ ителде.

Бу көннәрдә «Шигырь көтепханәсе»нең элегрәк табгы ителгән башка дәфтәрләре дә таралып бетә язганлыктан, алары да икенче мәртәбә табгы ителәчәктер. Хәзергә 9, 10, 11 нче дәфтәрләр табгы итәргә хәзерләнеп куелдылар. Тизлектә бер-берсе артлы нәшер ителерләр»,— дип хәбәр итәләр.

*«3 нче дәфтәр». Икенче басма, 1909, 4 б.*

Китапта барысы 32 әсәр урнаштырылган, шулардан «Васыятем» шигыре беренче мәртәбә басыла. Яңалардан «Күңел» (10 февраль), «Тәрәддед вә шөбһә» (18 февраль), «Хатыннар хөрriяте» (2 март) кертелгән.

**9 март.** «Алтын әтәч» китабының икенче басмасына Г.Камалның «Яңа китаплар» исемле рецензиясе басыла.

«Ошбу көннәрдә китапчылык галәмендә ике гүзәл әсәр күзгә күренде. Берсе Габдулла Тукаев җәнапләре тарафыннан нәзым илә язылган «Алтын әтәч» нам бер хикәядер.

Габдулла әфәнде бу әсәрен яшь балалар өчен язмыш вә китапның мәфһүмен Пушкинның «Золотой петушок» нам әсәреннән алмыштыр. Нәзымы гаять җиңел булу өстенә, тасвирлары да гаять шагыйранәдер. Китап «Сабах» көтепханәсе тарафыннан мосаувәр уларак бик яхшы кәгазьдә, гүзәл сурәттә табгы ителмештер».

*«Йолдыз», 373 нче сан.*

**11 март.** «Габдулла Тукаев шигырьләре» басылып чыга («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр. 2 нче кыйсем. Икенче табгы. Казан, «Үрнәк» матбагасы).

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

Китапка барысы 31 шигыре кертелгән. Беренче басмасы белән чагыштырганда, текстлар беркадәр үзгәртелгән, төшереп калдырылган шигырьләр дә бар. Алар урынына шагыйрьнең

---

Дәрҗ ителгән — басылып чыккан.
Бәгъзе — кайбер.
Нәзым — шигырь.
Нам — исемле.
Мәфһүмен — эчтәлеген, сюжетын.
Мосаувәр уларак — рәсемнәр белән бизәлеп.

яңа язылган әсәрләреннән кайберләре урнаштырылган. 1907 елда чыккан беренче басмасындагы «Китмибез» һәм «Кем ул?» дип исемләнгән шигырьләре бирегә кертелмәгән. Алар цензура тарафыннан сызылган.

**13 март.** Уральскига Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә бергә укыган якташы Гайнетдин Туприевкә хат яза. Шәхси тормышына кагылышлы якларны үзе болай сурәтли: «Минем хәлләрне сорыйсыз, минем хәлем Ходайга каршы мыгырданырлык түгел.

Казан күңелле. Мөхәррирләрдән, укучы яшьләрдән гыйбарәт дустларым күп.

Монда бай, байбәтчәләр дә гомумән диярлек русча укыган вә һәр җәһәттән аз-күп мәгълүматлылар. Шул сәбәпле аларга да катышам. Бәгъзан Казанның иң бай вә иң могтәбәр гаиләләре эченә дә кереп утырырга тугры килгәли».

Иҗатына бәйле булган эшләрен дә дустына белдерергә кирәк таба.

«...Җитди вә көлмичә язылган нәрсәләремне «Әл-ислах»ка бирәм. Һөҗүви вә көлке нәрсәләремне «Яшен»гә тапшырам.

Ара-тирә рисалә вә мәҗмугаларым да мәйданга килә.

Матди җәһәтне шулар илә тәэмин итәм.

«Яшен»нең секретаре мин булганга, анда бик күп язарга тугры килә. Шул сәбәпле төрле-төрле мөстәгар имзалар артына яшеренәм.

«Чүкеч» безгә каршы язган була. Ләкин без шундый икътидарсыз, каләмсез, бәхетсез вә зәгыйфь дошманнарымыз барлыгына тик куанабыз гына». Хатта ул эше күп булуы турында да яза һәм Уральскидагы танышларына сәлам юллый, язга Уральскига кайтып, андагы хәлләрне карап килергә теләген белдерә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 91 б.*

**14 март.** Публицист һәм шагыйрь буларак та хөрмәт иткән якын дусты С.Рәмиев, «Таң йолдызы», «Таң мәҗмугасы» һәм «Әл-ислах» та ябылгач, «Бәянелхак» газетасына хезмәткә керә. Бу хәлне Тукай авыр кичерә, демократик позициядән читенү дип бәяли. Алар арасында киеренкелек барлыкка килә. Һәм ул матбугатта да чагылыш таба.

С.Рәмиев «Казан мөхбире» газетасында «Уен-көлке музее» дигән исем астында сатира бүлеге ачылачагын игълан итә. Ул

---

Бәгъзан — кайвакыт, кайчак.
Һөҗүви — сатирик, юмористик.
Рисалә вә мәҗмуга — китап һәм җыентык.
Мөстәгар — кушамат, ялган исем.
Икътидарсыз — сәләтсез.

«Музей сторожы», «Музей сторожы Тимербулат» псевдонимнары белән «Яшен»гә һәм «Яшен»челәргә, «Ялт-йолт»ка каршы юнәлдерелгән мәкалә-фельетоннарын, шигырьләрен бастыра. Көлке журналлары белән көрәшү программасын тормышка ашыру йөзеннән, «Музей сторожы Тимербулат әфәнде» газетаның шушы санында ук иске патефоннан Тукайга ишарәләп мондый җыр җырлата:

Әй, «Яшен»че, «Яшен»че!
Ялтырама, яшеренче!
Бывший «Таң»чы тагы да чыккан,
Йә, городовой дәштерче.

*«Казан мөхбире», 320 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 348 б.*

**19 март.** 20 мартта «Сәүдә хезмәткәрләре җәмгыяте» бинасында Н.В.Гогольнең тууына 100 ел мөнәсәбәте белән лекция, әдәбият вә музыка кыйсемнәреннән гыйбарәт кичә ясалачагы турында хәбәр ителә.

*«Йолдыз», 377 нче сан.*

**20 март.** Казанда В.А.Александров (большевик) җитәкчелегендә Н.В.Гогольнең 100 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә оештырыла. Бу кичә ике телдә — рус һәм татар телләрендә булып, «бик җанлы» үтә. Татар телендә шагыйрь С.Рәмиев чыгыш ясаган.

*«Камско-Волжская речь», 1909, №136.*

Мондый кичәләрдә Г.Тукай элегрәк тә катнаша торган була.

*Нафигов Р. Тайны..., с. 131.*

**21 март.** «Ике юл» шигыре басылып чыга.

*«Яшен», 9 нчы сан.*

**26 март.** «Энҗе бөртекләре» исемле җыентыгы (Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы) басылып чыга.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

Китап 1906 елдан башлап «Әлгасрелҗәдит»тә, аннан соң «Яшен»дә чыгып килгән мәсәлләрне эченә ала. Җыентыкны төзегәндә Тукай аларны беркадәр редакцияләп, телен-стилен җиңеләйтә (барлыгы 78 мәсәл). Бу чәчмә формадагы мәсәл-

---

Кыйсем — бүлек.

ләрнең кайберләре рус язучыларыннан, гарәп-фарсы һәм төрек телләреннән тәрҗемә ителгән һәм аларга ияреп язылган.

Китапка беренче мәртәбә «Җил илә Кояш», «Казлар», «Мактанчык куян», «Умарта корты вә Чебеннәр», «Җылан илә Бәрән», «Ташбака илә Куян», «Бүре Этләр оясында», «Каз», «Арыслан илә Төлке», «Тычкан илә Күсе», «Әтәч илә Күке», «Күке», «Аш пешерүче», «Кыр кәҗәләре», «Этләрнең дуст булышуы», «Бала козгын», «Үткен пәке», «Әтәч илә Энҗе бөртеге», «Аккош, Чуртан һәм Кыскыч», «Арыслан илә Тычкан», «Җумарт дуст», «Бәти», «Көзге һәм Маймыл», «Сабан сөрүче», «Ишәк илә Сандугач» әсәрләре (барысы 26) урнаштырылган.

Наширләрнең җыентыкка кереш сүзендә («Бер-ике сүз») болай диелә: «Бу мәҗмугада кариэләремезгә гарыз итәчәк нәрсәмез Габдулла әфәнде Тукаевның моннан 3—4 ел мөкаддәм нәсер белән язган һәм гарәп, фарсы, рус әдәбиятыннан тәрҗемә иткәне кыска вә мөрид хикәяләрдән гыйбарәттер. Әдәбиятның бу нәүгысы, ягъни мәгыйшәткә даир зур-зур фәлсәфи мәгънәләре төрле кыска хикәяләр васитасы белән тәлкыйн итү, һәр милләтләрнең әдәбиятында бик искедән бирле истигъмаль ителгән рәвештер...

Моңар кадәр яшь әдәбиятымызда бу нәүгының тәрәкъкый таба алмавы зур кимчелек иде. Менә шул кимчелекне тутыруда өлге адым булсын фикере белән без халык мәхәббәтен үзенә караткан вә гали шигырьләре белән күңелләрдә хиссият уяткан шагыйрь-мөхәрриремезнең бу кыска-кыска хикәяләрен «Энҗе бөртекләре» исеме белән нәшер итәмез».

*«Энҗе бөртекләре», 3 б.*

**29 март.** «Пәйгамбәр» шигыре басылып чыга. «Лермонтовтан үзгәртелгән» дип куелган. М.Ю.Лермонтовның «Пророк» (1841) исемле шигыреннән файдаланып назыйрә рәвешендә язылган романтик шигырь.

*«Әл-ислах», 65 нче сан.*

Лермонтов кебек Тукай да пәйгамбәр образы аша халык мәнфәгатен күзәтүче, дөреслек, гаделлек сөюче, явызлыкны фаш

---

Мәҗмуга — җыентык, кечкенә китап.
Кариэ — укучы.
Гарыз итү — тәкъдим итү.
Мөкаддәм — элек.
Мөрид — ияреп язылган.
Нәүгы — бүлеге, өлеше.
Мәгыйшәткә даир — тормыш-яшәеш турындагы.
Васитасы белән — ярдәмендә.
Тәлкыйн итү — төшендереп сөйләү, аңлату.
Истигъмаль итү — куллану.

итүче гуманист шагыйрь образын тудыра. Тәрҗемә иткәндә Тукай Лермонтовның шигырен күләм ягыннан арттыра, аның ритмикасын да, үлчәмен дә үзгәртә. Үзеннән күп шигъри детальләр өсти. Тукайның пәйгамбәре үзенең ялкынлы аятьләре белән байга да, фәкыйрьгә дә, падишаһка да мөрәҗәгать итә, барысының да гаепләрен күрсәтә. Иҗтимагый катламнарның барысына да бертигез карый:

Кирәк баймы, фәкыйрьме, падишаһмы — күрсәтәм гайбен;
Укыйм ялкынлы аятьләр — карау юк һичберәү кәйфен.

Тукай Лермонтов «Пәйгамбәр»ен мөселман халкы тормышына якынайтып тәрҗемә итә, пәйгамбәр образына ислам тарихыннан һәм мифологиясеннән алынган башка күп образ-сурәтләрне өсти. Тукай Лермонтовның «Пәйгамбәр» шигыренең тәрҗемәсенә үзеннән күп яңалыклар өсти, рус әдәбияты традицияләрен Көнчыгыш шигърияте кануннары белән үреп, бербөтен итә. Нәтиҗәдә илаһият фәлсәфәсен гәүдәләндергән гүзәл бер шигырь тудыра.

*Халит Г. Тукай уткән юл, 1962 , 161—163 б.;*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 29—32 б.*

**21 апрель.** «Исемдә» дигән шигыре дөнья күрә.

Астөшермәдә: «Бу шигырьне Габделләтыйф Мостафин тарафыннан телемезгә тәрҗемә кыйлынган русча бер пьесада күптән түгел генә гыйффәтен җуйган бер кыз үзенең бәхетле заманнарын сагынып җырлый. Пьеса басылып чыккач укылса, тәэсире артыграк булыр»,— дигән искәрмә бирелгән. Бу пьеса «Җиңел хезмәттә» дигән исем белән шул ук елда «Мәгариф» көтепханәсе тарафыннан Казанда И.Н.Харитонов матбагасында дөньяга чыгарылган. Тәрҗемәчесе — Ләтыйф Мостафа. «Исемдә»не пьесаның төп герое Гайшә җырлый. Астөшермәдә «Бу шигырьнең мөтәрҗиме мәшһүр шагыйремез Г.Тукаев» дигән сүзләр бар.

*«Әл-ислах», 66 нчы сан.*

**27 апрель.** Г.Тукай белән С.Рахманколый Ф.Әмирхан янына баралар. Ф.Әмирханның Исмәгыйль Аитовка язган хатыннан күренә : «Солтан хәзер үзе монда, минем янда, сиңа сәлам укый. Тукаев та минем өстәл янында яңагына таянып утыра...»

*«Мирасханә. 16-ф., 3-тасв., 4-эш;*
*Әмирхан Ф. «Әсәрләр», 4т., 1986, 269 б.*

**29 апрель.** «Матбугат каһарманнары» дигән фельетоны «Мин язмадым» имзасы белән басылган. Шунда ук «Номерга төшкән искеләр» һәм «Ишан» дигән шигырьләре урнаштырылган.

Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган;
Кибән чалма кибәк башта: ишан булган, имеш, хайван!

*«Яшен», 8 нче сан.*

Әлеге шигырьгә мөнәсәбәттә З.Бәшири «Тутый» имзасы белән «Мулла» дигән әсәрен бастырып чыгара (исем астында «Г.Тукаевның «Ишан» шигыренә гыйлавә» дип куелган). Анда түбәндәге юллар бар:

Укый Коръән вә тасылдый, тышаудай тәсбихы кулда,
Җыеп фасыйк монафыйклар эшен эшли ул уртында.
Сират кичкән, Ходайның һәр газабыннан әман булган,
Кыяматтә шәфәгатьче була Шәмче Вәлиләргә,
Сата җәннәт билетларын, указ алган, имеш, шул да!

*«Ялт-йолт», 4 нче сан.*

«Дәүре галәм» шигыре имзасыз басылып чыга.

Йосыф Акчураның (1876—1955) — кадет, либераль буржуа идеологы, публицист, Икенче Дәүләт думасы әгъзасы — Палестинага, Габдрәшид Ибраһимовның (1853—1935) — либераль буржуа публицисты — Япониягә мәчет салдырам дип сәяхәткә китүе уңае белән язылган.

*«Яшен», 8 нче сан.*

«Гласный» шигыре «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында, имзасыз гына урнаштырылган.

Тукай бу шигырен «Чәйче Шәмси» дип йөртелгән кадимче бер байның Казан шәһәр думасына гласный (член) булып сайлануыннан көлеп язган.

*«Яшен», 8 нче сан.*

***(«Хайлым, хайлым, хайларга...») шигыре рәсем асты буларак имзасыз басыла.

*«Яшен», 8 нче сан.*

Рәсем-карикатурада Казан сәүдәгәре, «Бәянелхак» газетасы (1906—1907 елларда чыга) нашире һәм редакторы Әхмәтҗан Сәйдәшевкә охшатып ясалган портрет янына «Нашир әфәнде» дип язылган. Портрет күкрәгенең уң ягында тузган чәчле баш. Кырыена «Музей сторожы» диелгән. Сул ягында хатынкыз башы. Кырыена «Мәрьям илә җырлый» дип куелган.

---

Гыйлавә — өстәмә, кушымта.
Фасыйк — азгын.
Монафыйк — икейөзле.
Уртында — авыз эчендә.
Әман булган — котылган.
Шәфәгатьче — яклаучы.
Дәүре галәм — дөнья гизү, дөнья әйләнү.

Рәсем һәм җыр С.Рәмиевнең «Бәянелхак»ка эшкә керүенә ишарәли.

«С.Рәмиев бик яхшы җырчы да була. Аның граммофон пластинкасына берничә татар көен яздырганлыгы билгеле. Шулай ук ул Мәкәрҗәдә зур рестораннарда җырлаган Мәрьям Искәндәрева белән бер-ике дуэт та (мәсәлән, «Җизнәкәй») җырлап, пластинкага яздырган, дигән сүзләр бар. Җырның ике юлы шул хакта булырга кирәк»,— ди бу турыда Р.Гайнанов.

*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 348 б.*

Ф.Сәйфи-Казанлының «Безнең заман» исемле комедиясенә «Яңа әсәрләр» рубрикасында «Безнең заман» дигән тәнкыйть мәкаләсе — рецензия язып бастыра, имзасыз гына бирелгән.

Фатыйх Сәйфинең комедиясеннән әче көлеп, түбәндәгечә тасвирлап эпиграмма да яза: «Харис Фәхретдинов нәшер иткән, бер школьник язган «мәнзум» комедиядер.

Мөндәриҗаты шуннан гыйбарәт:

Мин урамга чыгам,
Баганага сөялеп торам,
Тамагымны да кырам.
Ну, яман безнең заман,
Яшьләр бозыла һаман.
Куда конь с копытом,
Мин дә кыстырдым ботым*.

Бу школьникның яшьләрдән көләм дип азаплануы нинди көлке булып чыкканлыгын күрер өчен, бу көлке бер пәрдәдә «мәнзум комедияне алып укырга эшсез кешеләргә тәүсыя итәмез».

*«Яшен», 8 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 99 б.*

**30 апрель.** «Күрсәтә» шигыре басылып чыга («Ахыры бар» дип куелган булса да, дәвамы күренми).

*«Әл-ислах», 67 нче сан.*

**21 май.** «Номерга төшкән искеләр» шигыре «Һөҗүвият» дигән гомуми баш астында рәсем асты буларак (икенче мәртәбә) басылган.

*«Яшен», 9 нчы сан.*

---

* Урынсыз, кирәкмәгән җиргә тыкшыну мәгънәсендә кулланыла торган «Ат тоягын дагалаганда, бака ботын кыстыра» дигән мәкальне шагыйрь үзенчә үзгәрткән.

Мәнзум — тезмә белән язылган.

Мөндәриҗат — эчтәлек.

Куда конь с копытом — ат тоягын тыккан җиргә.

Тәүсыя итү — тәкъдим итү, киңәш бирү.

«Габделхәмит» шигыре «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

Утыз елдан артык Төркиянең солтаны булган консерватив карашлы Габделхәмитне 1907—1908 елларда көчәйгән «Яшь төрекләр» хәрәкәте илгә Конституция бирергә мәҗбүр итә. 1909 елда Конституцияне бетерергә һәм самодержавиене яңадан кайтарырга тырышуы сәбәпле, Габделхәмит тәхеттән бөтенләй төшерелә. Шигырь шушы факт уңае белән язылган:

Утыз ел хөр фикерләрне үлтерт,
Төрекләрдә азатлык тамрын корыт,
Ватан яктыртучы шәмнәрне сүндерт,
Мөселманнан бөтен читләрне көлдерт, —
Утыз ел казыган баз бик тирән шул:
Менә инде Хәмитең шунда Гөмберрт!

*«Яшен», 9 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 348—349 б.*

«Муллалар (Йөриләр бу кешеләр сөйрәлеп һәрдәм бәлешләргә...)» шигыре «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында басыла.

Муллаларны ялкау хайваннарга тиңли:

Менә шулчаклы ялкау, шундый хайваннар да рухани,
Түбәнлек бу, кабул итмәс үзенә изге рух аны!

Шунда ук «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Вөҗдан зарары» (Ничек тормак тиеш, дустым, дисеңме...), «Гаилә тынычлыгы», «Киңәш» (Ялангач кал дисәң...) шигырьләре «Шүрәле» имзасы белән урын алганнар.

*«Яшен», 9 нчы сан.*

**26 май.** «Ике кояш» исемле шигырен яза. Шигырь беренче татар профессиональ актрисасы, Татарстанның атказанган артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга (1892—1974) багышлап язылган. С.Волжскаяның Татарстан Үзәк дәүләт архивында саклана торган альбомында шигырьнең Тукай кулы белән язган кулъязмасы да теркәлгән.

*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 349 б.*

**Җәй.** Московская урамындагы (хәзерге Киров урамы) «Москва» номерына урнаша. Монда Тукай бик аз гына торган булырга тиеш. Ул күбрәк «Болгар», «Амур» кунакханәләрендә яши.

*«КУ», 1970, 8 нче сан, 117 б.*

**2 июнь.** «Йолдыз» газетасы хәбәр итә: «Яңа китаплар басылып чыкты. Г.Тукай. «Алтын әтәч».

*«Йолдыз», 406 нчы сан.*

**19 июньгә кадәр.** Г.Камалның (1879—1933) «Кызганыч бала», «Бәхетсез егет», Я.Вәлинең (1879—1934) «Оят яки күз яше» спектакльләрен караві билгеле.

*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 100 б.*

Мөгаллим Каюм Мостакаев белән очраша. Тукай аны Ф.Әмирхан янына алып бара. Редакциядә эшләүчеләр (К.Бәкер, Ф.Әмирхан, В.Бәхтияров) барысы бергә Кабан күле аръягына Ф.Әмирханның җәйге дачасына барган булалар. (Хәзерге Һади Такташ урамы, Литовченко йортында.) Бу вакыйгага турындагы хатирәләрен К.Мостакаев болай искә ала: «Шунда очрашып, танышып, хәл-әхвәл сорашкач, Тукай елмаеп куйды да, куен кесәсеннән алып, Ф.Әмирханга шушы көннәрдә генә язылган шигырен сузды. («Эштән чыгарылган татар кызына» исемле шигыре иде ул.) Ф.Әмирхан, бөтен дикъкатен биреп, шигырьне укый башлады... укып чыккач, Тукайга карап елмаеп куйды да:

— Гаять халыкчан килеп чыккан бу!.. Минем уемча, синең бу шигырең шушы темага язылачак әйберләрнең беренчесе генә бит әле, мин моның иптәшләре дә күбәюен телим! — дип өстәде.

Ф.Әмирхан бу сүзләрне әйткәндә, Тукайның куанычы йөзенә чыккан иде һәм ул...

— Мин дә үзеңне мактап алыйм әле, алай булгач. «Татар кызы» исемле китабыңны зур дәрт һәм тирән ихтирам белән укып чыктым. Үзең әйтмешли, бу китабың өр-яңа бер стильдә язылган. Шуның өчен кулыңны кысып котларга рөхсәт ит! — диде.

... — Байгуралар, муллалар, Печән базары әһелләре ни әйтәсе билгеле инде,— диде Тукай.— Хәзер алар белән исәпләшеп торуның кирәге юк. Ә гади халыкка килсәк, алар, әлбәттә, бу китапны хуплап каршы алырлар».

*Мостакаев К. Габдулла Тукай һәм Фатыйх Әмирхан белән күрешү. «КУ», 1970, 8 нче сан, 169—173 б.*

**19 июнь.** Казанда Панаевский бакчаның* ябык театрында Гариф Богдановның «Хуҗа һәм приказчик» исемле пьесасы буенча «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан куелган спектакльне карый.

*«Йолдыз», 413 нче сан.*

---

* Панаевский бакча — хәзерге М.Горький урамындагы шәһәр Пионерлар сарае һәм «Динамо» стадионы урынындагы бакча.

**21 июнь.** «Эштән чыгарылган татар кызына» шигыре «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

*«Яшен», 10 нчы сан.*

Бу шигырь Тукайның «Әдәбият» исемле җыентыгында да бар («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр). Шушы китапка язган рецензиясендә Кәбир Бәкер түбәндәге юлларны яза: «Хосусан шагыйрь әфәнденең «эштән чыгарылган» татар кызына әйткән ачы кызганычлары күңеле таш булмаган һәркемнең җанын әрнетерлек вә шул ук вакытта бөтен иске стройның ерткыч хайваннарына укучының иң соңгы нәфрәтләрен әйтерлектер. Габдулла әфәнденең бу шигыре язылган көнне үк бөтен Казан яшьләре тарафыннан хифыз ителгән вә тәкъдир ителгән иде».

*«Йолдыз», 476 нчы сан.*

**21 июнь.** «Татарча театр» исеме белән «Хуҗа һәм приказчик» дигән спектакльгә язылган рецензиясе басылып чыга.

Һәвәскәр артистлардан аермалы буларак, «Сәйяр» труппасы артистларының уеннарын мактап, аларның профессионаллар дәрәҗәсендә торуларын әйтә. Бигрәк тә Г.Кариев (1886—1920), Н.Сакаев (1885—1927), В.Мортазин-Иманский (1886—1937), С.Гыйззәтуллина-Волжская (1892—1974) турында сүз алып барып, аларның тамашачы күңелен җәлеп итәрлек, табигый рәвештә уйнауларын ассызыклый. «Галимҗан ролен уйнаучы Кариев үзенең җанлы хәрәкәте вә килешле кыйланышы вә кирәк урыннарда төсен вә сүзнең тонын үзгәртә белүе илә хәзер генә базардан сәхнәгә тамашага тотып кертелгән бер татар бае иде».

*«Йолдыз», 413 нче сан.*

**24 июнь.** «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Бәгъзе зыялыларымыз» һәм «Татар бае» дигән шигырьләре «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шунда ук «Милләтче» фельетоны «Шүрәле» имзасы белән һәм «Гөмберт» имзасы белән «Безнең заман вә Сәгъди абзый» исемле фельетоны урын алганнар.

*«Яшен», 10 нчы сан.*

Фатыйх Сәйфи-Казанлының «Безнең заман» исемле бер пәрдәлек шигъри комедиясен (Казан, «Үрнәк» матбагасы, 1909. Наширe: Харис Фәхретдинов) бик мактап, «Сәгъди» псевдонимы

---

Хифыз ителгән — ятлап алынган.

белән журналист һәм әдәбият тәнкыйтьчесе Борһан Шәрәф «Вакыт» газетасының 1909 елгы 13 июнь (481) санында «Безнең заман» исемле рецензия бастыра. Тукайның бу фельетоны шушы уңай белән язылган.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 347 б.*

«Яшен» журналының соңгы номеры чыга.

*«Яшен», 10 нчы сан.*

**26 июнь.** «Вакты гаҗезем» (Төрекчәдән) исемле шигырен яза.

*«Әл-ислах», 68 нче сан.*

**12 июль.** Дусты Каюм Мостакаевка «Мөхтәрәм Габделкаюм әфәндегә ядкяр. 1909 сәнә, 12 июль. Габдулла Тукаев» дигән автограф белән үзенең фоторәсемен бүләк итә. Бу чорда алар еш очрашып, якынаеп китәләр.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 27-эш.*

**21 июль**. «Әл-ислах»та «Төрекчәдән» (Сөйгәнеңне мин көчам...), «Гашыйк», «Вакты гаҗезем», «Шекспирдан» (Күрәм кайчакта...) шигырьләре басылып чыга.

*«Әл-ислах», 68 нче сан.*

**Җәй.** Мәхмүт Дулат-Алиевның (1889—1920) чакыруы буенча, Дулат-Алиевлар өендә, Яңа Бистәдә Мехчылар урамындагы (элек Большая Симбирская дип йөртелгән) 37 нче йортта 15—20 көн чамасы кунак була. Мәхмүт һәм иптәшләре белән йортның түрендә — печәнлектә йоклый. Якын дусты Вафа Бәхтияров та берничә мәртәбә аның янына барганы хакында яза.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948;*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

«1909 елның җәендә шагыйрь Гурьевкада фабрикант Хәсән Акчуриннарда кунакта була. Хәсән бай татарча да, русча да шактый мәгълүматлы кеше булып, милли мәдәниятнең барышы белән кызыксынып торган, аны күтәрү хакына акчалата ярдәм иткән, ара-тирә җәмәгать эшләрендә катнашкан кеше.

Акчуриннар мәдрәсәсендә хәлфә булып торган Кыяметдин Кадыйриның истәлекләреннән күренгәнчә, Хәсән бай Казанның зур сәүдәгәре һәм җир хуҗасы Бәдретдин Апанаевка үзенең чакыруын Тукайга җиткерергә үтенеп хат язган һәм чыгымына акча да җибәргән. Апанаев исә шагыйрьнең дуслары-

на, башлыча Ф.Әмирханга мөрәҗәгать иткән. Фатыйх барырга киңәш бирә. Дустының икеләнүен күреп, кыстый, үгетли: әйдә, бу даирәне дә күрсен, тәэсирләре артсын, карашы киңәйсен, дип уйлый.

Каршылау, кунак итү, әлбәттә, ни җитте генә булмый. Поезд килеп туктаганда, ике тройка белән Хәсән бай үзе, туган-тумачасыннан, якыннарыннан берничә кеше көтеп торалар. Кыңгырау тавышы астында җилдәй очтырып, Хәсән Акчуриннарның зур таш йортына алып кайталар, якты зур бүлмәгә урнаштыралар».

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 200 б.*

Акчуриннарда кунакта чагында ул көн саен диярлек Кыям хәлфә Кадыйри белән бильярд уйный, еш очрашып, дусларча сөйләшеп, якынаеп китәләр. Гурьевкага килгәч, Кыям хәлфәгә Фатих Әмирхан җибәргән хатны тапшыра.

Хәсән Акчурин шагыйрь хөрмәтенә мәҗлес ясый. Бу турыда, һәм, гомумән, Тукайның Гурьевкада үткәргән бер атналап вакытта кемнәр белән аралашуы, шөгыле, кәефенә кагылышлы якларны яктыртып язылган Кыям Кадыйри истәлегеннән укып беләбез. Шуннан бер өзек: «Мәҗлес озакка сузылды. Ул мәҗлестә, рабочий, служащий һәм байлардан башка, укучылар да бар иде. Тукайга сораулар булды. Сорауларга кыска-кыска гына җавап биреп, җыелганнарны шатландырды. Тукай үзе дә мәҗлестә бик шат иде. Тукай фабрик-заводларга да кереп йөрде. Атна-ун көн ял иткәннең соңында, поездга утыртып, зурлап озатып калдык».

*Кадыйри К. Гурьевка фабрикасында.*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 65-эш.*

Тукай, Казанга кайткач, дуслары, фикердәшләре белән тәэсирләрен уртаклаша. Татар фабриканты Акчуриннарның үзен шулай зурлап, хөрмәт күрсәтүләрен әллә ни исе китмичә, үзе өчен зур, әһәмиятле, җитди эшкә санамый. Г.Камалның: «Ничек соң, кунакта сыйладылармы?» — дигән соравына да уенкөлке белән шаярып җавап бирә: «Сыйлавын шартлаганчы сыйладылар. Шулай да үземнең караватымны сагынып кайттым әле. Безгә кул кеше түгел алар. Әллә ничә горничный нянка шикелле ашаталар, нянка шикелле эчертәләр, нянка шикелле йоклаталар. Үзең теләгәнчә йокларга ирек тә юк. Сыйлары да гел коньяк та шампанский. Безнең шикелле кара корсакка кул нәрсәләрмени алар?» — диде, ник барганына үкенгән көнгә төшкәнен белдерде»,— дип укыйбыз истәлекләрдән.

*Камал Г. Габдулла Тукай турында истәлек.*
*«Хатирәләр», 67 б.*

Гурьевкада фабрикант Акчуриннарда булып кайтканнан соң, апасы Газизә Зәбировага хат яза. Хатның сәфәргә кагылышлы өзеге вафатына бер ел тулу уңае белән басылган мәкалә эчендә китерелгән: «Казаннан бер дә читкә чыкканым юк, диер идем, әле шул арада гына Сембер ягындагы Хәсән Акчурин нам фабрикантка барып, биш кич кунып кайттым. Бер дә көтмәгәндә, аңсыздан хәбәр бирделәр. Мин үзем Казанда да шалапай йөрим. Рәтләп киенергә дә юынырга да өлгерә алмадым. Алар, әлбәттә, бай кешеләр. Сыйлауларын язудан каләм гаҗиз. Бару-кайту расходы алардан. Шуның өстенә, киткәндә, 50 тәңкә акча һәм киемлекләр биреп җибәрделәр. Бер белмәгән, танымаган кешенең кисәктән шундый хөрмәт күрсәтүе гаҗәп түгелме? Гаҗәп булган өчен яздым».

*«Ил», 1914, 2 апрель;*
*Нуруллин И. Юл уңаеннан.*
*«Социалистик Татарстан», 1986, 4 май, 103 сан.*

**3 сентябрь.** «Яңа кыйраәт» исемле китабы (Әдәбияттан дәреслек хрестоматия. Казан, «Үрнәк» матбагасы) басылып чыга.

Бу китап мәктәпләрдә әдәбият укыту өчен хрестоматия формасында төзелгән. Китапка Тукайның 18 шигыре һәм 47 вак хикәясе урнаштырылган. Рус классик язучыларыннан Пушкин, Лермонтов, Кольцов һәм Толстойдан тәрҗемә ителгән әсәрләр дә бар.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 305 б.*

**17 сентябрь.** «Йолдыз» газетасында «Яңа әсәрләр» бүлегендә Кәбир Бәкернең «Яңа кыйраәт» (Габдулла Тукаев әсәре, «Үрнәк» матбагасы) исемле рецензиясе басылып чыга. Мәкаләдә автор, кыйраәт китаплары нинди методлар белән төзелергә тиешлеге әлеге җыентыкның керешендә ачык язылганлыгын әйтеп, китапның мөндәриҗәсенә тукталып, түбәндәгеләрне яза: «Хикәяләре мәгънәле, шигырьләре дә тирән хиссиятләр калдырырлык дәрәҗәдә гүзәл... Бу китаптан беренче максат та мөкаддәс ана теле үгрәтү булганлыктан, китапның бу җәһәте тәмамы илә тәкъдир итәрлектер».

К.Бәкер фикеренчә, китаптагы тәрҗемә әсәрләрнең теле шулай ук бик матур һәм җиңел. Ул китапның тарыз тәртибенә караган кимчелекләрен дә күрсәтә. Аңлау өчен авыррак әсәрләрне (мәсәлән «Тәэссер» кеби) китапның ахырына калдырып, баштагы битләргә җиңелрәк әсәрләрне урнаштыру отышлырак булыр иде дип саный ул. «Инде безнең мәктәпләр өчен,—

---

Кыйраәт китабы — уку китабы, хрестоматия.
Мөндәриҗә — эчтәлек.
Тарыз тәртибе — төзелеше.

дип яза автор,— русларның мәктәп китапларыннан файдаланып, милли шигырьләр, уртак хикәяләргә, табигать, тарихи вакыйгалар, мәшаһирләрнең тәрҗемәи хәлләрен катыштырып, 200—300 битлек кыйраәт китаплары эшләргә дә вакыт һәм дә бик вакыт иде».

*«Йолдыз», 446 нчы сан.*

**22 сентябрь.** «Китап» шигырен яза.

*«Йолдыз», 453 нче сан.*

**29 сентябрь.** «Исемдә калганнар» исемле автобиографик хикәясенең кереш өлешен (мөкаддимә) язып тәмамлый.

«Бу «Исемдә калганнар»ны язуыма башлыча сәбәп берничә наширләрнең миннән тәрҗемәи хәлемне язып бирергә үтенүләре булды.

Мин аларга туганымнан алып хәзерге яшемә кадәрге тәрҗемәи хәлемне кыска гына рәвештә язып бирү нияте илә кулыма каләм алган идем, әллә ничек сүз озынга китте.

Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде.

Шунлыктан Уральскига килеп җиткәнемә кадәр кичердегем хәлләр илә аннан соң шушы сәтырларны язып утырган вакытыма кадәрле башыма килгәннәрне икесен ике рисалә итеп чыгарырга* мәгъкуль күрелде». Керешнең азагында Тукай үз кулы белән «29 нчы сентябрь, 1909 сәнә» дип язып куйган.

*«Исемдә калганнар», 3 б.*

**29 сентябрь — 26 октябрь.** «Вакыт» газетасы хәбәр итә: «Мөгаллим әфәнде дикъкатенә! Габдулла әфәнде Тукаевның «Яңа кыйраәт» нам әсәре басылып чыкты. Урта кулда 64 битле кыйраәт китабы мәктәп балаларына укыту өчен гүзәл мәгънәле хикәяләр вә балаларга укырдай иң яхшы шигырьләр кертелмештер».

*«Вакыт», 525—538 нче саннар.*

**3 октябрь.** «Китап» шигыре басылып чыга. Әсәр рус балалар шагыйре Н.И.Позняковның (1857—1910) «Книга» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

*«Йолдыз», 453 нче сан.*

**9 октябрь.** «Идел» газетасы хәбәр итә: «Бу көннәрдә «Яңа кыйраәт», ... нам әсәрләр идарәмезгә килде.

---

* Икенче өлеше язылмый калган булса кирәк.

Мәшаһирләр — мәгълүм шәхесләр, бөек кешеләр.

Сәтыр — юл, язу юлы.

Рисалә — китап, җыентык.

Мәгъкуль — урынлы, тиеш.

«Яңа кыйраәт» мәктәп балаларына махсус бер дәрес китабы улып, гаять гыйбрәтле вә файдалы, көлке, кыска-кыска кинаяләр, гаять ләззәтле шигырьләрдән гыйбарәт. Шигырьләрнең мәгънәле вә ләззәтле булуы Габдулла Тукаев әсәрләре идекеннәндер. Әсәр Казанда «Үрнәк» матбагасында табгы ителмеш».

*«Идел», 194 нче сан.*

**12 октябрь.** Яңа кулъязма дәфтәр («Мәктәп шигырьләре») ача һәм аңа беренче шигырь итеп «Мөкаддәмә» әсәрен терки.

Г.Тукай кульязмаларын өйрәнгән галим Зөфәр Рәмиев 8 биттән торган бу дәфтәр турында: «Дәфтәр бертөрле кәгазьләрдән һәр бите ак кәгазьгә ябыштырып эшләнгән, моны соңыннан җыйганнар булса кирәк»,— дигән искәрмә ясый.

*Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты..., 2002, 92 б.;*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 12-эш.*

**15 октябрь.** «Ай һәм Кояш» шигырен яза.

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 157 б.*

«Йолдыз» газетасы: «Бу көннәрдә мәшһүр шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаевның «Әдәбият» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр) нам әсәре басылып чыкты»,— дип хәбәр итә.

*«Йолдыз», 457 нче сан.*

**16 октябрь.** «Бишек җыры» шигырен яза.

*Өч томлы* «Әсәрләр», 2 т., 158 б.*

**19 октябрь.** «Ана догасы» шигырен яза.

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 158 б.*

**21 октябрь.** «Сабыйга» шигырен яза.

*«Балалар күңеле», 5 б.*

И.С.Никитинның «Ласточка» шигыренә ияреп, «Карлыгач» әсәрен яза.

*«Балалар күңеле», 16 б.*

---

* Ф.Сәйфи-Казанлы тарафыннан төзелгән өч томлы Г.Тукай «Әсәрләр»енең 2 нче томында (1929) түбәндәге юллар бар: «Татар мәдәнияте йорты янындагы китап палатасында Г.Тукайның ике кулъязмасы саклана. Бу кулъязмада Тукай үзенең шигырьләренең тарихын күрсәтеп барган. «Киләчәк искәрмәләрдә «Кульязма» дип әйтелсә, шунда саклана торган кулъязма дип белергә кирәк».

Хәзерге вакытта бу кулъязма дәфтәрләрнең язмышы билгесез. Кайбер шигырьләрнең язылу вакыты, башка ышанычлы чыганаклар булмаганда, шушы өч томлы «Әсәрләр»дән алып куелды.

«Кышкы кич» шигырен яза.

*«Балалар күңеле», 19 б.*

**23—24 октябрь.** «Эш беткәч уйнарга ярый» исемле шигырен иҗат итә. Әсәр А.Н.Майковның «Кончай дело, гуляй смело» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 159 б.*

**25 октябрь.** «Мәктәптә» шигырен яза.

*«Балалар күңеле», 11 б.;*
*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 159 б.*

**27 октябрь.** «Әдәбият» исемле шигырьләр җыентыгы («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр. Казан, «Үрнәк» матбагасы. Беренче битендә Тукайның рәсеме дә бар) басылып чыга.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.*

«Әдәбият»ка барлыгы 30 шигырь кертелгән, шулардан 20 се моңарчы төрле газета-журналларда басылган әсәрләр. 10 шигырь исә җыентыкта беренче тапкыр дөнья күрә. Алар түбәндәгеләр: «Эш», «Әнә-менә», «Яратырга ярый», «Могҗиза», «Туган авыл», «Чыршы», «Яңгыр илә кояш», «Милли моңнар», «Сөбханалла, сөбханалла».

Тукайның замандашы һәм аралашып торган дусты, моңлы, көйле тавышка ия булган Солтан Рахманколый бер истәлегендә болай ди: «Тукай үзенең «Сөялгәнсең чатта...» дип («Эштән чыгарылган татар кызына») һәм «Ишеттем мин кичә бераү җырлый...» («Милли моңнар») дип башлана торган җырларын иң әүвәл миңа (үтенеп) җырлатты».

«Япун хикәясе» исемле шигъри хикәясе дә беренче мәртәбә бу җыентыкта басылган.

Рус язучысы В.П.Буренинның (1841—1926) «Японская сказка» исемле көйле хикәясеннән тәрҗемә дип санала. Тукай хикәянең төп юнәлешенә зур үзгәреш кертми, тик Буренин хикәясендәге «император» сүзен «хан» дип алмаштыра һәм, үзеннән кайбер детальләр өстәп, хикәяне тулыландыра.

Япониядә яшәүче бер ташчы, авыр эштән тәмам туйгач, байлыкка кызыга һәм аны ишетеп алган бер фәрештә теләгенә ирештерә. Егетне байга, кояш, болыт, тау-ташка да әверелдереп карый, ләкин аңа берсе дә ошамый. Ахырдан егет:

Кирәк түгел, мин яңадан ташчы булам,
Әүвәлгечә иҗтиһадлы эшче булам! —

ди һәм яңадан ташчы була.

*«Әдәбият», 3 б.*

Ә Р.Нәфыйгов исә: «Япун хикәясе»нең сюжетын Тукай «Уралец» газетасыннан алган дип уйларга була. Аның 1903 елгы 13 декабрь санында «Японский каменщик» исемле әкияте басылган»,— дип язды.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986,с. 9.*

**28 октябрь.** «Уянмас йокы» шигырен яза.

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 160 б.*

**29 октябрь**. К.Д.Ушинскийның «Мальчик и мотылек» исемле шигыреннән файдаланып, «Бала белән күбәләк» шигырен иҗат итә.

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 161 б.*

**31 октябрь.** «Кярханәдә» шигырен яза.

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 159 б.*

**2 ноябрь.** Дусты Якуб Байбуринга «Әдәбият» дигән җыентыгын «Иптәшем Якуб Байбуринга ядкяр», 2 ноябрь, 1909 ел, Г.Тукаев» дигән автограф белән бүләк итә.

*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 4-эш.*

**10 ноябрь.** «Кәҗә белән Сарык хикәясе»н яза.

*«Балалар күңеле», 28 б.;*
*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 171 б.*

**12 ноябрь.** «Исемдә калганнар» исеме белән автобиографик әсәре (Казан, «Үрнәк» матбагасы) басылып чыга. Тышлыкта Тукайның фоторәсеме бирелгән. 38 б., 4000 данә.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.*

**13 ноябрь.** Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы таләбе буенча, «Әл-ислах» газетасы редакторы буларак, Тукайның якын дусты Вафа Бәхтияров полициянең яшерен күзәтүе астына алына һәм бу күзәтү 1914 елга кадәр дәвам иттерелә.

*ТРМА. 1-ф., 260-эш, 2-3, 9 б.;*
*Нәфыйгов Р. Габдулла Тукай биографиясе. «КУ», 1966, 8 нче сан.*

**15 ноябрь.** «Йолдыз» газетасы хәбәр итә: «Яңа чыккан китаплар. Г.Тукаев. «Әдәбият», «Исемдә калганнар».

*«Йолдыз», 470 нче сан.*

**19 ноябрь.** «Иртә» дигән шигырен яза.

*«Балалар күңеле», 13 б.;*
*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 174 б.*

**22 ноябрь.** «Күңел йолдызы» исемле шигыре басылып чы-

га. Төрек шагыйре Габдулла Җәүдәтнең (1869—1932) «Бер кыйтга» исемле шигыреннән:

Тәнәфферләр, тәхаттырлар, тәрәххемләрлә дөньядан
Гәзәрем, захмедар васле бер һиҗрә мөкәүкәбдер!* —

дигән ике юлы эпиграф итеп китерелгән һәм «Күптән инде, Габдулла Җәүдәтнең шул ике сәтыры күңелемә ошагач, мин дә бер нәрсә язган идем. «Йолдыз»га мөнәсәбәте булганга, шунда дәрҗ иттердем» дип искәрмә бирелгән.

*«Йолдыз», 472 нче сан.*

**23 ноябрь.** «Балалар күңеле» исемле китабы (Беренче җөзьэ. Ибтидаи мәктәпләр өчен шигырьләр мәҗмугасы. Казан, «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы)** «Сабах» ширкәте идарәсеннән кереш сүз белән басылып чыга.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 306 б.*

**27 ноябрь.** «Киңәш (Чикмә гамь шул нәрсәгә...)» шигырен яза. Шигырь ике кисәктән тора. Беренчесе «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен...» дип, икенчесе «Чикмә гамь шул нәрсәгә...» дип башлана. Аска «27 ноябрь, 1909 сәнә» дип куелган. Соңрак («Күңел җимешләре»ндә) мөстәкыйль ике шигырь итеп басылган.

*«Йолдыз», 472 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 353 б.*

Бу шигырьнең беренче кисәгендә:

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.
Караңгыдыр, күңелсездер гомре юлы,
Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры,
Шиксез, аның җәрәхәтле күкрәгендә
Яшерен генә янып яткан хәсрәт тулы,—

дигән юлларда сабый чагыннан ук халыкның ачы газабын, хурлану - кимсетелүләрен, бөлгенлекләрен үз җилкәсендә кичергән шагыйрьнең хезмәт иясе язмышына битараф булмавын, халык күңелендәге «ачы хәсрәт көе» белән дулкынлануын күрәбез.

**28 ноябрь.** «Әдәбият» исемле шигырьләр җыентыгы һәм «Исемдә калганнар» әсәренең дөнья күрү уңае белән «Вакыт»

---

* Нәфрәтләнү, хәтерләүләр, ачынулар белән дөньядан үтәрмен,
Шулай да яралы күңел бер сөю белән нурланган.

** «Теркәү дәфтәре»ндә «Балалар күңеле» (беренче җөзьэ) китабының дөньяга чыгу вакыты «1909 ел, 23 ноябрь» диелгән. Китапның тышлыгында исә «1910» датасы тора.

газетасы игълан итә: «Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр». Мәшһүр шагыйрьләремездән Габдулла әфәнде Тукаев әсәре, шагыйрьнең рәсеме илә.

«Исемдә калганнар» — шагыйрьнең автобиографиясеннән бер өзек (үз каләме илә язылган тәрҗемәи хәленнән)».

*«Вакыт», 550 нче сан.*

**29 ноябрь.** «Киңәш» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 472 нче сан.*

**1 декабрь.** «Вакыт» газетасы хәбәр итә: «Сабах» көтепханәсе. Балалар бәхетенә зур бер адым. Шагыйрь Габдулла Тукайның «Балалар күңеле» намендәге әсәреннән беренче җөзьэ басылып чыкты».

*«Вакыт», 551 нче сан.*

**2 декабрь.** «Йолдыз» газетасының «Яңа әсәрләр» бүлегендә Кәбир Бәкер Тукайның «Әдәбият» исемле китабына рецензия белән чыга.

Китапны төрле яктан анализлап, автор түбәндәгеләрне яза: «Бу мәҗмугада дәрҗ ителгән шигырьләр шагыйрь әфәнденең иң соңгы вә бер кыйсеме дә матбугатка бертөрле дә кермәгән яңа шигырьләредер... биредә бик оригинальный шигырьләр дә бар. «Тәрәддед вә шөбһә» шигыре мисалында шагыйрьнең рухи халәтендәге өметсезлек, хандра, шөбһәләрнең вакытлы бер нәрсә икәнлеген күрсәтә. Рецензия «Тукаев шигырьләре, кирәк кафия, кирәк вәзен җәһәтеннән булсын, чын татар шигырьләредер... Тукаев шигырьләрен укыганда, гаҗәп бер җиңеллек, кафия вә сәҗегъләрнең татар гармониясенә тәмамилә килеп торганлыгы хис ителә.

Шуның илә бәрабәр мәгънә җәһәтеннән дә бөек бер галилек, чын шагыйрьләрдә генә була торган муаффәкыятьлек күренеп тора. Шуның өчен Тукаевны чын татар шагыйре дип танучы вә аның шигырьләрен иң әүвәл тәкъдир итүче Фатих Әмирхан вә Борһан Шәрәф әфәнделәр алданмадылар* дип беләм.

Бу мәҗмугада Тукаевның иң муаффәкыятьле вә иң тәкъдир ителергә тиешле булган шигырьләре дә — «Милли хисләр», «Эштән чыгарылган татар кызына» һәм «Сөбханалла, сөбханалла» шигырьләре, «Гашыйк»ны да шул рәткә куярга ярый.

Без бу шигырьләрне укып, бөтен татар дөньясындагы укучылар белән хиссиятләремезне уртаклаша алабыз»,— дигән юллар белән тәмамлана.

*«Йолдыз», 476 нчы сан.*

---

* Тукайның элеккеге китапларына Ф.Әмирхан, Б.Шәрәфләр язган рецензияләрендәге югары бәягә ишарә ителә.

**6 декабрь.** «Йолдыз» газетасының «Яңа китаплар» бүлегендә Кәбир Бәкер Тукайның «Исемдә калганнар» исемле китабына рецензия белән чыгыш ясый.

Анда түбәндәге юллар бар: «Югарыдагы исем белән күптән түгел беренче шагыйрьләремездән Габдулла әфәнде Тукаевның автобиографиясе — үз каләме белән язылган тәрҗемәи хәле чыкты. Биредә шагыйрь әфәнденең истикъбален күрсәтүдә иң әһәмиятле булган тәрбияи гыйльмия дәвере зикер ителмәгән. Бу рисаләдә фәкать туган көндән алып 9—10 яшьләренә кадәр башыннан үткән хәлләр генә язылган.

Тәрҗемәи хәлнең бу җөзьэсе хакында әйтәчәк сүзем булса, ул да шуннан гыйбарәт: шагыйрь әфәнденең бала вакыты бик аянычлы һәм шуның белән бергә бик гаҗәеп кызык бер сурәттә үткән.

Булачак шагыйрьнең куәт вә истигъдадына иң яхшы бер тәрбия кирәк вакытта аның вөҗүде табигатьнең иң явыз эскәнҗәләре арасында кысылган.

Шуның өчен булырга кирәк, без моңа кадәр шагыйрь әфәнде авызыннан табигатьне (природаны) мактап язган вә аның төрле үзгәрешләрен матур картиналарда тасвир иткән бер шигырь ишеткәнемез юк*.

Икенче бер гыйбарә белән әйткән вакытта, шагыйрь әфәнде тарафыннан тасвират кыйсемендә җумартлык вә ул бабта күрсәткән рәссамлыкка бер дә очраганымыз юк. Аның да сәбәбе — әлеге тәрҗемәи хәлдә күрдекемез золым аркасында шагыйрьнең күңелендә калдырган яман тәэссорат.

Җиңел гыйбарә, тәкәллефсез тәгъбират белән язылганлыктан, һәрбер укыган кешенең күңелендә балалык вакытын мөҗәссәм бер сурәттә күрсәтерлек тасвират (материал) бардыр.

Һәркемгә алып укырга тәүсыя итәчәгем өстенә, мәктәп балалары өчен аеруча игътибар белән укырга кушам. Хрестоматия язучылар, әдәби мәкаләләр җыеп кыйраәт китаплары ясаучыларга да материал булырлык җирләре бар».

*«Йолдыз», 477 нче сан.*

---

* Болай дип әйтү дөреслеккә бик үк туры килми, чөнки Тукайның инде бу чорда табигать күренешләренә багышлап язылган шигырьләре басылып чыккан, мәсәлән, «Яз галәмәтләре», «Кышка бер сүз», «Ай һәм Кояш», «Җир йокысы» һ.б.

Истикъбаль — киләчәк, булачак.
Тәрбияи гыйльмия дәвере — уку, белем алу чоры.
Зикер итү — искә алу.
Рисалә — кечкенә китап, әсәр.
Җөзьэ — кисәк, өлеш.
Истигъдад — сәләт.
Вөҗүд — яшәү.
Эскәнҗә — фаҗига.
Мөҗәссәм — җыйнак, нык.
Тәүсыя итү — киңәш бирү.

**17 декабрь.** «Теләү бетте» шигырен яза.

*«Йолдыз», 481 нче сан.*

**19 декабрь.** «Идел» газетасы хәбәр итә: «Яңа әсәрләр. 1. «Исемдә калганнар» Г.Тукаев. 2. «Әдәбият». «Шигырь мәҗмугаларыннан 10 нчы китап улан бу әсәре янә Габдулла Тукаевныкыдыр. Һәр икесе «Юл» көтепханәсе нәшрияты».

*«Идел», 213 нче сан.*

**20 декабрь.** «Теләү бетте» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 481 нче сан.*

**31 декабрь.** Габдулланың бабасы (әнисенең әтисе) Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы Әмиров үлә (1829 елның 30 декабрендә туган). Өчиле авылы имамы булып торган. Өчиле авылы зиратына җирләнгән.

*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 14 б.;*
*Әмирова-Мөхәммәтҗанова Р. Тукай Өчиле авылында. «Истәлекләр», 161 б.*

**1909—1910 еллар.** Тукай вакыт-вакыт Казанның Яңа бистәсендәге Мәхмүт Дулат-Алиевлар йортына килеп чыга, кеше күзеннән югалып торып, иҗат эше белән шөгыльләнә.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

## 1910

**Кыш — яз.** Тукайның дусты һәм замандашы Вафа Бәхтияров истәлегенә караганда, шагыйрь 1910 елның кышында 4—5 ай чамасы «Амур» номерларында (хәзерге Киров урамы, 70 нче йорт), 3 нче катта, 33 нче бүлмәдә яши. «Ачы тәҗрибә авазы», «Авыл җырлары», «Ник? Нигә?» исемле шигырьләрен монда яза.

*Бәхтияров В. «Альбом», 1948.*
*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 6-эш.*

**1 гыйнвар.** «Татар мөхәрриренә» исемле шигырен яза. И.Нуруллин: «Тукай 1910 елны... гаять тәшвишле шигырь белән каршы ала»,— дип искәртә.

*«Йолдыз», 486 нчы сан;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 180 б.*

---

Т ә ш в и ш л е — каршылыклы.

М.Бигиев «Рәхмәте илаһия гомумияте хакында борһаннарым» дигән күләмле мәкаләсенә эпиграф итеп Тукайның «Васыятем» шигыреннән дүрт юлын китергән:

Дустларым, кордашларым! Сез муллаларга әйтегез:
Шул ике юлны мин үлгәч укырлар кабремә.
Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен күреп актык сүзем:
«Күр, нә рәсмә тулган иман илә Коръән садремә!»

*«Шура», 1 нче сан.*

**3 гыйнвар.** «Татар мөхәрриренә» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 486 нчы сан.*

**7 гыйнвар.** «Нәсыйхәт» шигыре басыла.

*«Йолдыз», 488 нче сан.*

**12 гыйнвар.** Г.Ибраһимовның «Габди» имзасы белән басылган «Татар матбугаты» дигән тәнкыйть мәкаләсендә Тукай шигырьләре, аларның татар әдәбиятында тоткан урыны һәм укучыларның бу иҗатка мөнәсәбәтләрен күрсәтеп язылган мондый юллар бар: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле вә галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗә ки: татар шагыйре диелүгә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була. Бу шагыйребез көннән-көн күтәрелә. Халык күңелендә хак вә ихтирамлы урын ала барадыр. Татар шигыре мәйданында Тукаев иң гали ноктада тора... шулай булуы табигыйдер, чөнки табигый талант вәһаби истигъдад янында әһбабе һәвәс вә әҗваф яшәргә мөмкин түгел». Бу озын мәкаләдә Г.Тукайдан тыш, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан һ.б. язучыларның иҗатына да күзәтү ясалган.

*«Йолдыз», 490 нчы сан.*

**19 гыйнвар.** «Идел» газетасы Тукайның шигырьләр җыентыгы басылып чыгу уңаеннан игълан урнаштыра: «Балалар күңеле» ибтидаи сыйныф балаларына укытыр өчен Габдулла Тукаев тарафыннан тәртип ителмеш дәрес китабы, шигырьләр

---

Әһле тәкфир — кяфер, динсез дип әйтүчеләр.
Садыр — күңел.
Шәүкәтле — куәтле.
Галәбәле — өстенлекле.
Мәүҗүд була — пәйда була, туа.
Гали — бөек.
Вәһаби истигъдад — табигать бүләк иткән сәләт.
Әһбабе һәвәс вә әҗваф — һәвәскәр һәм бушкуыклар.
Ибтидаи сыйныф — башлангыч класс.
Тәртип ителмеш — төзелгән.

мәҗмугасыдыр. Гаять гыйбрәтле вә гаять файдалы, балаларның рухларын вә милли хиссиятләрен уйгатуга хезмәт итәчәк».

*«Идел», 222 нче сан.*

«Йолдыз»ның «Яңа әсәрләр» бүлегендә Кәбир Бәкернең «Балалар күңеле» дигән рецензиясе басыла.

«Бездә, мәктәпләрдә, чын татар телен өйрәтә вә шуның белән бергә гали хиссиятләр тудыра торган бер кыйраәт китабы юк иде,— дип яза автор.— Менә алдымда беренче шагыйрьләремездән Тукаев җәнабләренең «Балалар күңеле» исемле шигырьләр мәҗмугасы. Бу мәҗмуганың башыннан алып ахырына кадәр бар шигырьләре дә балалар өчен язылган вә азмы-күпме кирәкле хиссиятләр тудыра торган, балалар күңеленә азык бирә торган шигырьләрдер. Хосусан «Туган тел» балалар рухына бик якын һәм бик муаффәкыятьле бер рәвештә язылган.

Моңарчы булган уку китапларында көйле әсәрләр зур урын ала. Балалар хәтта бик тәэсирле мәкаләләрне дә «Фазаиле шөһүр» китабы көенә салып укыйлар һәм бөтен бирә торган тәэсирен җуялар иде. Бу китапка кертелгән шигырьләр исә көйгә килми, чөнки тәэсирле уку үзенә күрә бик зур бер кәмаләт санала торган нәрсә. Шуның өчен мәктәп балаларын тәэсирле укырга да өйрәтергә кирәк. Бу китап исә шуңа хезмәт итәчәк».

*«Йолдыз», 493 нче сан.*

**4 февраль.** «Яшен» журналы чыгудан тукталганнан соң, 8 ай үткәч, демократик яшьләрнең һәм Тукайның тырышлыгы белән Әхмәт Урманчиев «Ялт-йолт» дигән сатирик журнал чыгарырга рөхсәт ала.

*ТРМА. 20-ф., 1-тасв., 166-эш.*

«Мәҗрух указ» шигырен яза. Ул элекке Самар губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе) Бозаулык шәһәре мулласы, язучы Галиәсгар Гафуровның (Чыгтайның) «Исабәт» исемле китабына каршы күтәрелгән шау-шу уңае белән язылган. Кадимчеләрнең басымыннан куркып, Чыгтай, үзенең фикерләреннән кайтып, китабын яндыра һәм «тәүбә» итү һәм указын саклап калу өчен, Уфага Духовное собраниегә бара.

*«Йолдыз», 501 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 348 б.;*
*Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар, 1968, 208—209* б.

---

М ә җ м у г а — җыентык.
Г а л и  х и с с и я т — бөек хисләр.
К ы й р а ә т  к и т а б ы — уку китабы, дәреслек-хрестоматия.
М у а ф ф ә к ы я т ь л е — уңышлы, туры килгән.
К ә м а л ә т — камиллек, җитешкәнлек.
М ә җ р у х — яралы, җәрәхәтле.

**7 февраль.** «Мәҗрух указ» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 501 нче сан.*

**23 февраль.** «Кәҗә тугрысында» шигыре «Шүрәле» имзасы белән дөнья күрә.

*«Йолдыз», 508 нче сан.*

**6 март.** «Йолдыз» газетасы редакция исеменнән Тукайны мактап шигырь җибәргән бер хәбәрчесенә атап түбәндәге ачык хатны урнаштыра: «Тукаев җәнабләренә» сәрләүхәле шигырегезне Тукаевның үзенә күрсәттек. Хөсне занығызга тәшәккер итсә дә, үзе хакында күтәренке сүзләрне басмавыбызны үтенде. Шул сәбәпле дәрҗ ителмәде».

*«Йолдыз», 512 нче сан.*

Биредә шагыйрьнең гаҗәеп тыйнаклыгы күренә. Билгеле булганча, шул заман җәмәгатьчелеге үзенең сөйгән шагыйре Тукайга зур хөрмәт белән карый. Хатлар яза, аңа багышланган шигырьләр, әсәрләрен хуплап язылган мәкаләләр бастыра. Шагыйрь мондый мактауларга каршы төшә һәм үзенә билгеле булган очракларда аларны бастырмаска тырыша. Аның бу мәсьәләгә карашы укучыларга да билгеле була.

**15 март.** Казанда Әхмәт Урманчиев редакторлыгында һәм наширлегендә, секретаре Г.Тукай булган рәсемле сатирик «Ялт-йолт» журналының 1 нче номеры чыга. Демократик юнәлештәге бу журнал 1918 елга кадәр дәвам итә.

Истәлекләрдә (мәсәлән, К.Бәкер, Г.Камал) бу журналның Тукай инициативасы белән чыгарыла башлавы, үлгәнчегә кадәр журналда аның берьялгызы эшләве әйтелә.

Тукай «Ялт-йолт»ка язышучылар даирәсен киңәйтүгә, аның һәр саны тирән эчтәлекле булып чыгуга күп көч куйган. Журналда Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Әхмәт Урманчиев, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Нәҗип Думави, Сәгыйть Сүнчәләй, Шәһит Әхмәдиев, Миргазиз Укмасый һ.б.ның әсәрләре басылган. Бик күп язмалар яшерен имза белән чыккан.

«Ялт-йолт» Казанда, Идел буенда яшәүче татарлар арасында гына түгел, Уралда һәм башка регионда яшәүче төрки телле халыклар (башкортлар, казахлар, үзбәкләр, азәрбайҗаннар) арасында да тарала. Башта, 1910—1911 елларда, аның тиражы 1200 тирәсе була.

Журналның халык арасында бик популяр булуы да Тукайга бәйле. Ул — аңа нигез салучы, оештыручы һәм идея җитәк-

---

Сәрләүхәле — исемендәге.

Хөсне занығызга тәшәккер итсә дә — яхшы караштa булуыгыз өчен рәхмәт әйтсә дә.

Дәрҗ ителмәде — басылмады.

чесе дә. Бу турыда журналның үзендә дә күп мәртәбәләр язып чыгалар. Мәсәлән, 55 нче сан түбәндәге сүзләр белән ачыла: «Габдулла Тукаев «Ялт-йолт»ны оештыручыларның берсе иде. Ул биредә 1 нче саннан башлап эшләде... Габдулла Тукай «Ялт-йолт»ның системалы чыгуына һәм таралуына булышлык итте. Тукайның юмористик һәм сатирик таланты, аның «Ялт-йолт»та басылган мәкаләләренең югары сыйфатлы булуы безнең укучыларыбызның ихтирамын казанды».

*«Ялт-йолт», 55 нче сан, 2 б.;*
*ПҮДТА. 776-ф., 21-тасв., 11 кисәк, 11-эш, 418 кәгазь;*
*821-ф., 133-тасв., 421-эш, 10 кәгазь;*
*Бәкер К. Тукай Петербургта, 1914, 4 б.;*
*Камал Г. Габдулла Тукай турында истәлек.*
*«Замандашлары», 73 б.;*
*Гимадиев У. Сила сатирического слова,*
*1987, с. 62—63, 67.*

«Ялт-йолт» журналының беренче санында «Гаҗәп талантлар» дигән фельетоны (имзасыз), «Исабәтченең тәүбәсе» исемле рәсем-карикатура белән янәшәдә (анда бер чалмалының, ул «Исабәт»нең авторы Чыгтайга охшатып ясалган, күп чалмалылар алдында тәүбә итеп утырганы сурәтләнгән), «Мәҗрух указ» шигыре, «Сабын ашаганнар» исемле («Шүрәле» имзасы белән) һәм «Ике хәзрәт вә извозчик» дигән мәкаләләре, «Зур бәшарәт» шигыре («Гөмберт» имзасы белән) басылып чыга.

1910 елда Петербург мулласы, дин философы Муса Бигиев «Рәхмәте илаһия гомуми» (Алланың рәхмәте барлык кешегә дә) дигән китап чыгара. Анда Алланың рәхмәте киң булуы, мөселманнарның да, мөселман түгелләрнең дә ахирәттә оҗмахка керәчәкләре Коръән аятьләре белән исбатланып сөйләнә. Китап чыккач та, динчеләр арасында шау-шу күтәрелеп, газета һәм журналлар, аеруча клерикаль «Дин вә мәгыйшәт», «Бәянелхак» кебекләр, айлар буе озын-озын мәкаләләр бастыралар. Тукай бу шигырендә, «зур сөенеч» дип, шул китаптан, аның тирәсендәге шау-шудан көлә.

*«Ялт-йолт», 1 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 356 б.*

**23 март.** «Җәйге таң хатирәсе» исемле шигыре басыла. Әсәр рус шагыйре А.М.Федоровның «Рассвет» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

*«Йолдыз», 518 нче сан.*

**26 март.** «Яңа әсәрләр» исеме астында рецензия басылып

Бәшарәт — сөенеч.

чыга. Биредә «Кәшшаф Патин шигырьләре» исемле җыентыкны мактап язылган. Кәшшаф Патинның иҗатын Тукай белән чагыштырып: «Г.Тукайдан соң беренче шагыйремез»,— диелә.

*«Идел», 241 нче сан.*

**1 апрель.** «Ялт-йолт» журналының икенче номеры басылып чыга. Биредә Тукайның түбәндәге әсәрләре урнаштырылган: «Шүрәле» имзасы белән «Авыл җырлары» (дүртенче көлтә) шигыре, «Догачы шүрәле» имзасы белән «Яшен» мәрхүм» исемле мәкаләсе. Соңгысы 1909 елның җәендә материаль һәм цензура кыенлыклары аркасында «Яшен» журналы чыгудан туктап, аның традициясен дәвам иттерүче «Ялт-йолт» журналы дөньяга килү уңае белән язылган: «Заман кичте. Сулар акты. Менә көннәрдән бер көн мәйданы матбугатка «Ялт-йолт» журналы килеп чыкты. Ул ялт-йолт итте һәм руи зәмин яктырып китте.

«Ялт-йолт» чыгып ялтырагач, табигый уларак, минем исемә мәрхүм «Яшен» килеп төште. Чөнки «Яшен» дә ялтырый иде бит...

Һәм, вакыйган: сез бу «Ялт-йолт»ны кайдан ялтырый дип беләсез? Ул һаман да шул яңадан терелгән «Яшен» нурыннан ялтырый.

Яшәсен «Яшен», яшәсен «Ялт-йолт!»

Шунда ук «Тиле» имзасы белән «Ихтар», «Шүрәле», имзасы белән «Авыл җырлары» (дүртенче көлтә) урнаштырылган. «Үзе сәркатип булган журналда ике әсәре арасына башка берәүнең биш-алты юллык кына текстын кертеп җибәрмәс иде Тукай. ...«Ихтар» — һичшиксез, аныкы. «Тиле» имзасы текстның эчтәлегеннән чыгып куелган»,— дигән фикер әйтә З.Рәмиев.

*«Ялт-йолт», 2 нче сан;*
*Рәмиев З. XX йөз башы татар әдәбияты..., 2002, 41 б.*

**1 апрель.** «Ялт-йолт» мөхәррирләреннән берәү-икәү» имзасы белән «Гәзитәләрдән» дигән баш астында: «Вакыт» гәзитәсе Казанда Галиәсгар Камалетдинов тарафыннан «Яшен» чыгарылмаячак икән... дип язганның соңында Әхмәд Урманчиев тарафыннан «Ялт-йолт» исемендә көлке журналы чыгарылачак вә мөхәррирләре арасында Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Габдулла Тукаевлар да бар... дип хәбәр бирә»,— дигән юллар урнаштырылган һәм шуңа җавап рәвешендә «Вакыт»тан көлеп хәбәр китерелгән.

*«Ялт-йолт», 2 нче сан.*

Г.Ибраһимов, «Әдәбият мәсьәләләре» дигән мәкаләсендә («Тәгъриф» исемле бүлекчәсендә) әдәбият нидән гыйбарәт? Аңа

---

Руи зәмин — җир йөзе.
Вакыйган — чыннан да.
Тәгъриф — аңлатма, билгеләмә.

ниләр керә? кебек сорауларга аңлатма биреп, Тукай иҗатына да кагыла: «Рус әдәбияты дигәндә, күз алдында Пушкин, Гоголь, Лермонтов һәм Горький, төрек әдәбияты дигәндә, Әхмәд Мидхәт һәм Тәүфыйк Фикърәтләрне хәтерләсәң, татар әдәбияты хакында сүз чыктымы, Г.Тукай һәм Ф.Әмирханның әдәби һәм шигъри әсәрләре күз алдына килә... Безнең үзебездә татар әдәбияты тәхтенә җәмгы татарча асарь* керсә дә, бу кәлимә мотлак әйтелгәндә, Г.Тукаев ... Ф.Әмирханов кеби шагыйрь вә әдипләребезнең әдәби вә шигъри әсәрләре, ягъни татар телендә язылган шигырь, нәзым, роман, хикәя вә драмаларның мәҗмугы ирадә кыйлынадыр».

*«Йолдыз», 522 нче сан.*

**6 апрель.** «Вакыйф Җәлалның «Суксуи» имзасы белән китап укуның белем, хикмәт чишмәсенә алып керүен тасвирлаган «Тәфәккер» исемле (Тукаевның «Тәәссер»енә каршы»**) шигыре басылып чыга.

*«Идел», 243 нче сан.*

**10 апрель.** «Габди» имзасы белән Г.Ибраһимовның «Татар яшьләре» мәкаләсе басылып чыга. Автор яшьләрне сүгеп, каралтып, эшлексез итеп күрсәтү белән килешми. Киресенчә, аларга уку юлында ярдәм итәргә кирәк, ди. Мәсьәләнең бу ягы милләт өстендәге бер бурыч икәнен күрсәтә. Яшьләр арасында үрнәк булырлыклары да шактый. Матбугат мәйданына килсәк, әсәрләре милли әдәбиятның чәчәге диелмәгә лаек булган Гаяз әфәнде, шигырьләре бөтен аңлылар тарафыннан сөеп укылган Тукаев вә чыккан әсәрләре илә киләчәктә олуг өмид биргән Ф.Әмирхан әфәнделәр шул яшьләрнең алгы сафындагы егетләр түгелме, дип куя.

*«Йолдыз», 529 нчы сан.*

**12 апрель.** «Күңелле сәхифәләр» исемендә рәсемнәр белән бизәлгән, балалар өчен язылган шигырьләр җыентыгы басылып чыга. («Мәктәп мөкяфәте»ннән 4 нче китап. Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Милләт» матбагасы. 16 б., 5000 данә.) Бу китапта «Имтияз алган бала», «Һәр ялтыраган алтын түгел», «Безнең гаилә», «Гали белән Кәҗә», «Фатыйма белән Сандугач», «Һәркемнең ашыйсы килә», «Ялкау Маэмай», «Шаян Пе-

---

* Асарь дигән сүз астына барлык татарча әсәрләр керә (*Г.Ибраһимов аңлатмасы*).

** Тукаевның «Тәәссер» исемле шигыре уңае белән» дигән мәгънәдә.

К ә л и м ә — сүз.

М о т л а к — шартсыз, абсолют.

И р а д ә  к ы й л ы н у — күздә тотылу.

Т ә ф ә к к е р — уйлану, фикер йөртү.

И м т и я з — мактау кәгазе.

си», «Кызыклы Шәкерт», «Бичара Куян», «Ак Бабай», «Кичә һәм Бүген» дигән шигырьләр кертелгән.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

**8—13 апрель.** Йолдыз газетасында «Лекция. Ушбу тиз арада «Шәрык» клубы залында Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты тугрысында лекция укыячак»,— дигән игълан урнаштырыла.

*«Йолдыз», 525 һәм 527 нче саннар.*

**13 апрель.** «Мигъраҗ» шигыре басыла. Коръәндәге һәм башка дини китаплардагы «Мигъраҗ» сюжетына ияреп язылган.

*«Йолдыз», 527 нче сан.*

«Ялт-йолт» журналының 3 нче санында «Чүп-чар» исемле мәкаләсе, «Ник? Нигә?» шигыре, «Һөҗүвият» дигән рубрика астында «Шүрәле» имзасы белән «Ике иптәш арасында» шигыре басылып чыга. Соңгысы А.С.Пушкинның «Любопытный» исемле шигыреннән файдаланып язылган.

«Ник? Нигә?» шигырендә, мәсәлән:

Ник, «Болакыл-хак», сиңа юктыр мәхәббәт һәм мәрак?
Шул сәбәптер ки: Болак гөлдән вә рәйханнан ерак,—

дигән юлларда редакциясе Болак буена урнашкан «Бәянелхак» (1906—1914) газетасының исемен шул пычранып беткән Болакка бәйли. «Бәянелхак»тан болай көлүнең сәбәбе аның редакторы һәм нашире журналистика һәм, гомумән, язу эшенә бернинди дә мөнәсәбәте булмаган атаклы консерватор, динче, ысулы кадимче Әхмәтҗан Сәйдәшев булуына да бәйле. Чөнки аның газетасында кем нәрсә теләсә, шуны бастыра алган. Шуңа да бу газетаны Тукай кайчан «Бәянел-кых-тфю!» һәм «Табанел-хак» дип тә атый.

Нигә тынчыкты «Чүкеч» атлы нәҗес вулканы да?
Кем атар инде бу милләтнең йөзенә былчырак? —

дигән юлларда Оренбургта чыккан «Чүкеч»кә (1906—1919) ишарә. Тотрыклы мәсләге булмаган, эчтәлеге-формасы да әллә ни булмаган, тел җәһәтеннән дә шактый чатаклык һәм тупаслыклар күп булган һәм демократик матбугатка да тел-теш тидергән бу журналны Тукай еш тәнкыйтьли. «Чүкеч»нең нашире Тимершаһ Соловьев, җаваплы секретаре Зариф Бәшири була.

*«Ялт-йолт», 3 нче сан. Гимадиев У.*
*Сила сатирического слова, 1987, с. 40.*

---

Һөҗүвият — сатира.
Мәрак — кызыксыну, күңел бирү.
Рәйхан — хуш исле җил.

**15 апрель.** «Йолдыз»да «Катиле нәфескә» шигыре басыла һәм шунда ук игълан-реклама бирелә:

«Бүген, пәнҗешәмбе, 15 апрель, кич 9 сәгатьтә «Шәрык» клубында Габдулла әфәнде Тукаев халык әдәбияты турында лекция укыячак. Билет бәясе утыз тиеннән унбиш тиенгә кадәр».

*«Йолдыз», 529 нчы сан.*

Тукай «Шәрык» клубында үзенең «Халык әдәбияты» дигән лекциясен укый. Тыңлаучыларның күбесе Казанның зыялы яшьләре һәм шәкертләрдән гыйбарәт була.

Язучылардан Гафур Коләхметов катнашканлыгы мәгълүм.

Лекциянең тарихын ул үзе болай аңлата: «Мин халык әдәбияты тугрысында лекция укыйм»,— дип әйткән идем. Ул, шуңар ышанып, Тукаев лекция укыячак икән, дип, могтәбәр гәзитәләребезнең берсенә язып та өлгергән.

Мин, ул иптәшем яныннан чыкканда, уйнап әйттем, ышанып калма тагы, дип әйтергә онытканмын.

Менә шулай итеп, ялгыш, уеннан уймак чыгып куйгандай булып, мин, теге гәзитә хәбәрен тәкзибкә-фәләнгә керешмичә, чынлап та халык әдәбияты хакында үземнең белгән вә хис иткән кадәр фикерләремне сөйләргә җәсарәт итәм».

*«Йолдыз», 19 апрель, 529 нчы сан;*
*Тукай Г. Халык әдәбияты, 1910, 2 б.;*
*Коләхметов Г. Яшь гомер, 1981, 365 б.*

Татар теле һәм фольклор галиме, профессор Хуҗа Бәдигый Тукайның әлеге лекциясен тыңлаган кеше, үзенең истәлегендә болай яза: «Теоретик материал күп булмаса да, лекция миңа бик ошады. Тукай үзенең лекциясендә, хәзерге күзлектән караганда да, халык әдәбиятының (фольклорның) эчтәлеген яхшы ук дөрес билгеләп бирде».

*Бәдигый Х. Исемдә калганнар.*
*«Замандашлары», 121 б.;*
*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 21-эш, 3 б.*

**19 апрель.** «Газаптан соң» дигән шигыре басылып чыга. Автор үзе «Майковтан мокътәбәс» дип куйган. Әсәрдә чагылыш тапкан:

Булмады шул газаплар бәхтемнең ачкычлары!
Җитмәкемнең изге максудка ләгыль баскычлары! —

---

Катиле нәфес — үз-үзен үтерүче.
Могтәбәр — хөрмәтле.
Тәкзиб — ялганга чыгару.
Җәсарәт итү — батырчылык итү.
Мокътәбәс — файдаланып язылган.

дигән юлларны укыгач, борчулы уй-хисләр турында И.Нуруллин болай ди: «Тукайны пессимизмнан саклап калган, аны эшкә, әлбәттә, иҗатка рухландырган төп нәрсә — аның ныклы һәм олы идеалы. Гади кешеләр, хезмәт кешеләренең бәхете өчен яшәгән шагыйрь, көрәшче һәм сугышчы шагыйрь үз эчке дөньясына бикләнә алмый иде. Милләтнең эчендәге һәм тышындагы дошманнарны фаш итә торган сатирасында төшенкелек юк икәнен күрәбез».

*«Йолдыз», 529 нчы сан;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 182 б.*

«Йолдыз» газетасында «Казан хәбәрләре» бүлегендә «Шәрык» клубында лекция» исемле мәкалә басыла. Анда мондый юллар бар: «Пәнҗешәмбе көн 15 апрельдә шагыйрьләремездән Габдулла Тукаев җәнабләре халык әдәбияты һәм милли көйләр вә шигырьләр хакында лекция укыды. Лекциядә нинди көй вә шигырьләрнең халык әдәбияты дип аталганлыгы, татар көйләрендән бәгъзеләренең ни мөнәсәбәт илә чыкканлыгын, татарлар арасында һәртөрле кайгылы вә фаҗигале вакыйгалар тугрысында бәет чыгарырга һәвәс барлыгын һәм халык арасында сөйләнә торган хикәяләрнең әдип вә шагыйрьләр тарафыннан төзәтелеп язылгандан соңра халык әдәбияты җөмләсендән чыкканлыгын мисаллар илә күрсәтте. Мисаллар арасында көлдергеч шигырьләрнең булуы тыңлаучыларның хушына килде. Лекция укылып беткәч, Тукаев җәнабләрен кул чабып тәбрик кыйлдылар».

*«Йолдыз», 529 нчы сан.*

Г.Ибраһимов, «Татар яшьләре» исемле мәкаләсендә Тукай иҗатына югары бәя биреп, аны «шигырьләре бөтен аңлылар тарафыннан сөенеп укылган Тукаев» дип атый.

*«Йолдыз», 529 нчы сан.*

**21 апрель.** «Ачы тәҗрибә авазы» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 530 нчы сан.*

**25 апрель.** «Йолдыз» газетасы «Яз хәбәре» (русчадан, дип куелган), «Мәҗлес» (әсәр А.С.Пушкинның «Веселый пир» (1819) исемле шигыреннән файдаланып язылган), «Җәй көнендә» шигырьләрен бастырып чыгара. Соңгысы рус шагыйре В.И.Водовозовның «Летом» исемле шигыреннән файдаланып язылган.

*«Йолдыз», 531 нче сан.*

---

Лагыль — кыйммәтле ташлардан ясалган.

**29 апрель.** «Халык моңнары» исемендә халык җырларын эченә алган китабы (Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Милләт» матбагасы) «Җыючысы Шүрәле» дигән имза белән басылып чыга.

Бу җыентыкка кыска һәм озын көйләргә җырланган халык җырлары, «Сак-Сок» бәетләре кертелгән.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

**1 май.** «Ялт-йолт» журналының дүртенче саны басылып чыга. Биредә: «Киләчәктә «Яшен» журналының мөштәриләренә «Ялт-йолт» җибәреләчәк»,— дигән игълан урнаштырылган. Бу факт. Әлеге ике журнал бер-берсенең традицияләрен дәвам иттерүче икәнлеген тагын бер кат раслый.

Бу санда шагыйрьнең:

Биек тауның башында күренәдер бер авыл;
Хатын өстенә хатын асрау менә шулай була ул,—

дигән ике юллы шигыре рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган. Аска «Авыл җырлары»ннан» дип куелган. Рәсемдә татарча җыештырылган бүлмә. Сандык өстенә мендәр өелгән. Стенада Мәккә-Мәдинә сурәте. Ике хатын өстәл кырыенда бер-берсенә артларын куеп утырганнар; әле генә кычкырышканлыклары аңлашыла. Кәҗә сакаллы, кара түбәтәйле ир-ат пары чыгып торган самовар күтәреп килә.

Шунда ук «Тутый» (З.Бәшири) имзасы белән «Мулла» дигән шигырь басылган. («Г.Тукаевның «Ишан» шигыренә гыйлавә» дип куелган.)

*«Ялт-йолт», 4 нче сан.*

**2 май.** «Кайчакта» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 534 нче сан.*

**12 май.** «Гомер юлына керүчеләргә» шигырен яза.

*«Йолдыз», 540 нчы сан.*

**15 май.** «Шура» журналында З.Вәлиди «Җырларымыз хакында» дигән мәкалә бастырып чыгара. Ул Тукайның «Халык әдәбияты» дигән китабы һәм анда әйтелгән фикерләр белән полемика рәвешендә язылган. З.Вәлиди Тукайның «безнең җырлар җитлексез», «безнең җырларымыздагы мисраглар арасында мөнәсәбәт тә юк» кебек фикерләре белән килешмәвен әйтә.

*«Шура», 10 нчы сан.*

---

Мөштәри — подписчик, яздырып алдыручы.
Гыйлавә — өстәмә.

«Ялт-йолт» журналында «Имам хатиб» имзасы белән «Яңа хотбә» исемле памфлеты басылып чыга. Мәчетләрдә укыла торган хотбәләргә пародия рәвешендә язылган. Бу әсәр, кайбер үзгәрешләр кертелеп, «Килешү хотбәсе» исеме белән «Яшен ташлары» (1911) җыентыгына урнаштырылган. Аннан соң чыккан басмаларда да шул исем белән кертелә.

*«Ялт-йолт», 5 нче сан.*

Журналның шул ук санында «Гөмберт» имзасы белән «Кешехайваннар» әсәре урнаштырылган. Шул заманда татар дөньясындагы һәм әдәбият-сәнгать өлкәсендәге тискәре күренешләрдән көлеп, вакытлы матбугат органнарын («Шура», «Дин вә мәгыйшәт» кебек журналларны), үз чорының мәгълүм шәхесләрен тәнкыйть итеп язылган әсәр. Аерым алганда Тукай шагыйрь һәм журналист Сәгыйть Рәмиевне (1880—1926), Бозаулык шәһәре мулласы, шул ук вакытта публицист һәм язучы буларак та танылган Галиәсгар Гафуров-Чыгтайны телгә ала, аларның эшчәнлекләрендә чагылган идея ягыннан тотрыксызлык күренешләрен күрсәтә, тәнкыйть итә.

«Үзе шагыйрь итеп тә, публицист итеп тә олылап, хөрмәт итеп, аралашып йөргән Сәгыйть Рәмиевнең «Бәянелхак» редакциясенә эшкә керүе Рәмиев белән Тукай арасында билгеле бер киеренкелек тудырды. Тукай С.Рәмиевнең демократик позициядән чигенүен мәгълүм фельетонында бик кискен бәяләде»,— дип язды бу хакта әдәбият галиме Ш.Садретдинов.

*«Ялт-йолт», 5 нче сан;*
*Садретдинов Ш. Сәгыйть Рәмиев иҗаты, 1973, 38 б.*

**16 май.** «Гомер юлына керүчеләргә» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 540 нчы сан.*

**20 май.** «Вакыт» газетасы игълан урнаштыра.

«Яңа китап... «Халык моңнары» «Шүрәле» әфәнденең камил муаффәкыять илә интихаб иткән, һәркемнең милли хисләрен кузгатырдай җырлар мәҗмугасыдыр».

*«Вакыт», 619 нчы сан.*

**22 май.** «Өмидсезлек» шигыре басылып чыга.

*«Вакыт», 620 нче сан.*

---

Камил муаффәкыять — биредә: нечкә, зәвык.
Интихаб иткән — сайлап алынган.

**Май.** Г.Тукай Ташаяк ярминкәсендә була, карусельдә әйләнә. «Туйганчы бала чакта эләкмәгәннең «үчен алдым»,— дип сөйли азактан дусларына.

*Байбурин Я. Г.Тукаев хатирәсе. «Хатирәләр», 1976, 98 б.*

Петропавловскида җәдид мәктәбе укытучысы Кәшфи Мостафин хосусый рәвештә русча укыр өчен Казанга килә. Тукай белән танышып, аннан киңәш сорый. «Репетитор профессионал» студент Моисей Адольфович Берлин турында сораштыра. Тукай аңа: «Ул студент бөтен фәннән берүзе өлгерү аттестаты алуга әзерли ала, өч-дүрт тел белә. Ул гыйлем тәпәне инде. Мин сезгә аннан укырга киңәш итәм»,— ди.

Кәшфи Мостафин белән Панаев бакчасына спектакль карарга баралар.

«Бу вакытта Тукай «Болгар» кунакханәсендә яши иде»,— ди истәлек авторы.

*Мостафин К. Тукай киңәше белән. «Тукай Башкортстанда», 1966, 41 б.*

**Җәй.** Замандашларының истәлекләренә караганда, каләмдәш дуслар — Г.Тукай, Ф.Әмирхан, В.Бәхтияров, Я.Байбурин Казанда Ботаник бакча (хәзер Зооботаника бакчасы) каршында квартира алып, дача сыман итеп яшиләр. Тукай һәм Әмирхан аерым-аерым бүлмәләрдә, Вафа белән Якуб бергә торалар. Алар янына еш кына дуслары, интеллигентлар килеп йөриләр.

*Шакиров З. Мин география укытканда. «Тукай Башкортстанда», 1966, 34 б.; Байбурин Я. Габдулла Тукаев хатирәсе. «Истәлекләр», 142 б.*

**1 июнь.** «Акыллы башлар» исемле фельетоны «Гөмберт» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 6 нчы сан.*

**6 июнь.** «Хале хазир» исемле шигырен яза.

*«Йолдыз», 550 нче сан.*

**8 июнь.** «Йолдыз» газетасында Г.Ибраһимовның «Г-җан» имзасы белән «Әдәбият мәсьәләләре» дигән мәкаләсенең «Халык мосаннәфаты» дип исемләнгән бүлеге басылган. Автор татар халык иҗаты, фольклоры турындагы фикерләрен әйтеп,

---

Халык мосаннәфаты — халык иҗаты әсәрләре.

руслардагы халык иҗатының җыеп өйрәнелүен күрсәтә, шуны өйрәнүче авторларны саный. Татар халкының авыз иҗаты шулай ук гаять бай, ләкин өйрәнелмәгәнлеген, бу хәзинәне җыю, өйрәнү тиешлеген әйтә.

Г.Ибраһимов, әдәбият һәм халык авыз иҗаты арасындагы мөнәсәбәтләрне күздән кичереп, Тукай иҗатының татар әдәбияты барышындагы кабатланмас урынын билгеләп уза, татар халкының үз фольклорына мөнәсәбәттә күзен ачуда, аңарга үз авыз иҗатының нинди бай һәм саекмас рухи мирас булуын күрсәтүдә шагыйрьнең ролен ассызыклый. Бу мәсьәләдә Тукайны татар шагыйрьләренең бөтенесенә үрнәк итеп куя ул: «Бу турында һәркемнән артык мәшһүр шагыйребез Тукаевка бурычлыбыз. Ул үзенең матур вә шагыйранә җөмләләре илә шул гавам әкиятләрен тасвир итеп, һәркем тарафыннан сөелеп укырлык бер хәлгә куйды.

Мисал: аның күптән чыккан «Шүрәле»се... «Су анасы» моның иң гүзәл нәмүнәләреннәндер. Тукаевның бу шигырьләре шулкадәр ачык вә табигый чыккан ки, чи гавамның авызыннан да шулкадәр генә чыгар иде».

*«Йолдыз», 549 нчы сан.*

**10 июнь.** «Хале хазир» шигыре дөнья күрә.

*«Йолдыз», 550 нче сан.*

**15 июнь.** «Ялт-йолт» журналында «Кәчимский» имзасы белән Касыйм татарларыннан көлеп язылган исемсез сатирик шигырь басыла. (Тукаевның «Безне урынсыз яманлыйлар» дигән әсәренә икътибасән язылды, дип куелган.)

*«Ялт-йолт», 7 нче сан.*

**20 июнь.** «Халык әдәбияты» китабы (Казан, «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы, 43 б., 2000 данә) басылып чыга.

Татар халык җырларының тарихын һәм килеп чыгышын тикшереп, озын һәм кыска көйләр турында («Тәфкилев көе», «Ашказар», «Сак-Сок көе», «Касимский Ибырай», «Җизнәкәй», «Башмак көе») язып үтә дә: «Халык җырлары — безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу — кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.

Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да

---

Икътибасән — үрнәк итеп алып, файдаланып.

халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан, муллалар әйтмешли, мәсүн вә мәхфуз уларак калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле...

Белергә кирәк ки, халык җырлары — халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер...» дигән мәгълүм юлларны яза.

Бу китап хакында автор үзе болай ди: «Халык әдәбияты» намындагы бу рисаләи Казанда «Шәрык» клубында ушбу 15 апрельдә укыдыгым (итлакъ җаиз исә) лекциясенең мәзмуненнән гыйбарәттер».

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.*

Китапка наширләр тарафыннан язылган кереш сүздә мондый юллар бар: «Габдулла әфәнде бу әсәрендә халык әдәбияты, халык җырларының нидән гыйбарәт идекене вә аның сонгый әдәбият вә сонгый җырлардан ничек аерылдыгы хакында ачык вә төпле мәгълүмат бирә.

Татар халәте рухиясенең аңларга теләүчегә бер данәсене алып уку һәм бөти кебек үзе илә саклау лаземдер».

*Тукай Г. Халык әдәбияты. Казан, «Сабах» көтепханәсе. «Милләт» матбагасы, 1910, 3—5 б.*

**28 июнь.** «Үкенеч» исемле шигырен яза.

*«Йолдыз», 558 нче сан.*

**1 июль.** «Үкенеч» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 558 нче сан.*

«Нечкә хиссият» әсәре «Шүрәле дип белгәйсез» дигән имза белән, «Фәлсәфи сүзләр» әсәренең беренче кисәге «Фәйләсүфләр» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 8 нче сан.*

**2 июль.** «Хасият» шигырен яза.

*«Йолдыз», 560 нчы сан.*

**2 июль.** Вакыйф Җәлалның «Истикъбаль өмидләре» (Тукаевның «Өмидсезлек» әсәренә каршы) шигыре басыла. Опти-

---

Мәсүн вә мәхфуз уларак — сакланып.
Намендәге — исемендәге.
Рисалә — әсәр, кечкенә китап.
Итлакъ җаиз исә — әйтергә яраса.
Мәзмун — эчтәлек.
Сонгый — ясалма (биредә: профессиональ).

мистик рухта, төшенкелеккә бирелмәскә, киләчәккә өмет белән карарга чакырып язылган бу шигырьдә автор Тукайны ялкынлы шагыйрь дип атый.

*«Идел», 269 нчы сан.*

**6 июль.** «Хасият» шигыре басылып чыга.

*«Йолдыз», 560 нчы сан.*

**9 июль.** «Әдәбият» исемле шигырьләр китабы («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 10 нчы дәфтәр. 2 нче басма. Казан, «Мәгариф» көтепханәсе) дөнья күрә.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

**15 июль.** «Ялт-йолт» журналында халык язмышына карата ваемсызлык күрсәткән буржуаз интеллигенциясенең эшсезлегенә нәфрәтләнеп, каты тәнкыйтьләп язылган «Яшьләр» шигыре һәм «Фәйләсуф» имзасы белән «Фәлсәфи сүзләр»нең икенче кисәге басылып чыга.

Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут, кабныр-кабынмас.
Кичә якты вә милли бер көнелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас.
Вә кем бар, йөз чөерми милләтеннән,
Көмеш, алтын санәмнәргә табынмас?

*«Ялт-йолт», 9 нчы сан;*
*Лаисов Н. Габдулла Тукай, 1985, 70 б.*

**27 июль.** «Идел»дә Тукайга багышлап язылган шигырь басыла. Авторы күрсәтелмәгән.

**Габдулла Тукаевка.**

Бөтен әшгареңез барысы кыйммәтле,
Халыкка файдалы һәм иң кирәкле;
Килешле, шундый шәп, укырга дәртле,
Татарча, чын, матур, тәмле, бизәкле.

* * *

Яшә, Тукай! Сезне милләт онытмас!
Күмелсә дә җисем, нам бер дә бетмәс!

*«Идел», 275 нче сан.*

---

Санәм — пот, Алла.

**29 июль.** Фатих Әмирхан, Һади Максудиның «Төрки нәхүе» исемле китабына бәя биргәндә, аерым кагыйдәләргә мисалларның урынлы түгеллеген әйтеп: «Габдулла Тукаев, Закир Һади шикелле татарчаның матуры берлән яза торган кешеләрнең әсәрләреннән китапта һәр кагыйдәгә әллә никадәр мисаллар табарга мөмкин булачагы шөбһәсездер»,— дип яза.

*«Йолдыз», 569 нчы сан;*
*Әмирхан Ф. «Әсәрләр», 4 т., 1986, 109 б.*

**1 август.** «Ялт-йолт»та «Шүрәле» имзасы белән «Танса» шигыре, «Адәмнең биш әгъзасы ни эшли?» мәкаләсе басыла.

*«Ялт-йолт», 10 нчы сан.*

**6 август.** «Иссез чәчәк» шигырен иҗат итә. «Русчадан» дип куелган. Әсәр рус шагыйре И.А.Дмитриевның (1780—1837) «Полевой цветок» исемле парчасыннан файдаланып язылган.

*«Йолдыз», 578 нче сан.*

**13 август.** «Яңа әсәрләр» дигән рубрика астында «Идел»дә Тукай әсәрләренә реклама рәвешендә игълан басыла: «Халык моңнары». Мәшһүр җырчы «Шүрәле» әсәре. «Халык әдәбияты» китабы — бәетләр, җырлар хакында, бөтен булмаса да, күңелле мәгълүмат биргән бер китап. Беренче шагыйрьләребездән Г.Тукаевның әсәре. Ул ,«Шәрык» клубында Тукаев тарафыннан лекция итеп укылганнан соң, «Сабах» көтепханәсе тарафыннан табгы ителеп нәшер ителгән».

*«Идел», 280 нче сан.*

**15 август.** «Сибгатуллин» шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Бозау кадәрле зур фәлсәфә» исемле фельетоны басылып чыга. Тукай бу әсәрен үз чорында Россиянең төрле өлкәләрендә чыккан газета-журнал, китап бастыру оешмалары, типографияләр, әдәби әсәрләр исемнәренең сүзлек мәгънәләрен файдаланып язган.

*«Ялт-йолт», 11 нче сан.*

«Күгәрчен» шигыре басылып чыга. «Русчадан» дип куелган. Әсәр А.С.Пушкинның (1770—1830) «Голубка» дигән шигыреннән файдаланып язылган.

*«Йолдыз», 575 нче сан.*

**22 август.** «Иссез чәчәк», «Баскыч» шигырьләре дөнья күрә.

*«Йолдыз», 578 нче сан.*

**23 август.** «Бер мән» шигырен яза.

*«Вакыт», 671 нче сан.*

**26 август.** «Йолдыз»ның 578 нче санында басылган шигыренә төзәтмә бирә:

«Йолдыз»да басылган «Баскыч» исемле шигырьнең дүртенче юлы басылмый калган, ул болай:

Югары басмалар тиңләшми түбәнге басмалар белән.

Г.Т.».

*«Йолдыз», 579 нчы сан.*

**1 сентябрь.** «Толстой хакында мәшһүр татарларның фикерләре» исемле мәкаләсе «Имзасыз да Яраретдинов» псевдонимы белән басылып чыга. Бу имза беренче мәртәбә күренә.

*«Ялт-йолт», 12 нче сан.*
*Рәмиев З.XX йөз башы татар әдәбияты..., 2002, 37 б.*

Л.Н.Толстойның авыруы һәм үлеме татар дөньясында төрле катлау кешеләр арасында төрлечә карашлар барлыкка китерә. Толстой иҗаты белән кызыксынган, аны өйрәнгән һәм аңардан үзен борчыган мәсьәләләргә җавап эзләгән һәм үзе дә Толстойга багышлап шигырьләр һәм мәкаләләр язган шагыйрь С.Рәмиевнең фикерләре бу парчада тәнкыйть күзлегеаша уздырыла. Рәмиевнең тар карашы аңарда протест уята. Рус либераль буржуаз матбугаты материалларына ияреп, Л.Толстой хакында сенсацион характердагы мәкаләләр язучы, «Йолдыз» газетасы редакторы Һади Максуди, «Бәянелхак» газетасы редакторы Мөхәммәтҗан Сәйдәшев һәм Печән базары сәүдәгәре «Чәйче Шәмси»нең бу вакыйгага мөнәсәбәтләре гаять оста рәвештә көленгән.

**15 сентябрь.** «Мөбарәк тәсбих өзелде» исемле нәсере басылып чыга. (1910 елның көзендә (7 ноябрь) Л.Н.Толстойның вафаты уңае белән язылган нәсер.)

Л.Н.Толстойның үлемен Тукай бик авыр кичергән, аны олы кайгы итеп, тетрәнеп кабул иткән. Бу зур югалту турында хисләрен белдерү өчен нәсер жанрына мөрәҗәгать итүне үзенең вөҗдан эше дип караган. Әсәргә китергән эпиграфта шагыйрь:

Ушбуны яздырды нәсрән вөҗданымның көчләве,
Мәсьәлә бик зур — сыйдырмый тар шигырьләр үлчәве, —

дигән. Толстой иҗатын Тукай бәяләп бетергесез әхлакый кыйммәт дип саный, аны «бөтен җанварларның җаны һәм бөтен инсаннарның вөҗданы» дип олылый. Нәсеренең башыннан алып азагына кадәр Толстой һәм кояш образларын янәшә куеп тасвирлый. Аның үлеме турында йөрәк өзгеч хәбәр килгәч, бөтен дөньяны караңгылык һәм салкынлык чолгап ала: «Кояш йөзен

чытты. Елады. Инде көлми. Агар сулар дәфгатән бозландылар...»

Тукай Л.Н.Толстойның рус әдәбияты тарихындагы урынын бик тә югары куя, аны рус әдәби «дисбесенең» Мәрьям анасы, Имамы, ягъни рухи җитәкчесе дип атый.

*«Ялт-йолт», 13* нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 141—142 б.;*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 32—33 б.*

«Милләткә файда урынына зарар» мәкаләсе «Гөмберт» имзасы белән басыла. Ул шагыйрь Мәҗит Гафуриның «Милли шигырьләр», «Кызларга махсус милли шигырьләрем» исемле шигырь җыентыклары басылып чыгу уңае белән язылган.

*«Ялт-йолт», 13 нче сан.*

**22 сентябрь.** «Актык тамчы яшь», «Бер мән» исемле шигырьләре басылып чыга.

*«Вакыт», 671 нче сан.*

**25 сентябрьгә кадәр.** Кушлавычтагы Бәдри абзыйның Уральскида яшәүче улы (вак сәүдәгәр) Камалетдин Хисаметдиновның (1882—?) бер-бер артлы өч хаты килә. Аның бер үтенече — Тукайдан «Дөруссеш-шифаһия»** исемле китап җибәрүне сораудан гыйбарәт.

*Тукайның Казаннан Уральскига язган хаты.*
*Мирасханә. 9-ф., 2-тасв., 15 б.*

Казаннан Уральскига Камалетдин Хисаметдиновка ачык хат яза. Адресаты: «Кара-Тюбинский базар Уральской области, Камалетдину г-ну Хисаметдинову». Тукай, аны якын итеп, «борадәр Камалетдин әфәнде» дип эндәшә һәм үтенечен «Юл» көтепханәсенә җиткергәнлеген хәбәр итә.

*Мирасханә. 9-ф., 2-тасв., 15 б.*

---

* Л.Н.Толстой 1910 елның 7/20 ноябрендә вафат була. Г.Тукайның мәкаләсе исә журналның 15 сентябрь датасы белән чыккан санында басылган. Ничек аңларга? Эш шунда ки, ул чагында журналлар, аеруча демократик юнәлештәге басмалар, материаль кысынкылыклар сәбәпле генә түгел, цензура киртәләре аркасында да бик соңлап чыгалар.

Бу очракта «Ялт-йолт»ның 1 сентябрь саны ике айдан артык вакытка соңлаган, типографиядә басылуы Толстой үлгән көннәргә туры килгән. Ялтйолтчылар, оперативлык күрсәтеп, Тукай нәсерен тиз генә шушы санга урнаштырганнар (кара: Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 361 б.).

** «Дөруссеш-шифаһия» — «Тел дәресләре» — гарәп телендә язылган берничә томлы китап.

**1 октябрь.** «Граммофонда татар җырлары», «Ит базарында тәрәкъкый» шигырьләре «Шүрәле» имзасы белән, «Фәлсәфә» исемле мәкаләсе «Олуг фәйләсүф» имзасы белән басылган һәм «...Сәгатьләр келт-келт итәдер, төн уртасы җитәдер...» дип башланган шигыре урнаштырылган. Соңгы икеюллык «Гаилә сәгате» дигән рәсем асты итеп, имзасыз басылган. Рәсем-карикатурада бер калфаклы хатын ялгызы гына чәй эчә, читтәрәк самовары кайнап утыра. Стенада сәгать берне күрсәтә. Урындыкта бала, ире өйдә юк.

...Сәгатьләр келт-келт итәдер, төн уртасы җитәдер.
Йокласа да курка мискин,— исрек ирен көтәдер.

*«Ялт-йолт», 14 нче сан.*

«Шура» журналында Нәҗип Думавиның «Безнең мәктәпләр» исемле мәкаләсе басыла. Автор мәктәпләребездә китапханәләр һәм балалар өчен махсус язылган басмаларның юклыгын әйтә. Бу эшнең башлангычы итеп «Тукаевның җен-пәри хикәясен тасвир иткән шигырьләре «Мәктәп мөкяфәте» исемендә... нәшер итәләр булса кирәк» дип күрсәтә. Тукайның «Шүрәле», «Су анасы» әсәрләрен истә тотып яза дип уйланыла.

*«Шура», 19 нчы сан.*

**5 октябрь.** «Яңа кыйраәт» исемле китабы (үзгәртелгән, өстәлгән 2 нче басма. Казан, «Үрнәк» матбагасы) басылып чыга. Җыентыкка моңарчы төрле җирләрдә дөнья күргән һәм, шул исәптән беренче басмадан да алып, 25 исемдәге әсәр кертелгән: «Елның дүрт фасылы» (Боз һәм кар эрде...), «Беренче мәртәбә мәктәпкә бару», «Әлифба», «Баланың ата-анасын сөюе», «Тыш якка карап кына хөкем итмә», «Үзең белгәнне кешедән сорама», «Гадәләт», «Яхшылыкка яхшылык», «Ике сабан», «Һәркем эштә», «Һәр нәрсәнең үз урыны бар», «Әтәч һәм асрау кызлар», «Кыш» (Кыш декабрь аеннан башлана...), «Көз» (Кояш көннән-көн түбән...), «Җәй» (Июнь аеннан җәй башлана...), «Яз» (Яз март аеннан башлана...), «Елның дүрт фасылы» (Елның тәүлеге дүрт фасылга бүленәдер...), «Җир», «Су», «Һава», «Кояш», «Чыпчыклар һәм Кызылтүш», «Тоз һәм Болыт», «Тургайлар ашыймыз», «Чылбырдагы эт».

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.*

Шулардан: «Елның дүрт фасылы» (Боз һәм кар эрде...) исемле шигырь беренче мәртәбә басыла, «русчадан» дип куелган. Ул рус телендәге дәреслекләрдә басылып йөргән «Четыре времени года» исемле шигырьдән файдаланып язылган.

---

Мөкяфәт — бүләк.

Үзенең бер мәкаләсендә бу җыентыкка кергән әсәрләр турында Тукай болай яза: «...Балада ата-анасына мәхәббәтне көчләндерү. Аннан... туган тел вә әдәбиятымызга мәхәббәт уяту... дөнья вә табигать хакында уйлату һәм аны сөйдерүне күзгә алу... балаларны эш вә иҗтиһадка тәргыйб итү.

Аннан да соң мотлак рәвештә берничә мәсәлләр язып үткәч, балаларга галәме табигатьнең һәртөрле хәл вә эшләрен күрсәтер өчен (балаларга бераз күңелсезрәк булса да), «Кояш», «Җир», «Су», «Һава», «Елның дүрт фасылы» кеби фәнни вә гыйльми мәкаләчекләр язылды»,— дип, китапның максатын әйтә.

*«Яңа кыйраәт», 1910, 3 б.*

Матбугат эшләре буенча Баш идарә Петербургка җибәргән отчетларында («1910 елда империядә мөселман матбугаты») бу дәреслек-хрестоматия турында түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Керештә Тукай китапның планын аңлата һәм аерым әсәрләр ярдәмендә укучыларда мондый хисләр тәрбияләү максатын куя:

1. Алланы ярату;
2. Табигатьне ярату («Туган авыл»);
3. Ата-ананы ярату;
4. Туган телгә һәм әдәбиятка мәхәббәт;
5. Хезмәтне ярату («Эш», «Ике сабан»);
6. Милләткә һәм милли хисләргә мәхәббәт («Шүрәле», «Су анасы»)».

*ПУДТА., 821-ф., 133-тасв., 451-эш, 35 б.*

**15 октябрь.** «Мөфти җүбәләе» исемле фельетоны имзасыз басылып чыга. Биредә 1886 елда Россия һәм Себер мөселманнарының дин башлыгы итеп сайланган мөфти Мөхәммәдъяр Солтановның (1827—1915), мөселманнарның дин эшләрен, көнкүрешләрен рәткә салуда берни дә эшләмәсә дә, 25 ел мөфти булып торуын юбилей ясап билгеләп үтүдән көлә.

*«Ялт-йолт», 15 нче сан.*

**1 ноябрь.** «Шура»да «Яңа кыйраәт» әсәренә аннотация басылып чыга: «Яңа кыйраәт» — (икенче табгы) Габдулла әфәнде Тукаев әсәре улып, балалар укыр өчен күңелле хикәятләр вә гүзәл шигырьләр җыелмыштыр. Ушбу китап Казанда «Мәгариф» тарафыннан нәшер улынмыштыр».

*«Шура», 21 нче сан.*

---

Иҗтиһад — тырышлык, күңел биреп эшләү.
Тәргыйб итү — кызыксындыру.

**5 ноябрь.** Г.Камалның әдәби эшчәнлегенә 10 ел тулу мөнәсәбәте белән үткәрелгән юбилей кичәсендә катнаша.

«Ушбу сәнә 5 ноябрьдә «Новый клуб» залында «Сәйяр» мөселман артистлары тарафыннан Галиәсгар әфәнденең 10 сәнәлек әдәби вә милли каләм хезмәте шәрәфенә аның «Бәхетсез егет» драмасы илә «Бүләк өчен» комедиясе куелды».

*«Октябрьгә кадәрге татар театры», 1988, 96—97 б.*

Тукай, бу пьесаларны карап, үзенең бәяләмәсен дә яза: «Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре чын татар тормышыннан бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән «Бүләк өчен»дәге угылын өйләндерә торган татар хатынының халәте рухиясен белү, аның издиваҗ кеби олугъ бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне Әлхәм укыган кеби яңлыштырмый, гармонично санату фәкать, фәкать Галиәсгар әфәнденең нечкә хиссенә вә тирән күрүенә генә хас бер эш булганга, аннан соң «Сәйяр» артистларының сәхнәдә һәрвакыт, һәр җирдә, һәр шәһәрдә күрсәтәчәк мабиһил-ифтиһарлары шушы Галиәсгар әфәнде әсәрләре булганга, шул сәбәпле алар күп уйналганга, бу әсәрләрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхассыйс булып киткәнгә, табигый, уен яхшы чыкты».

*«Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсы». «Йолдыз», 22 ноябрь, 613 нче сан.*

**9 ноябрь.** Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза*. Аңа, якын итеп, «бөрадәр» дип эндәшә. Язган шигырьләрен анализлап һәм ничегрәк язарга кирәклек турында киңәшләр бирә, тәнкыйть сүзләре дә әйтә. Кайчак ашыга-ашыга шагыйрьлек шөһрәтенә ирешәм дип, уртакул шигырьләр язуын өнәп бетермәвен сиздерә: «...кулыма төшкән шигырьләрегезне укыйм... Сездә милләткә һәм шөһрәткә кызу мәхәббәт бар... Бөрадәр. Мөмкин кадәр шигырьне аз язсагыз да, матур вә хуш иттереп языгыз. Сәнаигы нәфисә аз гына бер хата сәбәпле тупас һөнәрләрдән булып китүе бар... Шигырьләрегездә ...провинциальный... сүзләр... катыштырмасагыз икән...» Тукай үзенең иҗат планнары, шу-

---

* Шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй истәлегендә Тукайның аңа 19 хат язуы әйтелә. Шулардан 9 хатның гына текстлары сакланып калган.

Издиваҗ — өйләнү.

Әлхәм — Коръәннең беренче «Фатыйха» сүрәсе халык телендә шулай йөртелә.

Мабиһил-ифтиһар — мактаныч.

Мөтәхассыйс — оста, белгеч.

Сәнаигы нәфисә — матур сәнгать, әдәбият.

шы моментта эшли торган эшләре белән дә таныштыра. «...Менә шушылай дип бер шигырьчек яза башладым» дип, «Өзелгән өмид» шигыренең баштагы алты юлын хатка теркәп җибәрә:

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьяләр төсе;
Сизелә: үтте яшь вакытлар, җитте гомерем яртысы.
Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урынында — анда тулган айның яктысы.
Нинди дәрт белән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җуләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.

(Шигырь бу вакытта языла гына башлап, тулысынча шушы елның 29 ноябрендә басылган. «Вакыт», №700)

*«СӘ», 1960, 4 нче сан, 63 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 95 б.*

**13 ноябрь.** «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исеме белән матбугатка әзерләгән дәреслек-хрестоматия рәвешендә төзегән китабына кереш сүз «Мөкаддәмә» яза.

*Мәктәптә милли әдәбият дәресләре, 1911, 5—8 б.*

**17 ноябрь.** «Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсе» мәкаләсен яза. Бишенче ноябрьдә булып узган тантаналы кичәдә алган тәэсиратларын кәгазьгә төшерә.

*«Йолдыз», 22 ноябрь, 63 нче сан.*

**20 ноябрь.** «Төш» шигыре басылып чыга.

*«Вакыт», 696 нчы сан.*

**22 ноябрь.** «Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсе» исемле мәкаләсе дөнья күрә.

Юбилей тантанасын сурәтләп, ул: «...Ихтимал, шул халык арасында иң нечкәргән күңеллесе мин булганмын,— ди.— Минем күңелемдә Галиәсгар әфәнде әсәрләрендә моннан әллә ничә еллар элек, ярты сабый вакытымдук, мәхәббәт орлыклары чәчелгән иде. Аның әсәрләрен бу елларда сәхнәдә күрә-күрә вә муаффәкыятьле чыкканнарына тәгаҗҗеб итә-итә, шул мәхәббәт һаман үсә бара, тамыр җәя барадыр.

Мин юбилей кичәсендә Галиәсгар әфәндене алгы сафтан торып, тамагым карылганчы кычкырып тәбрик иткәнем кеби,

---

Әшьяләр — әйберләр.
Һилал — яңа туган ай.
Муаффәкыятьле — уңышлы.
Тәгаҗҗеб итә — гаҗәпләнә.

хәзер дә тәбрик итәм: «Мөбарәк булсын Сезнең 10 еллык хезмәтеңез!»

Һәм дә татар тормышының, Казан мещаннарының иң безгә мәҗһүл почмакларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәтергә каләменең көченнән килгәнлегенә хәйрат итәрәк, аны, Галиәсгар әфәндене, «татар Островские» намы мөкәррәм һәм мөстәхәкъкы белән тәгъзыйм итеп*, сүзне бетерәм»,— дип яза.

*«Йолдыз», 613 нче сан.*

**29 ноябрь.** «Өзелгән өмид» шигыре басыла. Хөр фикер эзәрлекләнгән реакция елларында иҗат ителгән бу шигырь моңсу, хәсрәтле кичерешләр белән сугарылган. 24 яшьлек Тукай инде иҗатының җитлеккән чорына аяк баскан шагыйрь кебек хис итә. Аның өчен әшьяләр төсе дә үзгәргән. Гасырлар дәвамында шагыйрь халкы өчен илһам чыганагы булган мәхәббәт тә, җир гүзәлләренең матурлыгы да анда иҗат дәрте уятмый. Лирик герой образы белән тәңгәл килгән шагыйрь үз җисми яшәешенең һәм моңлы сазының, ягъни шигъриятенең кыска гомерле булачагын пәйгамбәрләрчә алдан сизә.

И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

Ул дөньяга шат яшәр өчен туса да, Раббысы аны җиһанга ят яраткан. Гаделсезлекләрдән интеккән геройның күңеле, читлекне хәтерләткән дөньядан туеп, кош булып күкләргә оча. Самимилеге белән елатырлык күңел икърарында күрәбез: милләте турындагы идеаллары да тормышка ашмаган, елмаюы белән тормыш юлын яктыртучы сөйгән яр да аңа насыйп булмаган, ягъни Тукайның күңеленә сурәте яшерелгән кеше — аның сөйгән кызы Зәйтүнә туташ. Шагыйрьне кечкенәдән ятим калдырып, ире үлүгә егълап күз яше дә кипмичә иртә вафат булган сөекле анасының кабер ташына ачы күз яшьләрен койган мизгелдә генә үзенә рухи юаныч таба.

Аның сөйгән яры да, кадерле әнисе дә юк; милләт тә, җәмгыять тә аңа ихтирамын тиешенчә белдерә алмаган. Шагыйрьнең азатлыкка омтылучы җаны төрмәне хәтерләткән дөньядан күкләргә очып китүне үлемнән хәерлерәк күрә.

Бу шигырь 1914 елда ук русчага да тәрҗемә итеп басыла.

Соңрак А.М.Горький Сергеев-Ценскийга язган бер хатында бу шигырьгә һәм аның авторына мөнәсәбәттә түбәндәге-

---

* Хөрмәтле һәм лаеклы исеме белән олылап.

Мәҗһүл — билгесез, яшерен.

Хәйрат итү — сокланып.

Мөкәррәм — хөрмәт итеп.

Мөстәхәкъкы — гадел рәвештә.

ләрне әйтә: «Сез вәгазьчеләр (проповедники) художникларның бугазыннан тоталар дип зарланасыз. Бу һәрвакыт шулай булды. Бу дөнья художниклар өчен түгел, анда һәрвакыт аларга кысынкы һәм уңайсыз булды. Шуңар күрә аларның роле мактаулырак та һәм батыррак та.

Ачлыктан һәм чахоткадан үлгәндә, Казан татарларыннан бер шагыйрь: «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы!»* дип бик шәп әйткән...»

*«Вакыт», 700 нче сан;*
*«Мәктәп», 1914, 4 нче сан;*
*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 137 б.;*
*Сборник статей о Горьком, 1928, с. 406.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1977, 142 б.;*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 34—36 б.*

Петербургта чыгучы «Нур» газетасы «Бәйрәм бүген» шигырен күчереп баса. «Диван»нан** алып кертелде, диелгән.

*«Нур», 436 нчы сан.*

**1 декабрь.** «Кайда? Кем?» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Анда шәхескә кагылышлы мондый юллар да бар:

Кем, дисез, бу фетнәле эшләр башы?
Кайда бу хаксызга тәфтишләр башы?
Бәдбәхет, мәлгунь кеше кем, дустларым? —
Түнтәр аулы чалмалы карт марҗасы.

Шигырь шул чордагы иҗтимагый вазгыятьне чагылдыра. XX гасыр башында булган җәдит-кадим тартышулары тарихта билгеле. Рәсәй империясе яулап алынган, буйсындырылган халыклар өстеннән хакимлекне дәвам итү өчен барысын да эшләгән. Милләтләрне, һәр милләтнең аерым катлауларын, төркемнәрен бер-берсе белән дошманлаштыру, ызгыштыру ише алымнар милләткә каршы сәясәтне тормышка ашыруда киң кулланылган. Татар зыялылары арасындагы каршылыкны тагын да көчәйтеп, соңгы чиккә җиткерү максаты белән җәдитчеләрне, ягъни диндә, мәгърифәттә яңарышны яклаучыларны һәм бу үзгәрешләргә каршы чыгучыларны, ягъни кадимчеләрне яшерен рәвештә һәрдаим бер-берсенә каршы котырту эше дә алып барыла. Татар тормышындагы прогрессив һәм демократик хәрәкәт яклы булган Тукай бу шигыре белән иске карашлы динче

---

* Г.Тукай. «Өзелгән өмид», 1910.
Русчасында: «Из железной клетки мира
Улетает, улетает юная душа моя».

** Габдулла Тукаев диваны. («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр». 3 нче кыйсем, 1909.)

Тәфтиш — «тикшерү-төпчену» мәгънәсендә.

Ишми ишанны — элекке Малмыж өязе (хәзерге Татарстан Республикасы, Балтач районы) Түнтәр авылы мулласы Ишмөхәммәт хәзрәт Динмөхәммәтовны тәнкыйтьли. Соңгы вакытта табылган мәгълүматлар аның патша жандармериясенә донослар язучы, аның агенты булуы турындагы сүзләрне расламый.

*«Ялт-йолт», 18 нче сан;*
*Нәкыйпов Ф. Җәдит-кадим тартышы бармактан суырылган. « Ватаным Татарстан», 2003, 14 март.*

«Тәләһһеф» шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 18 нче сан.*

**4 декабрь.** Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. Бу — Сүнчәләйнең Тукайга язган хатына җавап булып аңлашыла. Хатта Сүнчәләйгә дусларча кайгыртучанлык күрсәтеп: «Байронның «Шильон мәхбүсе» поэмасын тәрҗемә итәргә көчегезнең микъдарын үлчәмичәрәк тотынганга охшыйсыз» дигән фикерен белдерә һәм тәрҗемә эшенең ни икәнен үз җилкәсендә татыган кеше буларак, бу эшкә мөнәсәбәтен белдереп инде март аенда ук басылып чыккан «Пәйгамбәр» шигырен искә ала: «Менә С.Рәмиев—Пушкин «Пәйгамбәр»ен, мин фәкыйрь дә Лермонтов «Пәйгамбәр»ен тәрҗемә иттек. Безнең икебезнеке дә шактый шома чыктылар»,— дигән. «Минем синең хат эченә язып җибәргән күңелсез шигыремнең ахырлары да «Вакыт»ның бәйрәм номерында басылып чыкты»,— дип, Сүнчәләйгә шушы елның 9 ноябрендә язган хаты эченә өлешчә теркәп җибәргән «Өзелгән өмид» шигырен (29 ноябрь, «Вакыт», 700 нче санда басылган) укып карарга киңәш итә.

Цензура комитеты Тукайның һәр язган шигырен, мәкаләсен күзәтеп бара һәм бу турыда губерна жандарм идарәсенә даими хәбәр итеп тора. Шуңа күрә ул күп әйберләрен бастырып чыгара да алмый. Бу хатта ул шуларны истә тотып, Сүнчәләйгә: «Мөселман» журналы татарча чыга башласа, монда басылмаслык редкий нәрсәләремне шунда җибәрмәкче булам»,— дип, Парижда рус телендә чыга торган «Мусульманин» журналына материаллар җибәрергә ниятен белдерә.

*«СӘ», 1960, 4 нче сан, 65 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 97 б.*

**15 декабрь.** «Кушмый ишан җилкәсендә...» дип башланган дүрт юллык рәсем-карикатура асты итеп басылган. Рәсем өстенә «Әннәсолул хәдидә» кайда тәсниф ителгән?» дигән баш

---

Тәләһһеф — кайгыру, хәсрәтләнү.

куелган. Чалмалы, түбәтәйле искеләр тезелешеп утырган, уртада Гыйлаҗ мулла (өстенә «Әннәсолул хәдидә» язучы» дип куелган...) «Кушмый хәзрәт бер китап җазарга кушкан иде»,— ди. Реакцион мулла Гыйлаҗетдин Мөхетдинов-Сәрдәи язган «Әннәсолул хәдидә ли-иб татыйль ысулы җәдидә»не... («Ысулы җәдидәне юкка чыгара торган тимер кебек нык китап») исемле китап турында сүз бара.

*«Ялт-йолт», 19 нчы сан.*

**18 декабрь.** «Балалар күңеле. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (Әдәбияттан хрестоматия. Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, «Үрнәк» матбагасы) басылып чыга. (Тышлыкта — 1911 дип куелган). 144 б. 5200 данә.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

Китапка сүз башында («Мөкаддәмә»дә) автор болай ди:

«Үземезнең яңа үсеп килмәктә булган милли әдәбият бакчамыздан җыеп, ...ушбу «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабыны тәртип иттем. Сабый балаларымызның кулына... шушы китап кеби чәчәк бәйләмнәре бирелергә тиештер.

Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф булып, анчак гүзәл вә мөкаддәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр.

Моның киресенчә: кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы ачык күк кеби саф күңелләре томаланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез караучы буладыр.

Рус тәрбия голямасының соң заманда мәйданга китердекләре «Живое слово» нам кыйраәт китабы минем «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең тарзы тәртибендә рәһбәр итеп тотылды.

152 сәхифәлек бу китап «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең беренче кыйсьмедер... киләчәк кыйсемнәр тәртип ителсә, аларга күбрәк хезмәт кертеләчәк вә шаять мәшһүр кешеләремезнең тәрҗемәи хальләре вә рәсемнәре дә дәрҗ улыначактыр»,— дип, бу өлкәдә киләчәккә планнарын күрсәтә.

Китапның титул битендә Тукайның:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле,
Дөньяда күп нәрсә белдем, син туган тел аркылы, —

дигән юллары китерелгән.

---

Тәсниф ителгән — язылган.
Назик вә ләтыйф — нечкә һәм гүзәл.
Анчак — тик, фәкать.
Тарзы — үрнәге, системасы.
Рәһбәр — юл күрсәтүче, башлаучы.

Бу җыентыкка: «Мөкаддәмә» («Үземезнең яңа үсеп килмәктә...»), «Гомер юлына керүчеләргә», «Исемдә калганнар», «Туган җиремә», «Мәрхүм Мөхәммәтзаһир әфәндегә», «Тәәссер», «Пәйгамбәр», «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты», «Үз-үземә», «Хикмәтле әтәч» («Алтын әтәч»тән), «Кемдән ярдәм эзләргә» исемле әсәрләре кертелгән, китапта тагын Ф.Әмирхан, Ф.Кәрими, К.Насыйри, В.Радлов, Ш.Шәрәф, Р.Фәхретдинов, Дәрдмәнд, Г.Исхакый, З.Һади, М.Гафури, Г.Баруди, Н.Думави, С.Рәмиев һ.б. әсәрләре дә урын алган.

Казан губерна канцеляриясенең Эчке эшләр министрлыгына язган отчетында бу хрестоматия турында болай диелгән: «Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле китабы белән (махсус дәреслек-хрестоматия) укучыларны «төрки» белән, матур әдәбият теле сыйфатында таныштыруга нигез салынды.

Бу хрестоматия хәзерге татар язучыларының иң әйбәт әсәрләреннән өзекләрне эченә алган».

Ләкин шунда ук китапны тар, милли чикләнгәнлектә гаепли.

Матбугат эшләре буенча Баш идарәдә дә бу хрестоматия турында: «Мәктәпләрдә уку китабы буларак, Ватанны ярату, Россиягә мәхәббәт тәрбияләү бурычы куелмаган һәм бу турыда бер урында да искә алынмый»,— дип, китапта әйтергә теләгән фикерне берьяклы, тенденциоз аңлап, Петербургка хәбәр ителә.

*ПҮДТА. 821-ф., 133-тасв., 451-эш, 8-35 б.;*
*821-ф., 133-тасв., 472-эш, 125 б.*

**28 декабрь.** «Балалар күңеле» матбугатка чыгу белән үк әдәби тәнкыйтьнең игътибарын җәлеп итә. Бу китап турында Г.Ибраһимовның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле рецензиясе китап таралып ун көн үтү белән үк язылганлыгы мәгълүм.

*«Йолдыз», 1911, 628 нче сан.*

«...га» (Бул кеше... дип башланган) шигырен яза.

Бул кеше: байбәтчәләрнең калдыгы хәмерен көтеп,
Алты еллык образованиеңне йөрмә селкетеп!

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 37 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 363 б.*

**Ноябрь — декабрь.** Дуслары һәм фикердәшләре Г.Газиз һәм Г.Коләхметов белән өчәүләп фотога төшәләр.

*Габдулла Тукай. «Альбом», 1978, 86 б.;*
*«Мирасханә», 9-ф., 3-тасв., 57-эш.*

## 1911 ел

**1911—1912 ел башы.** Хөсәен Ямашев студентларның әдәби-политик түгәрәге җитәкчеләренең берсе була. Аның белән бергә түгәрәктә укытучы Г.Коләхметов, шагыйрь Г.Тукай, наширләр һәм редакторлар, язучылардан Г.Хәсәнов, Ф.Әмирхан, Г.Камал, М.Дулат-Алиев, Г.Сәйфетдинов һәм башкалар эшлиләр. Жандармерия аларны берөзлексез яшерен күзәтү астында тота.

*Нафигов Р. Тайны..., 1981, с.131.*

**1911 ел эчендә.** «Золым» исемле шигырен яза (үзе исән чакта басылмый).

*«Тукай шигырьләре», 1926, 31 б.*

«Кечкенә музыкант» шигырен яза (үзе исән чакта басылмый).

*Өч томлы «Әсәрләр», 2 т., 1929, 11 б.*

**1 гыйнвар.** «Ялт-йолт» журналының чираттагы 20 нче санында «Борын» шигыре «Шүрәле» имзасы белән, «Кушмый ишәк җырлый» шигыре «Түнтәреф» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 20 нче сан.*

«Бу шигырь элекке Малмыж өязе Түнтәр авылының (хәзерге Татарстан АССР, Балтач районы) иске фикерле, кадимче мулласы Ишми ишан — Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов турында. Тукай аның хәл-теләкләрен үзеннән сөйләтә. Шуның өчен дә имзаны аның исеменнән «Түнтәреф» дип куя».

*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 364 б.*

Шул ук санда ***(«Төркия янгын эчендә: монда ут һәм анда ут...») шигыре рәсем асты рәвешендә имзасыз* басылган. Рәсемдә фәсле, мыеклы бер төрек басып тора, аның тирәягы ут, төтен, ялкын белән чолгап алынган.

«Әстерхан мөзакәрәләре» исемле фельетоны «Телсез телеграф хәбәрләре» рәвешендә басылып чыга.

Әстерханда чыккан «Идел» газетасы секретаре шагыйрь С.Рәмиевне тәнкыйтьләп, аннан көлеп язылган мәкалә.

*«Ялт-йолт», 20 нче сан.*
*«КУ», 1966, 4 нче сан, 124 б.*

---

* Бу шигырьнең Тукайныкы икәнлеге әдип Н.Исәнбәт тарафыннан да әйтелгән.

Сараш Усадта мөгаллим булып эшләүче шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. Үзенең шигырь үлчәмнәре турында фикерләрен язып: «Әле без татарларда теория словесности вә шигырьләр өчен хорей, дактиль-фәләннәр ясалмаган чакта, вәзен вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк. Фәкать мәгънә кирәк, гүзәл ифадә кирәк»,— ди. Тормышы турында: «Казанның «Болгар» атлы номерында торам. 33 нче номер. Көндез Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов вә бәгъзан Фатих Әмирхан вә башка интеллигентлар белән катышам. Кич белән күрше мәйханәгә кереп, тиречеләр, итчеләр, извозчиклар, жуликлар белән катышам»,— дип яза.

*«СӘ», 1960, 4 нче сан.*

**4 гыйнвар.** «Балалар күңеле» (Мәктәптә милли әдәбият дәресләре) исемле хрестоматиясенә карата Г.Ибраһимов шундый ук исемдә тәнкыйть мәкаләсе бастырып чыгара.

«Милли әдәбиятыбызның мәктәп сыйныфында тәдрис кыйлына башлаган һәр аңлы бәндәмез көтә, сагына иде... Бу бабта Габдулла әфәнде Тукаев тарафыннан беренче адым ясалды... Әсәрнең исеме кадерле вә җәлбе дикъкать. Мөкаддәмә дә бик вә бик өмидле»,— ди дә, әсәрнең эче белән танышу күңелсез тәэсир калдыра, дип, тәнкыйть фикерләрен яза: «...әдәбияте нәфисәбезнең художественный парчаларын җыю түгел, бәлки, вәгазь вә фәлсәфә чүпләгән икән дияргә урыннары күптер»,— ди. Тәрҗемә әсәрләрнең күп булуын ошатмый. Чөнки бу китапка Тукай үзенең язганнары белән генә чикләнмичә, шул заманның талантлы шагыйрь һәм прозаикларыннан уңышлы һәм мәктәп балалары өчен лаеклы дип тапканнарын сайлап алып кертә. «Беренчедән, алынган парчалар, милли оригинальный һәм әдәбияты нәфисәдән булырга тиеш. Икенчедән, балага аңлаешлы, рухына яраклы, бигрәк тә мөһиме — анда гүзәл хисләр кузгатырлык булырга тиеш»,— ди.

Хрестоматиягә Тукай керткән кайбер әсәрләр турында:

«Бала рухына карап эшләнгән нәрсә түгел, укыр өчен ләззәтле дип тә булмый»,— ди Г.Ибраһимов. Ләкин мәкаләсен:

---

Теория словесности — әдәбият теориясе.
Вәзен — ритм, үлчәм (шигырьдә).
Ифадә — аңлата белү.
Бәгъзан — кайвакыт.
Интеллигент — зыялы.
Тәдрис кыйлына — дәрес бирелә.
Җәлбе дикъкать — дикъкатькә лаек.
Әдәбияты нәфисә — матур әдәбият.
Художественный — сәнгатьле.
Парчалар — әсәрләр.
Оригинальный — үзенчәлекле.

«Буноксаннар бу әсәрнең кыйммәтен... җуймый... Бу... адымы өчен Габдулла әфәндегә... рәхмәт... әйтергә мәҗбүрмез»,— дип тәмамлый.

*«Йолдыз», 628 нче сан.*

«Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нә рецензия басылган көнне Галимҗан Ибраһимов үзе «иттифакый туры килеп» Тукай номерына барган. Бу вакыт анда Гыйльметдин Шәрәф, Галиәсгар Камал, Ибраһим Кули һәм тагын берничә кеше була. Сүз рецензиягә күчә. Бәхәсләшеп алалар. Тукай болай ди: «Сез бик инсафлы язгансыз... Сезнең бу фельетоныгыз — минем хакта первый отрицательный мәкалә».

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 278 б.*

**15 гыйнвар.** «...га» (Шома тормыш...) шигыре басылып чыга. «Пушкиннән мокътәбәс» дип куелган. Әсәр А.С.Пушкинның «Когда твои младые лета» исемле шигыре тәэсирендә язылган.

*«Шура», 2 нче сан.*

**18 гыйнвар.** «Йолдыз» газетасы игълан бастыра: «Сәүдә хезмәткәрләре җәмгыяте тарафыннан 21 гыйнварда русча вә татарча әдәбият һәм музыка кичәсе ясалачак».

*«Йолдыз», 634 нче сан.*

**21 гыйнвар.** Большевиклар В.А.Александров, В.В.Адоратский һәм В.И.Ленин оештырган Лонжюмо (Франция) мәктәбе укучысы А.Н.Догадовлар белән берлектә Тукай Казан партия оешмасының «Звезда» һәм «Правда» газеталарын алдыру фондына акча җыюда катнаша. Шушы көнне үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә Тукай үзенең шигырьләрен укый. Кичәдән җыелган акчаның бер өлеше А.И.Догадовка В.И.Ленин җитәкчелегендә үткәрелгән VI Бөтенроссия Прага конференциясенә бару өчен бирелә. Бу турыда А.И.Догадовның распискасы сакланган.

*«Йолдыз», 634 нче сан;*
*ТРМА. 199-ф., 1-тасв., 2322-эш, ;*
*Нафигов Р. К формированию политических взглядов Тукая, 1986, с.57.*

---

Н о к с а н — җитешсезлек.
И т т и ф а к ы й — очраклы.
П е р в ы й  о т р и ц а т е л ь н ы й  м ә к а л ә — беренче тәнкыйть мәкаләсе.
М о к ъ т ә б ә с — файдаланып язылган.

**22 гыйнвар.** Күптән төзелгән җырлар дәфтәренең кульязмасын бастырып чыгару максаты белән Шәрәфләр нәшриятына тапшыра. Г.Ибраһимов исемендәге институт мирасханәсендә Тукайның үз кулы белән Уральскида ук төзелгән җырлар дәфтәре саклана. Дәфтәрнең тышына Тукай русча «Тетрадь для списывания ученика 1-го класса А.М.Тукаева» дип язган. Җыентык 27 битлек тексттан гыйбарәт. Дәфтәрнең титул битенә «Контора 1-го т-ва Бр.Шараф и К°. Казань» дигән язулы түгәрәк мөһер сугылган. Уртасында «22 января 1911 г.» дигән дата бар.

Тукайның беренче шигырь җыентыкларының да шушы ширкәт тарафыннан чыгарылуын искә алып, Тукай җырлар дәфтәрен дә бастырып чыгарырга уйлаган, ләкин ни өчендер кире уйлап, җыентыкны чыгаруны туктаткан, дип уйларга мөмкин.

*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 21-эш.*

Усад авылында мөгаллим булып эшләүче Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. Тукай аны үз итеп фикерләре белән уртаклаша, теге яки бу мәсьәләгә мөнәсәбәтен белдерә: «Минем мәктәп китапларына керешкәнемне «жәл» дисең. Алай түгел, мин мәктәпләребезнең хәл теле илә миннән ярдәм көткәнен күрдем. Мин моңа салкын кан белән карый алмадым. Мәктәп китаплары язарга башладым. Мин язган китапларымда (әлбәттә, хрестоматия) русларның Пушкины, Лермонтовы, Аксаковы, Майковы, Плещеевы вә башка да бик күбе булып являться итәм. Мин иттифакый гына тәрҗемә иткән вә икътибас ителгән шигырьләрем татар мәктәбендә беренче урынны алачак булды»,— дип яза, бу көннәрдә «Сабах» көтепханәсе тарафыннан «Күңел җимешләре» исемле шигырьләр җыентыгы дөньяга чыгарылачагын хәбәр итә.

*«СӘ», 1960, 4 сан, 123 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 100 б.*

**10 февраль.** «Йолдыз» газетасы: «Милли шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаевның соң көннәрдә басылып мәйданга чыккан әсәрләре: «Юаныч», «Балалар күңеле», «Алтын әтәч», «Халык әдәбияты», «Халык моңнары», «Күңелле сәхифәләр». Тиздән «Күңел җимешләре» дигән мәҗмугасы да басылып чыгачак»,— дип хәбәр итә.

*«Йолдыз», 644 нче сан.*

Г.Ибраһимов «Әдәбият мәсьәләләре» дигән гомуми исем

---

Хәл теле илә — бик авыр хәлдә.
Являться итәм — буларак чыгам (гәүдәләнәм).
Икътибас иту — файдалану.

астында чыккан «Шигырь» исемле мәкаләсендә Тукай шигырьләренең табигате, сурәтләү объекты, тел һәм стиле белән халык рухына якынлыгын, аның шигъри осталыгы халык тарафыннан танылуын искәртә: «Нәзым ягы да, шигърияте дә ярыйсы булган вә биннисбә яхшы вә муаффәкыятьле чыккан шигыре мәнзумга мисал табу өчен без Габдулла әфәнде Тукаевның мәҗмугаларына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүрбез. Аның әшгаре инде күплек тарафыннан тиешле мәүкыйгъсына мендерелеп танылган. Аларга нәзым да, шигърият тә матур табалар».

*«Йолдыз», 644 нче сан.*

**11 февраль.** Усад авылындагы Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. «Күңел җимешләре» — вакыйган матур исем. Аны тапканга үзем дә кәефләндем... чыккач та сиңа җибәрәмен»,— дип, «Сабах» көтепханәсенә бастырырга биргән җыентыгы турында яза.

С.Рәмиевне искә алып, ул тагын бер кат: «Рәмиевнең «Толстой» шигыре, минемчә дә, бөтенләй тозсыз, вәзенсез, ямьсез, бигрәк холостой выстрел»,— ди һәм үзенең «Саташкан» шигыренең С.Рәмиев турында икәнлеген раслый.

*«СӘ», 1960, 4 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 102 б.*

**2 мартка кадәр.** Ф.Әмирхан белән фотога төшәләр. Әмирхан бу рәсемне «Вафага. Ф.Әмирхан, Г.Тукай. 2 март, 1911 ел»,— дип язылган автограф белән В.Бәхтияровка бүләк итә. Бу фотоның оригиналы саклана.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 29-эш.*

**4 нче мартка кадәр.** «Мияубикә» исемле әсәрен язып бетерә.

*«СӘ», 1960, 4 нче сан.*

1911 ел башларында Тукайның үпкә авыруы көчәеп китүен белеп, Сәгыйть Рәмиев ык борчыла һәм аны кымыз белән дәвалау, доктор Нариман Наримановка күрсәтү өчен үз янына Әстерханга чакыра.

---

Биннисбә — чагыштырмача.
Муаффәкыятьле — уңышлы.
Мәнзум — тезмә әсәр.
Әшгарь — шигырьләр.
Мәүкыйгъ — урын.
Вакыйган — чынлап та.
Вәзен — шигырьдә ритм, такт, иҗек саны.
Холостой выстрел — кысыр ату.

Тукай, бу чакыруны кабул итеп, апрель аенда Әстерханга барырга карар кыла.

*«СӘ», 1960, 4 нче сан;*
*Садретдинов Ш. Сәгыйть Рәмиев иҗаты, 1973, 41 б.*

**4 март.** Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. Анда ул Г.Ибраһимов мәкаләләренең «шактый гына төпле чыгу»ларын, ләкин кайберләрендә «нәфасәт вә мәһарәт» күрмәвен әйтеп уза да, үзенең уй-фикерләре белән уртаклаша: «Бер поэма хакында башымда әнвагъ төрле хыяллар йөри. Гайяи хыялым — татарча, татар рухында, татар геройлары белән дөньяга бер «Евгений Онегин» чыгарудыр... Язын беренче пароход илә Әстерханга Сәгыйть Рәмиевкә кунакка китмәкче булам, вә аннан икәүләшеп кыргыз арасына кымызга бармакчы булабыз. Ният җәй буе Идел өстендә йөрү, мөмкин булса, Истамбулга да берике атнага заглянуть...

Мин бу арада балалар өчен «Песи Г.Җамал» яки «Песибикә» исемле бер рәсемле рисалә язып бетердем. Шактый муаффәкыятьле чыкты...» дип, «Мияубикә» исеме белән дөньяга чыккан (12 июнь, 1911) китабы турында яза.

*«СӘ», 1960, 4 нче сан; Г.Тукай.*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 103 б.*

**4 март.** Казаннан Әстерханга Сәгыйть Рәмиевкә хат яза.

Татар тормышында шушы арада булган, әле сүнеп тә өлгермәгән иҗтимагый-сәяси вакыйгага мөнәсәбәтен белдерә.

Татарстанның төньяк-көнчыгыш почмагында Иж-Бубый исемле авылда прогрессив карашлы бертуган Габдулла һәм Гобәйдулла Бубыйлар җитәкләгән, заманының зур, атаклы мәдрәсәләре белән рәттән торган танылган мәдрәсә була. Биредә фикер иреге хөкем сөрә, үзешчән сәнгать белән шөгыльләнәләр. Дин дәресләреннән тыш, анда рус теле, физика, химия, тригонометрия, ботаника, алгебра, геометрия, зоология, астрономия, педагогика һәм... француз теле укытылган.

Тирә-як авылларның фанатик муллалары, иске фикерле дин әһелләре диндә һәм мәгърифәттә үзгәрешләр кертүгә, ягъни бу мәдрәсә тәртипләренә каршы карагруһчылар хәрәкәте ачалар. Башлап йөрүчесе исә Түнтәр авылының консерватор мулласы Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов (Ишми ишан), ул Бубыйлар өстеннән хөкүмәт органнарына донослар җибәрә, дигән хәбәрләр тарата империя жандармериясе. Шундый чаралар

---

Нәфасәт вә мәһарәт — нәфислек һәм осталык.
Әнвагъ — күптөрле, төрле-төрле.
Гайяи хыялым — иң зур хыялым.

ярдәмендә татар зыялылары арасында каршылыклар, дошманлык уяталар. Татар дөньясындагы теләсә нинди яңарыш, алгарышны, прогрессив хәрәкәтне буалар, тамырдан корыталар. Бу очракта да хөкүмәт органнары мәдрәсәне контроль астына алалар. 30 гыйнварда исә йөздән артык жандарм стражниклары килеп мәдрәсәдә тентү үткәрәләр. Бубыйларны һәм ун мөгаллимне кулга алалар. Белем учагы сүндерелә. Шуңа бәйләп Әстерхан, Оренбург, Казан һәм башка урыннарда күп типографияләр, китапханәләр ябыла, китапларга арест салына.

Иж-Бубый фаҗигасе татарның алдынгы интеллигенциясенә аяз көнне яшен суккандай тәэсир иткән, кадимче Ишми Ишаннар һәм аларның кылган эшләренә нәфрәтләре көчәйгән.

Әлбәттә, Тукай да бу вакыйгага тыныч кына карый алмаган: «Эчем-тышым Ишми вә игъванына злоба белән тулды. Бөтен көтепханәләрне, матбагаларны вә газеталарны ябып бетерсәләр, бу көннән яңа киемнәремне җыртып ташлап, яланаяк чыгып йөгерәчәкмен. Күз алдым караңгыланды, милли тормыш, милли хәяттан вә үземнең хыялларымнан тәмам өмид кистем. Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...»

*Тукай Г. «Мәҗмугаи асарь», 1914, 5 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 105 б.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 225—227 б.*

**26 март.** «Күңел җимешләре» исемле китабы басылып чыга. (Казан, «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов литотипографиясе, 46 б., 6000 данә.)

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

Китапның тышлыгында ук «Күңел» шигыреннән эпиграф китерелгән:

Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!
Күп сөекледер бөтеннән — таңрегә сынган күңел.
Һәр минут миннән тели дөнья күңел җимешләрен,
Нәрсә пешсен, булса ялкынсыз күңел, сүнгән күңел?

Г.Т.

---

Игъван — булышчылар.
Злоба — ачу.
Поэт — шагыйрь.
Политик — сәясәтче.
Общественный деятель — җәмәгать эшлеклесе.
Инкисар ит — кител, сын.

Беренче биттә авторның 1908 елда төшкән фоторәсеме урнаштырылган (озын чәч өстеннән түбәтәй кигән, бизәкле галстуктан).

Китапка «Сабах» идарәсе исеменнән кереш сүз бирелгән. Анда әлеге җыентыкка кергән шигырьләрнең үзенчәлекләренә тукталып, әсәрләрнең характеры авторның рухи халәтенә бәйләп анализлана: «Габдулла әфәнденең шигырьләре, аларның әдәбиятымыз эчендә алган мөхтәрәм урыннары тугрысында сүз сөйләп тору гаммәгә мәгълүм булган бер хакыйкатьне генә тәкърар булыр иде. Халкымыз тарафыннан сөеп укыла торган шигырьләр, эчләрендәге милли аһәң, милли хиссият, милли рух һәм милли гармонияләре белән күптән инде татарның йөрәгендә тирән бер эз калдырып киләләр. Халкымызның төрле гыйнванлар астында нәшер ителә торган әллә никадәр нәзым мәҗмугалары белән Габдулла әфәнденең шигырьләрен саташтырмавын хәтеремезгә алсак, бу шигырьләрнең татар күңелендә никадәр тирән хис калдырганлыгын тугры тәхмин итәрмез. Шулай, Габдулла әфәнденең гомуми шигырьләренә вә аларның әһәмиятенә даир сүз сөйләп торырга хаҗәт юк. Фәкать бу «Күңел җимешләре» мәҗмугасындагы бер хосусият аерым игътибарны җәлеп итәдер. Габдулла әфәнде мәҗмуганың өстән бер җиренә:

«Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!» дигән девизын язып куя да шул юлын тәгъкыйб итеп китә: күңел, чынлап та яна, чынлап та сызлана. Ул әүвәл эзләнә, карый, ниһаять, бер тынычсызлык һәм гасабыйлык белән тормышның иң мөһим һәм нурлы бер почмагын табарга тырыша.

Менә сезгә «Җәйге таң хатирәсе»: «Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата»да шагыйремезне үзенең матурлыгы белән мәфтүн итә. Иң куәтле һәм иң гүзәл шигырьләреннән берсен илһам итә. Ләкин бу мәфтүният озакка сузылмый: ниндидер бер дәһшәтле дулкын Габдулла әфәндене үз эченә ала да «тормышның нурлы почмагын» башка нәрсәләрдә эзләндерә башлый.

Менә сезгә «Китап», менә «Мәҗлес».

Шундый мәҗлес: «Анда хөррият белән шатлык рәис».

Менә сезгә «Ачы тәҗрибә» һәм «Үкенеч» шигыре:

Монафыйклар камап һәр дүрт ягымны,
Куралмыйм мин кояшым һәм аемны, —

дип игътикад итә башлый.

---

Тәкърар — кабатлау.
Гыйнван — исем.
Тәхмин итү — чамалау.
Даир — мөнәсәбәттә.
Тәгъкыйб итү — юл буйлап китү.
Мәфтүн итә — сокландыра.
Монафыйк — икейөзле.
Игътикад итү — ышану, күңел беркетү.

Ләкин тормышның шагыйрь эзли торган нурлы почмагы һаман табылмый кала. Күңел, әүвәлдә әйткәнчә, яна, сызлана, аһ ора. Менә шуннан соң инде Тукай:

Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен,—

ди дә ачы хәсрәт җырлары башлый. Моннан соң инде «Төш» һәм «Актык тамчы яшь»ләр ихлассыз чыгалар. Аның каравы «Сәрләүхәсез», «Теләү бетте», «Өзелгән өмид»ләр рухның иң эчке катында киләләр дә укучыны да үзләре галәменә тарталар. Болар инде каләмне күз яшьләренә манчып язылганнар.

И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы! —

дип, ул сазының үзенә хитаб итә дә, моның белән генә канәгатьләнмичә:

Язасылай сүземне яза алмыйм,
Ни булды икән минем каләмемә?.. —

дип, шикаятен читләргә дә белдертә. Шулай итеп, без бу мәҗмугада Габдулла әфәнде Тукаевның әүвәле мәҗмугаларында очрамаган рух вә халәте рухиягә очрыймыз. Шагыйрьнең үзенчә тәгъбир иткәндә, аның каләме астында хәзер инде «Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы», ягъни «Хәзер генә сыгылып-сыгылып елаган яшьнең зур-зур тамчылары коелалар». Кем белә, бәлки, бу рух вә бу мәсләк шагыйремезнең мөстәкъбәлдә язачак бөтен шигырьләренә баш мәсләк булып китәр. Ул вакытта бу мәҗмуга шагыйремезнең тормышында вә рухындагы иң мөһим бер инкыйлабның башлап тышка чыгышы булачактыр.

Бу фикерләр тәнкыйтьчеләр вазифасы булса да, соңгы вакытта вакытлы матбугатта әдәби әсәрләр тәнкыйтенә бик аз урын бирелү сәбәпле, бик күп хосусиятләр тәнкыйтьчеләр тарафыннан бөтенләй игътибарсыз калуын искә алып, без бу хосусиятләргә тукталуны кирәк таптык»,— дип тәмамлана шактый күләмле кереш мәкалә.

Эчтәлегенә шагыйрьнең утыз сигез шигъри әсәре кергән бу китапта, моңарчы вакытлы матбугатта дөнья күргән әсәрләре белән беррәттән, «Карга», «Иртә», «Сакмар суы» көенә», «Эшкә өндәү», «Җил» дигән шигырьләре беренче мәртәбә басылган.

Китапның соңгы 47—48 нче битләрендә шагыйрьнең «Сабах» көтепханәсе тарафыннан моңарчы бастырып чыгарылган

---

Хитаб — мөрәҗәгать.
Мөстәкъбәлдә — алда, киләчәктә.

алты китабына аннотация урнаштырылган. Болар түбәндәгеләр: «Җуаныч» (1908), «Алтын әтәч» (1908), «Күңелле сәхифәләр» (1910), «Балалар күңеле» (1909), «Халык әдәбияты» (1910), «Халык моңнары» (1910).

**Апрель.** Нәҗип Гасрыйның «Современник» журналында басылган «Россия татарларының уянуы һәм аларның әдәбияты» дигән мәкаләсендә күп кенә татар шагыйрьләре арасыннан «бары икәү — Габдулла Тукаев белән Сәгыйть Рәмиевнең аерылып торуы» әйтелә, алар иҗатындагы кайбер характерлы сыйфатлар күрсәтелә.

*«Современник», 1911, 4 нче сан;*
*Садретдинов Ш. Сәгыйть Рәмиев иҗаты, 1973, 4 б.*

**5 апрель.** «Күңел җимешләре» исемле шигырьләр җыентыгына карата «Яңа әсәрләр» исеме белән Г.Ибраһимовның рецензиясе басылып чыга.

«...Габдулла әфәнде Тукаевның соңгы шигырьләре җыелып, «Күңел җимешләре» исеме илә мәйданга чыкты. Бер-бер аккан мәҗмугалары эченә тагын берәү ялганды.

Монда кайгы да, көенеч тә, изтираб та бар, уен-көлке дә юк түгел, һөҗүләргә дә урын бирелгән. Дәхи бер җәһәте әүвәлдә бер гади һәм тупасрак ингыйкас ителә торган иман вә игътикад хисе — шагыйрьнең бу әсәрендә голуви бер рәвештә мәйданга чыккан. Буңа «Мигъраҗ»ы ачык шәһадәт итә...

Ул мәйданга чыкканнан бирле кайгыра да, елый да, көлә дә, сүгә дә һәм вәгазьли дә»,— дип, шушы җыентык уңае белән Тукай иҗатын төрле яклап бәяли. Тукай табигать хакында аз яза, ди һәм шунда ук: «Күңел җимешләре»ндә исә бу хакта яңалык бар, ди, мисал итеп аның «Җәйге таң хатирәсе»ннән ике строфаны китерә:

Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата...

Габдулла әфәнде хәзер үз хиссиятен әүвәлгедән артык тулырак, киңрәк һәм ачыграк итеп җиткезә ала, һәм бундагы тәгъбирләр, ифадәләр биннисбә шигъри вә җанлылар».

*«Йолдыз», 666 нчы сан.*

---

Изтираб — аптырау.
Һөҗү — сатира, юмор.
Ингыйкас ителү — чагылу.
Иман вә игътикад — ышану һәм инану.
Голуви — югары.
Ифадә — аңлату.
Биннисбә — чагыштырмача.

**15 апрель.** «Шура» журналында Габдерәшид Юлдашевның «Ил җырлары» исемле мәкаләсе басыла. Мәкаләгә эпиграф итеп ул Тукайның:

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле! —

дигән шигъри юлын китерә. Мәкалә Тукайның халык әдәбияты турында укылган лекциясе мөнәсәбәте белән Тукайның халык җырлары турындагы кайбер фикерләренә тәнкыйть күзе белән карап язылган.

Тукайның: «Безнең халыкта җырлар өчен әүвәлге ике юлның күп әһәмияте дә булмыйдыр. Әүвәлге ике юл анчак скрипкә уйнаганда бер кәррә кыл тарту кабилендә бер нәрсәдер, мәсәлән, гавамдан берәү җырлый:

Сандугачлар су ташый,
Кайда икән су башы?

Ул бу сүзләрне җыруга да санамый, бәлки, тыңлаучыга үзеннән бер нәрсә көттерә. Тыңлаучы: «Бу нәрсә әйтмәкче була икән?!» — дип көтеп торганда гына ул:

Безнең җанкай ялгыз башы, —
Хозыр булсын юлдашы, —

дип куя.

Шулай көтмәгәндә килеп чыккан бу сүзләр, әлбәттә, «тыңлаучының күңеленә вә колагына хуш килә... соң мәгънәле сүз әйтә» дигән юлларына каршы Юлдашев тәнкыйть фикерен китерә: «Юк кына сүз белән тыңлаучының колагы тора микән? Мәгънәле сүз янына мәгънәсез сүз китереп кую үзе бер начар нәрсә»,— дип яза.

*«Шура», 8 нче сан, 253 б.*

**20 апрель.** ***(«И төрек, иң әүвәл үк әйтим сиңа: борның кылыч...») дип башланган ике юллык шигыре* журналның тышлыгында рәсем асты рәвешендә имзасыз басылган. Рәсемдә борыны бик озын булып салынып төшкән, башына фәс кигән бер төрек сурәте бирелгән һәм бер ягына «Тасвири әфкяр»** мөхәррире дип язылган. Аста әлеге ике юллык.

*«Ялт-йолт», 21 нче сан.*

---

* Бу шигырьнең Тукайныкы икәнен Н.Исәнбәт тә раслый. Казан утлары.— 1966.— № 4, 124 б.

** «Тасвире әфкяр» («Фикерләр тасвиры») Истамбулда 1862 елдан башлап Ибраһим Шинаси (1826—1871) чыгарган беренче прогрессив төрек газетасы.

**23 апрель.** «Мөкаддимә» (Арамызда әдәбият вә шигырь...) Сәгыйть Сүнчәләйнең инглиз шагыйре Байроннан тәрҗемә иткән «Шильон мәхбүсе» исемле поэмасына сүз башы итеп язган.

«Бу көннәрдә Сәгыйть әфәнде Сүнчәләй тарафыннан Байронның «Шильон мәхбүсе» исемле поэмасы (шигыре) татарчага шигырь белән тәрҗемә кылынуын ишеттем вә тәкъдим итүенә күрә укып чыктым...

Менә шушы бөтен дөньяга «байронизм» мәзһәбен тудырган вә, бәгъзе көчсез кешеләр күңелендә туып та, аларның күңел вә каләм ягыннан гаҗизлекләре сәбәпле, дөньяга чыга алмый яткан бөек, югары вә гүзәл бер хисне зәмингә агызып җибәргән кешенең кулга алырлык берәр әсәре безнең татар теленә күчерелгәне бар идеме? — Әлбәттә, юк иде. Инде бу бурычны Сәгыйть әфәнде үтәде».

*Сүнчәләй С. Мөкаддимә. «Шильон мәхбүсе», 1911, 2 б.; Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 201 б.*

**23—24 апрель.** Г.Тукай Казаннан «Самолет» ширкәте «Тургенев» исемендәге пароходының өченче классына утырып, Әстерханга сәфәргә чыга.

Ул өстенә озын пальто, аягына ботинка, башына фуражка кигән, чәчен озын итеп үстергән була.

Пароходта барганда үз-үзләрен бик гади-табигый тоткан дүртенче класс пассажирлары арасына чыгып озак-озак йөри. Шагыйрь үзе өчен гади халык арасында булуны кирәк саный: «Эчем пошкач, приличие-фәлән рамкасына кысылмаган, простой дүртенче класс халкы арасына чыга идем.

Вакыйган, анда чыгу бушка китмичә, бер хили заман карап торырлык күренешләр булгалый иде»,— дип искә ала үзенең бу сәфәре турында язылган юлъязмасында.

*Кечкенә сәяхәт. «Ялт-йолт», 24 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 284 б.;*
*«КУ», 1978, 4 нче сан;*
*Әмирова Б. Тукайны каршылау. «Замандашлары», 148 б.*

«Тургенев» пароходы Саратов шәһәрендә тукталыш ясый. Биредә шагыйрь үзен көтеп торучы Мәүсәфә Яраева җитәкчелегендәге кызлар мәктәбенең бер төркем укучылары белән очраша. Кыз балалар аңа чәчәк бәйләмнәре бүләк итәләр. Тукай

---

Зәмин — җир йөзе, дөнья.
Бер хили заман — байтак вакыт.

аларга рәхмәт әйтеп: «Тырышып укыгыз. Халкыбыз өчен файдалы кешеләр булып үсегез»,— ди.

*Әмирова Б. Тукайны каршылау. «Замандашлары», 144 б.*

**Апрель азагы.** Әстерханга килеп төшкәч, ул «Люкс» кунакханәсенә урнаша.

Бу шәһәрдә торган чакта (апрель азагы — 6 июнь) ул дуслары, танышлары һәм биредәге интеллигенция белән аралашып яши.

Ерак булмаган Балык Базары авылына барып, кымыз эчеп берникадәр сәламәтлеген рәтли, иҗат эше белән дә шөгыльләнә. Азәрбайҗанның күренекле җәмәгать эшлеклесе, доктор һәм язучы Нариман Нариманов белән очраша (Нариманов бу вакытта патша хөкүмәте тарафыннан Бакудан Әстерханга сөргенгә җибәрелгән була). «Идел» газетасы редакциясендә хәреф җыючы булып эшләүче Габдерәхим Утабалиев истәлегенә караганда, Тукай Әстерханга килеп төшкәч тә иң элек дусты Сәгыйть Рәмиев янына — «Идел» газетасы редакциясенә килә.

*«Замандашлары», 146 б.*

**29 апрель.** «Идел»дә Тукайның Әстреханга килеп җитүе турында белдерү басылып чыга: «Мәшһүр шагыйрьләремездән Габдулла әфәнде Тукаев шәһәремездә мөсафирдыр».

*«Идел», 348 нче сан.*

**Май башы.** «Идел» газетасы хезмәткәрләре бакчага чыгу оештыралар. Сәмәк авылына Латыйп Үмәров бакчасына баралар. Аларга Тукай да кушыла. Бу чыгу — маевка була. Биредә доктор Нариман Нариманов та катнаша һәм 1 Май бәйрәменең тарихы турында сөйли.

«Әстерханда чакта Тукай редакциягә көн дә диярлек килә иде»,— ди истәлек иясе.

*Утабалиев Г. Тукай «Идел» газетасы редакциясендә. «Замандашлары», 148 б.; Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 54—56 б.*

Сәгыйть Рәмиев Тукайны «Люкс» номерыннан үзе яшәгән квартирага — көймәләр күтәрүче конопотчы эшчеләр бригадиры, прогрессив карашлы, үзе дә спектакльләр, төрле җәмәгать чаралары оештыруда катнашып йөрүче Даут Мөхәммәдевләр өенә, үзе янына күчерә. Тукайның авыру икәнен күреп, Д.Мөхәммәдев белән С.Рәмиев аны доктор Н.Наримановка алып баралар. Нариманов аның авыруын карагач, кымыз эчеп көч җыярга киңәш бирә.

*Алиев В. Сәгыйть Рәмиев белән. «Замандашлары», 152 б.*

Тукай Әстерханда да иҗат эше белән шөгыльләнүдән туктамый. Төрле жанрда әсәрләр яза. Кайберләрен «Идел»дә бастыра, беришеләрен Казанга җибәрә. Бу хакта И.Нуруллин болай дип яза: «Әстерханга килеп төшүгә,— «Идел» редакциясенең үтенече беләнме, әллә инде бу газетада эзен калдырырга теләпме, Мәҗит Гафуриның «Хәмитнең хәяты» исемле повестен укып чыга да рецензия яза. Сатирик шигырь һәм мәкаләләрен, «Кечкенә сәяхәт» исемле юмористик очеркын яза һәм Казанга озата». «Идел»дә «Яңа әсәрләр» («Хәмитнең хәяты») басылып та чыга (10 июнь).

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 236 б.*

**1 май.** «Шигърият һәм нәсер» шигыре «Сөенче Алаев» имзасы белән басылып чыга. Тукай бу шигырен иҗатының башлангыч чорында тормышның матур, шигъриятле якларын гына сурәтләргә яраткан шагыйрь С.Сүнчәләйгә (1889—1941) пародия итеп язган. Сүнчәләй шигырьләрендәге кайбер җитешсез якларны тәнкыйтьләгән.

*«Ялт-йолт», 22 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 368 б.*

**5 май.** Әстерханнан Казанга «Ялт-йолт» журналының редакторы Әхмәт Урманчиевкә хат яза.

Ул шушы кыска сроклы сәяхәте вакытында да «Ялт-йолт» белән элемтәсен өзми. Журналга материаллар, киңәшләр биреп тора: «Киләсе хатымда рәсемнәр өчен темалар, вә булдырып булса, мәкалә вә шигырьләр дә җибәрсәм кирәк»,— дип вәгъдә итә.

Хаттан күренгәнчә, Тукай Әстерханда үзен чолгаган даирәдән һәм үзенә булган мөнәсәбәттән канәгать. Әстерханда Тукайга күрсәтелгән хөрмәт һәм кайгыртучанлык шагыйрьнең сәламәтлегенә һәм настроениесенә уңай йогынты ясый:

«Мин... Әстерханда... тагын бер ай кадәре торырга карар бирдем... Әле хәзер кунакка йөрүдән бушаганым юк... Кымыз эчәм, ит ашыйм. Һава яхшы. Хәзердән үк үземдә җисмән вә рухан бер көч хис итә башладым.

Квартирам да ничава. Сәгыйть белән бергә торабыз...»

*Бурнаш Ф. Талант юлы. «СӘ», 1936, 5 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 106 б.*

Әстерханда ул башлыча «Идел» тарафдарлары белән аралаша. Тукайны мәҗлесләргә чакыра башлыйлар. С.Рәмиев белән берлектә, мәсәлән, ул «Идел»дә языша, кайвакыт исә редактор вазифасын башкара торган Габдрахман мулла Ниязида да, яңалыкларны яклаган тирече сәүдәгәр Әбүбәкер Даш-

кинда да, Тияк малайлар мәктәбе мөгаллиме Гани Ниязида да кунакта булган.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 235 б.*

**5 майдан соң.** Сәгыйть Рәмиев белән ике-өч атна бергә яшәгәч, Тукай Идел аръягына, Калмык Базары дигән татар авылында мөгаллимлек итүче Шәһит Гайфигә күчеп китә.

Максаты — биредә торып кымыз эчү. Шәһит Гайфи аны пристаньда җигүле ат белән каршылый. Тукайны пароходта озатып, аның белән бергә Сәгыйть Рәмиев һәм тагын берничә кеше киләләр. Биредә Тукай кымыз эчеп дәвалана, ял итә. Өйдә торып ялыкса, яр буена бара, тупыл күләгәсенә утырып Идел өстен, пароход, баржа һәм көймәләрне күзәтә. Шәһитнең энесе Хәнәфи, Туликов дигән байның атын җигеп, Кендекле Күл авылыннан көн аралаш кымыз китереп тора. Хәнәфи Гайфетдинов истәлегендә: «Кымызның шифасы тиде: шагыйрь тазарды, йөзендәге сарылык югалып, бит урталары тулып китте»,— диелә.

*ГайфетдиновХ. Калмык Базарында.*
*«Замандашлары», 151 б.*

Тукай Калмык Базарында чагында Шәһит Гайфинең дусты, Әстерханның атаклы фотографы И.М.Бочкарев килә. Шул вакытта Сәгыйть Рәмиев һәм Шәһит Гайфи белән Габдулла Тукай рәсемгә төшәләр.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 35-эш.*

Хәнәфи Гайфетдинов истәлегендә тагын кызыклы фактлар күрәбез: «И.М.Бочкарев килгән көнне Шәһит абый Тукайның берничә шигырен җанландырып күрсәтте. Бу күренешләрне фотограф рәсемгә төшерде.

Шәһит абый хаҗи булып, ә җиңгәм Нурбиби яшь кыз булып киенделәр. Идәнгә җәелгән табынга... ат казылыгы, тутырган каз һәм бер табак кымыз куелды. Бу рәсем соңыннан русча һәм татарча язулы төсле открытка итеп таратылды. Аңа Габдулла Тукайның «Бер шәехнең мөнаҗате» шигыреннән беренче куплет язылган иде. Абый белән җиңги шунда ук «Егет илә кыз», «Шәйтанның муенына» һ.б. шигырьләрне театрлаштырдылар».

*«Замандашлары», 153 б.*

«Тукайның дуслары, аны якын итүчеләр көн дә диярлек Әстерханнан Калмык Базарына килеп йөриләр һәм ул үзе дә Шәһит Гайфи белән әледән-әле шәһәргә бара.

Тукай Калмык Базарында чакта артистлар килеп театр куялар. Камил Мотыйгый да килә. Аның концерты турында «Бор-

һане тәрәкъкый»да: «Концертта Казан кунаклары да булды» дигән хәбәр басыла»,— дип укыйбыз истәлекләрдән. Димәк, Тукайның да концертны каравы ихтимал. Биредә Тукай, әлбәттә, иҗат эше белән дә шөгыльләнгән. Бу истәлекләрдә дә чагыла: «Тукай көн буе бүлмәдә ялгыз калып һаман укый һәм яза иде. Аның бер тапкыр абыйга бездә, бер мәҗмуга булырлык шигырьләр яздым, дигәнен ишеттем»,— дигән юлларны укыйбыз.

*Гайфетдинов Х. Калмык Базарында. «Замандашлары», 151 б.*

**10 май.** «Идел» газетасында «Яңа әсәрләр» (Хәмитнең хәяты) исемле мәкаләсе урнаштырылган. Хезмәт Мәҗит Гафуриның «Хәмитнең хәяты, яхуд Ләйлә вә хәятым» дигән исем белән 1911 ел башында Уфада чыккан китабына рецензиябәяләмә рәвешендә язылган. М.Гафуриның бу әсәре шәкертләр тормышын, хәлен, укыту системасындагы схоластиканы тасвирлауга багышланган.

Тукай китапка бәя биреп: «Мәҗит Гафуриның бу әсәре... ул язган әсәрләрнең иң яхшысы вә иң тормыштан алынып язылганыдыр, җаиздер. Бу әсәрдәге бәян ителгән хәлләр... чапкыр тормыш артыннан җитмәгән вә ничектер куарга да керешә алмаган шәкертләрнең хәл-әхваленнән гыйбарәттер,— ди,— һәм анда сурәтләнгәннәр күбемезнең тормышы. Шуңа күрә бу әсәрне укырга тәүсыя итәм»,— дип, укучыларга реклама ясый.

*«Идел», 351 нче сан.*

**13 май.** «Иһтида» исемле шигырен яза.

*«Шура», 12 нче сан.*

**15 май.** «Шура» журналында З.Вәлидинең «Ерларымыз хакында» исемле мәкаләсе басылып чыга. Мәкалә Тукайның «Халык әдәбияты» (Казан, «Сабах» көтепханәсе, 1910) дигән китабына мөнәсәбәттә язылган. Конкрет алганда: «Мин Габдулла әфәнде Тукайның, безнең җырларымыздагы мисраглар арасында мөнәсәбәт тә юк, дигән сүзенә каршы язмыш идем»,— ди автор һәм Тукайның раславына капма-каршы үз фикерләрен китерә:

«Безнең җырларымыз бар. Алар бер-берсенә башка булган мисраглардан кушылалар... ләкин алар арасында мөнәсәбәт булырга тиеш... Ике мисрагның бергә кушылуында аңлашыл-

---

Җаиздер — дөрестер.
Тәүсыя итү — киңәш бирү.
Иһтида — дөрес юлга керү.

ган мәгънә фәкать ахыргы мисрагдан гына аңланган мәгънәдән кыйммәте әдәбия илә бик ачык аерыла. Чөнки җырдан булган мәгънә аңлашылганның өстенә ул бер-бер тәлкыйн илә җанландырылып калебкә тәэсир итә».

Төрки җырларны автор төрки халыкның табигатьне, җир-су, маллар, атлар, гаилә һәм башка тормыш күренешләрен бик сөюләре белән бәйләп, тематик яктан аерып күрсәтә. Шуларны җырга кертеп, исемнәрен атап җырлау төркилек, татарлык билгесе, ди.

«Әсәр татар җырларына шушы табигатькә һәм җанлы тормышка турыдан-туры кагылышлы сүзләр кушып җырлану миңа сәер тоела икән, бу инде минем төрек-татар тормышыннан, аның рухи халәтеннән ераклыгымны гына күрсәтә»,— дип тәмамлый.

*«Шура», 10 нчы сан, 318 б.*

Идел аръягында Шәһит Гайфидә атна-ун көн ял иткәннән соң, Тукай яңадан Әстерханга С.Рәмиев янына әйләнеп кайта.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 237 б.*

Истәлекләрдә Тукайның С.Рәмиев һәм аның иптәшләре белән Яңа Гаскәр авылына баруы әйтелә. Бу сәяхәтне моторлы көймәдә Д.Мөхәммәдев оештыра. Сәяхәт күңелле булып, Тукай аннан бик риза кала.

*«Замандашлары», 153 б.*

Вәлит Алиев истәлегендә Әстерханда Тияк бистәсендә Г.Тукайга багышлап әдәби кичә үткәрелүе турында әйтелә. Залда халык тулы була. Тукай бу кичәдә халык әдәбияты турында сөйли. Аннан соң артистлар Габдерәхим Адаков (1894—1918), Барый Әминев, Әждәр Моратов һ.б. Тукай шигырьләрен укыйлар, Тукайны бик олылап тәбриклиләр.

*Алиев В. Сәгыйть Рәмиев белән.*
*«Замандашлары», 154 б.*

Әстерханда «Аркадия» исемле җәйге бакчада (хәзер Карл Маркс исемендәге культура паркы) Сәгыйть Рәмиев һәм Даут Мөхәммәдевләр белән бергә җырчы Мәрьям Искәндәрова концертын карый. Концерттан соң Мәрьям Искәндәрова Тукай һәм аның дуслары утырган өстәлгә килеп, Тукай белән таныша, сөйләшә.

*«Замандашлары», 154 б.*

«Борһане тәрәкъкый» газетасында Сәгыйть Рәмиев белән Тукайга карата карикатура урнаштырыла. Бу уңай белән Тукай газетаның редакторы, төркиләрнең берлеге яклы, Мостафа Лотфига карата «Мостафа» исемле сатирик шигырен яза:

---

Тәлкыйн илә — аңлатып, ышандырып.
Калебкә — күңелгә, йөрәккә.

Төркиядә бер теләнче, сухта булган Мостафа;
Монда кайтып, ил казасы, фетнә булган Мостафа...

Бу шигырь шунда ук «Идел»дә басарга уйланылса да, Тукай карарын үзгәртә, инде наборга җыелган шигырьне кире ала. «Аның «Һазиһи касидәтен фи мәдһи Мостафа» исеме белән билгеле шигыренең үзгәртелгән варианты»,— дип яза үзенең истәлегендә «Идел» газетасында хәреф җыючы булып эшләүче Габдерәхим Утабалиев.

*Утабалиев Г. Тукай «Идел» газетасы редакциясендә. «Замандашлары», 149 б.*

Тукай Әстерханнан китәр алдыннан, аның шәрәфенә Кышкы театрда Зәйни Солтанов җитәкчелегендә зур кичә үткәрелә*.

Кичәдән соң Зәйни Солтанов җитәкчелегендәге Татар драма түгәрәге членнары белән берлектә фотога төшәләр. Уртада З.Солтанов, Г.Тукай һәм С.Рәмиев. Өченче рәттә Ш.Гайфи.

*«Замандашлары», 155 б.;
Мирасханә, 9-ф., 3-тасв., 44-эш;
Габдулла Тукай, «Альбом», 1978, 114 б.*

**25 май.** Казан университеты типографиясе эшчесе Әхмәтвәли Әхмәдуллин өендә тентү була. Донос кәгазендә Әхмәдуллинның тыелган китаплар саклавы турында әйтелгән. Беркетмәдә тасвирланган 88 басма китапның беренчесе итеп «Габдулла Тукаев шигырьләре» (4 нче дәфтәр) язылган.

*ТРМА. 199-ф., 2-тасв., 1237-эш;
«КУ», 1986, 4 нче сан, 185 б.*

**Май—июнь башы.** Әстерханда ялгыз гына фотога төшә. Чәче кырып алынган бу фотосының өстенә түбәндәге юлларны язган:

Кайтмады уч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 7-эш.*

**4 июньгә кадәр.** Г.Тукай Г. Коләхметовның «Ник уйгандым?!» хикәясен укый һәм «Ялт-йолт» журналының 23 нче санында басылган «Хикәя язарга теләүче яңа әдипләргә үрнәк» фельетонында аның аерым моментларыннан файдалана.

*Коләхметов Г. «Яшь гомер», 1981, 358 б.*

**4 июнь.** «Ялт-йолт» журналының 23 нче саны дөнья күрә.

---

Сухта — шәкерт.
* И.Нуруллин Әстерханда Тукайга багышлап махсус кичә уздырылмаган, дип исәпли. Нуруллин И. Габдулла Тукай.— Казан.— 1979.— 238 б.

Биредә Тукайның «Мөхәррире мин түгел» имзасы белән «Хикәя язарга теләүче яңа әдипләргә үрнәк» исемле мәкаләсе, идарәдән җаваплар бүлегендә дә аның имзасыз язмасы һәм рәсем-карикатура асты рәвешендә имзасыз гына тагын берничә ике юллык шигыре урнаштырылган. Болар түбәндәгеләр: ***(«Уңга да мин әйләнәм, сулга да мин әйләнәм...»).

Рәсемдә чалмалы бер җил тегермәне ясалган. Шигырьдә җәдит мәктәпләрен яндырып, мөгаллимнәрне сөргенгә җибәрткәндә, иске карашлы муллаларның ике яклы роль уйнауларына ишарә:

Уңга да мин әйләнәм,
Сулга да мин әйләнәм;
Бай алдында җәдит күрсәм,
«Син кяфер» дип бәйләнәм.

***(«Һәзад-дөнья әкалле»).

Һәзад-дөнья әкалле мин калили,*
Кафа сыра эчеп исерә Хәлили.

***(«Приемныйның ишекләре...»).

Рәсемдә ике әтәч сугыша, җоннар оча, аста:

Приемныйның ишекләре тар ләхеттән тар икән,
Әстерханда ике әтәч — «Борһан», «Идел» бар икән,—

дигән юллар белән ул Әстерханда чыгып килгән демократик юнәлештәге «Идел» (бигрәк тә Сәгыйть Рәмиевнең тырышлыгы аркасында) һәм редакторы Мостафа Лотфи булган төркичелек юнәлешендәге «Борһане тәрәкъкый» газеталарының даими рәвештә бер-берсен чукып, матбугат битләрендә талашып, әйткәләшеп яшәүләреннән көлә.

*«Ялт-йолт», 23 нче сан;*
*«КУ», 1960, 4 нче сан.*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2т., 367, 385 б.*

**6 июнь.** Г.Тукай Әстерханнан «Василий Лапшин» исемле пароходка утырып (беренче класста, аерым каютада), Казанга кайтырга чыга. Бер төркем дуслары аны озатып калалар. Истәлекләрдә аның килгәндәгедән күп үзгәргәнлеге, кымыздан соң тазарганлыгы әйтелә.

*Алиев В. Сәгыйть Рәмиев белән.*
*«Замандашлары», 155 б.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 238 б.*

Ул Казанны, «Ялт-йолт»ны, иптәшләрен сагынып кайта. Кайткач та «Болгар» кунакханәсендәге үзенең кечкенә бүлмәсендә яши. Җиң сызганып эшкә чума.

---

* Бу дөнья кечкенәдән кечкенә.

**10 июнь.** «Астраханский вестник» газетасында «А.Р.» имзасы белән «Әстерхан татарлары тормышыннан» дигән мәкалә басыла. «6 июнь киче Әстерхан татарлары өчен үтә тантаналы бер кич санала алган булыр иде, чөнки бу кичне яшь татар шагыйре Г.Тукаев Әстерханнан китте. Биредә ул бер ай чамасы булды. Ләкин шагыйрьне шактый ямьсез кыяфәттә рәсемгә төшергән бер карикатураны санамаганда, Әстерхан татар интеллигентларыннан берсе дә шагыйрь белән кызыксынмады.

Шигырьләренең көче, мәгънәви тирәнлеге һәм киң колачлы булуы ягыннан Тукаевны даһи шагыйрь дип әйтергә мөмкин. Моннан берничә ел элек аның кайбер шигырьләре Пушкин һәм Лермонтов әсәрләре белән тиңләштерелделәр. Моннан, әлбәттә, татарлар өчен Тукаев Пушкин һәм Лермонтов дәрәҗәсендәге шагыйрь дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин булыр иде. Әмма безнең Әстерхан татарлары, күрәсең, даһиларның талантына бәя бирерлек дәрәҗәгә үсеп җитмәгәннәр һәм 6 июнь көнне кичен туры килгән очрактан тиешенчә файдалана алмадылар.

Шагыйрьне якын дусларыннан һәм аны ихтирам иткән укучылардан торган бер кечкенә төркем кеше озатты. Ә шунда булган бик күп татарлар, пароходчылык дебаркадерында буталып йөреп, авыз ачып калды, алар үз милләтләренең даһие һәм киләчәк буыннарының горурлыгы булган кешенең бу вакытта шунда булуын белмәделәр дә»*.

Шул елларда ук алдынгы рус матбугаты Тукайның шигъри талантына югары бәя биргән.

*«Астраханский вестник», 138 нче сан.;*
*Миңнуллин Р. Г.Тукай Әстерханда.*
*«КУ», 4 нче сан.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 238—239 б.*

**12 июнь.** «Мияубикә» исемле китабы басылып чыга. («Мәктәп көтепханәсе»ннән 1 нче китап. «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов литотипографиясе. Рәсемле, 24 б. 6000 данә.)

Китапның ахырына Тукай: «Живописное обозрение» (1872—1905) журналыннан икътибас ителеп, шигырьгә әйләндерелде»,— дигән.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

«Бер-ике сүз» дип «Сабах» идарәсеннән бирелгән сүз башында: «Моңа кадәр чыгарып килгән «Мәктәп мөкяфәте» сериясе урынына «Мәктәп көтепханәсе» исемендә арзанлы вә һәрбер укый-яза белгән яланаяклы бала аңларлык рәвештә

---

* Тәрҗемә И.Нуруллинныкы.

яңа бер серия ачтык вә шул мәҗмугадан беренче китап уларак шагыйрь Габдулла әфәнденең ушбу «Мияубикә» нам әсәрене мәйданга куйдык»,— диелә.

**14 июнь.** «Идел»дә «Матбугатымыз» исеме астында игълан-реклама басыла: «Габдулла әфәнде Тукаев тарафыннан «Мияубикә» исеме белән балалар өчен укырга күңелле итеп шигырь белән язылган бер китап идарәмезгә килде.

Казанның «Сабах» көтепханәсе тарафыннан гүзәл итеп табгы кылынган китапта песиләрнең төрле вакыттагы төрлечә халәтләре тасвир кыйлынган һәм песиләрнең шул халәтләрендәге сурәтләре дә китапта рәсем белән төшерелгән».

*«Идел», 562 нче сан.*

**15 июнь.** «Иһтида» исемле шигыре басылып чыга.

*«Шура», 12 нче сан.*

Мәхәббәт һәм халыкка хезмәт фәлсәфәсен чагылдырган шигырь. Өч бүлекчәдән һәм 12 бәеттән торган бу шигырьдә Шәрык әдәбиятлары һәм эстетикасы өчен традицион булган «Нәрсә ул сөю?» — тән ләззәтеме, әллә хис-тойгылар белән яратумы? — дигән сорауга җавап эзләнә. Шагыйрь Шәрык гашыйкларыдай төрле хисләр утында янган, үзенең сөйгәненә сәҗдә кылган, табынган, шигырьләре белән аңа мәдхия укыган.

Табындым, сәҗдә кыйлдым мин сөйгән җанашның алдында,
Өмид иттем вә куркътым да, кызардым һәм оялдым да.
Миңа ул бер вә бар, көчле вә һәйбәтле санәм булды;
Аңар хәмдем, салатымны ирештергән каләм булды.

Лирик герой фикеренчә, саф мәхәббәт бөек максатларга илтә. Шәрык әдәбияты авторларыныкы кебек үк, Тукайның гашыйгы да мәхәббәт диңгезендә йөзгән, ләкин каты бәгырьле гүзәл аның сөю хисләрен уртаклашмаган, күңел газапларына дучар иткән, бу янудан бары тик көй һәм гамь калган. Ахыр чиктә тән мәхәббәте ләззәтләрен белмәгән лирик герой саф, нәфис хисләр белән өретелгән Әфләтүнчә яратудан да баш тарта.

Вакытлар үткәч тә, сөйгән яр алдында сәҗдәгә китүләр лирик геройга мәгънәсез бер эш булып тоела. Лирик геройның дөньяга карашы үзгәрә; мәхәббәт дигән «зольмәт» — караңгы-

---

Нам — исемле.
Табгы кылынган — басылган.
Иһтида — дөрес юлга керү.
Хәмед, салат — мактау һәм гыйбадәт (намаз).

лык артыннан аңа «фикер кояшы» балкый, «нурлы хәят» иңә. Үз үзенең мәхәббәт газаплары белән үткән чагын, кайчандыр потларга баш игән җаһил гарәпләр белән чагыштырып, оялып кына искә төшерә. Хәзер инде аның мәхәббәт кыйбласы үзгәргән, ул яңа идеалга — яраткан шөгыленә һәм халыкка хезмәт итүгә юнәлтелгән. Шигырьнең «Яшә, тугры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!» дигән мәгърифәтчелек лозунгысы белән тәмамлануы шул хакта сөйли.

Шагыйрьнең соңгы фикерен рус язучысы Л.Н.Толстойның фәлсәфи-этик карашлары яссылыгында карарга кирәк. Мәгълүм булганча, Л.Толстой мәхәббәт шәхеснең халык файдасына булган иҗтимагый эшчәнлегенә аяк чала дип исәпли. Акыл белән хезмәтне сөю хисләреннән өстен күрә. Күп кенә шигырьләрендә Толстойның бу фикерен Тукай да уртаклаша.

*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 36—38 б.*

«Кечкенә сәяхәт» исемле әсәре «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

Әстерханга сәфәре вакытында юлда Казаннан Самарага кадәр арада күргәннәрен, тәэсирләрен яза.

«Бу ел апрель ахырында Казаннан «Самолет» ширкәтенең «Тургенев» нам пароходына утырып, Әстерханга сәфәр иттем... урыным өченче класста иде...»

*«Ялт-йолт», 24 нче сан.*

**21 июнь.** «Яңа әсәрләр» рубрикасында «Мияубикә» әсәренә Г.Ибраһимовның рецензиясе басылып чыга.

«Русча журналдан алып эшләнгән бу әсәрнең мөндәриҗәсе зыянсыз; балалар, шаять, күңел табарлар... җиңел, ачык, чат татарча һәм аңлаешлы язылган вә оста гына тәрҗемә дә кыйлынган бу әсәрнең бөтен фазыйләте телендә, тик телендә генәдер... матур, уңайлы, үземезчә генәдер... балалар рәхәтләнеп укырлык.

«Мәктәп баласы өчен» исеме белән,— ди Г.Ибраһимов,— Тукай әһәмиятсез, вак-төяк тәрҗемәләр белән шөгыльләнә, мәнзумә этәч, сунарчы һәм песи экиятләре урынына ...ул ...рус, Гарби дөнья әсәрләреннән мөһим вә җитди бер нәрсә тәрҗемә кыйлса, һәрхәлдә, «Алтын этәч», «Мияубикә»дән дә күп дәрәҗә хәер булса кирәк... матбугатымызга зур вә бик кадерле бүләк бирелгән булыр иде дип уйлыйм».

*«Йолдыз», 699 нчы сан.*

**1 июль.** Журналның «Идарәдән җаваплар» исемле бүле-

---

Мәнзумә — тезмә, шигырь белән язылган хикәя.

гендә укучыларның сорауларына һәм «Ялт-йолт»ка җибәргән материаллары басылмый калган кайбер авторларга идарә исеменнән язылган җаваплары имзасыз гына урнаштырылган. Алар юмористик планда язылган, мәсәлән:

«Казанда Х.Н. әфәндегә:

— Мәкаләң чибәр генә булса да, бәгъзе бер әдипкә хилаф сүзләр булдыкыннан, дәреҗ ителмәде.

Әстерханда М.Б.гә:

— Синең, шаять, моңарчы берәр гәзитә вә журналда: «Имзасыз мәктүбләр дәреҗ ителми»,— дигән сүзне күргәнең бардыр. Без дә шул сүзне тәкърар әйтәмез: ачык имзасы идарәгә мәгълүм булмаган һичбер язу дәреҗ ителми. Хәер, имзаң булса да, дәреҗ итмәгән булыр идек. Чөнки кешенең әүвәлдә чәче озын булып, соңыннан алдыруы, безнеңчә, һичбер әһәмияткә малик түгел. Андый төк, җоннар хакындагы мәкаләңне безнең идарәгә түгел, бәлки, «Җон вә бишмәт» идарәсенә җибәр. Үзеңә фатиха кыйла-кыйла басарлар. Моннан берничә ел элек «Игълан фәкать» гәзитәсе дә кешеләрнең чәчләрен вә башка һәртөрле җоннарын тикшерә башлаган иде дә, ничектер сизенеп, туктап калды. Шулай итеп, ул мәсьәләне син түгел, Әхмәтҗан абзаң да хәл кыйла алмаган иде.

Әстерханнан килгән башка мәктүбләргә дә шул — ул хәтле мәгълүм кешенең чәче хакында күбрәк бәхәс ителә. Аның нәрсәсенә исеңез китте, әллә моңарчы шәһәреңездә озын чәчле кеше юк идеме?»

Шундый характердагы җиде җавап урнаштырылган.

*«Ялт-йолт», 24 нче сан.*

**25 июнь.** «Аз гына төзәтү» исемле мәкаләсен яза.

*«Йолдыз», 703 нче сан.*

**26 июнь.** «Яшен яшьнәгәндә» исемле шигырен иҗат итә (яисә акка күчереп яза):

Куркытма син, Алла, яшен белән,
Барыбер мин куръкмыйм, яши беләм!
Куркытсаң да — куръкмыйм, аязымны
Сатып алдым аһым, яшем белән!

Ләкин ул аны беркайчан да бастырмаган. «Яшен яшьнәгәндә» дигән бу шигырь С.Рәмиевнең «Мәҗит сүзе» тәэсирендә язылган дип расларга мөмкин.

*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 6-эш;*

---

Малик — ия.

**30 июнь.** «Аз гына төзәтү» исемле мәкаләсе басылып чыга. Бу Г.Ибраһимовның «Мияубикә»гә рецензиясенә каршы җавап мәкалә.

«Могътәбәр «Йолдыз»ның 699 нчы номерында Габди* әфәнде, «Мияубикә» исемендәге бер әсәремне интикад иткәндә, сүз арасында болай дип әйтә: «Бу әсәр шигырь түгел, бәлки, нәзым вә мәнзумә генә, һәм безгә шигырь белән нәзымны аерырга күптән вакыт»,— дип, Г.Ибраһимовның, «Мияубикә» поэзия төренә кермичә, рифмалаштырылган коры хикәя генә»,— дип аңлатырга тырышуы белән килешмичә, укучыларга газета аша аңлатма бирүне кирәк саный.

«Минемчә, соңгы җөмләдән мөхтәрәм укучыларның, «Мияубикә»не язучы нәзым белән шигырьне саташтыра икән, дигән фикергә заһиб булу ихтималлары бар. Шуның өчен изах итәмен ки, «Мияубикә»не шагыйрь, саф поэзия, чын шигырьгә әйләндердем дип ышанганга күрә, «шигырьгә әйләндерелде» дип куйган.

...Габдинең югарыдагы сүзләре ялгыз бер интикадчының фикере генә дип тәлкыйн ителсен».

*«Йолдыз», 703 нче сан.*

**1 июль.** Галәэтдин Ходаяровның «Кайгы (Тукаевка тәкълид)» дигән шигыре басылып чыга:

...Яшь, сабый чагымда гиздем кайгы-хәсрәт күрмичә,
Бу егетлектә тәҗәссем итте кайгы төрлесе;
Мәңге килмәскә югалды шатланып көлгән заман,
Бер кычыткандай булып калды чәчәкләр күренеше...

*«Шура», 13 нче сан.*

**14 июль.** «Читен хәл» шигырен яза.

*«Шура», 17 нче сан.*

**15 июль.** «Ялт-йолт» журналының 25 нче саны дөнья күрә. Биредә Тукай үзе Әстерханда чакта танышкан һәм дуслашып киткән, Калмык Базары авылында укытучы булып эшләүче һәвәскәр рәссам, «Туп» журналында сәяси карикатуралар да ясаган Шәһит Гайфине «Ялт-йолт» журналы белән хезмәт-

---

* Габди — Галимҗан Ибраһимовның псевдонимы.
Интикад — тәнкыйть.
Нәзым вә мәнзумә — тезмә сүз.
Заһиб булу — китү.
Изах итү — ачыклап бирү.
Тәлкыйн ителсен — аңлансын, кабул ителсен.
Тәкълид — ияреп, охшатып язу.
Тәҗәссем итте — гәүдәләнде.

тәшлек итәргә чакырып һәм аның сатирик рәсемнәрен пропагандалап язып чыга: «Шәһит әфәнденең рәсем сәнгате белән шөгыльләнүе һәм үзебезнең милли татар тормышына караган төрле рәсемнәр ясавы билгеле. Без Шәһит әфәндене беренче гүзәл уңышлары белән котлыйбыз һәм киләчәктә дә аның бу эшкә күп хезмәт куячагына ышанабыз»,— ди. Журнал укучыларына аның берничә көлке рәсемен дә тәкъдим итә. Ш.Гайфинең бер рәсемендә Муса Бигиевнең «Рәхмәте илаһия гомуми» дигән китабы турында шау-шудан көленә.

Кулына мунча себеркесе, комган, сөлге, галошлар тоткан бер изге мөселман, әлеге китапта язылганча, Алла мөселманнарга һәм мөселман булмаганнарга да бертигез карагач, оҗмахка руслар да кереп тулса, бу әйберләремне кая куярмын, дип борчыла. Икенче рәсеме исә Тукайның «Бер шәехнең мөнәҗәте» дигән шигыренә иллюстрация.

*«Ялт-йолт», 25 нче сан.*

**23 июль.** Жандармерия подполковнигы Databы Добродеев тәрҗемәче ярдәмендә Әхмәдуллиннан алынган китапларны тикшерә. Һәм берничә китаптагы, шул исәптән «Габдулла Тукаев шигырьләре»н дә аерым тенденциоз урыннарны тәрҗемә итеп, эчтәлектәге сәяси юнәлешләрне билгеләү өчен «жандармерия идарәсе»нең начальнигы аша Казан Матбугат комитетының (цензурасының) председателенә җибәрү турында отношение яза. Шулай итеп, 1908 елда жандармерия агенты «Персий»ның доносыннан соң, сүрелеп торган «эш» яңадан калкып чыга.

*ТРМА. 199-ф., 2-тасв., 1237-эш;*
*Нафигов Р. Тайны..., с.186.*

**Җәй.** Шәехзадә Бабич «Габдулла әфәнде Тукаев» исемле шигырен яза:

Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь Габдулладай,
Ул караңгы төндә яктырган матур, ак тулган ай.

Ул бөек, нечкә хис тәкъризләргә бик бай, диям,
Бар урыннардан аның урынын кадерле, дәү, диям.

Бакыр эчендә көмешләр ялтырап яткан кебек,
Ап-ачык, ап-ак булыр тик ак күңел аккан кебек.

Күп китапларның арасында китаплары —
Ап-ачык нурлар чәчәр, күренеп тора һәр яклары.

Алса, укыса халык шигърен аның, истә кала,
Һәм аның шигъре халыкның күңеленә зур хис сала.

---

Т ә к ъ р и з — мактау, югары бәяләү.

Галидер Габдулланың хәзер Казанда мәскәне,
Ул уяткыч, ул юаткыч, ул терелткеч хәстәне.

Билгеле, безнең ма биһилифтихар ул, мөхтәрәм,
Зур шагыйрь, мәшһүр шагыйрь бар бездә дә, дип шатланам.

Тәсбих вә тәһлил итеп җырлап йөримен җырларын,
Җырлаганда нечкәрә күңелем, эри һәр җирләрем.

*1911.*

*Искужин З. Тукай турында Бабич. «СӘ», 1936, 7 нче сан, 67—68 б.*

**Август.** «Болгар» номерларының 40 нчы бүлмәсендә шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй белән очраша. Августта Сүнчәләй Казанга килгәч, ай буе алар еш күрешәләр, сөйләшәләр, күп вакытларын икәү бергә үткәрәләр. Кайбер көннәрне Сәгыйть шагыйрьнең бүлмәсендә кунып та кала. «Төннәрдә күбесенчә сөйләшми-лыкылдамый утыра идек. Тик утыра идек. «Сөйләшмик,— ди торган иде йә җырлый иде»,— ди истәлегендә С.Сүнчәләй.

*«Замандашлары», 128 б.*

**1 август.** «Яшен ташлары» исемле китабы (Беренче җөзьә. Авторы: Шүрәле. Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы. 23 б. 3000 данә) басылып чыга. Китап авторның кереш сүзе белән ачыла. Биредә әлеге җыентыкны дөньяга чыгаруның тарихын һәм ни өчен шушы исем белән атавын бәян итә:

«Мәйдандадыр ки олуг мөхәррирләремездән Фатыйх Кәримов иң элек аннан-моннан җыеп «Аннан-моннан» атлы мәҗмуга чыгарды.

Аннан соң Гаяз әл-Исхакый җәнабләре дә төрле урыннарда чәчелеп яткан язуларын бер җиргә җыеп, «Җыентык» исемендә җыйнак кына бер китап таратты.

Болардан соң Фатыйх әфәнде Әмирхан җәнабләре үзенең вак-төяк тәхриратеннән җыеп, «Вак-төяк» исемле әсәр бастыра.

Бәс, боларны күргәч, минем дә төрле урында чәчелеп яткан «чүп-чарым» исемә төште. Мәзкүр өч мөхәррир кеби минем дә шул чүп-чарны бер почмакка өясем килде.

Китабымның исемен үземә махсус бер фикер белән «Башыңдагы чабата» дип куймакчы булган идем дә, «Матбугат клауыны» диярләр, дип шүрләдем.

Шул сәбәпле инде туктаган «Яшен» журналы хатирәсе өчен... «Яшен ташлары» дип атарга карар бирдем.

*«Шүрәле».*

---

Мәскән — яши торган җир.
Ма биһилифтихар — мактаныч, горурлык.
Мәзкүр — алда әйтелгән.

Егерме өч биттән торган бу китапның эчтәлеге түбәндәге әсәрләрдән гыйбарәт: «Керешү хотбәсе», «Авыл җырлары», «Ачы хакыйкать», «Төрлечә дөнья тану», «Гашыйк уты», «Матбугат каһарманнары», «Милләтче», «Ахыр күрешүләр», «Актык сүзләр». Болардан «Ачы хакыйкать» исемлесе 1909 елгы «Яшен»дә (10 нчы сан) «Ачы хакыйкатьләр» дигән гомуми баш астында «Татар бае» дип, «Гашыйк уты» 1910 елгы «Ялт-йолт»та (8 нче сан) «Нечкә хиссият» дип басылган була. Китапның соңгы битендә «Икенче җөзьэ тиздән нәшер ителәчәк» дигән белдерү бар.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

**15 август.** «Ялт-йолт» журналының 26 нчы саны дөнья күрә. Биредә шагыйрьнең «Шүрәле» имзасы белән «Өч баш» исемле мәкаләсе, «Гакыллылар фәлсәфәсе» дигән шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Русчадан дөрест тәрҗемәләр» дигән мәкаләсе һәм «Төрекчәдән» («Эзләдем, филлаһ...») икеюллык шигыре урын алган.

*«Ялт-йолт», 26 нчы сан.*

**30 август.** «Вакыт» газетасы: «Шагыйре мәшһүр Габдулла әфәнде Тукаевның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» — иң мәшһүр әдипләремезнең әгъла әсәрләреннән җыелып язылмыш кыйммәтле китабы чыккач ук Казан мәдрәсәләренә милли әдәбият өчен дәрес китабы итеп кабул ителде»,— дип хәбәр итә.

*«Вакыт», 835 нче сан.*

**1 сентябрь.** «Хатыннарның русча, татарча кушаматлары» исемле парчасы «Салам-Торхан» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 27 нче сан.*

«Читен хәл» шигыре басыла.

*«Шура», 17 нче сан.*

**6 сентябрь.** «Кадер кич» шигыре дөнья күрә.

*«Вакыт», 839 нчы сан.*

Бу шигырьнең язылу тарихы турында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Мансур Мозаффаров түбәндәгечә яза: «Бервакыт әнием* Тукайдан: «Менә Кадер

---

Филлаһ — Алла белән ант итәм дигән сүз.
*Мөгаллимә, шагыйрә Маһруй Мозаффария.

кич җитә, балаларга җырлар өчен бер шигырь булмасмы синдә, Габдулла?» — дип сорады. Тукай берничә көннән безгә «Бу Кадер кич елда бер кич» дип башлана торган шигырен үз кулы белән язып, чәчәк ябыштырылган открытка китерде».

Бу ел Кадер киче 9 сентябрьдә була.

*«Азат хатын», 1988, 4 нче сан.*

**11 сентябрь.** «Ялт-йолт» журналының 27 нче саны дөнья күрә. Биредә «Иблиснең гайде фитыр тантанасы» («Рамазан гаетендә Иблиснең шәйтаннарына хитабы») шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

Бу шигырьдә кайбер кешеләрнең бик динле булып күренеп тә, азып-тузып йөрүләренә шәйтан гаепле, дип, үзләренең гаебен шәйтанга сылтауларыннан көленә.

Журналның соңгы битендә рәсеме дә бирелә: бер көтү мөгезле җеннәр бииләр, берсе гармунда уйный.

Бу ел 11 сентябрь Ураза гаете көне булганга, күрәсең, журналның тышлыгында ук Г.Тукай һәм Ә.Урманчиев исеменнән җәмәгатьчелекне Гает бәйрәме белән котлау тексты урнаштырылган:

«Барча кардәш-ыруг, дуст-иш, таныш-белешләрне, мөхтәрәм укучыларымызны, җиде ятларны, дошман вә эче пошканнарны, таныш вә белеш түгелләрне, вә укымаучыларымызны — барысын, берсен дә калдырмыйча, Гайде сәгыйд фитыр илә тәбрик итәмез».

Әхмәт Урманчиев, Габдулла Тукаев.

*«Ялт-йолт», 27 нче сан.*

**6, 11 сентябрь.** Ф.Агиевның «Әдәбият мәсьәләләре» цикленнан «Көндезге сәхәр» дигән мәкаләсе басылган. Ф.Әмирханның шул исемдәге китабына рецензия. Ике санда да эпиграф итеп Тукайның:

Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан
Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан, —

дигән юллары алынган.

*«Идел», 384, 385 нче саннар.*

**15 сентябрь.** «Сайфия» шигыре басылып чыга. Шагыйрьнең Идел буйлап пароход белән Әстерханга сәяхәте вакытында күргәннәрнең тәэсире белән язылган тирән реалистик шигырьләреннән берсе.

*«Шура», 18 нче сан.*

Шигырь башыннан ахырына кадәр социаль контрастларга корылган. Бер яктан анда Идел буендагы мохтаҗлыктан интеккән авыл күренешләре тасвирланса, икенче яктан авыл мужикларының җимерек йортлары янәшәсендә үк оҗмахны хәтерләткән мәһабәт дачалар һәм пароход яллап шунда ашыгучы бай образы пәйда була. Автор бәяләмәсе вазифасын үтәгән дүртенче бәеттә ачлар белән туклар дөньясы арасындагы социаль тигезсезлек мәсьәләсе сыйнфый каршылыклар дәрәҗәсенә күтәрелә һәм байлык хуҗаларына халык тарафыннан әйтелгән каргыш сыман гомумиләштерелә:

Бай киенгән франт-шикларча халык тиресе белән,
Батсачы шунда үзе һәм аләте нәкълиясе.

Шигырьдә иҗтимагый гаделсезлекләргә автор исеменнән бәя бирелә.

*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 38—39 б.*

«Мияубикә» шигыренә карата «Сәгъде Вәкъкас» имзасы белән Сәгыйть Сүнчәләйнең рецензиясе басылып чыга. Әсәргә, гомумән, уңай бәя бирелә.

Автор фикеренчә, «Мияубикә»нең җитешмәгән урыннары булса, сәҗгы-рифмаларның ямьле оеша алмаулары өстән-өстәнлектер. Мәсәлән: «нәрсәсен — нәрсә өчен», «кәгазь — эшләмәс», «нәрсәгә — мәсьәлә», «куркаклар — фәркы бар», «тиз энкәмә — зинһар, тимә» вә башкалар.

*«Шура», 18 нче сан.*

**29 сентябрь.** Көннәрнең суытуыннан, «Болгар» кунакханәсенең номеры ягылмавыннан һәм шуның аркасында авыруы көчәеп китүеннән зарлана: «Мин быел 29 сентябрьдән ук салкынлыктан зарлана башладым. ...Миңа шул якмый торган арада бизгәкнең шәбе эләккән. Бинаән галәйһи мин, җылылыкфәлән сизмичә, көне-төне туңуда идем». Бу турыда «Мич башы кыйссасы»ннан укып беләбез.

*«Ялт-йолт», 1912, 32 нче сан.*

**3 октябрь.** Ф.Әмирхан, Ризван Алушига (1883—1938) язган хатында, Тукай исеменең халык арасында киң таралганлыгына, наширләр каршындагы авторитетына, халык аны һәм аның әсәрләрен яратуына ишарә итеп, болай яза: «...көтепханәләр* имзасына карап бастыралар. Мәсәлән, шул синең язган «Тәр-

---

Аләте нәкълиясе — транспорт чарасы; биредә: пароход.
Сәҗгы-рифмалар — актык сүзләр.

җемәи хәлең» өстенә (...) Тукай имзасын куйсаң, һәрбер китапчы с удовольствием бастырыр иде... чөнки халык күбрәк вакытта әсәрне имзасына карап ала икән».

*Мирасханә. 16-ф., 3-тасв., 1-эш;*
*Әмирхан Ф. «Әсәрләр», 4 томда, 4 т., 1986, 291 б.*

**12 октябрь.** «Ялт-йолт» журналының 28 нче саны дөнья күрә. Биредә шагыйрьнең «Шүрәле» имзасы белән «Поезд барган көйгә», «Тәүбә вә истигъфар» («Пушкиннән үзгәртелде» дип куелган. Әсәр А.С.Пушкинның «Десятая заповедь» исемле шигыреннән файдаланып язылган) шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Өйләнгәнче, өйләнгәч» шигыре, «Ялт-йолт» идарәсеннән сөальләр» исемле мәкаләсе кергән. Шулай ук октябрь башларында кабынып киткән Италия-Төркия сугышы мөнәсәбәте белән язылган «Тәмсил» исемле шигыре имзасыз басылган. Эчтәлегендә сугышка этәргән төп көчләрнең берсен — Германия империализмын — Арыслан, иярчене Австро-Венгрияне — Юлбарыс, Италияне — Мәче образында алып, аларның ачкүзлелеген, капитал хакына берни белән дә исәпләшмәүләрен һәм алар арасындагы мөнәсәбәтне оста итеп сурәтли:

Дус кушылдылар Арыслан белән беркөн Юлбарыс,
Бер киңәштә эшләнергә булды эшләнгән бар эш.
Шул заманны әллә кайдан килде чыкты бер Мәче,
Каршылыйлар: «Әйдә, безгә иттифакка кер, Мәче!»
Булса да сүзләр береккән, бу өчәү айрым яши,
Һәрбере үз тапканын айрым ятып, айрым ашый.
Юлбарыс күрсә ишәк-куйны, тизүк ертып ала;
Мөттәфыйк безнең Мәче, тик күзләрен йөртеп кала.
Ат-сыер күрсә, Арыслан иткә тиз әйләндерә:
Тик бәхетсез безнең Мәче күзләрен майландыра.
Аңлый алмый бу Мәче һич, ач үләр хәлләр килә;
«Иттифак туклыклымы?» — дип, дустлары аннан көлә.
Зар җылый безнең Мәче: «Сез туйдыгыз,— ди,— мин ач ич!
Нигә тик мин ач калырга, мин Великий держав ич!»

Тукайның империалистик илләр арасындагы намуссыз, гаделсез һәм икейөзле мөнәсәбәтләрне калкытып куеп, колониаль сәясәтне тәнкыйть иткән үткен мәсәле бу.

*«Ялт-йолт», 28 нче сан.*

---

* Биредә: нәшриятлар мәгънәсендә.
Тәмсил — мәсәл.
Иттифакка — союзга.
Мөттәфыйк — союзник.

**12 октябрь.** «Толстой фикере» исемле шигыре имзасыз басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 28 нче сан.*

Шигырьдә Тукайның хатын-кызга карата Толстой карашларын уртаклашуы күзгә ташлана. Толстой хатын-кызларны ирләрнең эшчәнлегенә зыян китерә дип уйлаган. Хатын-кызның кияүгә чыгуын да ул әхлакый азатлыкка богау киертү дип санаган.

Тукайның Л.Н.Толстой әсәрләре белән Уральскида чакта ук танышуы, аларны кызыксынып укуы мәгълүм. Толстойның дусты һәм биографы В.Г.Чертков, П.И.Бирюков рус журналларында һәм биографик хезмәтләрендә аерым өзекләр бастырганнар. Толстой үзе боларны бастырып чыгару «халык өчен файдалы булуы мөмкин» дип исәпләгән. Ышанып әйтергә мөмкин: көндәлектә басылган өзекләрне Тукай укып барган. Гомеренең соңгы айларында түшәккә яткач язылган «Толстой сүзләре» циклыннан өч шигырендә шагыйрь үз карашларының Толстойның гуманистик идеяләренә туры килгәнлеген раслый. Толстой көндәлегендә, мәсәлән, мондый кагыйдә бар: «Беренче кагыйдә: Хатын-кыздан ерак тор». Шуңа нигезләнеп Тукайның «Толстой фикере» шигыре язылa:

Әле мөмкин икән иркенне тоткынлыкка сатмаска,
Жаның көчсезлеген һич тә бу дөньяга сынатмаска, —
Өйләнмә, баш имә һич, телгә дә алма хатын-кыз, дип;
Олуг җан бул, куан-шатлан, шөкер, мин бит хатынсыз, дип.

Тукай фикеренчә, өйләнү — күрәләтә торып үзеңне төрмәгә ябу, иркеңнән мәхрүм булу, җаныңның көчсезлеген күрсәтү, тигез урында абынып егылу:

Өйләнмәк бер-берәүнең җәбере-каһре өсткә менмичә,—
Егылмак берлә бердер, һичбер әйбергә абынмыйча.

Иҗатында толстойчылык мотивлары булу — әле Тукай тулысы белән суфый булган дигән сүз түгел. Ул да мәхәббәт утында яна, сөеклесе Зәйтүнәне ярату хисләрен җанында бикләп яши, тышка чыгарырга теләми. Тукайның хатын-кызга карата толстойчылыгы милләтенә олы мәхәббәт, аның мәдәниятен, әдәбиятын үстерү һәм аңа фидакарьләрчә хезмәт итү турындагы уй-фикерләре белән тыгыз бәйләнгән.

*Мәһдиев М. Шагыйрьнең зур бер остазы. «Социалистик Татарстан», 1986, 17 октябрь; Магдеев М. Тукай и Толстой. «Научный Татарстан», 1992, № 4, с.64—66; Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 40—41 б.*

**20 октябрь.** Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. Бу хаттан Тукайның җитди авыруы аңлашыла. Шулай ук аның Парижда 1908 елда ук чыга башлаган «Мусульманин» журналына Оренбургтан торып язышкан шагыйрь һәм журналист Мирсәяф Кырымбаев белән очрашканлыгы да ачыклана. Шушы елның апрель аенда Петербургта чыга башлаган «В мире мусульманства» газетасын да ул кызыксынып, хәтта язышырга да исәп тотып укып бара. Ләкин әлеге органнарның төп идеяләре аны сагаерга мәҗбүр итә. «Мусульманин»ның нашире һәм редакторы М.Хаҗи-Теләши һәм «В мире мусульманства»ның редакторы А.Г.Датиевлар турында ул Сүнчәләйнең дә фикерен беләсе килеп: «Син аларны кемнәр дип таныйсың? М. ул кавказлыларга алданып йөрмиме икән?» — дип яза.

*Мирасханә. 9-ф., 2-тасв., 8-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 107—108 б.*

**29 октябрь.** Бу вакытта «Болгар» кунакханәсендә яши, инде көннәр бик суык булуга да карамастан, номерлар җылытылмый. Шагыйрь суыклыктан зарланып бәет яза. «Мин быел 29 сентябрьдән үк салкынлыктан зарлана башладым. Шуннан бирле икәнлеге язып ташлаган бер бәетемнең түбәндәге тарихыннан беленде»,— дип күрсәтә:

Номер салкын, якмыйлар бит, арка туңа,
Иртә берлән, киям дисәң, яка туңа;
Авыр да соң иртә белән тышка чыгу,
Чыкмый хәл юк, чыгасың шул ката-туңа.
Җәйләр үтте, җиттек инде октябрьгә,
Җылылык юк җирдә һәм дә күктә бер дә.
Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер, ди,
Миһманнарның якмаучыга үпкә бергә.
Хөкем итмим, Ходай кыйлыр үзе судын,
Кайгырмый бай, күтәргән дә ята ботын;
Акчам янга калыр, ди ул, якмый торсам,
Барыбер бит җәһәннәмгә үзе утын.

*Туңучы.*

Бу вакытларда авыруы җитди төс ала. Бу турыда үзе үк яза: «Миңа шул якмый торган арада бизгәкнең шәбе эләккән. Бизгәк... көтелгән кунак шикелле миңа рәхим итеп, тәнемдә күпме тамыр бар исә, һәммәсен селкетеп, мине хәрәкәттәге поезд шикелле итә иде...» Бизгәктән туңу һәм дерелдәү белән шактый интеккәч, бер иптәше аңа аспирин эчәргә тәкъдим итә. Бизгәк башлану белән аспирин эчә башлый, ләкин авыруы үтми, киресенчә, арта гына бара. Докторларга күренергә теләмичә, шул рәвешле декабрь урталарынача «Болгар» номерында кала.

*«Мич башы кыйссасы» («Баштан үткән бер эш»).*
*«Ялт-йолт», 1912, 32 нче сан.*

**3 ноябрь.** Матбугатта Тукайның каты авыруы хакында хәбәр бирелә.

*«Вакыт», 1065 нче сан.*

**7 ноябрь.** Балкандагы Италия-Төркия сугышлары мөнәсәбәте белән 1911 елда («Ялт-йолт», 12 октябрь) язылган «Тәмсил» дигән шигыре яңадан басыла.

*«Вакыт», 1067 нче сан.*

**8 ноябрь.** «Вакыт» газетасы Казанда «Сабах» көтепханәсе тарафыннан «Балалар күңеле» исемле айлык әдәби журнал чыгарылачагын, редакторы Г.Тукай булачагын хәбәр итә. Журналда балалар өчен әдәби әсәрләрдән үрнәкләр бирү, тәрбия һәм укыту мәсьәләләрен тикшерү планлаштырыла, танылган язучылар катнашачагы әйтелә. Ләкин властьлар Тукайның бу теләгенә каршы төшәләр, журнал чыкмый кала.

*«Вакыт», 872 нче сан;*
*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986, 172 б.*

**13 ноябрь.** «Көзге җилләр» шигырен яза. Шигырь 1910—1911 елларда Урта Иделдә хөкем сөргән ачлык фаҗигаләре тәэсире белән язылган.

*«Йолдыз», 758 нче сан.*

**15 ноябрь.** Шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләйгә хат яза. «Бер кешенең гәзитәдә: «Хөррият! Инсаният! Исламият!» — дип кычкыруы аның рухын аңларга җитмәгәнлеге сиңа билгеле инде...

Казанга килгәч, бөтен милләтчеләрне күреп, хәлләрен аңладым. Мәгаттәәссеф, алар минем колагыма: «Синең шигырьләр халыкка үтә, фәлән хакка гына саткансың икән, без фәләнне биргән булыр идек»,— кеби ач күзле сүзләре илә мине мыскыллый башладылар. «Киләчәкне тәэмин итәргә кирәк-фәлән»,— дип лыгырдадылар. Миңа, һәрвакыт милләт вә миллият фикере белән рухланып, илһамланып торган шагыйрьгә, табигый, ул сүзләр тәхкыйрь иде. Мин ни эшлим аларның киләчәкләре белән? Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора. Миңа хәзерге вакыт кадерле... алар миңа тынычлык бирмәделәр: «Син бу язганыңны безгә бир, фәлән нашир сиңа аз биргән, ул вөҗдансыз». Менә шулар мине тәмам ваксыттылар, изделәр...» дигән юлларда Тукайның җәмгыять тормышында, әдәби иҗатта үз урынын ни дәрәҗәдә аңлавы ачык күренә.

*«СӘ», 1960, 4 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 109—110 б.*

---

Мәгаттәәссеф — кызганычка каршы.
Тәхкыйрь — хурлау.

**18 ноябрь.** «Ялт-йолт»ның 29 нчы саны дөнья күрә. Биредә «Сәгъде Вәкъкас әфәндегә» исемле мәкаләсе басылган. Ул «Мияубикә» шигыренә карата «Шура» журналының 18 нче санында С.Сүнчәләй язган рецензиягә җавап итеп язылган.

Биредә ул төгәл һәм шома рифмаларга караганда якынча рифмаларның кулайрак булуын исбатлау өчен, Лермонтовтан, төрек һәм гарәп шагыйрьләреннән һәм С.Рәмиевтән мисаллар китереп, тапкыр комментарийлар бирә дә аңа гына хас юмор белән болай ди: «...һичбер шагыйрь шигыренең бер юлы ахырын «такмак» дип язгач та, каләмен колагына кыстырып, мич арасыннан кыштыр-кыштыр «шакмак» эзләп йөрергә мәҗбүр түгелдер».

Журналның әлеге санына «Гарәпчә яңа масдарлар» дигән мәкаләсе һәм имзасыз рәвештә «Татарча сарыф, нәхү язучыларга ихтар» мәкаләсе урнаштырылган.

*«Ялт-йолт», 29 нчы сан.*

**18 ноябрь.** «Көзге җилләр» шигыре басылып чыга. Шигырь иҗтимагый темага язылган. Эпиграф итеп рус шагыйре А.Майковның «Из Апполодара гностика» шигыреннән өзек китерелгән:

Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен;
Ядыма Тәңрем төшә, бәхтем кара булган саен.

Шигырь Тукайның Идел буйлап сәяхәте вакытында 1911 елгы корылыкның халыкка алып килгән фаҗигаләрен күрү тәэсире белән Корбан гаете бәйрәме алдыннан язылган. Табигатьнең рәхимсезлегеннән туган хәвеф сыйнфый яссылыкка күчерелә. Ачлык кебек иҗтимагый-социаль яңгырашлы үтә авыр теманы табигать күренешләре белән янәшә куеп гәүдәләндерелгән бу шигырьдә халыкның авыр язмышы өчен борчылу, сыкрау, елау авазлары илаһият биеклекләренә дә, Җир шары киңлекләренә дә тарала:

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.
— Иң сөекле эшче әуладым бу ел ач калды,— дип,
Изге, шәфкатьле анабыз — мәрхәмәтле җир җылый...

Шигырьдә төнге хәбәрче вазифасын үтәүче җилләр белән бергә ил елый, хәтта кешеләрнең җанын кыеп йөрергә күнеккән Газраил фәрештә дә елый.

*«Йолдыз», 758 нче сан;*
*Халит Г. Тукай үткән юл, 1976, 120—121 б.;*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 41—42 б.*

---

Ә ү л а д — балалар.

**23 ноябрь.** «Балалар күңеле» исемле китабының икенче басмасы (Казан, «Сабах» көтепханәсе, беренче кыйсем, 2 нче табгы) чыга.

Беренче басмадан аермасы: «Кадер кич» шигыре өстәлгән.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

Тукайның рус телен яхшы белүен, талантлы тәрҗемәче булуын һәм бу өлкәдә әзерлекле булуын шушы китап уңае белән Г.Ибраһимов та мактап телгә ала: «Тукай, гомумән, яхшы тәрҗемәче. Ул сайлый да белә. Мәфһүмне дә җанлы вә әдәби рәвештә күчерә ала... «Балалар күңеле»ндәге Пушкин вә Лермонтовтан тәрҗемә кылынган мәхәббәт шигырьләре үз оригиналларының күбесеннән матур вә самимирәктер».

*Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре, 1913, 81 б.*

**26 ноябрь.** Казан Эчке эшләр министрлыгының матбугат эшләре комитеты, «Габдулла Тукаев шигырьләре»н (4 нче дәфтәр, 1909) тәрҗемәсе белән бергә теркәп, Казан Суд палатасына рәсми кәгазь (отношение) җибәрә. Комитет анда аерым шигырьләрдә җинаять билгеләре табылуын һәм китапка арест салынуын хәбәр итә. Суд палатасыннан арестны раславын, җыентыкның авторын хөкемгә тартуын үтенә.

Отношениедә түбәндәге сүзләр бар: «Иҗтимагый төзелешнең нәкъ менә шул якларын (кимчелекләрен.— *И.Н.*) гына күреп, аның бүтән якларына игътибар итмәү ул төзелешкә карата нәфрәт кузгатырга тырышу максатыннан килә...»

«Бу шигырьдә («Хөррият хакында».— *И.Н.*) комитет илдәге иҗтимагый төзелешне җимерергә чакыру күрә».

«Бу шигырьдә («Тавыш» хакында».— *И.Н.*) эшчеләрне турыдан-туры көрәшкә чакыру булганлыктан, комитет анда җәза бирү положениесенең 129 нчы статьясының 6 нчы пунктында каралган җинаять билгеләрен таба».

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 179-эш;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 249 б.;*
*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986, с.171.*

**28 ноябрь.** Казан Матбугат эшләре комитеты Петербургтагы Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә «Габдулла Тукаев шигырьләре»нә (3 нче дәфтәр, 1907) арест салу һәм авторын хөкемгә тарту турындагы фикерен һәм Казан Суд палатасына киткән отношениесенең күчермәсен җибәрә.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 183-эш;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 249 б.*

**Ноябрь — 1912 елның апреле.** Цензура комитетының Тукайны эзәрлекләве дәвам итә.

*ПУДТА. 776-ф., 21-тасв., 260-эш;*
*Нафигов Р. Габдулла Тукай биографиясе. «КУ», 1966, 8 нче сан.*

Авыруы җитдиләнә, күбесенчә урын өстендә ята. Тукайның авыруы һәм, гомумән, аның хәле турында «Вакыт»та басылып килгән белдерүләргә таянып, Петербургта рус телендә чыккан «В мире мусульманства» газетасы 9 декабрь санында шагыйрьнең хәле турында: «Авыру Тукай бернинди караусыз һәм тәрбиясез «Болгар» номерларында ята»,— дип хәбәр бирә.

*Нафигов Р. Тукай и его окружение, 1986, с.182.*

Тукайны күреп белгән Фоат Саллави истәлегеннән аның белән даими рәвештә аралашып, авырганда хәлен белеп килеп йөргән дусларын, аны хөрмәт иткән даирәне күрәбез: «Без «Болгар»дагы Тукай абый яшәгән бүлмәнең каршысындагы номерда тора идек. Габдулла абый инде ул вакытта бик авыру иде. Минем әнием... һәрвакыт Тукайның хәлен белешеп тора иде. Еш кына Тукай янына олы гәүдәле, гөрләп торган көчле тавышлы Габдулла абый Кариев, Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Гөлсем Болгарская, Хөсәен Ямашев белән Хәдичә апа, китап нашире Шиһап Әхмәров белән хатыны Әминә Әхмәрова, ...Закирә апа белән ире журналист Борһан Шәрәф, нашир Гыйльметдин Шәрәф белән хатыны Рәхимә апа киләләр иде. Тукайның хәлен белешергә татар кызларыннан беренче булып гимназия тәмамлаган апалы-сеңелле Әминә, Мәдинә Терегулова һәм Габитовлар да киләләр иде. Гөлсем Камалова, Гайшә Богданова, Зәйнәп Хәсәни, Әминә Мөхетдинова, Заһирә Әхмәрова, татар кызларыннан беренче булып югары белем алган Мәрьям Акимбетова һәм соңыннан граждannар сугышында беренче татар бригадасы составында Урта Азиядә басмачыларга каршы сугышларда катнашкан һәм икесе дә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән апалы-сеңелле Мәрьям белән Гайшә Саиновалар (Мулланур Вахитовның туганнан туган сеңелләре) — болар барысы да Тукайны олылаучы, килеп даими рәвештә аның хәлен белешеп торучылар иде».

*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 63 б.*

**16 декабрь.** Казан Суд палатасыннан Казан Матбугат эшләре комитетына рәсми кәгазь җибәрелә. Анда Суд палатасының 26 ноябрьдә комитет җибәргән отношениедәге фикер белән килешмәве, «Габдулла Тукаев шигырьләре»ндә (4 нче дәфтәр, 1909) җинаять билгеләре юк дип санавы һәм китапка арестны расламавы әйтелә.

Шулай итеп, прогрессив кешеләрнең тырышлыгы белән, 1908 елдан бирле гаепләү акты булып килгән «эш» туктатугаирешелә.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 179-эш;*
*«КУ», 1986, 4 нче сан, 27 б.*

**18 декабрь.** Казан Суд палатасы Петербургтагы Матбугат эшләре буенча Баш идарәгә үзенең «Габдулла Тукай шигырьләре»нә (4 нче дәфтәр, 1909) арестны расламау турында 16 декабрьдәге карарын җибәрә.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв., 179-эш;*
*«КУ», 1986, 4 нче сан, 27 б.*

**Декабрь урталары.** Үпкә авыруы тагын да көчәя, шуның өстенә бизгәк тә аның сәламәтлеген соңгы чиккә җиткереп какшата. Тукай өчен газаплы, эчпошыргыч көннәр бер-берсенә ялгана. Кичтән, түшәгенә яткач, ул туңудан калтырана, төннәрен шау тиргә батып уяна, бүлмә бөркүләнгән төсле тоела. Коридорда туктаусыз шапылдау, кычкырып сөйләшү авазлары тынмый, кайчак аның ишеген шакырга тотыналар...

Ул туйдырып бетергән «Болгар» кунакханәсен алыштырырга уйлый.

Әлбәттә, иптәшләре дә аның сәламәтлеге өчен кайгырып, борчылып торалар. Вафа Бәхтияров белән Галиәсгар Камал аңа «Свет» кунакханәсеннән* бер бүлмә карыйлар. Тукай күчәргә риза була, бүлмә аңа ошый: «Бу номер әүвәлге номерым кадәр өч бар. Идәне паркет, түшәме биек. Киң тәрәзәсе кояшлы якка карый».

Тукай «Свет» кунакханәсенә күчеп тора башлый. Ләкин анда бик суык була. Ул яңадан өшеп, калтырап төннәрен үткәрә: «Андагы сырость, ...монда бөтенләй зәмһәрир. Бу көн аралаш бөтенләй ягылмый».

Әле кайнар чәй, әле аспирин эчүнең дә файдасы күренми. Ул, монда калырга ярамый, дигән фикергә килә. Җитмәсә тагын Бәхтияров аңа берничә ел элек чыккан китабы белән жандармнарның кызыксынуын хәбәр итә. Һәм Тукай Өчиледәге абыйсына кайтып торырга карар итә. «Наплевать на все»,— дидем дә, беркөнне ямщик ялладым да авылга киттем...» — дип яза үзе бу турыда.

*Мич башы кыйссасы. «Ялт-йолт», 1912, 32 нче сан;*
*Вәлиев Р. Дөнья гаме. «КУ», 1986, 4 нче сан, 94 б.*

---

* Казанның хәзерге Чернышевский урамындагы йортта урнашкан була.

**Декабрь урталары — 1912 елның март башына кадәр.** Авыруы көчәеп, хәле бик авырлашу сәбәпле, Тукай әнисе Мәмдүдәнең туган авылы Өчилегә (Татарстанның Арча районына керә) үги әбисе Латыйфә белән бабасы Зиннәтулла улы Кәшфелкәбир Әмиров (1885—1938) йортына кайта. Биредә ул кышны үткәрә һәм ял итә.

Истәлекләрдән күренгәнчә, К.Әмиров һәм аның хатыны Рабига каты авыру* Тукайны яхшы каршы алалар. Үзләре яшәгән өйдән тыш, аларның кышын ягылмый торган кечкенә генә өйләре булган. Тиздән хуҗалар аны җылытып, Тукайны шунда (кечкенә генә, нараттан салган, сандык шикелле җыйнак, матур бер өй) урнаштыралар. Ул көненә ике мәртәбә ягыла, һавасы да Тукайга бик хуш килә. Җиңгәсе исә һәр көн үрдәк шулпасы пешереп кертә, алдында һәрчак җылы сөт. «Монда бер 15 көн эчендә 29 сентябрьдән бирле күргән салкын михнәтләре һәм юлда килгәндәге адашулар, туңулар — барысы да онытылды»,— дип яза ул бу турыда «Мич башы кыйссасы»нда. Туганнарыннан, үзен тикшерәләр дип уйлап, өйгә килгән кешеләргә аның кайтуын белгертмәскә үтенгән Тукай. Бераздан, хәле әйбәтләнә төшкәч, урамга чыгып йөри башлый, авыл мәктәбенә барып, балаларның сабак укуын күзәтә, ә төн утырып иҗат эше белән шөгыльләнә. «Җан азыклары» җыентыгына керәчәк шигырьләрнең күпчелеген, юл очеркларын ул шушы айларда яза. «Ялт-йолт» журналына әсәрләрен җибәреп тора, дуслары, танышлары белән хатлар алыша.

*«Ялт-йолт», 1912, 32 нче сан;*
*Әмирова-Мөхәммәтҗанова Р. Тукай Өчиле авылында. «Истәлекләр», 160—162 б.;*
*Рәсулева З. Тукай эзләреннән. Казан, 1985, 59 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 34 б.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 253 б.*

## 1912

**1 гыйнвар.** «Былтырның хисабы» исемле фельетоны «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Еллык отчет рәвешендә язылган бу фельетонда: «Былтыр Петербургта «В мире мусульманства» дигән әллә нинди рус исемендә бер чын мөселман пәйда булды. Ул әлләниләр эшли... Багана-багана хәдисләр дәреҗ итә. Мусульманин, ди, панисламизм, ди, единоверцы,

* Әмирова-Мөхәммәтҗанова Р.: «Чанадан үзе төшә алмады, ирем белән без култыклап төшереп, күтәреп өйгә алып кердек»,— ди.

ди. Әлхасыйль, бигрәк җете кызыл мөэмин булып кылана. Мөселманнар: «Ай-һай, тиз узмаса ярар иде»,— дип, шиктә торалар»,— дип яза шагыйрь.

Үзен «политик» дип атаган Тукайның сизгерлегенә гаҗәпләнми мөмкин түгел: шагыйрь үлеп, ике-өч ел да үтми, М.Хаҗи-Теләшинең провокатор һәм авантюрист булганлыгы фаш ителә.

Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» комедиясе, иҗтимагый сатирик комедия буларак, чынбарлыкны күрсәтүдә тоткан ролен, Казан мещаннарын, либераль сәүдәгәрләр тормышын һәм аларның җәмәгатьчелек оешмаларын реалистик гәүдәләндерүче әсәр буларак билгели: «Былтыр Галиәсгар Камал «безнең шәһәрнең серләрен» чит шәһәрләргә сөйләде дә куйды. Элек тә чит шәһәрдә йөргәндә синең яныңа киләләр дә: Казан ничек? Халкы ничек? Андагы «Шәрык» клубы ничек? Фәлән ничек?» — дип йөдәтеп бетерәләр иде. Әлбәттә, эчләреннән Казан вә аның мөтәгалликатына бик мактаулы җавап көтәләр иде.

Менә хәзер аларга — «Безнең шәһәрнең серләре», укысыннар да белсеннәр. Кемнәр барын күрсеннәр».

Моннан тыш тагын камчылы ишан, карагруһчы Мөхәммәтҗан хафиз, Дума депутаты Байбурин, «Новое время» исемле карагруһ газетасы редакторы Меньшиков, Иран революциясен вәхшиләрчә бастыру кебек тарихи конкрет кешеләр һәм тормыш күренешләре тәнкыйть уты белән көйдерелә.

*«Ялт-йолт», 31 нче сан;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 242 б.;*
*Лаисов Н. Габдулла Тукай, 1985, 68 б.*

Яңа 1912 елны Казан артында Өчиле авылында каршылый.

Өчиледән Казанга «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиевкә хат яза. Үзенең авылдагы тормышыннан ризалыгын, канәгатьлелеген белдерә. Ләкин ул анда ял итеп, дәваланып кына ятмый, туктаусыз эшли, яза. Үзенең яраткан журналы «Ялт-йолт» турында кайгыртудан туктамый: «Ялт-йолт» чыккач, миңа җибәрерсез әле. Русча көлке журналлар җибәрегез. Иншалла, рәсем мәүзугълары вә мәкаләләр җибәрсәм кирәк. Түбәндә адресым булыр. Фатыйхтан, бер дә ялыкмыйча, «Ялт-йолт»ка язгалаштыруын просить ит. Колагын тондырганнан соң гаҗиз калып, бер-ике нәрсә язса да файда. Габди тавышы ахыры ни булып калды? Ул беркөн, бик шәбәеп, «Ялт-йолт»ның соңгы номерын эзләп йөридер иде... Берәр җирдә журналга

---

Мөтәгалликаты — хәлләре.

бәйләнеп, язарга йөрми микән...» — дип сорый һәм киңәшләр бирә. Шунда ук тулы адресын яза, ләкин кем сораса да бирмәгез, дип кисәтеп тә куя, Гыйльметдингә дә шулай яздым, ди.

*«СӘ», 1961, 4 нче сан, 28 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 113 б.*

Өчиледән Казанга «Мәгариф» матбагасының хуҗасы Гыйльметдин Шәрәфкә хат яза. Тукай әсәрләренең шактый өлешен шушы матбагада бастырганга, алар якын мөнәсәбәттә булалар. «Ниһаять, авылга кайтып җиттем. Сандык шикелле кечкенә генә, нараттан салынган ак өй үземнеке. Көненә ике ягылганга, бик җылы, тәмам чишенеп йоклыйм, иртә белән яңа сауган җылы сөт эчәм. Хәзер үк үземдә бераз яхшыру вә хәлләнү сизә башладым. Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм. Эшләр болай барса, бер-ике айдан сихәтләнермен кебек...» — дип, Тукай үзенең хәле турында яза.

*«Мәҗмугаи асарь», 1914, 5 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 111 б.*

**Ел башы.** «Яшен ташлары» исемле китабы (икенче җөзьэ. Авторы: Шүрәле. Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матбагасы) басылып чыга. 24 биттән гыйбарәт бу китапның эчтәлегендә түбәндәге әсәрләр бар: «Борын», «Граммофонда татар җырлары», «Тормыш», «Өйләнү түгел, сөйләнү», «Кайда? Кем?», «Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә», «Гаилә тынычлыгы», «Сөбханалла», «Зур бәшарәт!», «Йокы», «Бер кайгы көнендә», «Тотса мәскәүләр якаң», «Бозау кадәрле зур фәлсәфә», «Төрекчәдән», «Исемнәребез хакында».

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

**10 гыйнвар.** «Идел» газетасында басылган «Тагын Коръән тәрҗемәсе» хосусында» дигән мәкаләдә Садыйк Иманколыйның: «Коръәнне татарчага тәрҗемә итәргә ярамый, чөнки татар теле — тупас тел»,— дигән сүзләре кире кагыла һәм татар теленең нәфислеге, аның мөмкинлекләре конкрет авторлар һәм әсәрләр мисалында раслана: «Татар әдәби теленең гаять матур, нәфис бер тел икәнен исбатлау өчен без үземезнең әдәбиятымызны күрсәтәбез. Мәсәлән, Тукаев әфәнде шигырьләреннән «Васыятем» (әлеге шигырьнең алты юлы кителелә), С.Рәмиев, З.Бигиев, Ф.Кәрими, Г.Исхакый әсәрләрен укып карагыз...»

*«Идел», 417 нче сан.*

**12 гыйнвар.** Өчиле авылыннан Ф.Әмирханга хат яза. Хат үзе сакланмаган, бары тик конверты гына исән. Анда түбәндәге адрес язылган: (заказное)

Казань, Евангелистовская,

Контора Б-р Шарафь

от Абдуллы Тукаева (дер.Малый Верезей* Казанск.губ. и уезда, Ново-Кишитской вол.).

Аста, Фатыйх Әмирханга тиз генә тапшырыгыз, дип язылган.

Конвертка Арча почта бүлегенең печате сугылган. Дата шуннан алып куелды.

*Мирасханә. 9-ф., 2-тасв., 20-эш.*

**15, 22 гыйнвар.** Г.Ибраһимовның «Әдәбият (еллык хисап урынында)» дигән күзәтү мәкаләсе басыла. Ул биредә: «1911 елда Габдулла Тукаев белән Сәгыйть Рәмиев тә матбугатта сирәк күренделәр... Тукаев та бу елга хас китабындин «Мияубикә»не генә бирде. «Күңел җимешләре» бу ел чыкса да, аның җыелуы гына бу елга гаид булып, эчендәгедән күбе алдагы елгыдыр. (Чынлыкта 1911 елда Тукайның дүрт китабы дөнья күрә. Алда саналганнардан тыш, «Яшен ташлары» (беренче җөзьэ), «Балалар күңеле» (беренче кыйсем). Сәгыйть әфәнде Рәмиевнең тавышы да бик сирәк чыга. ...Мин шагыйрьләр хакында уйлый башласам, хәтеремә янып торган шәм килә. Ул яна-яна да, мае беткәч сүнә. Нишләмәле — табигать шулайдыр»,— дип яза.

*«Йолдыз», 780, 783 нче саннар;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 267 б.*

**Гыйнвар.** Бераз тернәкләнүгә, Тукай дәртләнеп эшкә керешә. «...көне буе йоклап, төне буе язып утыра башлады. Язган язуларын Габдулла һәрвакыт миңа биреп куя иде. Арчага барганда, ирем аның язуларын почтага алып барып сала иде» (җиңгәсе Рабига истәлегеннән).

Өчиледән Казанга Әхмәт Урманчиевкә хат яза**. Хатта үзенең авылдагы тормышы, сәламәтлеген хәбәр итә; сөт эчүен әйтә. «Миңа «Горе от ума» белән Лермонтовның «Полное собрание сочинение»сен җибәрә күр әле, кирәк». (И.Нуруллин бу юлларны Г.Шәрәфкә язган хаттан, дип раслый. Кара: «Истәлекләр», 253 б.)

Теге рәкымнәр астында языла торган нәрсә 20 рәкымнән

---

* М.Верезей — Өчиленең русча исеме.

** Бу Әхмәт Урманчиевкә 1 гыйнварда язган хатның дәвамы булуы ихтимал. (Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 114, 286 б.)

Рәкым — цифр.

артты. (Син күргәндә 7 рәкым иде.) Әгәр хөсне хатимә белән тәмам булса, исемен дә «Рәкымнәр астында» куярмыз. «Рәкымнәр астында» пессимистический рух белән башланган иде, монда бөтенләй оптимистландым, ахры»,— дип, ике атна эчендә унөчтән артык эреле-ваклы шигырьләр язуын әйтә. Күп эшләгәнлеге сизелеп тора.

Хатта киләчәк тормышы турында уйланулары да чагылыш тапкан: «Казанга апрель башларысыз кайтмаска дип торам. Чөнки «Болгар» белән «Шәрык»тән өмид өздем... салкын булыр кебек... Әле авыл хатирәсе булыр дип бер юрган, ике мендәр эшләтеп алдым. Моннан соңра мин фатирда гына торачак булганга, бунлар тормышта да әһәмиятле нәрсәләр...»

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 114, 286 б.;*
*Әмирова-Мөхәммәтҗанова Р. Тукай*
*Өчиле авылында. «Истәлекләр», 1986, 163 б.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 246—247 б.*

**20 гыйнвар.** Оренбургта «Вакыт» газетасы укучыларына Тукайның шигырь җыентыклары басылып чыгуын хәбәр итә: «Соң көннәрдә нәшер ителгән шигырь мәҗмугалары: М.Гафуриның «Моң вә зар», «Тәссоратым»; Г.Тукайның «Күңел җимешләре», «Яшен ташлары» (1), «Яшен ташлары» (2).

*«Вакыт», 910 нчы сан.*

**21 гыйнвар.** «Мич башы кыйссасы» исемле юмористик очеркы «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 32 нче сан.*

Истәлекләрдән укып белгәнебезчә, аның Өчиледә авыл кешеләре белән аралашып-сөйләшеп утырган чаклары да була. Ара-тирә ишегалдындагы мәдрәсәгә кереп, хәлфәнең дәрес биргәнен тыңлап утыруын һәм чатнама суыкта яланаяк мәдрәсәгә йөргән бер малайга Казаннан киеп кайткан киез итеген бүләк иткәнлеген дә, һәм, әлбәттә, мулла агасының кечкенә кызы Нурания һәм песи белән рәхәтләнеп, ихластан уйнавын да күз алдына китерәбез.

*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1985, 60 б.;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 248 б.*

**11 февраль.** «Балалар күңеле» китабы (икенче кыйсем. Казан, «Өмид» матбагасы, 32 б., 5000 данә) басылып чыга.

«Яшен ташлары» исемле китабы (беренче җөзьэ, 2 нче басма. Авторы: Шүрәле. Нашире: Су анасы. Казан, «Өмид» матба-

Хөсне хатимә — яхшы нәтиҗә.

гасы, 23 б., 3000 данә) басыла. Беренче басмасы белән әлеге икенче басма арасында үзгәреш юк.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 306 б.*

**27 февраль.** «Сабитның укырга өйрәнүе» исемле шигырен яза. Шигырь И.Н.Харитонов чыгарган «Татар әлифбасы» дигән китапка кушымта итеп, рәсемнәр белән басылган.

*Татар әлифбасы, 1912, 17 май;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 373 б.;*
*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 17-эш.*

**Февраль азагы — март башы.** Туганнарының: «Тагын бераз тор әле»,— дип кыстауларына да карамастан, Тукай февраль азагында Өчиледән Казанга кайткан. «Казанга кайтыш» исемле автобиографик очеркыннан (11 мартта басылган) күренгәнчә, ул Казанга кайткач, тыныч, аулак җирдән фатир табып, шау-шулы иптәшләреннән читтәрәк яшәргә карар бирә. Һәм ул квартирада бер атна чамасы торып та чыга.

Истәлекләрдән күренгәнчә, Өчиледән киткәндә ул инде рухи һәм физик яктан да ныгый төшкән, озак-озак утырып яза — эшли башлаган.

Казанга аны Кәбир абыйсы ат белән илтеп куя. Рабига җиңгәсе ике мамык мендәр бүләк итә.

*«Ялт-йолт», 35 сан;*
*Әмирова-Мөхәммәтҗанова Р. Тукай Өчиле авылында. «Истәлекләр», 163, 249 б.*

**Март.** «Болгар» һәм «Шәрык» кунакханәләрендәге суыктан туеп һәм авылдагы тынлыкка күнеккән шагыйрь тыныч фатирда торырга, азрак аралашырга, күбрәк иҗат эше белән шөгыльләнергә план корып кайта. Овражная урамындагы бер йортка фатирга да урнаша. Ләкин андагы шартлардан канәгать булмыйча, яңадан кунакханәләрдән номер эзли. Нәтиҗәдә «Свет» кунакханәсендә бер бик матур, якты, затлы җиһазлы бүлмәгә урнаша. Әмма бу юлы да уңмый, номерында күселәр аңа тынгылык бирми. Бу турыда «Казанга кайтыш» исемле әсәрендә кызганыч һәм көлке рәвештә тасвирлап яза.

*«Ялт-йолт», 85 нче сан.*

**11 март.** «Казанга кайтыш» очеркы «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Бу биш өлешкә бүленгән очеркның I өлешендә авыл тормышы, халыкның уй-фикере тасвирлана. Авыллардагы ачлык хәлләрен сөйли, наданлык турында искәртә. Шунда ук «Бәет» диеп, соңыннан «Җан азыклары»нда «Авыл мәдрәсәсе» исеме белән басылган шигыре дә бар:

## Бәет

Мәдрәсә дип нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе,
Нәкъ эче азган мөрит, мәҗнүн ишаннар хилкасе.

Чәйниләр монда җирәнгеч әллә нинди мөһмәлят,
Яше гомерләр мөһмәлят чәйнәп була монда һәлак.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Очеркның II өлешендә иртәнге сәгать алтыдан кичке сәгать җидегә чаклы Өчиледән Казанга кадәр булган юлда күргәннәре, төрле исемдәге авылларны үтү, Тимерче, Чыпчык, Кинderле..., шуларга нисбәтән уй-фикерләре тасвирлана.

III, IV, VI бүлекләрдә исә Казанга килеп урнашкандагы маҗараларын яза. Тыныч квартирада торып, ялгызы эшләргә, укырга-язарга план корса да, фатир хуҗалары — мещанкалар белән килешә алмыйча, тагын номерга урнаша. «Свет» кунакханәсенең (хәзерге Чернышевский урамы) бик матур, якты бер паркет идәнле бүлмәсенә урнаша. Әмма дөньяда бер нәрсә дә камил булмый, яхшының да начар ягы табыла икән. Бу мактаулы номер да күсе оясы булып чыга. Шуннан мәче эзләп тә таба алмыйча йөрүе һәм төнлә үзенең песи булып мияулавы искиткеч юмор белән тасвирлана: «Башыма шәп фараз килде. Мин үзем мәче булырга уйладым. Беркөн кич аякка киез итек һәм өсткә, эчен тышка әйләндереп, тун кидем. Башта да эче тышка чыгарылган бүрек иде. Тунның арт итәгенә мунчаладан койрык төсле бер нәрсә тактым. Бервакыт мәчечә кычкырып, номерымда репетиция ясарга тотындым: «Мияу!», «мырау!», «мәаааум!», «морррауууу!»

Үземә бик яхшы, бөтенләй мәчечә тоелганга, мин төн уртасында, һәйбәтләп аяк бөкләп, күсе чыга торган тишек янында утырам. Менә мияулыйм, менә мораулыйм!»

Язганнарының ахырында «Гыйбрәт вә нәсыйхәт» дип исемләнгән шигырь китергән:

Номерың матур булса — күсе булгай,
Һәр матурда начар якның берсе булгай;
Ансы булып җитмәсә дә, монсы булгай, —
Андин җыртык, мондин җыртык туннарым бар.

Бер адәмнең чын дошманы күсе булгай,
Икенчесен җөдәтүче кеше булгай;
Һәркемнең үзенчә бер эше булгай, —
Андин сүтек, мондин җыртык туннарым бар.

*«Ялт-йолт», 35 нче сан.*

---

Мөрит — ишанга иярган кеше.
Мөһмәлят — буш, файдасыз нәрсәләр.

**13 март.** «Гасыр» китапханәсендә Г.Коләхметов, Ш.Әхмәров һ.б. белән сөйләшеп торганда, күренекле татар революционеры, большевик-ленинчы, Тукайның якын дусты Х.Ямашев баш миенә кан йөгерүдән үлә.

*«Бәянелхак», 1912, 1014 нче сан.*

**18 март.** Җәмәгатьчелек Х.Ямашевны зурлап күмә. Озатучылар саны күп була. Газеталар бу югалтуга үзләренең мөнәсәбәтләрен белдерәләр. Биографиясе бирелә, кайгы мәкаләләре басыла, шигырьләр багышлана.

Бу үлем Тукайны, һичшиксез, тетрәткән, ул шактый вакыт исенә килә алмаган. Мәрхүмгә багышланган шигырьләренең бер ай узгач кына язылуы да шул турыда сөйли.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 252 б.*

**31 март.** «Ялт-йолт» журналының 36 нчы саны дөнья күрә. Бу санда «Америкадан Вәли муллага телеграмм», «Вәли мулладан Америкага», «Көлеп язмыйбыз, көлеп әйтмибез» исемле фельетоннары «Гөмберт» имзасы белән басылган («Ялт-йолт»-ның 26 нчы санында басылган «Өч баш» исемле мәкаләнең дәвамнары). Шул ук номерда «Яз галәмәтләре» исемле шигыре «Городской ломбард» дигән рәсем асты итеп имзасыз басылган һәм «Мәкальле киңәшләр» мәкаләсе «Гөмберт» имзасы белән кертелгән.

*«Ялт-йолт», 36 нчы сан.*

**Март ахыры — апрель башы.** Истәлек өчен фотога төшә. (Ак күлмәк, бант бәйләп костюмнан төшкән рәсем.) Аның бу фоторәсеме «Гасыр» нәшриятында почта открыткасы формасында эшләнеп тә таратылган.

*Габдулла Тукай. «Альбом», 1978, 126 б.*

**Апрель башы.** Фатирда яшәү шартларыннан канәгать булмыйча, Тукай «Свет» кунакханәсенең бер матур, якты номерына урнашып яши башлый. «Иптәшләрнең: «Синдә чахотка бар»,— диюләреннән гаҗиз булып, алардан читтәрәк бу номерга күчкән идем»,— ди үзе Габдулла Гыйсмәтигә (1883—1939), монда күчүенең сәбәбен аңлатып.

*Гыйсмәти Г. Ике елдан соң бер хисап.*
*«Замандашлары», 159 б.*

Петербург мулласы, дин галиме, җәмәгать эшлеклесе Муса Бигиевтән Петербургка килергә чакырып бер-бер артлы ике хат ала.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1989, 255 б.*

Дусты Габдулла Гыйсмәти белән очраша. Ул, «авыру» сүзен кулланмыйча гына, Тукайны Казаннан китеп, һавасы әйбәт булган җиргә барып хәл җыярга өнди һәм шуңа күндерә. Сөйләшү вакытында Кырымга баруның яраганлыгы исбат ителә. Ләкин Тукай берьялгызы ул якларга чыгып китәсе килмәвен әйтә. «Син барсаң гына ул якка барам...» — ди.

*Гыйсмәти Г. Ике елдан соң бер хисап. «Истәлекләр», 168 б.*

**7 апрель.** «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» исемле шигырен яза.

*«Ялт-йолт», 37 нче сан.*

**14 апрель.** Җәй буе кыргыз даласында кымыз белән дәвалануны күздә тотып (Троицк мулласы Габдерахман Рахманкулов та чакырып киткән була), Троицкига барырга, бераз сәламәтләнгәч, көз көнендә Петербургка барып докторга күренергә ниятләп, «Фултон» пароходында Казаннан Самарага юнәлә*. Аны пристаньга дусты, «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиев озатып төшкән.

*«Йолдыз», 820 нче сан;*
*«Ялт-йолт», 40 нчы сан.*

**15 апрель.** «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигыре басылып чыга. Әсәр Тукайның якын дусты Хөсәен Ямашевның (1882—1912) вакытсыз үлеме мөнәсәбәте белән язылган.

*«Йолдыз», 817 нче сан.*

«Янә бер хатирәм» исемле дүрт юллы шигырьдә сүз Хөсәен Ямашев турында бара:

Мин — кунакчыл бер җыручы, миндә — бар ярлы-гидай,
Ханәмә яшьләр килә һәм сәүдәгәр, бай угълы бай.

Ул бәләнд мәрхүм дә килсә, мин сизә торган идем:
Күктән иңгән, ханәмә килгән шикелле тулган ай.

*«Ялт-йолт», 37 нче сан.*

«Шыер» әсәре «Айнюк Самакай малае» дигән имза белән басылган.

Хөсәен Ямашев үлгәч, Казандагы бер төркем иптәшләре аңа багышлап «Йолдыз» газетасына кушымта бит чыгаралар.

---

Бәләнд — бөек, югары.

* Гайнанов Р. Тукайның Самарага китү көнен 4 апрель дип күрсәтә. (Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 270 б.)

Шул кушымтага басар өчен, журналист, язучы Фәхрелислам Агиев (1887—1938) Лермонтовның «Ангел» исемле шигыренә охшатып бер шигырь язып җибәрә. Әсәр «мишәрчәрәк» килеп чыкканга, Тукай аңа пародия рәвешендә шушы шигырен яза.

*«Ялт-йолт», 37 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 375 б.*

«Һазиһи касыйдәтен фи мәдхи Мостафа»* шигыре «Кыйссасел-әнбия (Рабгузый)» имзасы белән басылып чыга. Бу сатирик әсәр Әстерханда чыккан «Борһане тәрәкъкый» газетасы мөхәррире, алдынгы фикерле кешеләргә, революцион демократларга матбугат аша һөҗүмнәр ясаучы, татар телен төрекләштерергә чакыручы Мостафа Лотфи Исмәгыйлев-Ширванскийга багышланган. Истәлекләрдән күренгәнчә, Тукай аны 1911 елда ук Әстерханда язып, «Идел» дә бастырырга уйлый. Ләкин ни сәбәптәндер набордан кире ала.

*«Ялт-йолт», 37 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 371 б.;*
*«Замандашлары», 149 б.*

**15 апрель, кич.** Пароход белән Самарага килеп төшә («...икенче көнендә бугай, төнгә табарак Самарга җиттем»). Анда бик мәһабәт бинага урнашкан «Бристоль» кунакханәсенә туктый. Шул көнне үк Самараның мулласы, «Икътисад» журналы мөхәррире Фатыйх Мортазин белән очрашып, озаклап сөйләшеп утыралар.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 47—48 б.*

**16 апрель.** Сәяхәтен дәвам итеп, Самарадан поездга утырып Уфага китә. Аны вокзалга Фатыйх Мортазин җибәргән шәкерт резиналы фәйтун белән озатып куя.

*«Ялт-йолт», 41 нче сан.*

Самарадан Уфага барып җитә. Уфада Тукай «Сабах» көтепханәсенә туктала. Биредә ул шагыйрь Мәҗит Гафури белән очраша. Моңарчы М.Гафури белән танышлыклары язылган әсәрләре аркылы гына һәм Тукайның Гафури әсәрләренә үткен тәнкыйть рецензияләре дә язганын уйласак, бу очрашу аларның икесен дә дулкынландырган. Әмма алар бик тиз уртак тел табалар. Фикер алышып, ике көн бергә үткәргәннән соң, ул аңа үзенең Петербургка чакырылганын һәм анда барып кайтырга теләвен белдерә. Чөнки кымыз сезоны башланмаган, әле иртәрәк була.

---

* Бу касыйдә Мостафаны мактауга багышлана.

Тукай Петербургка барачагын хәбәр итеп телеграмма суга, Уфада Тукай «Сабах» көтепханәсенең гади генә бер буш бүлмәсенә урнашса да, көннәре күңелсез үтми; «Квартир, гомумән, күңелле. Кеше күп килә. Эч пошырлык түгел. Монда һәр көнне мөхәддисе кәбир Әхмәтфәиз Даутов белән күрешәбез. Ул скрипкәдә маташтыра, әлегә яхшы уйный алмый. Ләкин җырласа, мин андый җыруны бөтен гомеремә тыңлар идем. Аның гади сөйләшүдә дә металлический вә музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вә голувиятен изһар итә»,— дип язып, татар-башкорт көйләрен тыңлап рәхәтләнгәнен әйтә.

*Гафури М. Габдулла Тукай Уфада. «Истәлекләр», 1986, 175—176 б.; Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 49 б.*

**17 апрель.** Тукайның сәфәре хакында хәбәр басылып чыга: «Г.Тукай 14 апрельдә Самарага китте, аннан озак вакытка кымызга чыга».

*«Йолдыз», 820 нче сан.*

**18 апрель.** Х.Зәбири алып биргән билет белән поездда Тукай Уфадан Петербургка китә.

**20 апрель.** Иртәнге сәгать сигездә поезд белән Николаевский вокзалга килеп төшә. Үзен чакырып хат язучы Муса Бигиевкә телеграмма җибәргән булса да, аны каршылаучы булмый. Ул, извозчикка утырып, М.Бигиевнең өенә бара (Сергеевская, 81). М.Бигиев аны кабул итә һәм үз өендә үзенең бүлмәсенә урнаштыра. Тукай биредә үзенең элекке танышлары, иптәшләре белән дә күрешә алмаган хәлдә, 5 көн яши.

Муса Бигиев белән Петербург имамы, җәмгыяте хәйрия мәктәбенең мөдире Лотфулла Исхаковларда кунакта була. Шагыйрь белән күрешергә курсистка кызлар киләләр, ләкин, авыруын сылтау итеп, Тукай аларны кабул итмәгән.

Петербург бае, Муса Бигиевләр партиясе тарафдары Галим Максудов үзенең Истамбул дарелфөнүнен тәмамлап кайткан улы Кәрим белән күрешер, танышыр өчен, үзләренә кунакка чакырып Тукай янына киләләр.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 57 б.; Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 261—262 б.; Әхмәтҗанов Ш. Искә төшерү. «Хатирәләр», 166 б.*

**24 апрель.** (Петербургта бишенче көне.) «Нур» газетасы редакторы Сафа Баязитов студент Шәриф Әхмәтҗанов (Ма-

---

Мөхәддисе кәбир — хәдисләрне (пәйгамбәр сүзләрен) әйбәт белүче.
Голувият — бөеклек.
Изһар итү — ачып бирү.

натов) аркылы Тукайга дәгъватнамә җибәрә. Кичен Кәбир Бәкер (1883—1939) белән бергә очрашуга баралар.

*«Ялт-йолт», 45 нче сан;*
*Кәбир Б. Тукай Петербургта.*
*«Истәлекләр», 179 б.*

**25 апрель.** Тукай «Нур» газетасы идарәсенә бара. Анда ул элекке иптәшләре Кәбир Бәкер, Габделкәрим Сәгыйтовлар белән күрешә. Сафа Баязитов, студент Шакир Мөхәммәдъяровлар белән очраша. Ул Муса Бигиев өендә яшәп ятудан кыенсынуын һәм аерым номер алып торасы килүен әйтә.

Иптәшләре белән бергәләп карап, Невский проспектка якын «Казанская» исемле кунакханәнең (хәзерге Плеханов урамы, 5 нче йорт) бер номерына урнаша. Монда Тукай үзе хуҗа, тулы ирек. Таныш-белеш һәркайсы килә, теләгәнчә утыра. Шагыйрь үзе: «Тагын үземнең мөкатдәс ялгызлыгыма кайттым...» — дип сөйли бу турыда, ягъни үзе хуҗа, үзе теләгән кешеләр белән аралаша: «Менә Шакир әфәнде Мөхәммәдъяров килеп чыкты. Менә укучы яшьләр, мөгаллимнәр, менә Габделкәрим Сәгыйтов. Инде монда күңелсезләнергә урын калмады. Чөнки минем бүлмәм чирек сәгать тә кешесез тормый».

Сафа Баязитовның чакыруы буенча аның өенә кунакка бара. Анда граммофонда Пушкин, Лермонтов әсәрләрен, «Евгений Онегин» арияләрен яратып тыңлый.

Опера һәм балет театрына барып, «Евгений Онегин» операсын тыңларга планлаштырып билетлар да алына, ләкин Тукай авыруы сәбәпле (көннең яңгырлы, юеш, салкын булуы Тукайда бизгәкне көчәйтә) операга бара алмый калалар.

*Мәкаләи махсуса. «Ялт-йолт», 45 нче сан;*
*Кәбир Б. Тукай Петербургта. «Истәлекләр», 192 б.*

**26 апрель.** Петербургтан Казанга «Ялт-йолт» журналы идарәсенә «Яңлыш уйланмасын» дигән искәрмәсен язып җибәрә. Сәбәбе: «Йолдыз» газетасы идарәсе «Хөрмәтле Хөсәен ядкаре» шигыренә «әүлияләр» дигән сүзгә ялгыш аңлатма бирә (астөшермәдә :«Дустлар» мәгънәсендә аңланырга тиеш»,— дигән шәрех бирелгән була). Моңа игътибар итмичә, 5 көн үткәч, «Ялт-йолт» та бу шигырьне нәкъ шулай күчереп баса. Бу хатаны күреп, Тукай аңлатма бирүне кирәк таба.

«...Минем шигыремдәге «әүлияләр» сүзе үзенең чын-дөрест мәгънәсе белән «изгеләр» мәгънәсендә генә аңланырга тиеш...»,— дип журнал аша укучыларга мөрәҗәгать итә.

*«Ялт-йолт», 39 нчы сан.*

---

Дәгъватнамә — чакыру кәгазе.

**Апрель ахыры — 6 майга кадәр.** Ш.Әхмәтҗанов Тукайга Петербургта чыга торган большевистик «Звезда» газетасында басылган Хөсәен Ямашев турындагы мәкаләсен күрсәтә. Шагыйрь укый да: «Менә заман. Безнең хакта пайтәхеттәге рус газеталары да сөйли башладылар бит. Күптән кирәк иде... Мин Хөсәен мәрхүмне тәкъдир вә ихтирам итәм һәм аны бик сагынам... Мин үзем социалист түгелмен, шуның өчен дә ул мәсләктәге кешеләр хакында артык сүз сөйли алмыйм. Фәкать, һәркем үз мәсләген гүзәл аңлап, чыннан халыкка, ватанга хезмәт итсен иде».

*Әхмәтҗанов Ш. Искә төшерү. «Хатирәләр», 168 б.*

Дуслары Тукайны докторга күренергә үгетлиләр һәм, ризалыгын алгач, Ш.Мөхәммәдьяров аны университет докторы Александр Робертович Польга күрсәтә.

«Петербургта университет докторына күрендем, кыяфәте белән пәйгамбәр төсле кеше икән. Ул кымыз белән дәваланырга кушты. Аны Шакир Мөхәммәдъяров минем номерыма алып килгән иде»,— дип яза ул турыда Ә.Урманчиевкә.

Доктор Тукайның иптәшләренә: «Туберкулезның соңгы дәвере... тын ала торган әгъзаларының дүрттән бере белән генә сулап тора»,— ди. Тукайга Петербургтан тизрәк китәргә, санаторийга барып дәваланырга киңәш итә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 115 б.;*
*Кәбир Б. Тукай Петербургта. «Истәлекләр», 192 б.*

«Нур» идарәсенә ул яңадан да килеп йөри. Яңа килгән татар гәзитәләрен укып, танышып бара, алардан аерым мәкаләләрне кисеп алып, «Нур»да басарга тәкъдим итә. Петербургка килгәндә, аның бер җирдә дә басылмаган берничә яңа шигыре була. Кәбир Бәкер истәлегенә караганда, ул «Нур» газетасында шуларның берсен — «Дин вә гавам» исемле шигырен бастырырга риза була: «Ләкин соңыннан аның да «Нур» мәсләгенә муафыйк булып бетмәгәнлеге аңлашылды. Бу шигырьдә Тукай хәзерге дин башында торучыларны «каргалар» дип атый. «Нур» исә мулла вә мөәзиннәр «органы» булганлыктан, дин башында торучыларга ул тарызда тел тидерергә разый түгел».

*Бәкер К. Тукай Петербургта. «Замандашлары», 180 б.*

«Нур» газетасы мөхәррире Сафа Баязитовка «Йолдыз»да Садыйк мулла Иманкуловның Муса әфәндегә каршы язган «Ифрат» исемле мәкаләсе барлыгын һәм шуны алып «Нур»да басарга тәкъдим итә. С.Баязитов, Муса әфәндегә каршы язарга

кушмыйлар бит дисә дә, Тукай: «Аның мәкаләсенә әһәмият бирерлек бар»,— ди. Һәм «Нур»ның 208 нче номерында «Ифрат» басылып та чыга.

*Бәкер К. Тукай Петербургта, 1914 ел,63 б.*

«Нур» газетасы идарәсендә утырып идарәгә килгән хатларны, мәкаләләрне, шигырьләрне караштыра. Тозтүбәдән бер мөгаллим Хәбибрахман Әлмөхәммәдевнең җибәргән шигырьләреннән берсен азрак төзәтеп газетада бастырырга киңәш бирә*. К.Бәкер аны пессимистик рухта язылган дисә дә, Тукай: «Бер нәрсә дә юк бит инде... Шулай да әһәмияте бар. Пусть халык башымыздан кичердекемез көннәрнең өмедсез — кара көннәр икәнен белеп калсын... Аның характерный ягы шул: бүген кулына чак каләм тота белгән татар балаларының бары да шул өмедсезлек җырларын җырларга мәҗбүрләр... Менә шул хәзер матбугатта бик нык сизелеп калырга тиеш...

*Бәкер К. Тукай Петербургта, 1914, 38 б.*

**4—5 май.** Петербургтан китәсе көннең алдагысында мәктәп балаларының шагыйрь белән очрашасылары килгәнен хәбәр итәләр, һәм мәктәптә укыган ир вә кыз балалар исеменнән Тукайга (номерына) алты кешелек делегация җибәрелә. Вәкилләрдән өчесе кыз, икесе ир бала, берсе мөгаллим Мәхмүт Сипаев була.

Кыз балалар чәчәк букеты, ир балалар бик матур карасавыт бүләк итәләр. Карасавытта бронзадан бер ау эте белән сумка сурәте төшерелгән эмблема була. Истәлекләргә караганда, Тукай бу шәкертләргә дә һәм бүләкләргә дә бик куанып кала. «Шәкертләр киткәч, ...бик озак карасавыт өстендәге эт белән сабыйлар кебек шаярып ятты»,— ди К.Бәкер.

*«Хатирәләр», 160 б.*

**5—6 май.** Тукайның Петербургтан китәсе тәгаен билгеле булгач, иртән Сафа әфәнде Баязитовның Мойкадагы квартирында шагыйрь хөрмәтенә иртәнге аш мәҗлесе ясала. Кич белән зур бер сәүдә оешмасында хезмәт итүче Мөхәммәтша Җиһаншин квартирасында Тукай хөрмәтенә озату мәҗлесе үткәрелә. Биредә, приказчик вә сәүдәгәрләрдән башка, яшьләрдән Шакир Мөхәммәдьяров, Кәрим Сәгыйтов, Кәбир Бәкер, берничә Петербург мөгаллиме, Муса Бигиев, Петербург имамнарыннан Сафа ахун Баязитов, Лотфулла Исхаков катнаша. Ку-

* «Тормыш» исемле шигырь «Нур»ның 1912 елның 208 нче санында басылган. Сүз шул турыда бара булса кирәк.

накка чакыручы күп булса да, Тукай ул дәгъватларны кире каккан. Хикмәт авыруында һәм һаваның салкын, юеш булуында гына түгел, әлбәттә. Шуңа күрә сәүдә хезмәткәрләре һәм приказчиклардан торган 30—40лап кеше, шагыйрьне бер генә мәртәбә «мәшәкатьләргә» теләп, уртак мәҗлес оештыралар. Мәҗлескә җыйналган халык Тукайны бик яратып, җылы кабул итәләр. «Чөнки,— дип яза К.Бәкер,— кайсының углы, кайсының кызы бар. Боларның мәктәптә иң яратып укыган китаплары Тукаев әсәрләре, Тукаев шигырьләре идеке мәгълүм. Мәҗлестә булганнардан берсе үзенең ун яшьлек бер баласының Тукайны белгәнлеген сөйләде. Тукаев килгән дигәч, бу бала анасына Тукайны шулай тәгъриф кылган: «Ул минем шикелле кечкенә бер Апуш булган, шуннан соң «зуп-зур Тукай» булган».

Мәҗлес күңелле генә үтә. Мәҗлестә сөйләнгән сүзләрнең күбесе Тукайга ихтирам һәм хөрмәтне белдереп, аның сәламәтләнеп, яңадан матур бер вакытта Петербургка килеп кунак булырга чакыру була. Ахырдан мәҗлесне ясаучылар исеменнән Тукайга адрес тәкъдим ителә һәм акчалата бүләк тапшырыла.

Үз чиратында Тукай мәҗлесне оештыручыларга һәм үзен хөрмәт итеп очрашуга килүче милләттәшләренә рәхмәтен белдерә. Петербургның юеш-салкын һавасы сәламәтлегенә начар тәэсир итүен һәм тизрәк моннан китеп, кымыз эчеп дәвалану нияте белән Уфа вә Троицк якларына сәфәр кылачагын әйтә.

*Әхмәтҗанов Ш. Искә төшерү.*
*«Истәлекләр», 205 б.*

Әлбәттә, авыру шагыйрь тиктән генә ерак юлга сәфәргә чыгып китмәгән. Ул, башкалага баргач, күп нәрсәне белергә, күрергә, танышырга хыялланган була. Ләкин, авыруы көчәю аркасында, теләкләре үтәлми кала. «Мәкаләи махсуса» әсәрендә үзе болай яза: «Мин дә Петербургка бардым, дегет чиләге дә! Никадәр мөмкин була торып, Думага керә алмадым. Финляндиягә чакырдылар, анда бара алмадым. Бер театрга, бер музейга вә, гомумән, бер достопримечательный җиргә булсын, йөреп булмады: әлеге хасталык!

Тик Сафа әфәндегә барганда гына бер җан рәхәте була иде».

Тукай «Нур» газетасы редакторы Сафа Баязитовның искиткеч бай граммофон язмалары (пластинкалар) фондыннан төрле арияләр тыңлап, музыка аһәңнәре белән ләззәтләнгән.

Биредә ул А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» романы буенча П.И.Чайковский язган операны да беренче мәртәбә ишетә. Киләчәктә опералар тыңларга йөрермен дип күңеленә беркетә.

*Мәкаләи махсуса. «Ялт-йолт»,*
*45 нче сан.*

**6 май төне.** Петербургның Николаевский вокзалыннан Тукай поезд белән Уфага китә. Вокзалда аны озатырга дуслары һәм фикердәшләре Кәбир Бәкер, Шәриф Әхмәтҗанов, Шакир Мөхәммәдъяров, Кәрим Сәгыйтов һ.б. белән бергә имамнардан Сафа ахун Баязитов, Лотфи әфәнде Исхаков, зыялы мөгаллимнәр, байлар, төрле сәүдә йортларында хезмәт итүче мөселман приказчиклары, төрле мәктәпләрдә укучы яшьләр, студентлардан торган 30 лап кеше җыйнала. Һәммәсен дә, сыйнфый аерымлыкларны куеп торып, бөек шагыйрьне ихтирам белән озатып калу теләге берләштергән һәм бирегә китергән, әлбәттә.

Үзе бу турыда: «13 көн Петербург ризыгын ашагач, тагы Уфага таба сәфәр иттем»,— дип яза «Мәкаләи махсуса» дигән әсәрендә.

Өченче класстан плацкарт белән билет алына һәм Кәбир Бәкер Тукайны Мәскәүгә кадәр озата бара.

*Бәкер К. Тукай Петербургта. «Истәлекләр», 200 б.; Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 62 б.*

**7 май, иртәнге сәгать 10 нарда.** Петербургтан Мәскәүгә килеп җитәләр һәм озак тормыйча Тукай Уфага юнәлә.

Кәбир Бәкер истәлегендә болай яза: «Иртәгесе көн сәгать 10 нарда Мәскәүгә җиттек. Анда Николаевский вокзалдан Рязанский вокзалга күчеп, аш (обед) ашап, чәй эчүгә, поезд килде. Бик сайлап бер урын алып, Тукайны утыртып озатып калдым. Ялгыз китәргә булгач, бик уңайсызланган кебек иде. Уфадан язган хатында бик яхшы кайтканлыгын белдерде.

*Бәкер К. Тукай Петербургта. «Истәлекләр», 200 б.*

**8—9 май.** Петербургка сәяхәтендә унбиш көн чамасы йөреп, яңадан Уфага кайта. Бу сәфәрдән ул гаять йончып, арып кайта. Бу вакытта инде Уфа яшәргән, агачлар яфрак ярган, җир өсте яшел мамык кебек яшь үләннәр белән капланган, кымызлар хәзерләнгән була. Тукай Уфаның саф һавасын, матур бакчаларын ярата, кымыз эчә. «Сәламәтлек һавасы эчәм» дип сөйли иде Г.Тукай,— ди М.Гафури үзенең истәлегендә.

*Гафури М. Габдулла Тукай Уфада. «Замандашлары», 164 б.*

**9 майдан соң.** Тукай Уфада яши.

«Уфа Тукайның дәрәҗәсенә мөнасип һичбер хәрәкәт күрсәтә алмады. Тукайның Уфага килү хөрмәтенә һичбер мәҗлес-фәлән тәртип кылынмады. Аның Уфага килгәнен күп кеше белми дә калгандыр.

Тукайның Уфада үткәргән ун-унбиш көн гомере «Сабах» көтепханәсенең артындагы бүлмәдә үтте»,— дип яза М.Гафури.

Истәлекләргә караганда, Уфада Тукай Себер якларында мөгаллимлек кылучы Мөбарәк Әмиров белән очраша. Ул аннан Себергә кайчан баруы, анда нинди шартларда эшләве һәм кемнәрне укытуы турында гаять кызыксынып сораша.

Уфада яңадан докторга күренә. Бу турыда 12 нче майда Кәбир Бәкергә язган хаттан укыйбыз: «Уфа докторына кан тәхлиле тугърысында бардым... Җүтәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә кушты».

*«Замандашлары», 164 б.;*
*Тукай Башкортстанда, 1966, 44 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 117 б.*

**11 май.** Уфадан Казанга Әхмәт Урманчиевкә хат яза. Анда ул үзенең Уфадан Петербургка баруын һәм аннан кире кайтуын хәбәр итә. Бу сәфәрдән канәгатьсезлеген белдерә. Андагы суыклыктан һәм шуның аркасында килеп чыккан бизгәк авыруыннан зарланып, шул шәһәрдә үткәргән 12—13 көн гомерен кызганып искә ала. Уфада гына торган булсам, хат түгел, мәкаләләр дә язган булыр идем, ди... «Ялт-йолт»ның үзе Казаннан киткәч чыккан 37, 39 саннары хакында фикере белән уртаклаша. «37 нче санның беренче сәхифә рәсемен Галиәсгар* бозып чыгарган»,— дип ачына. Бөтенләй Тукай катышыннан тыш эшләнгән 38 нче сан (29 апрель) турында: «38 «Ялт-йолт» гомумән яхшы чыккан. Мәскәү мулласының лекциясен әүвәлге биткә басарга кирәк иде. Бу номерда да әдәпсез сүзләр бар. Шундый сүзләргә юл киселсен иде»,— ди.

Тиздән Троицкига китәсен хәбәр итеп: «...минем корзинкада онытылып калган кара тышлы дәфтәрне дә җибәрсәңез иде, зинһар. Ул дәфтәрдә минем «Җан азыклары» дигән почти шул мәҗмугалык шигырьләрем бар»,— дип сорый,— Хәзер Уфада булсам да, сезнең өчен адрес: «Троицк (Оренбург.губ.) Абдрахману Рахманкулову. Передать А.Тукаеву»,— дип яза. Димәк, ул тәгаенләп үзен чакырган Габдрахман хәзрәткә бара һәм Троицкида яшәгән вакытта аның белән элемтәдә торачагы аңлашыла.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 115, 288 б.*

**12 нче майга кадәр.** Уфадан Петербургка «Нур» газетасы редакторы Сафа Баязитовка хат яза (тексты табылмаган).

*Бәкер К. Тукай Петербургта.*
*Оренбург, 1914, 11 б.*

---

* Галиәсгар Камал турында сүз бара.

Тәхлил — анализ

**12 май.** Уфадан Петербургка дусты Кәбир Бәкергә хат яза. Петербургтан Уфага кайту уңайлы, җайлы булды, дип хәбәр итә. Петербургта күрешкән, аралашкан иптәшләре Кәрим Сәгыйтов, Шәриф Әхмәтҗановка (Манатов) сәлам тапшыруны үтенә. Шакир Мөхәммәдъяровка «пәйгамбәр» төсле кешесе өчен» (доктор) аеруча рәхмәтен белдерә.

Тиздән Троицкига китәсен хәбәр итеп, адрес яза: «Троицк, Оренбургская губерния. Габдрахман Рахманкуловка (Тукаевка)».

*Бәкер К. Тукай Петербургта, 1914, 11 б.*

Тукай Уфада бер атналап тора. Монда шагыйрь күбрәк вакытын М.Гафури белән уздырган. Кымыз сатыла торган бакчага чыгып, яшел чирәм өстендә кымыз эчәләр, Агыйдел буендагы бакчага чыгып, биек ярдан баржа, буксир, салларны күзәтәләр... Бер атнадан соң, әүвәлге карары буенча, кымыз эчәр өчен Троицкига китәргә карар кыла.

Уфада журналист һәм әдәбиятчы Габделбарый Батталов (1874—1959) белән очраша.

Габделбарый Баттал аны поезд белән Троицкига озатып җибәрә. Ләкин билет алганда ялгышлык килеп чыга. Тукайга Полетаевкага барырга кирәк, ә поезд анда туктамый, туры Чиләбегә бара икән. Тукай Чиләбедән ат яллап кире Полетаевкага кайтырга карар итә.

Г.Баттал, Тукайны каршы алырга кушып, Чиләбегә уртакул сәүдәгәр А.Галиевкә телеграмма җибәрә.

*Мәкаләи махсуса. Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 63 б.*

Чиләбе вокзалында Тукайны Галиев каршылый. Аның өенә барып чәй эчеп, хәл җыйганнан соң, Тукайны извозчикка утыртып озатып җибәрәләр: «Чәй янында хата билет алганлыкны сөйләп, Троицкига барырга берәр иптәш юкмылыгын сораштым. Бу мөхтәрәм әфәнделәр, мин аштан соң ятып хәл җыеп торганчы, иптәш тә тапканнар. Ат та киләчәк булган.

Бераздан атлар килеп, Троицкига бара торган бер приказчик юлдаш булып, Полетаевкага юнәлдек»,— дип яза үзе.

Төнлә поездга утырып, иртән Троицкига килеп тә җитә. Ул бирегә мулла Габдрахман Рахманкуловның икенче кат чакыруы буенча кымыз белән дәваланырга килә. Габдрахман мулла Рахманкулов, кеше җибәреп, аны поездан каршы алдыра: «Габдрахман хәзрәткә барып кердем... наконец, гакыйбәт авызга кымыз тиде. Мине кымыз өчен Уфага бару фикереннән кайтаручы вә андагы кымызның җәгълилеген (искусственный) сөйләүче вә яз көне кымыз эчәргә үзенә чакырган вәгъдә алып китүче ошбу Габдрахман хәзрәт иде».

Троицкида Габдрахман Рахманкулов өендә берничә кич куна.

Истәлекләргә караганда, Троицкига килеп төшкәч, Тукайны каршыларга «Сөембикә» мәктәбендә укучы кыз балалар килгән була. Алар шагыйрьне тимер юл станциясендә чәчкәләр биреп каршы алалар. Тукайны каршылаучы кеше мулла Г.Рахманкуловның кодасы Хәкимҗан Бакиров була.

Истәлекләрдә Тукайның Троицк яшьләре көн дә җыела торган урын — театр һәм музыка һәвәскәрләре җәмгыяте урнашкан Васильевский тыкрыгындагы 5 нче йортта, Хәкимҗан Бәкеровларда булуы, Х.Бакиров белән Троицкиның мәшһүр бае Яушевларның өлкән туганы Муллагали Яушевларга чәйгә баруы да сөйләнә.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 64 б.;*
*Рәсүлева З. Тукай эзләреннән, 1986, 106 б.;*
*Һилалов И. Тукай Троицкига килгәч.*
*Тукай Башкортстанда, 1966, 45, 48, 79 б.*

**15 май.** Г.Тукайның Петербургта булып китүе турында Кәбир Бәкернең «Тукаев вә Петербург мөселманнары» дигән мәкаләсе басылып чыга. Анда Тукайның апрель азакларында 13 көн Петербургта кунак булуы әйтелә: «Петербург мөселманнары авыру шагыйрьне яхшы тәкъдир иттеләр...»,— диелә.

*«Йолдыз», 832 нче сан.*

**17 май.** «Сабитның укырга өйрәнүе» шигыре «Татар әлифбасы» исемле китапка кушымта итеп чыгарылган «Бүләк» дигән китапчыгында (Казан, И.Н.Харитонов матбагасы) басылып чыга. Монда берничә рәсем һәм шушы шигырь урнаштырылган. Харитонов татар хәрефләре эшләткәч, беренче итеп бу китапны бастырып чыгара.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.;*
*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 307 б.*

**20 май.** «Мәкаләи махсуса»ның беренче бүлеген яза, һәм Казанга «Ялт-йолт» журналы идарәсенә җибәрә. Бу сәфәргә үзен озатып җибәргән дусты «Ялт-йолт» журналы мөхәррире Әхмәт Урманчиевкә адреслап, болай ди: «Мөхәррир әфәнде! Әле минем авырудан башка эшем юк, бик зур эш эшләгән шикелле, әллә кайларга барып авырып йөрим. Авылда авырдым, Казанда авырдым, Самарада авырдым. Ахирeләмер, патша тора торган шәһәргә — Петербургка барып авырдым. Троицк халкы да күрми калмасын, дип, монда да авырыйм. Ләкин монда эш шәп. Терелермен кебек. Терелсәм, әллә нәрсәләр язармын кебек».

*«Ялт-йолт», 40 нчы сан.*

**Май азагы.** Берничә көннән Хәкимҗан Бакиров Тукайны кымызга Габдрахман Рахманкуловның дачасына илтеп куя.

Совет власте елларында бу урыннарда кымыз белән дәвалану санаторийлары ачыла.

Шагыйрь исә: «Троицкида берничә көн торгач, сахрага, шәһәрдән егерме биш чакрым җиргә киттем... Анда хәзрәт тарафыннан ялланган казакълар аның йөзләп баш биясен савып, бүтән малларын көтеп торалар. Ике киез өйдән гыйбарәт шул казакъ авылына өченчегә миңа махсус чатыр тегелде. Шәһәр смрадыннан, завод агуыннан, бозык һавадан качып чыгып, арбадан пароходка, пароходтан поездга күчә-күчә эштән чыккан мин бичара, ахры, бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым... Бу — сахра... коры степь һавасы... Бөтен нәрсә табигый...» — дип яза. Бу казакъ даласына барган беренче көнне үк күңел күтәренкелеге белән табигатьнең матурлыгына, киңлегенә рухланып шигырь дә яза:

«Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!
Ак күмәч белән ашарлык саф һава;
Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!
Ак болыт, күчмә казаклардай күчеп,
Бер куньшлык җирне сайлый, валлаһи!
Аз гына бер җил исү белән үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Иштә бу — сахрада беренче көнемдә язылып ташлаган бер кәгазьдән алынган җырулар!» — ди.

*Һилалов И. Тукай Троицкига килгәч. «Тукай Башкортстанда», 1966, 47 б.; «Мәкаләи махсуса». «Ялт-йолт», 45 нче сан.*

**25 май.** «Халык моңнары» (Икенче табгы. Җыючысы: Шүрәле. Казан, «Сабах» көтепханәсе) басылып чыга.

«Халык әдәбияты» (Икенче табгы. Казан, «Сабах» көтепханәсе, «Өмид» матбагасы) басыла.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.; Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 307 б.*

**1 июнь.** «Ялгыш уйланмасын» исемле искәрмә-мәкаләсе дөнья күрә.

*«Ялт-йолт», 39 нчы сан.*

«Мәкаләи махсуса» исемле әсәренең 1 нче кисәге «Хәкыйрь Шүрәле» имзасы белән басылып чыга*.

---

* Журналда «1 июнь» дип ялгыш басылган; 1 июньдә 39 нчы сан чыккан.

«Ялт-йолт» журналының редакторы Әхмәт Урманчиев хатына җавап рәвешендә язылган.

*«Ялт-йолт», 40 нчы сан.*

**11 июнь.** Троицкидан Казанга Гыйльметдин Шәрәфкә хат яза. Сәламәтлеге арулануын, хәле һәм кәефе әйбәтлеген, ләкин ялгызлык ялыктыруын хәбәр итә: «Урыным Троицкидан 25 чакрым җирдә. Һәр тараф сахра. Ике казакъ өеннән башка бернәрсә дә күренми, күңелсез, эч поша...»

«Авырдым, тагын яңадан башланмаса, бетә инде. Ләкин терелеп нәрсә бар?» — дип карыйм каравын. Ач кеше вакытның соң икәнен белсә дә ята. «Торып нәрсә бар?» — ди. Мин дә шулай, өмидем юк.

*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 18 б.*

**15 июль.** «Ялт-йолт» журналының 41 нче саны дөнья күрә. Бу санда «Мәкаләи махсуса» әсәренең икенче кисәге (I—V бүлекләре) «Сәяхәте көбралар ясаучы» «Шүрәле» имзасы белән, «Бәндәләр» шигыре имзасыз* басылган.

*«Ялт-йолт», 41 нче сан.*

**Май азагы — июльнең 20ләренә кадәр.** Казакъ даласында ике ай-ике ай ярым вакыт яши. Биредә ул «Мәкаләи махсуса»ның икенче кисәген язып (5 бүлекчә), почта белән Казанга җибәрә. «Хәзер җиләк-җимеш вакыты» фельетоны да җәйләүдә язылган булуы мөмкин.

Шәһәрдән аның янына килгәләп йөргәннәр. Үзе дә берничә мәртәбә, чакыруларга җавап йөзеннән, Троицкига барып кайткан.

Кайбер истәлекләргә караганда, Тукай ял иткән вакытта тагын бүтән җирләргә дә барган. Үзе кымыз эчеп дәваланган казакъ авылыннан ерак түгел Кушкүл авылына килә. Халыкка яңа шигырьләрен укый. Күлдә көймәдә йөри, болындагы чәчкәләр белән хозурлана.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 270 б.;*
*Бикбулатов М. Ике кечкенә хатирә.*
*«Тукай Башкортстанда», 1966, 49 б.*

**Июльнең 20ләре.** Ялы ял төсле булды дигән фикергә килгәч, үзендә азмы-күпме хәлләнү дә сизгәч, Тукай кайтыр юлга чыга. Июльнең егермеләрендә, ниһаять, Казанга, «Свет» кунакханәсендәге номерына кайтып керә. Ис алып, хәл җыеп

---

* Бу шигырьнең Тукайныкы икәнен Нәкый Исәнбәт тә раслады («Казан утлары», 1966, 4 нче сан).

тормастан, «Ялт-йолт»тагы вазифасын башкарырга керешә. «Җан азыклары» җыентыгын матбугатка әзерләргә тотына.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 270, 283 б.*

Троицкидан кайтып бер-ике көн үтүгә, Фатыйх Әмирхан белән икәүләп фоторәсемгә төшәләр.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 286 б.;*
*Габдулла Тукай. «Альбом», 1979, 19 б.*

**21 июль.** Календарьчы Шәрәф Шәһидуллин тарафыннан 1913 ел өчен чыгарылган «Заман календаре»нда Тукайның фоторәсеме һәм кыскача тәрҗемәи хәле урнаштырылган. «Идел» редакциясе биргән рекламада «Календарь»ны төрле яклап мактаганнан соң, түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Һәртөрле киңәшләр, статистика мәгълүматлары бирү өстенә, милли яшь мөхәррир, әдип вә шагыйрьләремезнең рәсем вә тәрҗемәи хәлләре һәрбер укый белгән мөселманның игътибарын тарта.

Без бит әле яшь мөхәррир вә әдипләремезнең рәсемнәрен дә күргәнемез юк... «Заман календаре» исә укучыларын шул мөхәррирләр белән таныштыра. Бу мәртәбәдә Тукаев, Гафури, Бәшири, Думави, Әмирхан вә башкаларның рәсемнәре бар...»

*«Идел», 473 нче сан.*

**26 июль.** Казанда Евангелистлар урамындагы Хәсәновлар йортында татар яшьләренең әдәби түгәрәге җыйнала. Бу утырышта журнал чыгарырга карар бирелә. Русларның әдәби журналлары кебек күләмле булуы күздә тотылып, аның татар яшьләрен оештыручы, берләштерүче үзәк булырга тиешлеге искәртелә.

Җыелышта бу мәсьәлә Гәрәй һәм Барый Хәсәновлар ... , Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, укытучы Гафур Коләхметовларның актив катнашы белән хәл ителә һәм әдәби-мәдәни «Аң» журналы чыгарырга карар бирелә. Басма өчен исемне Тукай тәкъдим иткән.

*Саратов өлкә Дәүләт архивы, 51-ф., 1-тасв., 44-эш, 59 б.;*
*Абдуллин И. Архивные документы о Г.Кулахметове. «Гафур Кулахметов», 1983, с.198.*

Г.Тукай әдәби түгәрәккә җыелган яшьләр, үзенең дуслары һәм фикердәшләре белән бергәләп фотога төшә. Ләкин бу фоторәсем тулы килеш, бөтен нөсхәсе бүгенге көнгә кадәр табылганы юк. Аның ике яктан да киселгән урта бер өлеше генә саклана. Китапларга, альбомнарга да шул урта өлеше (биредә:

Г.Тукай, Ф.Әмирхан утырганнар, Г.Коләхметов, К.Коләхметов артка басканнар) генә урнаштырылып килә. Фотограф Зөфәр Бәширов фикеренчә, «Фотографиядә кабул ителгән стандарт буенча аның иңе 27,5, биеклеге 22,5 см булырга тиеш. Әгәр дә Г.Тукай уртада утырган дип исәпләсәк, бөтен фоторәсемдә шагыйрьнең даирәсеннән тагын 6 кеше булырга тиеш дип уйларга урын бар». Алар кемнәр — билгесез. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты мирасханәсенең Тукай фондында фотосурәтнең бердәнбер нөсхәсе саклана. Иңе — 7, биеклеге — 22,5 см булган. Фоторәсем ике ягыннан да пычак белән кисеп алынган, аның эзләре ап-ачык күренеп тора.

*«Мирасханә». 9-ф., 3-тасв., 65-эш;*
*Габдулла Тукай. «Альбом», 1978, 89 б.;*
*Бәширов З. Киселгән язмышлар.*
*«Шәһри Казан», 1995, 25 апрель.*

**26 июль.** Тукай фотога төшә. Үзе генә, профиль белән утырган. Чәче кыска итеп кистерелгән. Буйлы күлмәк кигән, галстук һәм костюмнан.

*«Аң», 8 нче сан;*
*Габдулла Тукай. «Альбом», 1989, 136 б.*

**31 июль.** Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы провокаторның 26 июльдәге җыелыш турындагы доносын Идел буе охранкасы башлыгына җибәрә һәм бу кешеләрнең жандарм идарәсенә билгеле булуы, алар артыннан яшерен күзәтү дәвам иттерелүе турында хәбәр итә.

Бу «бик яшерен» тамгасы салынган документның «Урында кулланылган чаралар» дигән графасында Казан жандарм идарәсе болай дип язган: «Монда исемнәре аталган кешеләрнең кайберләре (арада Г.Тукай да бар.— *Төзүче*). Идарәгә үзләренең элекке политик эшчәнлекләре буенча билгеле. Алар артыннан күзәтү дәвам итә».

*Саратов өлкә Дәүләт архивы, 55-ф.,*
*44-эш, 60 б.*

**5 август.** «Хәзер җиләк-җимеш вакыты» исемле сатирик мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 42 нче сан.*

**5 август.** «Гасыр» нәшриятында почта открыткасы формасында басылган рәсеменә (1911 елда алынган, яланбаш, буйлы күлмәк белән бант таккан, костюмнан) шагыйрь үз кулы белән:

«Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй вә Габдрахман әфәнделәргә ядкарем.

5 август, 1912 ел. Г.Тукай» дигән автограф язып бүләк итә.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 49-эш.*

Татарстан Дәүләт музее хезмәткәре Дания Баһаутдинова фикеренчә, бу рәсемен Тукай үзен Троицкига, казакъ даласына кымыз белән дәваланырга чакыручы Габдрахман хәзрәт Рахманкулов һәм аның ир туганы, әдәбиятчы һәм сәхнә әсәрләре дә язган кеше, Әхмәтгәрәйгә бүләк иткән булырга мөмкин.

*Баһаутдинова Д. Тукайның яңа табылган автографы. «Социалистик Татарстан», 1978, 28 апрель.*

**Күз башы.** Казанга килгән шагыйрь һәм мөгаллим С.Сүнчәләй Тукай белән очрашып тора. Мәгълүм истәлегендә ул болай дип яза: «Бу вакыт Тукайның хәле тәмам беткән, нервлары какшаган. Кечкенә генә нәрсәгә дә кәефе китә, бик тиз ачулана, юк-бар нәрсәдән дә шикләнә, курка, берәүне дә күрәсе килми иде».

Сүнчәләй авылына китәр алдыннан саубуллашырга да кергән. Тукай шунда аңа: «Менә, сиңа бүләгем булсын»,— дип, үзенең көмеш сәгатен бүләк итә. Бу аларның соңгы мәртәбә очрашулары була.

Тукай «Свет» номерларыннан яңадан «Болгар»га күчә.

*Сүнчәләй С. Тукай турында истәлек. «Истәлекләр», 141 б.*

**Күз.** Журналист Шиһап Әхмәров истәлегенә караганда, Тукай үзенең барлык шигырьләрен мәҗмуга итеп бастыру хокукын Г.Шәрәфкә биреп, аның белән договор төзи һәм шул җыентык («Мәҗмугаи асарь»)ны* әзерләү өчен бик бирелеп эшкә керешә. Г.Шәрәфнең бу договорга нинди шартлар куюы билгеле булмаса да, Тукайга якын кешеләр Тукай өчен бу договорның «кабальный», ягъни арзан гына хакка авторлык хокукы тулысынча сатылган булуын сөйлиләр.

*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 14-эш.*

---

* 1914 елның октябрендә дөньяга чыккан «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре» (Җәмалетдин Вәлиди тарафыннан язылган Тукайның тәрҗемәи хәле һәм әшгаре хакында бер мөляхәзә. Казан. «Мәгариф» көтепханәсе) әсәрен Тукай үзе исән вакытта, нигездә, төзеп бетереп калдыра. Дусларыннан Ш.Әхмәров әйткәнчә: «Бу Мәҗмуганың күп өлешен мәрхүм үз кулы белән төзеп калдырды. Ул үзенең ахыр көннәренә кадәр, хәтта шифаханәгә кергәч тә, шуның өстендә эшләвен туктатмады... Мәҗмуга Тукайның үзе исән вакытында басыла башлап, Тукай үлгәч... дөньяга чыкты». Кара: «Тукай турында замандашлары». Казан, 1960, 193 б.

**7 сентябрь.** «Идел»дә «Үземезнең әдәбият базары» дигән мәкалә басыла: «Каспий» газетасы Нижгород ярминкәсендә эчке Русия татар мөхәррирләренең әсәрләре кайсы дәрәҗәдә таралуы турында яза. Дини әсәрләрдән кала, Ф.Әмирханның әсәрләре, шагыйрьләрдән Тукаевның шигырьләре, Г.Исхакыйның «Өч хатын берлә тормыш...» дип санап кителгән.

*«Идел», 483 нче сан.*

**20 сентябрь.** «Динчеләр куаныштылар» мәкаләсе «Гөмберт» имзасы белән басылып чыга.

Динчеләрдән һәм Оренбургта чыккан «Дин вә мәгыйшәт» журналыннан, аның нашире Вәли мулла Хөсәеновтан көлеп язылган сатирик мәкалә.

*«Ялт-йолт», 43 нче сан.*

**3 октябрь.** Дусты революционер Мәхмүт Дулат-Алиевка үзенең фоторәсемен бүләк итә (Казанда И.Якобсон фотоательесында Тукайның профильдән төшкән рәсеме). Рәсем артына «Иптәшем Мәхмүткә ядкарь. Г.Тукай, 3 октябрь, 1912 сәнә» дип автограф язылган. Бу фото Кырлайда, музеенда саклана*. Анда аны М.Дулат-Алиевның олы кызы Ләлә Дулат-Алиева тапшырган.

«Әти белән Тукайның дуслыгы гомере буе дәвам итте»,— дип яза бу турыда истәлек авторы Ләлә Дулат-Алиева.

*Әпсәләмов Г. Тукайның тагын бер рәсеме. «КУ», 1970, 1 нче сан, 156 б.;*
*Рәүслева З. Тукай эзләреннән, 1985, 124 б.*

**Октябрь.** Авыруы каләм тотарга комачаулый башлый. Бу вакыт ул, «Ялт-йолт»ны чыгаруга хезмәт куюдан тыш, «Җан азыклары» җыентыгын матбугатка әзерли.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 283 б.*

**11 октябрь.** «Йолдыз» газетасы укучыларына заманның танылган шәхесләре турында хәбәр итә: «Ачык хат. Иң соң алынган рәсемнәрдән: Исмәгыйль Гаспринский, Йосыф Акчура фотоларыннан эшләнгән открыткалар, Мөхәммәдгаяз Исхакый, Габдулла Тукаев яңа гына заграницадан эшләтеп китерелеп сатыла башлады».

*«Йолдыз», 892 нче сан.*

---

* Мәһдиев М. Шагыйрь гомере энҗеләре. «Социалистик Татарстан», 1986, 15 октябрь.

**13 октябрь.** «Балканда» шигыре рәсем-карикатура асты итеп имзасыз басылган.

Бу икеюллык Төркия белән Балкан дәүләтләре арасындагы сугыш мөнәсәбәте белән язылган.

Шул ук санда «Иң соңгы хәбәр» исеме белән кечкенә информациясе имзасыз басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 44 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 342 б.*

**1 ноябрь.** «Тукайдан үзгәртелгән» исеме белән «Шура»да дүртьюллык шигырь басылган. «Ә» дип имза куелган: «Син булыш сөйсәң мине акчаң вә карманың белән! Күпме тапсаң да, икәү уртаклашыйк аның белән!..» Син исә: «Гыйлем вә гыйрфаным белән бүлешәм»,— дисең.— Файдаланмам, туган, мин андый гыйрфаның белән».

*«Шура», 21 нче сан, 652 б.*

**5 ноябрь.** «Ялт-йолт» журналының 45 нче саны дөнья күрә. Биредә «Шүрәле» имзасы белән «Мәкаләи махсуса» әсәренең VI—IX бүлекләре, шунда ук «Валлаһи» шигыре, «Гөмберт» имзасы белән «Хаксызлыктан котылдык» исемле мәкаләсе урнаштырылган. Анда сәүдәгәрләр, муллалар булышлыгы белән Дүртенче Дәүләт думасына депутатлыкка сайланырга тырышса да, актык минутта сайланмый калган Шәехгаттар Иманаевтан көленә. Шушы вакыйга уңае белән тагын «Казан мулласы һәм булачак депутат» дигән сатирик шигыре рәсем асты итеп «Шүрәле» имзасы белән басылган.

*«Ялт-йолт», 45 нче сан.*

**17 ноябрь.** Г.Тукайның дусты Ф.Әмирхан артыннан да күзәтү алып барыла. Губернаторның Рухани эшләр департапентына язган белдерүенә караганда, Ф.Әмирхан һәм Ә.Хәсәни квартираларына тентү ясала. Ләкин аларны гаепләрлек бернәрсә дә табылмый. «Алар бик нык конспирацияләнгән булганлыктан, фаш итеп булмый»,—дип яза губернатор.

*ПУДТА. 1-ф, 5809-эш, 41,73,76,82,84 б.;*
*Нәфыйков Р. Габдулла Тукай биографиясе.*
*«КУ», 1966, 8 нче сан, 127 б.*

**Көз.** Тукай яраткан һәм мәхәббәт турындагы шигырьләренең күбесен аңа мөнәсәбәттә язган Зәйтүнә туташның Казаннан Чистайга китүен Тукай бик авыр кичерә. Аңа кинәт кояш сүнгән, дөньяның яме киткән кебек тоела. Бу мәхәббәтен күпләрдән яшерсә дә, дусларыннан берсенә Зәйтүнәне һаман яратуын, оныта алмавы, сагынуы турында сөйли.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 152 б.*

**10 декабрь.** Казанда «Кояш» исемле демократик юнәлештәге газета чыга башлый. «1912 нче елда караңгы Казан өстенә «Кояш» чыгып, «Йолдыз»ны сүндерде»,— дип яза Тукай, бу вакыйгага рухланып. Газетаның җаваплы секретаре итеп Ф.Әмирхан билгеләнә. Тукайны, 40 сум айлык хезмәт хакы биреп, газетага язышучы итеп билгелиләр. Яңа газетаның идарәсе «Амур» кунакханәсенә (хәзерге Киров урамы, 70 нче йорт) урнаша. Ф.Әмирхан да, Тукай да «Амур»га күчеп* (Тукай — тугызынчы бүлмәдә, Ф.Әмирхан — унберенчедә) тора башлыйлар. Хәзер инде алар көн саен очрашып яшиләр.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 285 б.; Исмәгыйль Р. Ул сагышланды, күрә алмады. «Истәлекләр», 214 б.*

**15 декабрь.** Казанда «Аң» исемле әдәби-иҗтимагый журнал чыга башлый. Редакторы һәм нашире «Гасыр» китап ширкәте башлыкларыннан берсе — Әхмәтгәрәй Хәсәни (1883—1938). Киңәшү-сөйләшүдә, булачак журналның идея-политик һәм әдәби-эстетик юнәлешен билгеләүдә һәм Хәсәнине бу эшкә күндерүдә Тукай якыннан катнашкан. Журналга исемне дә Тукай тәкъдим итә. Беренче санында Тукайның журнал чыгу уңае белән язылган «Аң» шигыре урнаштырылган. Журналда тагын Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов актив катнашалар. Әлеге әдәби, фәнни сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал 1918 елның башына кадәр (барлыгы 113 сан) чыккан.

*«Аң», 1 нче сан.*

**22 декабрь.** «Тегеннән-шуннан» мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга.

*«Ялт-йолт», 48 нче сан.*

«Ялт-йолт»ның 48 нче санында «Журнал өчен материаллар «Амур» кунакханәсенең 9 нчы бүлмәсенә җибәрелсен»,— дигән игълан басылган, күрәсең, беркадәр вакыт «Ялт-йолт»ның редакциясе дә шагыйрь яшәгән бүлмәгә күчеп торган.

*«Ялт-йолт», 48 нче сан.*

**23 декабрь.** «Балкан» шигыре басылып чыга. (Төркия сугышы мөнәсәбәте белән язылган.)

*«Кояш», 7 нче сан.*

---

* Кайбер чыганакларда «Тукай 1912 елның икенче яртысында (Троицкидан кайткач) «Амур» номерларына күчеп яши» диелгән. Кара: «Замандашлары», 135 б.; Ф.Әмирхан. Әсәрләр, 1986.— 4 т.— 333 б.

«Балкан көйләре» исемле шигыре «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шигырь Балкан дәүләтләре (Болгария, Сербия, Греция һәм Черногория) белән Төркия арасында барган сугыш һәм Төркиянең шушы елның октябрендә җиңелүе хакында язылган.

*«Кояш», 7 нче сан.*

«Балкан сугышлары вакытында төрекләрнең сугыш башында ук Черногория чигендәге ныгытмаларын ташлап качуын шагыйрь: «Төрекләр белми эшләмәс; төрекләр — искедән сугышчан халык!» — дип, төрекләрнең кабат һөҗүмгә күчүләрен көтеп яткан пантюркистлардан һәм панисламистлардан ачы көлеп фаш итә. Хезмәт ияләре исәбенә һәм аларга каршы алып барылган талау сугышларына Тукай җаны-тәне белән каршы була».

*Нәфыйгов Р. Габдулла Тукай биографиясе. «КУ», 1966, 8 сан, 122 б.*

**29 декабрь.** «Вакыт» газетасы Г.Тукайның «Җан азыклары» исемле шигырь җыентыгы басылып чыгу турында «Яңа басылып чыккан иң мөһим әсәрләр...» дип игълан бастыра.

*«Вакыт», 4 нче сан.*

**30 декабрь.** «Җан азыклары» исемле шигырьләр җыентыгы (Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, Л.Г.Антонов матбагасы) басылып чыгу турында теркәү дәфтәренә языла.

*ТРМА. 420-ф., 1-тасв.*

48 битлек китап Тукайның үзе исән чакта басылып чыккан җыентыкларының соңгысы. Китапка кергән 4 шигырь һәм бер поэманың тугызы гына башлап вакытлы матбугатта басылган. Калган 31 шигырь 1911 ел ахырыннан башлап 1912 ел ахырынача төрле вакытта язылган, ләкин моңарчы беркайда да басылмаганнар. Алар түбәндәгеләр:

«Толугыш шәмси мин мәгърибиһа» («Кояшның көнбатыш яктан чыгуы»), «Үтенеч», «Дошманнар», «Кичке теләк», «Җегетләр», «Ваксынмыйм», «Бала оҗмахта», «Сагыныр вакытлар», «Картлар», «Авылда авырып яту», «Бәрәңге вә гыйлем», «Йолдыздан да курка», «Буран», «Көтмәгәндә», «Көлке түгел», «Әхлаксызлык», «Монафыйкка», «Сабыйлар җыруы», «Ни кирәк тагы?», «Пушкин вә мин», «Мөнтәкыйд», «Интикадка мөтәгалликъ», «Мәхәббәт шәрхе», «Казан вә Кабан арты», «Казан вә Казан арты», «Татар яшьләре», «Дин вә гавам», «Яңгыр», «Җил тавышы», «Авыл халкына ни җит-

М ө н т ә к ы й д — тәнкыйтьче.

И н т и к а д к а м ө т ә г а л л и к ъ — тәнкыйтькә бәйләнешле.

ми», «Өч хакыйкать» (поэма). Болар арасында Пушкин, Майков, Ушинский һ.б. язучылар әсәрләреннән ирекле тәрҗемәләр, аларга ияреп язылган шигырьләр дә бар.

*Сәгыйтова Э. Тукайның ике җыентыгы. «КУ», 1970, 1 нче сан, 153 б.*

1911—1912 елларда Горький милли әдәбиятлар әсәрләреннән, шул исәптән Казан татарлары әдәбияты әсәрләреннән тупланган җыентыклар чыгару фикеренә килгән. «Милләтчелек куерган безнең көннәрдә бу эш, минемчә, бик вакытлы булыр,— дип яза ул В.В.Вересаевка.— Һәм бу эшкә, Россияне үз-үзе белән таныштыру эшенә, табыш алу нияте белән эш итә торган нәшрият фирмасы түгел, бәлки, рус язучылары ширкәте алынса, үтә мөһим булыр иде».

*М.Горькийның 30 томлык әсәрләр җыентыгы. 29 том, 249 б.*

Эшне озын-озакка сузмастан, Горький бу уен тормышка ашыруга керешә. Г.Исхакыйның танылган татар язучысы Ф.Әмирханга 1912 елның 13 июлендә язылган һәм шәхси архивта саклана торган хатында мондый сүзләр укыйбыз: «Максим Горький «Алдым-бирдем» вә башка берничә хикәяләремнең мөхәрриренең әсәрене, шигырене кушып, «Татар мәҗмугаи әдәбиясе» исемендә бер китап бастырырга димләп хат яза. Мин бу эшне үз тарафымнан кабул итеп җавап бирдем».

Горький белән алышкан хатларның бер өлеше шушы җыентыкны әзерләү эше белән бәйле. 1912 елның 4 июнендә, мәсәлән, Г.Исхакый үзенең бу җыентыкта катнашырга өндәп берничә татар язучысына һәм шагыйренә мөрәҗәгать иткәне хакында яза.

*Нуруллин И. М.Горькийның ике хаты. «КУ», 1988, 8 нче сан.*

**1912 ел эчендә.** Оренбургта «Мәктәп балаларына махсус шигырьләр» исемендә Г.Тукай, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Зариф Бәшири шигырьләреннән тупланган хрестоматия басылып чыга. 102 битле, биш фасылдан торган бу китапта Г.Тукайның төрле елларда язылган түбәндәге шигырьләре урын алган: «Елның дүрт фасылы», «Яз хәбәре», «Җәй көнендә», «Яхшы хәбәрләр» («Язгы яңгыр тамчысы...»), «Арба, чана, ат», «Мәктәптә», «Бәхетле бала», «Иртә», «Ана илә бала», «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә», «Ана догасы» («Менә кич, зур авыл...»), «Туган тел», «Туган авыл», «Туган җиремә», «Бишек җыруы», «Авыл хатынының бала тибрәткәндә өмидләре», «Чыршы», «Бәйрәм бүген», «Эшкә өндәү», «Эш»,

«Сөткә төшкән тычкан», «Төлке һәм йөзем җимеше», «Теләнче», «Кошчык», «Карлыгач», «Сабыйга», «Уянмас йокы».

*«Мәктәп балаларына махсус шигырьләр». Җыючысы — Мәхмүд әл-Мәрҗани, Нашире — Хөсәен Хөсәенов. Оренбург, 1912.*

М.Горький «Татарский литературный сборник» дигән җыентык чыгару чарасына керешә, аның планын төзи. Җыентыкка кертү өчен Г.Тукай, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Г.Исхакый һәм башка әдипләрнең әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итәргә планлаштырыла. Ләкин ул вакытта бу җыентык чыкмый кала.

*Гайнуллин М. Горький и татарская литература, 1944, 21—22 б.; А.М.Горькийның тормыш һәм иҗат елъязмасы. 2 чыгарылыш, 1908—1916. М., 1958, 327 б.*

Күренекле азәрбайҗан шагыйре Галиәкбәр Сабирның сатирик шигырьләр җыентыгы «Һөд-һөд намә» («Һөд-һөд китабы») басылып чыга. Бу җыентыкны Тукай иптәшләре һәм үзе өчен өч данә Бакудан соратып алдыра.

Ул Г.Сабир әсәрләрен яратып укый, электән үк аның иҗаты белән кызыксына. (1908 елда ул Сабирның «Шикъят» дигән сатирик әсәрен «Мулланың зары» исеме белән татарчага тәрҗемә итә.)

*Мирәхмәдов Г. Г.Тукайның Сабирдан бер тәрҗемәсе хакында. Азәрбайҗан ССР Фәннәр академиясе хәбәрләре, 1954, 5 нче сан; Ганиева Р. Уртак кояшыбыз. «КУ», 1966, 4 нче сан, 90 б.*

**1912 елның ахыры.** «1912 елның ахырында (числосы исемдә калмаган),— дип яза, авыр көннәрдә шагыйрьгә ярдәм кулы сузган профессор Г.Клячкин,— миңа, авыру Тукайны барып карарга үтенеп, татар яшьләреннән берничә кеше килде. Исемдә калганынча, Тукай ул вакытта Московский (хәзерге Киров) урамында номерларда тора иде.

Мин анда неврастения күренешләре белән бергә җитди авыру таптым. Иптәшләре аның мондый нервлы хәлдә булуын буржуаз язучыларның кайберләренең һәм полиция агентларының аны туктаусыз эзәрлекләүләреннән килеп чыккан даими борчылулар аркасында булган, дип уйлыйлар иде».

*«Габдулла Тукай», 1948, 87 б.*

**1912 ел азагы — 1913 ел башы.** «Җан азыклары» шигыре Петербургка килеп җитү белән, Кәрим Сәгыйть, җыентыкка

карата үз фикерен әйтеп, Тукайга хат яза. Хатның караламасы К.Сәгыйть архивында саклана. 21×26 см зурлыктагы кәгазьгә язылган. Текст түбәндәгечә:

«Тукай!

Мин соңгы көннәрдә «Җан азыклары» дигән соңгы шигыреңне кулга төшереп укып чыктым. Моңа кадәр әсәрләрең арасында «Халык әдәбияты» дигәнен бигрәк тә тәкъдир иткән идем. Инде бу «Җан азыклары» минем сиңа булган өметемне арттыра гына түгел, көткәнемне тәкмил итәр дәрәҗәсенә җитештерде. Алты юлдан гыйбарәт «Тәләһһеф», ниһаять, фәсыйх вә балигъ, чын ихласыңнан әйтелгән дөрес шигырь. Фәкать уртадагы ике юлы, астагы һәм өстәге дүрт юлның шәрхе булганга, аны үзегез әйтмәенчә, шәрехләргә калдырсагыз, артыграк булачак иде дип зан итәмен. «Тәләһһеф»нең соңгы ике юлы бигрәк фәсыйх, тәркибе дөрес, пакь, мәгънәсе бөектер.

«Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем»,— дип, нигә һазым нәфес итәсең? Бакчабызда чүп-чар булмыймыни?

«Мин үлгәчтән, карагыз, типмәсеннәр нәгышемә»,— дигән васыятеңне, инша Аллаһ, онытмамын. Дошманнар, нәгышеңә тибү түгел, тәкъдис итәргә мәҗбүр булырлар, дип зан итәмен. Ләкин «дөньядан туйдым, өметем юк» дигән яңа сүзләрең мине кайгырталар. Соңгы хасталыкларың шулай әйттергәндер дип уйлыйм.

«Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна» дип, җитмәсә, тагын күңелне бутыйсың.

«Сагыныр вакытлар» дигәндә, син ник үзеңне иблискә тәшбиһ итәсең?

«Көзге җилләр» өчен мин сине адәм дип кенә түгел, Ходайның иң сөекле адәме дип тәкъдир итәм.

«Йолдыз»дан да куркучы авыл татары — бака, бу бик удачно.

«Буран»: «Йә тишелгәнме Ходайның бихисап зур мендәре» — бу җөмләгә татарлар һич риза булмаслар дип зан итәм.

Минем бу сүземә «Мөнәкъкыйд» дигән ачы хакыйкатьле шигырьләреңне җырлап җавап бирмә. Ачуны китермә.

«Һич берәүнең дә чәчәккә инде китмәс исләре» дигәндә, «берәү» мөфрәд сангысы булып, аның мөзафе булган «исләре»

---

Тәкмил итү — тулы, бөтен итү, канәгатьләндерү.
Фәсыйх — тел ягыннан нәфис эшләнгән.
Тәркиби — төзелеше, сүз тезмәләре.
Һазым нәфес итәсең — үзеңә үзләштерәсең.
Нәгыш — эчендә мәет ята торган табут.
Тәкъдис итү — изге санау.
Тәшбиһ итү — охшату.
Тәкъдир итү — тану, бәя бирү.
Мөнәкъкыйд — тәнкыйтьче.
Мөфрәд сангысы — берлек санда.
Мөзафе булган — кушылган.

сүзе җәмгъ сангысы булуга мин гаҗәпсендем. «Минем исләрем китте» дигән сүз хата бит, минем исем китте, диләр.

Бу сүзләрем өчен мине «Бу хаким ишәк, мәхәббәтсез килмешәк икән, дип сукмә. Хәер, ихтыярың».

*Сәгыйтова Э. Тукайның ике җыентыгы.*
*«КУ», 1970, 1 нче сан, 154—155 б.*

## 1913

**Ел башы.** Сәламәтлегенең көннән-көн начарлана баруына карамастан, Тукай күп эшли. «Ялт-йолт», «Аң» журналларында, «Кояш» газетасында әледән-әле аның әсәрләре чыгып тора. Басылачак «Мәҗмугаи асарь»ен хәзерли. Авыруы көчәюгә дә карамастан, күп яза, күп эшли. Бер истәлегендә Ф.Әмирхан Тукайның соңгы гомерендәге сәламәтлеге турында болай искә ала:

«Төннәрнең берсе иде. Тукайның озак-озак сузылган йөткерүе, минем бүлмәдәге тынычлыкны ярып, бөтен төнге дәһшәте вә куркынычлыгы белән колагыма керде. Менә-менә шул йөткерүләр аның үпкәләрен тәмамга өзеп ташларлар да Тукай дөньядан сәфәр иткән булыр шикелле тоела башлады. Минем бүлмәмнән бер стена белән генә аерылган җирдә дөньяның иң зур серләреннән булган вакыйга (үлем) менә хәзер, хәзер вакыйг булыр шикелле хис ителде. Мин урынымнан торып утырдым, киенеп, Тукай янына кермәкче булдым. Ләкин 2—3 минут үткәндә, Тукай үзе минем янымда иде. Ул йөткеренә-йөткеренә сүз башлады: «Үлемнән качып, синең яныңа кердем әле! Юк, үлемнән түгел, ялгызлыкта үлемнән качып...»

*Әмирхан Ф. Тукай үлем алдында.*
*«Кояш», 377 нче сан, 1914, 2 апрель.*

**1 гыйнвардан — 26 февральгәчә.** «Амур» номерларының 9 нчы бүлмәсендә яшәвен дәвам итә.

**1 гыйнвар.** «Суык» шигырен яза. Шигырь биш бүлектән тора. Шагыйрь январь суыгы турында, Казанның төрле кәсеп вәкилләренең суыкка мөнәсәбәтләре, шул суыкта үзләрен ничек тотулары турында гына яза кебек. Ләкин табигать суыгы белән бәйле картиналар илдәге иҗтимагый тормышны күз алдына китерәләр.

Әнә мичсез кибетләрдә сатучылар «малын сата, бии-бии кулын уып», әнә казенка янына җыелган сукбайлар, «эчтән безгә

---

Җ ә м г ъ  с а н г ы с ы — күплек санда.
К а з е н к а — кабак, аракы кибете.

бишмәт киерт, чикмән киерт» дип, гөнаһсыз шешәгә шакылдатып сугалар; әнә шәкерт белән школьниклар, суык тәэсиреннән араларындагы дошманлыкны онытып, колакларын саклый-саклый йөгерәләр. Яки:

Байлар кигән тиен толып, төлке толып,
Үз фикренчә, Печән базар күрке булып:
Куллар сузу, ялангачлык, ертык җилән
Күренә аңар кызык булып, көлке булып.

Икенче бүлектә шагыйрь Казаннан читкә чыга. Адаштыргыч буранда каршы чыгу ихтималы булган бүрегә эндәшеп, ул болай ди:

Нигә соң син мескен мәҗбүр мужикларны
Талавыңда белә алмыйсың хәт — чикләрне?
Мужик әллә сиңа азык булып туып,
Җирән атын сиңа булсын дип җиккәнме?!

Өченче бүлектә Кабан күле өстендә бай балаларының чыркылдашып тимераякта шуулары, байларны салкын, суык кына куркыта алмавын яза.

Дүртенче бүлектә шагыйрь үзенең ничек итеп «җылынуы» турында юмор белән сөйләп ала. Урамда йөргәндә бик өшегәч, сугышып алырга уйлап, ул, янәсе, берәүнең «яңагына менеп төшә» дә, тегесе артык «җылыта» башлагач, тизрәк торып «сыза».

Соңгы бүлектә исә Тукай җитди тонга күчә һәм Рождество бәйрәмендә русларның бик каты эчүләре, кайберләренең эчеп әрәм булулары, татарларның да алардан калышмый башлаулары турында әйтеп, әсәрне тәмам итә.

*«Ялт-йолт», 49 нчы сан;*
*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 286—287 б.*

«Шиһаб хәзрәт» шигыре басылып чыга.

Тарих һәм этнография буенча хезмәтләре белән танылган күренекле татар галиме Шиһабетдин Мәрҗанине (1818—1889) олылап, аның фикерләрен, дөньяга карашын хуплап, Мәрҗанинең 1918 елда тууына 100 ел тулуга багышлап язган:

Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм,
Шәрафәтләп, туган көнне бу мөхтәрәм;
Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне
Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм.

*«Аң», 2 нче сан.*

«Йокы алдыннан» шигыре басылып чыга. («Русчадан мокътәбәс» дип куелган.)

Кечкенә сабыйның кичен Тәңредән көне буе шаярууларын кичерүен, иртәгә бик матур күңелле көн булуын теләвен тасвирлап язылган.

*«Аң», 2 нче сан.*

**10—25 гыйнвар.** «Ялт-йолт» журналының редакторы Әхмәт Урманчиевка хат яза. Хатта сүз «Ялт-йолт» журналының 1913 ел 50 нче (28 гыйнвар) саны тышлыгында басылган рәсем турында бара. «Яңа ел» рәсеме ярар да, пожалуй; фәкать аның астына «Әзалияттән очып килгән Яңа ел үзенә дөньямызда урын да таба алмый» дип язарга кирәк. Шулай тәфсилләмәсәң, татар аңламый... Минем фикерем шул».

Рәсемдә күктән очып төшеп килгән кеше кыяфәтендәге фәрештә Җирнең кай төшенә утырырга белми, анда штыклар тезелгән. Рәсем рус телендәге «Будильник» дигән сатирик журналдан алынган.

*Урманчиев Ә. «Ялт-йолт» һәм Тукай.*
*«Ялт-йолт», 1913, 55 нче сан, 10 июль;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 119 б.*

**10 гыйнвар.** «1912 елның онытылганнан гына калган хисабы» исемле мәкаләсе «Счет төймәсе» имзасы белән басылып чыга.

Үзе яратып язышкан «Аң» журналы, «Кояш» газетасы чыгуны шатланып яза. «1912 елда караңгы Казан өстенә «Кояш» чыгып, «Йолдыз»ны сүндерде. Шулай ук «Вакыт» белән «Йолдыз» газеталары арасында дини вә дөньяви вак мәсьәләләр буенча еш кына булган үзара сүгешүләрдән көлә.

«Гаяз әфәнде татарларга бераз «чаршау арты» тормышын да язып күрсәтте»,— дип, Г.Исхакыйның (1878—1954) «Теләнче кызы» романындагы порнографик моментларга ишарәли.

Шәрәфетдин Шәһидуллинның «Заман календаре»нда еш кына «Мөхәррир», «Әдип» исеме астында очраклы кешеләрнең рәсемнәрен бастырып чыгаруын тәнкыйтьли.

*«Ялт-йолт», 49 нчы сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 4 т., 336 б.*

Шул ук санда «Шүрәле» имзасы белән «Суык» шигыре урнаштырылган.

*«Ялт-йолт», 49 нчы сан.*

**12 гыйнвар.** «Хәстә хәле» шигырен яза. Шагыйрь үзендәге авыруның җитдилеген аңлап, пессимистик халәттә яши.

---

Әзалият — мәңгелек дөньясы; монда «очсыз-кырыйсыз галәм, космос» мәгънәсендә.

Бар хәятым салкыныннан туңды җан, катты күңел;
Һәр ягында бар җиһанның зәмһәрирдән чик күрәм.
Кышта очкан күбәләк төсле гүзәл кызлар миңа
Ник йөриләр? — дим, кирәксез бер чуарлык дип күрәм.
Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым,
Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм!

*«Аң», 3 нче сан.*

**15 гыйнвар.** «Хәстә хәле» шигыре басылып чыга.

*«Аң», 3 нче сан.*

**22 гыйнвар.** «Яңа басылып чыккан әсәрләр» исеме астында «Вакыт» газетасы «Җан азыклары» китабы басылып чыгу турында хәбәр бирә.

*«Вакыт», 1114 нче сан.*

«Яңа әсәрләр» исеме астында «Хөсни» имзасы белән Тукайның «Җан азыклары» җыентыгына рецензия басыла: «Сабах» көтепханәсе тарафыннан шагыйрьнең рухына панихида укылмаса да, мәзкүр китапта Габдулла әфәнденең татар галәме өчен тыңларга күңелсез бәхилләшүләре бик күп. Менә шуларның барысы җыйналгач, ирекле-ирексез: «Тукай хакыйкый талант иде, татар йөрәген чәлпәрәмә китерә торган бер сүз дә әйтә алмыйча бетә, ахры,— дияргә мәҗбүр буласың»,— дигән юлларны укыйбыз.

*«Идел», 521 нче сан.*

**28 гыйнвар.** «Әнвәр бәк» шигыре басылып чыга (Төркиянең хәрби һәм сәяси эшлеклесе Әнвәр паша (1881—1922) турында язылган).

*«Ялт-йолт», 50 нче сан.*

**21 гыйнвар.** «Идел»дә Тукайның «Җан азыклары» исемле китабы басылып чыгып, сатыла башлавы турында игълан бирелгән.

*«Идел», 523 нче сан.*

«Амур» фәхеш ресторанны...» дип башланган шигырен Тукай шушы «Амур» кунакханәсендә яшәгән чорда язган булса кирәк. Тукай яшәгән 9 нчы бүлмә ресторан белән янәшәдә генә була.

*Биш томлы «Әсәрләр», 2 т., 338 б.*

**1 февраль.** «Даһигә» шигыре басылып чыга.

*«Аң», 4 нче сан.*

Вафатына ике ай чамасы калган вакытта да татар милли азатлык хәрәкәтендә сизелгән тернәкләнү, җанлану күренешләре турында уйлана һәм татар халкын колониаль изүдән коткару, аны иҗтимагый-мәдәни яңарышка алып чыгу юлларын эзләгән Даһи образын иҗат итә. Шагыйрьнең:

Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ошбу юлда син,
Чын сөбатлә алга бардың, бакмый уңга-сулга син,—

дигән юллары тулысы белән татар милли азатлык хәрәкәтенең танылган вәкиле Гаяз Исхакый шәхесенә һәм аның әдәбисәяси эшчәнлегенә туры килә. Милли азатлык һәм Яңарыш идеалларын тормышка ашыру юлында ныклыгы, тайпылмаслыгы өчен Тукай Гаяз Исхакыйны «Даһи» дип атый. Азатлык идеалының татар милләте өчен әле һаман да тормышка ашырылырга тиешле бөек максат булып калуы турында Тукай:

Артка бакма, Даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла табылса — Аллаһ ул!

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 271—272 б.;*
*Лаисов Н. Габдулла Тукай, 1985, 79 б.;*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 43—44 б.*

**1 февраль.** «Толстой сүзе» (Зур бәхет инсанга) шигыре басылып чыга. Үләр алдыннан язылган ике генә юлдан торган бу шигырьдә Тукай үзенең фәлсәфи-этик карашларын гәүдәләндерә. Бөек рус язучысы кебек, ул да кешеләрне әхлакый камиллеккә чакыра:

Зур бәхет инсанга — һәр көн, һәр сәгатьтә яхшыру;
Яхшыру юк, булса анда: — Яхшы мин! — дип лаф ору.

Яхшы кеше булыр өчен һәрдаим камиллеккә омтылу кирәк, дигән карашлар Тукайның башлангыч чор иҗатында да чагылган иде. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр шагыйрь Л.Н.Толстойның әдәби-эстетик һәм этик карашларына турылыклы булып кала.

*«Аң», 4 нче сан;*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 44—45 б.*

**14 февраль.** «Кояш»та түбәндәге игъланны укыйбыз: «Габдулла Тукаевның адресын сораучыларга: — «Кояш» адресын язып, «Габдулла Тукаевка» дип арттырасыз».

*«Кояш», 49 нчы сан.*

---

Сөбатлә (сөбат илә) — ныклык белән.

**17 февраль.** «Җан азыклары» китабы чыгу турындагы игълан («Вакыт», № 1078) кабатлап басылган.

*«Вакыт», 1135 нче сан.*

**21 февраль.** Казанда «Сабах» ширкәте наширлегендә, Шиһап Әхмәров (1884—1966) редакторлыгында (барлыгы 25 сан) чыккан «Мәктәп» журналының 1 нче саны дөнья күрә. Бу журналның берничә санында Тукайның әсәрләре басылган.

«Олугъ юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре» шигыре басылып чыга. Бу Романовлар династиесенең Россиядә патшалык итә башлавының 300 еллыгы уңае белән язылган шигырь. Шагыйрь авыру хәлендә дә татар дөньясында һәм ил күләмендәге вакыйгалардан хәбәрдар, алай гына да түгел, шуларга үзенең мөнәсәбәтен белдерергә тырыша. Ул рус халкына, алдынгы рус культурасына олы ихтирам белән карый.

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.
Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,
Без шаярыштык вакытлар алмашып.
Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? —
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.
Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.

*«Мәктәп», 1 нче сан.*

Февраль ахырына таба Тукайның саулыгы тәмам начарлана. Бу вакыттагы физик һәм рухи халәтенең ни рәвешле булганын дусты Ф.Әмирхан истәлегеннән беләбез. Шагыйрьнең көндез дә, төнлә дә горык-горык йөткергәне аермачык ишетелеп тора.

«Һәрбер көн генә түгел, бәлки, һәрбер сәгать, һәрбер йөткерүнең аның гомереннән бер кисәген кубарып алганлыгын без генә түгел, ул үзе дә белә вә аңлый иде. Ләкин бу турыда ул тел белән сөйләргә яратмый иде.

Соңгы көннәрдә ул ялгызлык сөя вә ялгыз дәкыйкаләрендә тирән бер уйга батып утыра вә шул уйланудан үзенә бер итмиэнане калеп тапкан шикелле була ки, уйлану дәкыйкаләреннән соң, тереклек хакында якты вә өметле нәрсәләр сөйләп куя иде».

*«Кояш», 1914, 2 апрель;*
*Әмирхан Ф. Тукай үлем алдында.*
*«Истәлекләр», 1986, 220 б.*

**25 февраль.** Больницага китәр алдыннан, дусты Фатыйх Әмирхан белән саубуллаша. Ф.Әмирхан болай искә ала:

---

Итмиэнане калеп — күңел утыру.

«Иртәгә иртә белән Больницага илтеләчәк дигән төнне ул минем белән күрешергә кергән иде. Сабыйларчарак шат йөз белән ул: «Мин иртәгә Клячкинга керәм, мин киткәндә, син тормаган булырсың... Моннан соң күрешмәсәк... хуш инде!» — диде. Докторлар аркылы миңа инде аның бер ай, күп булса, ай ярым гомере калганлыгы мәгълүм иде. Бу «хуш»ның да ахыргы «хуш!» икәнлеге билгеле иде. Алай да мин аңар: «Тиз терелеп чык, тиз күрешик!» — дидем. Ул, бүлмәдән чыга башлап: «Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә»,— диде һәм чыгып китте».

*Әмирхан Ф. Тукай үлем алдында.*
*«Хатирәләр», 172 б.*

**26 февральгә кадәр.** Ш.Әхмәров истәлегеннән күренгәнгә, Тукай шифаханәгә кереп ятар алдыннан аңа: «Ике-өч төн йокламыйча, «Мәҗмугаи асар»емне тәртипкә салдым, шул мине бөтенләй эштән чыгарды»,— дип сөйләгән булган. Бу басманы, тулысынча булмаса да, башлыча, үзе башкарган.

*Әхмәров Ш. Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы. «Мәктәп», 1913, 4 нче сан, 107 б.*

**26 февраль.** Иптәшләренең киңәше белән, айга 150 сум хак түләргә килешеп, Тукай Казанда Клячкин шифаханәсенә керә. (Казанның хәзерге Кави Нәҗми һәм Островский урамнары чатындагы шифаханә.) Биредә шагыйрьне врач Р.А.Лурия дәвалаган.

Бу турыда үзе «Ике ихтар» дигән мәкаләсендә дә яза. «Могътәбәр табибләрнең катгый киңәш вә карарларына буйсынып, 26 нчы февральдә Казанның Клячкин шифаханәсенә кереп яттым. Шуңар күрә үзем тәэсис итешкәннән бирле эшләп килдегем «Ялт-йолт» журналының секретарьлеген башка кешеләргә тәслим иттем. Шуңар күрә журналда моннан соң басылган һәммә мәзмуннар өчен үземне мәсьүл күрмәячәкмен».

*Фәйзуллин М. Тукайны кем дәвалаган?*
*«Социалистик Татарстан», 1985, 226 сан;*
*«Хатирәләр», 174 б.;*
*«Ялт-йолт», 53 сан, 5 март.*

**Февраль.** Клячкин больницасына кергәч тә Фатыйх Әмирханга хат яза.

«Больница хадимнәре миңа: «Ник алданрак больницага кер-

---

Тәэсис итешү — нигезләшү, оештырышу.
Тәэслим итү — тапшыру.
Мәзмун — эчтәлек.
Мәсьүл — җаваплы.

мәдегез?» — диделәр. Мин аларга: «Без больницаны үлемнең әүвәл стансасы дип беләмез. Аз булса да дөньяда торып калыйм, дип әйттем»,— дидем» дип белдерә.

*«Кояш», 1914, 377 нче сан;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 120 б.*

**26 февральдән соң.** Шифаханәдә профессор Клячкин белән берничә мәртәбә очраша.

Клячкин үзенең истәлегендә аның гаять киң карашлы, фикер алышу өчен күңелле кеше булуына басым ясый:

«Дәвалау өчен кергән вакытларда мин аның белән танышып, тиздән мин аның башкалар белән тиңләштермәслек кызыклы, киң карашлы, акыллы бер кеше икәнлеген белдем.

Больницада ихтыярсыз эшсез ятарга мәҗбүр булган Тукай миңа җитди әдәбият табып бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итте. Мин аңа Һейненең русчага тәрҗемә ителгән шигырьләренең кулымда булган җыентыкларын бирдем. Болардан тыш, таныш адвокатым О. аркылы политик әдәбияттан да кайбер китаплар табып бирә алдым. Бу китаплар арасында «Колокол»ның аерым номерлары, Герценның «Былое и думы» дигән әсәре, Чернышевскийның «Что делать?» әсәре һ.б. барлыгы хәтеремдә. Ул бу әдәбиятны зур кызыксыну белән укый иде».

*Гордлевский В. Тукай һәм рус әдәбияты.*
*Габдулла Тукай, 1948, 87 б.*

**1 март.** «Юбилей мөнәсәбәте белән» дигән мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән басылып чыга. Мәкалә Романовлар нәселенең Россиядә патшалык итүенә 300 ел тулу уңае белән уздырыла торган бәйрәмгә багышланып язылган.

*«Ялт-йолт», 52 нче сан.*

«Аң» журналының 6 нчы саны дөнья күрә. Биредә «Шөһрәт» һәм «Кыйтга» («Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым...») дигән шигыре урнаштырылган. «Кыйтга» шигыре үкенеч тойгысы белән сугарылган. Шагыйрь гомеренең соңы җитүен аңлый кебек.

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.
Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.
Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч, шул булды эш,
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

*«Аң», 6 нчы сан.*

«Шөһрәт» шигырендә шагыйрьнең әйтергә теләгән фикере: дәрәҗә һәм шөһрәт артыннан куу кешеләрнең әхлагын

боза, иҗади эшкә аяк чала. Бу тема аның иҗатында баштан азаккача дәвам итә.

Яз язу, ләкин кызыкма һичвакыт шөһрәткә син;
Бик төренмә иртәгүк артык булыр чүпрәккә син.

«Яз язу» дигән тәгъбир үзе генә дә шигырьнең каләм иясенә багышлануы турында сөйли. Тукайча, шөһрәт ул — бу фани дөньяда вакытлыча гына ялтырап, алдап торучы чүпрәк. Үзен әдәбиятка-сәнгатькә багышлаган кешеләр җир тормышын күңел тәрәзәсе аша кабул итәргә тиешләр:

Тапмасам шөһрәт, сизмәсләр димә күңлемдәген,
Зур тәрәзә бар дип аңла дөньяга күкрәктә син.

Шөһрәт мәсьәләсенә тискәре карашлар Тукай иҗатына Шәрык дини-суфичылык әдәбиятыннан ук кергән. Шагыйрьлек таҗын кигән бөек шәхес булса да, Тукай шөһрәт чире белән авырмый. Әдәби иҗатта ул халыкчан, ә көндәлек яшәештә гади халык улы булып калды.

*«Аң», 6 нчы сан;*
*Р.Ганиева. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 45—46 б.*

«Кояш» газетасында Тукайны Казанның Клячкин больницасына озату хакында хәбәр басылган.

*«Кояш», 60 нчы сан.*

**3 март.** «Кояш» газетасы «Авыруларыбыз» дигән баш астында Г.Тукай һәм Г.Камалның (ул Төркиядән авырып кайта) больницада ятуларын һәм аларның сәламәтлекләренең торышын хәбәр итә.

*«Кояш», 61 нче сан.*

**4 март.** Тукай Л.Н.Толстойның иҗатын хөрмәт итә, аны укый, даһилыгын таный.

Немец язучысы В.Поленцның «Крестьянин» романына язган сүз башында Л.Н.Толстой ашау-эчүнең кеше тормышының төп максат булмыйча, яшәү өчен чара гына булырга тиешлеген әйтә. Тукай исә, әлбәттә, ул текст белән таныш, укыган.

Клячкин шифаханәсендә ятканда ул, остазының әлеге сүзләрен исенә төшереп, «Толстой сүзе» дигән икеюллык шигырен яза.

Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга,
Кирәкми тик ашарга дип яшәргә.

Шигырьнең кулъязмасы Г.Ибраһимов исемендәге Тел һәм әдәбият институты Мирасханәсендә саклана.

*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 8-эш;*
*М.Мәһдиев. Шагыйрьнең зур бер остазы. «Социалистик Татарстан», 1986, 17 октябрь.*

**5 март.** «Ике ихтар» мәкаләсен яза. «Ялт-йолт»ның 1 март санында басылып чыккан «Юбилей мөнәсәбәте илә» дигән мәкаләсенә карата аңлатма бирә: «Әле генә үткән 52 нче номердагы баш мәкалә гәрчә минем мәкаләм булса да, хәзер мин андагы мәгънәләрдән шактый читтә торам. Чөнки ул мәкалә — гимназия вә приют мәсьәләсенең беренче генә шаулашы вакытында вә әллә кайчан язылып ташланган язудыр».

*«Ялт-йолт», 53 нче сан.*

**10 март.** Больницада ятучы шагыйрьнең хәле турында газеталар, шул исәптән «Кояш» үз укучыларына хәбәр биреп торалар. «...эсселеге 38$^{0}$, тамыр тибүе 103. Моннан элекке көннәрдә эсселеге 36,6 белән 39,7 арасында, тамыр тибүе 96 белән 120 арасында булды. Соңгы көннәрдә алмашынулар элеккегә караганда азрак. Үзен яхшы вә элеккегә караганда уңайрак хис итә. Укымый тора алмый. Газеталар укый».

*«Кояш», 67 нче сан.*

«Мөхәрриргә» шигырен яза. Тукайның соңгы шигырьләреннән берсе. Бу шигырьне үлеменә 23 көн кала язган. Сөргеннән кайткан Гаяз Исхакыйны лаеклы каршылау өчен барган кампания уңае белән язылган. Мөхәррир Г.Исхакый 6 ел сөрген, төрмә һәм качудан Казан шәһәренә керә алмаган.

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!
И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!
Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмале!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!
Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилях,
Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.
Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.

---

Мөхәррир — язучы.
Кибриа — олылык (монда: Аллаһ тәгалә мәгънәсендә).
Мосаувир — художник.
Лөгать, истилях — сүзләр, терминнар.
Зыя — яктылык, аң-белем.

Алты елда торды чупансыз, аерылышты яшь көтү,
Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.

*«Мәктәп», 3 нче сан, 24 март;*
*Тукай мәҗмугасы. Токио. Матбагаи Исламия, 1933, 207 б.;*
*Мөхәммәд Аяз Исхакый. Хәйәте вә фаалияте. 100 догум елы долайысыйла. Анкара. «Ай-йолдыз» матбагасы, 1979, 177 б.;*
*«Социалистик Татарстан», 1989, 9 апрель.*

**Март.** Тукайның хәле начарлана, температурасы гел югары тора. Үзе һаман көндәлек матбугатны күзәтеп, укып барырга тырыша.

Дусларыннан Шиһап Әхмәров истәлегеннән түбәндәгеләрне укыйбыз: «Барганда һәрвакыт матбугат хакында сүз ача вә төрле мөляхәзәләр булына иде, рус газеталарын да моталәга иткәли иде. Фәкать соңга таба күзем арый, ятып каршы тотып укыганда кулларым тала, дип зарлана башлады.

Шифаханәгә хәлен белергә баруны бик ярата иде, барган вакытта яткан булса, торып утыра вә янындагы кеше киткәнче, утырып сөйләшә иде.

Соңгы көннәргә кадәр ашау-эчүендә бер дә алмашыну булмады, яхшы ашый һәм эчә иде. Температурасы $38^0$ илә $38{,}5^0$ араларында, пульсы 100—105 тирәләрендә иде».

*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 14-эш;*
*Әхмәров Ш. Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы. «Истәлекләр», 223—224 б.*

**14 март.** «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсен яза. Бу аның Клячкин шифаханәсендә язылган озын һәм иң ахыргы мәкаләсе. Мәкаләдә ул үзенең иҗатына тәнкыйть ясый. Кайбер уңышсыз шигырьләр язуына ачына, аларның меңләгән халык кулында укылып йөрүенә уңайсызлана. Киләчәктә һичбер нәрсәгә карамый, фәкать үзенең җаны сөйгән шигырьләреннән генә җыеп мәҗмугасын бастырырга вәгъдә бирә*.

*«Кояш», 71 нче сан.*

**15 март.** «Ялт-йолт»ның 53 нче саны тышлыгында ат койрыгы тотып торган берәүнең рәсеме төшерелгән. Өстә: «Габди» дип куелган (Г.Ибраһимовның яшерен имзасы).

---

* Тукай вәгъдә иткән, үзе беркат сайлап туплаган бу җыентык 464 бит күләмендә «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре» исемендә (Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, 1914 ел) Җамал Вәлидинең мәкаләсе белән һәм шагыйрь иҗаты турында зур тикшеренү сүз башы белән басылып чыга.

Ч у п а н (ч а б а н) — көтүче.

Аска: Ул тота ат койрыгын да: «Бик озын сач»,— дип куя.

«Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаҗ»,— дип куя. Тукайның «Җан азыклары»нда басылып чыккан «Мөнтәкыйд» шигыренең ике юлы китерелгән.

Журналның бу санында «Ике ихтар» мәкаләсе «Шүрәле» имзасы белән һәм «Матбугатымызның фәсахәт» намунәләре» мәкаләсе «Гөмберт» имзасы белән басылганнар. «Мәктәп», «Акмелла», «Аң» журналлары һәм «Кояш», «Идел» газетасы битләрендәге төрекләштерелгән кайбер бик чуар телле, гарәпчәдән алынган гыйбарәләр тулып яткан мәкаләләрдән, яки мәгънә ягыннан буталчык, түбән булган өзекләр мисал итеп алынган һәм шуларга «Ялт-йолт» журналы исеменнән тәнкыйть фикерләрен әйтеп, алардан көлеп язылган: «Рәфикымыз «Аң»га татар матбугатындагы бу кеби «фәсахәт» намунәләрен күп күрсәтмәскә киңәш бирәбез»,— дип тәмамланган.

*«Ялт-йолт», 53 нче сан.*

**15 март.** «Толстой сүзе» (Кирәк анчак...) шигыре басылып чыга. Яшәү фәлсәфәсен чагылдырган бу икеюллык шигырьнең нигезендә халык мәкальләре традициясе һәм Толстойча белдерелгән фәлсәфи-этик карашлар ята. Кешеләр җирдә ни өчен яшиләр? Әллә байлык туплау өчен генәме? Мондый сорауларга Тукайның җавабы болай:

Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга,
Кирәкми тик ашарга дип яшәргә.

Җирдә яшәүнең максаты, Тукай фикеренчә, халыкка хезмәт итү идеалларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән булырга тиеш.

*«Аң», 7 нче сан;*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 46 б.*

**18 март.** Фатыйх Әмирханга Клячкин больницасыннан хат яза.

«Фатыйх!

Мәкаләне бик сирәк нәрсәне баскан кеби зурлап баскансыз. Рәхмәт. Тагы да язмый булмас, ахры, дип торам әле»,— дип, секретаре Ф.Әмирхан булган «Кояш» газетасында (74 сан) басылып чыккан «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсе өчен рәхмәт белдерә. Шунда ук «Кояш»ның редакторы Зәкәрия Садретдиновка сәлам күндерә. Вакытлы матбугат белән системалы кызыксынуы да күренә хаттан: «Кояш» тәртипсез килә.

---

Фәсахәт намунәләре — матурлык үрнәкләре.

Соң килә. 72 нче номер бер көндә өчәү килде. Бу көнге номер икәү килде. 73 не исә бөтенләй күргәнем юк. Зинһар, хәзер бер номерын җибәрсәгез иде»,— дип үтенә.

*Гайнуллин М., Вәзиева Җ. Татар әдәбияты. XX йөз, 1977, 122 б.;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 121 б.*

«Уянгач беренче эшем» мәкаләсе басылып чыга.

Башка талантлы язучылар һәм фикер ияләре шикелле, Тукай да үз әсәрләренә тәнкыйть белән караган. Хәле авыр булуына да карамастан, ул үз әсәрләрен яңадан күздән кичереп, башлангыч чорында язылган кайбер уңышсыз әсәрләрен «Яраксыз»га чыгарган.

Бу мәкаләсендә ул «Кичке азан», «Шәкерт яхуд бер тәсадеф» кебек шигырьләрен бернигә торгысыз әйберләр дип атый да, шундый шигырьләренең үз теләгеннән башка әллә ничәшәр кат басылып таратылуына борчылып, түбәндәге юлларны яза:

«Соң, боларның җидешәр ел буена бүлмәмдә ятуына ни сәбәп булган? Менә шул чүпләрнең язылуына нинди кабахәт вә кара көч сәбәп булса, шул сәбәп булды... Инде мин аларны себердем... Бүлмәмдә «үз сөйгәнем», «үзем сөйгән шигырьләрем» генә калдылар...»

Шунда ук ул, әлеге начар әсәрләре белән аны битәрләргә тырышучы тәнкыйтьчеләрнең мәкаләләрен басмаган өчен, «Вакыт», «Шура» һәм «Идел» редакцияләренә рәхмәтен дә белдерә:

«Әгәр алар мине үз-үземә дә, кешегә дә шул шигырьләр белән тәкъдим итсәләр, мәлгунанә бер сурәттә шаркылдып көлсәләр, вакыйган, максатларына җитәрләр иде. Ләкин миңа эш башында рух биргән идарә мөхәррирләре эш уртасында мине мәсхәрә иттермәделәр. «Теге»ләрнең мәкаләләре дә басылмадылар».

*«Кояш», 74 нче сан.*

**20 март.** «Аң» журналы редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәнидән хат ала. Биредә Хәсәни: «Аң»ның 8 нче санына кертү өчен «Бер мөхәрриргә» исемле шигыреңезне бирергә вәгъдә иткән идеңез. Шушы записка белән барган әфәндегә биреп җибәрсәңез, мәмнүн булыр идем»,— дип яза. Сүз «Мәктәп», 3 нче сан (24 март) журналында «Кыйтга» исеме белән басылган шигырь турында бара.

*Мирасханә, 9-ф. 2-тасв., 17-эш.*

---

Мәлгунанә — ләгънәтле.

Әхмәтгәрәй Хәсәнигә Клячкин больницасыннан хат яза. Хәсәнинең хатына каршы җавап рәвешендә язылган: «Бер мөхәрриргә» шигыремдә «Аң»га лаек дәрәҗәдә үк нәфасәт күрмәгәнемә күрә, «Мәктәп» журналына бирдем. Анда да ул шигырьне баш сәхифәгә керттермәдем. Ахырда вә незаметныйрак җирдә китәчәк». Тагын яңадан «Аң» журналына килеп: «7 нче санда минем шигырь бик аз вә кешегә сизелерлек аз кергән. Өстәп җибәрергә бер нәрсәм бар иде. Инде, әлбәттә, соңдыр. Инша Аллаһ, 8 нчедән дә гафил калмам. Бер шәй язармын»,— дип вәгъдә итә.

*Мирасханә. 9-ф., 2-тасв., 17-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 123 б.*

**24 март.** «Мөхәрриргә» шигыре «Бер кыйтга» исеме белән басылып чыга.

*«Мәктәп», 3 нче сан.*

**28 март.** «Толстой сүзләре» шигырен яза. Социаль эчтәлекле бу шигыре мәснәви жанрында язылган. Тукай, Толстой кебек, фәкыйрь кардәшләрен изгән байлар дөньясын күрә алмады, аларны кешелексезлектә, әхлаксызлыкта гаепләде.

Тәмле булганга гаҗәпләнмә бу байлар ашлары,
Күп вакыт борчы, тозы — мискин гидайлар яшьләре.

Шушы ике юлда никадәр социаль контрастлар күренә.

Толстойның дини-этник карашларын яхшы үзләштергән Тукай да фәкыйрь кардәшләрне изүчеләргә, алар хисабына баючыларга җан тынычсызлыгы, вөҗдан газаплары вәгъдә итә. Ул да, бөек рус язучысы кебек, сыйнфый каршылыкларны әхлакый ноктадан чыгып бәяли.

Җан тынычланды, димә, булганча малда артыгың,
Артык ул — алганга нәмәгълүм гарибләр актыгын.
Эстәмисең буй бөгәргә? Ирнәсең эшләргә эш?
Йә телән син, йә фәкыйрь кардәшеңне көчләргә кереш!

«Толстой сүзләре» шагыйрьнең үләренә биш көн калгач, шифаханәдә язылган. «Мәрхүм Тукаевның ин соңгы шигырьләре» дигән баш астында үзе үлгәч басылып чыга.

*«Аң», 8 нче сан (10 апрель);*
*Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы, 2002, 47 б.*

«Буш вакыт» шигырен яза. Шифаханәдә язылган иң соңгы шигырьләреннән. «Толстой сүзләре», «Мәктәп» шигыре дә бер

үк кәгазьдә язылып, азагына 28 апрель дип куелган. Вафатыннан соң (10 апрельдә) басылып чыга.

Шигырьнең кулъязмасы Мирасханәдә саклана.

*«Аң», 8 нче сан;*
*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 8-эш.*

«Мәктәп» шигырен яза. Бу шигырь шагыйрьнең теләге, васыяте — милләтен мәгърифәткә өндәү. Тормышның матди ягын кайгырту белән генә чикләнмичә, рухи алгарышка, үсешкә, аңбелемгә омтылып, рухи, көр яшәргә чакыру булып яңгырый:

Мәкаль бардыр: «Урыс байса — сала аулында дәү чиркәү;
Татар байса — хатын асрый, була хатыны өчәү-дүртәү».
Гүзәл тасвир кыйлынса, бу мәкальдән ушбудыр матлаб:
«Урыс байса — сала чиркәү, вәләкин әүвәле — мәктәп».

Шигырьнең кулъязмасы Мирасханәдә саклана.

*«Аң», 8 нче сан;*
*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 8-эш.*

«Кыйтга» («Хәзрәте Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш...»), «Казан» шигырьләрен яза. Болар, шулай ук үзе үлгәч, 20 нче апрельдә басылып чыгалар. Шигырьнең ахырына «Соңгы шигырьләреннән» дип куелган.

*«Мәктәп», 4 нче сан.*

«Аң» журналының секретаре Зәйнәп Хәсәнигә Клячкин больницасыннан хат яза.

«Мөхтәрәмә Зәйнәп ханым.

8 нче санга бер кадәремне җибәрдем. Беренче корректурасын үземә күрсәтсәңез икән. Аннан соң шушы язылган микъдар шигырьнең һәммәсе бер номерга кереп бетсә иде. Шулай булганда, ул шактый көч булырлык. Хәер, «Толстой сүзләре»нең бер икесен цензор бозар кеби сизәм. Ул вакыт һәммәсенең басылуы мәҗбүри үк булыр» дип язып, үзенең «Аң»ның 8 нче номерында соңгы шигырьләре булган «Толстой сүзләре», «Буш вакыт», «Мәктәп» исемле шигырьләренең язмышы өчен борчыла. («Аң» журналының 8 нче саны, Тукай үлгәч, 10 нчы апрельдә чыга.)

*Мирасханә. 9-ф., 1-тасв., 8-эш;*
*Биш томлы «Әсәрләр», 5 т., 124 б.*

---

Тафсир кыйлынса — аңлатылса.
Матлаб — теләк.

**31 март, көндез сәг. 1—2ләр.** Доктор Р.А.Лурия килә, авыруны бик дикъкать белән карап, сорашып, аны өметләндерә торган сүзләр белән юата. Тукай яныннан чыккач, аны көтеп торган иптәшләренә (Ш.Әхмәров, Әмин Мостафин, Габдулла Кариев), авыруның хәле ничек, дип сорауларына каршы доктор: «Сездән яшерүне кирәк дип тапмыйм, авыруның хәле яхшы түгел, бик күп торса, 3—4 көн торыр, авыруның үзенә белдермәгез, ялгызын гына калдырмагыз»,— ди. Дуслары, фикердәшләре аның янына еш килеп йөриләр, моннан соң чиратлашып яныннан китмичә саклыйлар.

*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 14-эш.*

**31 март, кич сәг. 5ләр.** Авыруның хәле кинәт начарлана. Температурасы күтәрелә, пульсы ешая, тын алуы авырлаша. Ашаудан калып, бу төнне йоклый алмый чыга. «Бердән авыраеп, ашау-эчүдән вә йокыдан тәмам киселде... Хәлен белергә килүчеләр белән бәхилләшә, аз сөйләшә вә сораган сөальләргә дә бер сүз яхуд баш ишарәсе илә генә җавап бирә башлады».

*Әхмәров Ш. Габдулла әфәнде*
*Тукаевның авыруы. «Истәлекләр», 224 б.*

**1 апрель.** Тукай янына больницага аның хәлен белергә шагыйрь Габдулла Харис белән татар журналисты Шәриф Байчура баралар. Бераз, 15—20 минут сөйләшеп, тизрәк сәламәтләнү теләп саубуллашып чыгалар.

*Мирасханә. 9-ф., 4-тасв., 23-эш.*

Мәһруй Мозаффария дус кызы Фатыйма Дәүләтгилдиева белән Тукайның хәлен белер өчен Клячкин шифаханәсенә киләләр һәм Тукайның тизрәк сәламәтләнүен теләп, саубуллашып китәләр. Истәлектән күренгәнчә:

«Сәгать өчне узган иде. Иптәшләреннән икесе аның янында иделәр... Без якынрак барып утырдык һәм: «Шәкерт туташларымыз сезнең сәламәтләнүегезне теләп калдылар. Сезнең шигырьләрегезне укып бик тәэсирләнәләр»,— дидек.

...Аның яныннан без инде бик авыр тойгы белән аерылдык».

*Мозаффария М. Тукай янында.*
*«Истәлекләр», 225 б.*

**1 апрель, иртән сәг. 11 тирәсе.** Ш.Әхмәров сөйләве буенча: «...хәлегез ничек» дип соравыма «әҗәл» диеп бер сүз илә җавап бирде дә, бераздан соң: «Хәлем авыр, болай булса, өч

көннән артык чыдый алмам»,— диде. Шул ук көндә доктор да: «Авыруның хәле начар, озак торса, өч көн торыр, алайга да бармас, сез инде аны ташламагыз, дуслары җыелышып, бер тәртип илә һәрвакыт берегез янында булыгыз»,— диде.

*Әхмәров Ш. Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы. «Истәлекләр», 224 б.*

**1 апрель, өйләдән соң.** Хәле кискенләшкәнне күреп, дуслары Тукайның рөхсәте белән фотограф Г.Якобсонны чакыралар, һәм ул шагыйрьне урын өстендә тезләрен кочаклап утырган килеш һәм кулларын баш астына куеп, ике мендәр өстендә яткан көенчә рәсемгә төшерә.

Тукай башлыча рәсемнәргә дуслары, танышлары, фикердәшләре белән төшәргә яраткан. Бу — исән чактагы соңгы рәсемендә дә ул дуслары белән. Баш очында утырганнар — халкыбызның атаклы артисты Габдулла Кариев, күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Сәйфи-Казанлы, журналист Шиһап Әхмәров. Нәкъ менә алар шифаханәдә Тукайның соңгы көннәрен күргәннәр, соңгы сулышынача янында булганнар.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 67-эш;*
*«Яңалиф», 1927, 3 нче сан;*
*Гарифуллин Д. Шагыйрьнең соңгы рәсеме. «Шәһри Казан», 1994, апрель.*

Үләр алдыннан Тукай наширләрдән алачак биш йөз сум акчасын бер ятим татар баласын стипендия биреп укыту өчен тотарга кушып, телдән васыять әйтә.

*Нуруллин И. Габдулла Тукай, 1979, 5 б.;*
*«Йолдыз», 1913, 14 апрель;*
*«Кояш», 1913, 88 нче сан.*

**1 нче апрельдән 2 нче апрельгә каршы төн.** Докторларның киңәшен тотып, бу төнне аны дуслары Ш.Әхмәров һәм Ә.Урманчиев саклап чыгалар. «Бу төндә хәле беркадәр яхшыланды: кыска-кыска, өзеп-өзеп булса да йоклады. Үзе дә: «Бүген беркадәр йоклый алдым, кәефем ярыйсы»,— дип сөйләде, ди Ш.Әхмәров».

*«Хатирәләр», 175 б.*

**2 апрель, иртән.** Иртән чәй эчәргә утыргач: «Бергә эчик»,— диеп, Ә.Урманчиев һәм Ш.Әхмәров (алар авыру шагыйрь янында төн үткәргән булалар) белән сөйләшә-сөйләшә чәй эчәләр. Чәйдән соң: «Без китәбез»,— дигәч, «Кичкә тагын

килсәгез, бик яхшы булыр иде, бүген уңай булды»,— диеп саубуллашып кала.

*Әхмәров Ш. Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы. «Истәлекләр», 224 б.*

**2 апрель.** Кичке сәгать алты. Больницага Тукай янына «Аң» журналы редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни килә. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, Тукай, гадәтенчә: «Актык корректура кайчан?» — дип сорый. Хәсәни, ул сораган корректура янында булса да, йә хәзер үк торып төзәтә башлар дип, аны кызганып: «Иртәгә була»,— ди.

Бу вакытта Тукай янында дусларыннан Әмин Мостафин була. Ә.Хәсәни Тукай янында 7 сәг. 30 минутка кадәр була һәм саубуллашып чыга.

*«Хатирәләр», 177—179 б.*

**2 апрель, кичке 8 сәг. 15 мин.** Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның йөрәге тибүдән туктый. Җан биргән вакытында аның янында Әмин Мостафин була.

*Мирасханә, 9-ф., 4-тасв., 14-эш.*

**3 апрель һәм аннан соң.** Тукайның үлеме турында газета-журнал редакцияләренә һәм бүтән шәһәрләрдәге дусларына-иптәшләренә хәбәр ителә, телеграммалар җибәрелә.

Татарлар яшәгән күп төбәкләрдән, Петербург, Мәскәү кебек шәһәрләрдән газета-журнал редакцияләренә Тукайның үлеменә тирән кайгы белдергән чиксез күп тәгъзия (кайгыны уртаклашу) телеграммалары, хатлар килә. Вакытлы матбугатта шагыйрьнең үлеме мөнәсәбәте белән дусларының, аны белгән, аралашкан иптәшләренең язган шигырьләре, мәкаләләре басыла.

Профессор Н.Ф.Катанов: «Шагыйрьнең үлеме бөтен халык өчен зур бер милли хәсрәткә әйләнде. Мәрхүм шагыйрьнең биографиясе һәм хатирәләр белән, шигырьләренең һәм талантының кыйммәтен тәкъдир итеп язылган мәкаләләр белән бөтен татар газеталары тулды»,— дип яза.

*«Инородческое обозрение», 1913, 3 нче сан.*

**3 апрель.** «Кояш» газетасында Тукайның хәле үтә авыр булуы турында түбәндәге хәбәрне бастыра: «Казан хәбәрләре. Авыру шагыйремез Габдулла әфәнде Тукаевның авыруы соңгы көннәрдә тагы да көчәеп торганлыгын тәэссеф белән хәбәр бирәләр.

---

Тәэссеф — үтенеч.

Соңгы көннәрдә яшьләрдән бер фирка нәүбәтләп аның янында торалар».

Бу хәбәр басылып чыкканда, Тукай инде вафат булган була.

*«Кояш», 87 нче сан.*

**4 апрель.** Г.Тукайны күмү көне. Ул көн чыккан газета битләре кайгылы мәкаләләр белән тулы. «Сабах», «Мәгариф», «Гасыр», «Юл» кибетханәләре ябык. Тәрәзәләренә кара рамка эченә Тукайның матәм рәсемнәре куелган. Газета-журнал идарәләре дә иртәдән үк ябык, эшләми.

Тукайның җеназасы өйләдән соң сәгать бердә Клячкин шифаханәсеннән чыгачагы бөтен шәһәр халкына таралып өлгергән.

Иртәдән үк шагыйрь белән соңгы мәртәбә хушлашырга халык төркеме җыела башлый. Тукайны күреп калырга теләүчеләргә кереп, күреп чыгарга рөхсәт бирелә.

Кибетханәләр, газета-журнал идарәләре, дуслары, иптәшләре, студентлар, «Сәйяр» труппасы артистлары, «Шәрык» клубы вә башкалар тарафыннан Тукайга соңгы бүләкләре итеп әзерләнгән чәчәкләр килә башлый. Һәркайсы чәчәкләргә ефәк лентала р бәйләп, үзләренең сөекле шагыйрьләренә әйтеп калачак соңгы сүзләрен язганнар.

Халык чыгып беткәч, Тукайның йөзе ачык хәлдә ахыргы рәсеме һәм маскасы алына.

**4 апрель.** Көндез 1 сәг. 30 минутта Тукайның гәүдәсе табутка салына, табут өстенә ак ефәк лентага үзенең шигыреннән:

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! Бар, юнәл, кит Тәңреңә;
Бирдең арканны моңарчы, инде бир бит әмренә! —

юллары язылган, кырые укалаган кара хәтфә ябыла.

Шифаханә ишегалдында, җеназа җирдән күтәрелгәч, рәсем алдырыла. Кузгалып, җеназа укыла торган мәйданга юнәләләр. Бирегә биш-алты меңләп халык көтеп торалар. Шулар арасында Казанның барлык имамнары була. Зариф хәзрәт Әмирхан (әдип Фатыйх Әмирханның әтисе) тарафыннан җеназа укыла. Җеназа соңында табутны имамнар күтәреп алалар (бу мизгел дә рәсемгә алына), һәм меңләгән халык төркеме, җеназаны озатып, Яңа бистә зиратына юнәләләр. Тукайның гәүдәсе кабергә иңдерелә (бу вакытта тагын рәсем чыгарыла). Һәркем туфрак салырга ашыга. Күмү тәмам була. Кабер өсте чәчәк өеменә әверелә. Зариф хәз-

---

Фирка — төркем.

рәт Тәбарәк укый. Догадан соң, мәрхүмнең васыяте буенча, Касыйм хәзрәт «Васыятем» шигырен укый. Соңыннан берничә кеше тарафыннан нотыклар сөйләнә.

*«Мәктәп», 4 нче сан;*
*Казанда 4 нче апрель.*
*«Истәлекләр», 128—131 б.*

Нотык сөйләүчеләр, Тукайның табутын күтәреп баручы якын дуслары, күмү комиссиясе башында йөргән Гыйльметдин Шәрәф, Шиһап Әхмәров, Габдулла Кариев, Гафур һәм Каюм Коләхметовлар була. Гафур Коләхметов Тукайның каберенә үз исеменнән венок та куя.

*«Истәлекләр», 219 б.;*
*«Кояш», 1913, 7 апрель, 89 нчы сан;*
*«Ак юл», 1913, 3 нче сан.*

Якын дусты Ф.Әмирханның Тукайны күмүгә багышланган мәкаләсе шул көнне «Кояш»та басылып чыга: «Шималь төрекләре бүген үзләренең иң мәшһүр, иң сөекле шагыйрьләрен күмәләр. Шималь төрек әдипләре бүген үз иптәшләреннән халык күңеленә иң якын тора торган берсен араларыннан югалталар. Без бүген халык шагыйре Тукайны озатамыз».

*«Кояш», 1913, 4 апрель, 88 нче сан.*

**4 апрель.** Тукайның җеназа мәрасимен, күмү күренешләрен чагылдырган биш фоторәсем алдырыла.

*Мирасханә. 9-ф., 3-тасв., 83-эш.*

Тукайның үлемен хәбәр итеп, барлык газета-журналларда некрологлар басыла.

Шушы кайгылы хәбәр билгеле булганнан соң, редакцияләр адресына дөньяның төрле почмакларыннан телеграммалар килә башлый. Петербург, Мәскәү, Харьков, Симферополь, Уфа, Тамбов, Саратов, Кунгур, Красноуфимск, Верхнеуральск, Екатеринбург, Астрахань, Семипалатинск, Әндижан, Бохара, Сәмәрканд шәһәрләреннән, Польша һәм Төркиядән кайгы телеграммалары алына. Хатын-кызлардан бигрәк тә күп телеграммалар килә. Халык Тукайга багышлап язган шигырьләрен җибәрә, киңәш-тәкъдимнәрен әйтә. «Вакыт» газетасының 1913 ел, 30 апрель санында күренгәнчә, Семипалатинск шәһәреннән берәү Тукайга һәйкәл куярга кирәклеген яза. Шагыйрь истәлеген мәңгеләштерүдә бу беренче тәкъдим була.

Вакытлы матбугатта берничә ай буена һәр газетада, һәр

санында мәрһүмнең фотолары, кайгы телеграммалары, тәгъзия хатлары, Тукайга багышланган шигырьләр, мәкаләләр басылып тора. «Мәктәп» журналы 4 нче санын тулысынча мәрхүм шагыйрь Тукайга багышлап чыгара. Якын дуслары аны сагынып хатирә-истәлекләрен уртаклашалар.

«Тукай безнең олуг милли шагыйребез иде. Тукай безнең иске тормышның черегән чүбе өстенә үскән матур чәчәгебез иде. Тукай безнең мәктәп балаларыбыз өчен, яшь буыныбыз өчен милли бер каһарманыбыз. Тукай безнең киләчәктә татар әдәбиятына салына торган таза бер нигезебез»,— дип яза «Ил» (39 нчы сан) газетасы.

Бу көннәрдә һәркем югалткан кешенең кем икәнлеген төшенә, аңлый. Татар милләте тирән кайгы кичерә.

## ИСЕМНӘР КҮРСӘТКЕЧЕ


Абдулов Әхмәди 21, 72
Абдулов Әүхәди 21, 72
Абдуллин И. 226
Агиев Ф. 112, 195, 214
Адаков Габдерәхим 184
Аитов Исмәгыйль 94, 107, 124
Адоратский В.В. 170
Акимбетова Мәрьям 203
Аксаков 171
Акчура Йосыф 125, 229
Акчурин Хәсән 130, 131,132
Алиев В. (Вәлит) 180, 184, 186
Алуши Ризван 153
Александров В.А. 122, 170
Алты-биш Сапый (кара: Сафый абзый) 12
Алтынбаев Галиәсгар 92
Алуши (Ризван) 69, 196
Антонов Л.Г. 232
Апаков Вәлиулла 25
Апанаев Бәдретдин 130
Аппаков Шәкүр 101
Ашмарин Н.И. 28

Әбүзәров Хөсәен 110
Әлмөхәммәдев Хәбибрахман 218
Әминев Барый 184
Әмиров Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы 6, 140
Әмиров Кәшфелкәбир Зиннәтулла улы 205
Әмиров Мөбарәк 221
Әмирова Б. 179, 180
Әмирова-Мөхәммәтҗанова Р. 140, 205, 209, 210
Әмирхан Зариф 254
Әмирхан И. (Әмирханов, Ибраһим) 79, 112
Әмирхан Ф. (Фатыйх) 43, 47, 69, 77, 78, 79, 83, 86, 88, 91, 94, 95, 96, 98, 99, 100, 101, 103, 105, 107, 108, 109, 111, 112, 117, 119, 124, 128, 131, 138, 141,

143, 145, 146, 152, 156, 167, 168, 169, 172, 193, 195, 196, 208, 226, 227, 229, 230, 231, 233, 234, 236, 241, 242, 247, 254
Әмрулла Габделвәли (кара: Габделвәли) 16, 19, 21
Әнвәр паша 239
Әпсәләмов Г. 229
Әхмәдиев Шәһит 143
Әхмәдуллин В. (Әхвәтвәли) 112, 185, 192
Әхмәров Ш. (Шиһап) 112, 203, 212, 228, 241, 242, 246, 251, 252, 254, 253, 255
Әхмәрова Заһирә 203
Әхмәрова Әминә 203
Әхмәтгәрәй 227, 228
Әхмәтҗан (кара: Сәйдәшев Әхмәтҗан) 190
Әхмәтҗанов Шәриф (Манатов) 215, 217, 219, 220, 222
Әхмәтсафа (кара: Байтирәков Ә.) 22

Бабич Шәехзадә 192
Байбурин (Җ.) 206
Байбурин Якуб 136, 152
Байтирәков Әхмәтсафа 22, 23, 26, 47
Байрон 165, 179
Байчура Шәриф 251
Бакиров Хәкимҗан 223, 224
Баруди Г. 167
Баттал Г. (кара: Батталов Габделбарый) 222
Батталов Габделбарый 222
Батыров Г. 92
Бах А.Н. 47
Баһаутдинова Дания 228
Башкуров Рөстәм 106, 107
Баязитов Сафа 215, 216, 217, 218, 219, 220, 221
Бәдигый Хуҗа 83, 148
Бәдри (Хисаметдинов Бәдретдин Хисаметдин улы) 12, 14, 158
Бәдретдин (Хисаметдинов Бәдретдин) 12, 14
Бәкер К. (Кәбир) 79, 112, 128, 129, 132, 139, 142, 143, 144, 216, 217, 218, 220, 221, 222, 223
Бәхтияров Вафа 73, 76, 77, 78, 79, 81, 82, 85, 86, 87, 88, 93, 95, 96, 97, 98, 101, 105, 111, 112, 118, 128, 140, 152, 172, 204
Бәшири З. (Зариф) 88, 99, 100, 108, 110, 115, 118, 119, 125, 142, 147, 150, 226, 233
Бәширов Зөфәр 227
Берлин Моисей Адольфович 152

Бибигафифә 9
Бибиҗиһан 96
Бибимәмдүдә Зиннәтулла кызы 6, 7, 8, 9
Бибисабира 11
Бибисаҗидә (Саҗидә, Сәгъди кызы) 12
Биги Габдулла (кара: Мостакаев К.) 105
Бигиев З. 108, 207
Бигиев М. (Муса) 141, 144, 192, 212, 215, 216,218
Бикбулатов М. 225
Бирюков П.И. 198
Богданов Гариф 128
Богданова Гайшә 203
Болгарская Гөлсем 203
Бочкарев И.М. 182
Буренин В.П. 135
Бурнаш Ф. 4, 181
Бурнашева М. 106, 107
Бубыйлар (бертуган Габдулла, Гобәйдулла) 173, 174

Вахитов Мулланур 203
Вәзиева Җ. 48, 54, 248
Вәли Я. 128
Вәлиди З. 150, 183
Вәлиди Җамалетдин 4, 15, 19, 228, 246
Вәлиев Р. 204
Вересаев В. 233
Водовозов В.И. 149
Г.Газиз (Гобәйдуллин Газиз) 167
Габделвәли (кара: Әмрулла Габделвәли) 16, 19, 71
Габделвәли (Олы Мәңгәрдән) 80
Габделкаюм (кара: Мостакаев К.) 130
Габделмәҗит (кара: Гафури М.) 84
Габделхәмит 54, 127
Габдерәкыйпов Рәкыйп (кара: Рәкыйби Рәкыйп) 105
Габдрахман (кара: Рахманкулов Г.) 221, 227
Габитовлар 203
Гаделшин Мортаза 23
Гаделшин Хәйрулла 66
Газизә (кара: Госманова Г.) 6, 12, 85, 89, 95
Газизә (кара: Зәбирова Г.) 9, 13, 14
Газизә (Мөхәммәтвәли хатыны) 9, 10, 86, 88, 89
Газизов Мөхәммәтгали 71

Гайнанов Р. 4, 12, 42, 52, 57, 66, 69, 100, 105, 106, 116, 117, 126, 213
Гайнанова Л. 4
Гайнетдин хәзрәт 23
Гайнуллин М. 111, 234, 248
Гайфетдинов Х. (Хәнәфи) 182, 183
Гайфи Шәһит (Гайфетдинов) 182, 184, 191
Галиәсгар (кара: Камал Г.) 161, 162, 221
Галиев А. 222
Ганиева Р. 124, 158, 164, 189, 196, 198, 201, 234, 240, 244, 247, 249
Гарифуллин Д. 252
Гаспринский И. 33, 58, 64, 110, 229
Гасрый, Нәҗип 177
Гафури М. 59, 71, 158, 167, 181, 183, 209, 214, 215, 220, 221, 222, 226, 233
Гафуров Галиәсгар (кара: Чыгтай) 49, 142, 151
Гаяз әфәнде (кара: Исхакый Г.) 80, 146, 238
Герцен 243
Гимадиев У. 144, 147
Гладышев Александр 27, 30, 39, 48
Гобәев Фәтхерахман Гатаулла улы 11
Гобәйдуллин Мортаза 21, 23, 24, 56, 62, 68, 71
Гобәйдуллин Садыйк 21
Гобәйдуллин Хәлилрахман 10, 12
Гоголь Н.В. 122, 146
Гордлевский В. 243
Горький М. 146, 163, 233, 234
Госманов Галиәсгар 12, 13, 15
Госманова Газизә 12, 85, 89, 93, 95
Гуно Ш. 93
Гучков А.И. 115
Гыйззәтуллина-Волжская Сәхипҗамал 103, 127, 129, 203
Гыйльметдин (кара: Шәрәф Г.) 207
Гыйсмәти Габдулла 212, 213

Датиев А.Г. 199
Даутов Әхмәтфәиз 215
Дашкин Әбүбәкер 181
Дәмини, Габдеррәхим 91
Дәрдмәнд 73, 74, 105, 167, 233
Дәүләтгилдиева Фатыйма 251
Дәүләтшин Габдрахман 82, 86, 95, 96, 98, 118
Динмөхәммәтов Ишмөхәммәт 165, 168, 173

Дмитриев И.А. 156
Догадов А.Н. 170
Добродеев 192
Дулат-Алиев Мәхмүт 83, 130, 140, 168, 229
Дулат-Алиева Ләлә 229
Думави Н. 71, 77, 106, 143, 159, 167, 226, 233

Жилкин И. 54, 55

Җамали 9
Җәлал, Вакыйф 146, 154
Җәләлетдинов Г. (Гайнетдин) 46
Җәүдәт Габдулла 137
Җиһаншин Мөхәммәтша 218

Закирә апа (Шәрәф) 203
Зариф Мөхәммәтгалим улы 6
Зариф хәзрәт (кара: Әмирхан Зариф) 255
Зәбири Хәбибрахман 83, 94, 95, 112, 215
Зәбиров Х. (Хөсәен) 77
Зәбирова Г. (Газизә) 9, 13, 14, 41, 132
Зиннәтулла (кара: Әмиров З.) 6, 7, 8, 9, 10, 205
Зәйтүнә (кара: Мәүледова З.) 163, 198, 230
Зөһрә 11

Ибраһимов Г. (Галимҗан) 3, 5, 24, 62, 76, 77, 79, 141, 145, 146, 149, 152, 153, 167, 169, 170, 171, 172, 173, 177, 189, 191, 202, 208, 231, 246, 247
Ибраһимов Габдрәшид (кара: Ибраһимов Рәшит) 125
Ибраһимов Гыйльметдин 115
Ибраһимов Рәшид (кара: Ибраһимов, Габдрәшид) 33, 108
Иманаев Шәехгаттар 230
Иманколый Садыйк 207
Иманкулов Садыйк (кара: Иманколый Садыйк) 217
Исәнбәт Н. 168, 178, 225
Искәндәрова Мәрьям 126, 184
Искужин З. 193
Исмәгыйль Р. 231
Исмәгыйлев-Ширванский (Мостафа Лотфи) 214
Исхаков Лотфулла (Лотфи) 215, 218, 220
Исхакый Г. (Гаяз, кара: Гаяз әфәнде) 24, 70, 80, 141, 167, 193, 207, 229, 233, 234, 238, 240, 245, 246

Ишми ишан (кара: Динмөхәммәтов Ишмөхәммәт) 81, 168, 173

Йосыфов Хәкимҗан 67
Кадыйри Кыяметдин 130, 131
Камал Г. (Галиәсгар) 54, 73, 78, 82, 84, 102, 103, 110, 119, 120, 128, 131, 143, 144, 145, 161, 162, 168, 169, 170, 204, 206, 221, 244
Камалетдинов, Галиәсгар (кара: Камал Г.) 145
Камалова Гөлсем 203
Камил (кара: Мотыйгый К.) 32, 41
Камилә 6
Карамзин Н.М. 102
Карахмәт 104
Кариев Габдулла (Миңлебай Хәйруллин) 16, 19, 21, 23, 32, 34, 56, 57, 61, 67, 71, 72, 85, 103,129, 203, 252, 255
Карлова Т. 79
Карлова Мария 101
Касыйм хәзрәт 255
Катанов Н.Ф. 253
Каюмов Ш. (Шәриф) 17, 21, 25
Кәбир (Әмиров Кәшфелкәбир) 210
Кәрим (Максудов) 215
Кәрими Ф. 24, 29, 94, 95, 167, 207
Кәримов Фатыйх (кара: Кәрими Ф.) 100, 193
Кемаль Нәмикъ 112
Клячкин Г. 234, 243, 244, 247
Князев В.В. 118
Коләхметов Гафур 148, 167, 168, 185, 212, 226, 227, 255
Коләхметов К. (Каюм) 227, 255
Колшәрәфи (Кашани) 55
Кольцов А.В. 31, 90, 132
Конкель Марек 47
Крылов И.А. 28, 34, 35, 45, 53, 65, 107
Кудаш Сәйфи 87
Кулахметов Г. (кара: Коләхметов Гафур) 226
Кули Ибраһим 170
Кулиев В.М. 62
Курамшин Ш. 16, 17
Кырымбаев Мирсәяф 199

Лаисов Н. 155, 206, 240
Латыйпов Гариф 93

Латыйфә (кара: Әмирова Латыйфә) 9, 205
Ленин В.И. 170
Лермонтов М.Ю. 13, 16, 50, 57, 64, 68, 69, 81, 82, 85, 89, 90, 91, 98, 99, 109, 118, 123, 124, 132, 146, 165, 171, 187, 201, 202, 208, 212, 214, 216
Лотфи Мостафа (кара: Исмәгыйлев-Ширвинский) 184, 186
Лурия Р.А. 242, 251

Магдеев М. (кара: Мәһдиев М.) 198
Максудов Галим 215
Максуди Һади 55, 156, 157
Майков А.Н. 103, 135, 148, 171, 201
Маһруйбикә 11
Мәгарри 59
Мәмдүдә (кара: Бибимәмдүдә Зиннәтулла кызы) 6, 7, 204
Мәргүбә 6, 21
Мәфтүхә Мөбин кызы 23
Мәүледова Бибиҗиһан 96
Мәүледова Зәйтүнә 96, 98, 99, 101
Мәрҗани Шиһабетдин 237
Мәрҗани Мәхмүд 233
Мәхмүдев Хөҗҗәтел-Хәким 48, 50
Мәһдиев М.(кара: Магдеев М.) 198, 229, 245
Меньшиков 206
Мирәхмәдов Г. 234
Миңнуллин Р. 187
Мидхәт Әхмәд 146
Мозаффария Маһруй 84, 195, 251
Мозаффаров Мансур 194
Мопассан Г. 53
Морадый Ярулла 13, 15, 28, 35
Моратов Әҗдәр 184
Мортазин-Иманский В. 129
Мортазин Фатыйх 214
Мостакаев Каюм (Габделкаюм, кара: Биги Г.) 105, 107, 113, 128, 130
Мостафин Әмин 251, 253
Мостафин Габделләтыйф 124
Мостафин Кәшфи 152
Мостафа Ләтыйф (кара: Мостафин Габделләтыйф) 124
Мотыйгулла (Төхфәтуллин Мотыйгулла Төхфәтулла улы) 15, 19, 22, 121
Мотыйгый К. 13, 14, 15, 16, 17, 18, 19, 20, 22, 25, 26, 27, 28, 29, 30, 32, 42, 45, 48, 53, 64, 65, 67, 68, 71, 75, 84, 182

Мөхәммәди 21
Мөхәммәтгалим 6
Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалим улы 6, 7, 9, 22
Мөхәммәткамил әл-Мотыйгый Төхфәтуллин (кара: Мотыйгый К.) 25, 29
Мөхәммәдев Даут 180, 184
Мөхәммәдъяров Шакир 216, 217, 218, 220, 222
Мөхәммәтвәли 9, 10
Мөхәммәтҗан Хафиз 206
Мөхәммәтшәриф 9
Мөхетдинов-Сәрдәи Гыйләҗетдин 166
Мөхетдинова Әминә 203
Муса әфәнде (кара: Бигиев М.) 217
Мусин М. 75
Мусин Мухамед Гали Фазлиевич (кара: Мусин М.) 76
Нариманов Нариман 172, 180
Насретдин әл-Хуҗаши 60
Насыйри К. 167
Нафигов Р. (кара: Нәфыйгов Р) 5, 27, 28, 40, 48, 50, 56, 65, 94, 104, 118, 122, 136, 168, 170, 192, 200, 202, 203
Нәкыйпов Ф. 165
Нәфыйгов Р. (кара: Нафигов Р.) 13, 14, 27, 55, 65, 136, 232
Недоносков В.В. 49
Нигъмәтуллин Нәҗип 62
Никитин И.С. 134
Ниязи Габдрахман 181
Ниязи Гани 182
Ниязов Пирмөхәммәт 25
Нурания 209
Нурбиби 182
Нуриәхмәт 17
Нуруллин И. 14, 15, 26, 61, 62, 72, 79, 80, 86, 87, 97, 98, 99, 107, 118, 131, 132, 140, 149, 164, 170, 174, 181, 184, 185, 186, 187, 202, 205, 206, 208, 209, 212, 215, 225, 226, 229, 230, 231, 233, 237, 240, 252

Островский 163

Патин Кәшшаф 63, 145
Пинкевич А. 97, 98, 99
Плещеев А. 105, 171
Позняков Н.И. 133
Покатилов Николай 39

Поленц В. 79, 244
Поль А.Р. 217
Помиранцев Л. 37
Пурешкевич 71
Пушкин А.С. 13, 14, 16, 45, 49, 50, 57, 81, 85, 98, 99, 109, 118, 120, 132, 146, 147, 149, 156, 165, 170, 171, 187, 197, 202, 216, 219

Рабига (кара: Әмирова-Мөхәммәтҗанова Р.) 205, 208, 210
Радлов В. 167
Рахманколый Солтан 124, 135
Рахманкулов Габдрахман (кара: Габдрахман) 213, 221, 222, 223, 224, 228
Рәкыйби Рәкыйп (кара: Габдрәкыйпов Рәкыйп) 105
Рәмиев Закир (кара: Дәрдмәнд) 74
Рәмиев Зөфәр 118, 134, 145, 157, 190
Рәмиев С. 80, 87, 91, 97, 101, 106, 111, 112, 113, 121, 122, 126, 151, 157, 165, 167, 168, 172, 173, 177, 180, 182, 184, 185, 186, 190, 201, 207, 208, 233, 234
Рәсүлева З. 9, 79, 83, 140, 164, 180, 203, 205, 209, 229
Рәхимә апа (Шәрәф) 203
Рәхмәтуллин Фәтхетдин 13
Рәшид әфәнде (кара: Ибраһимов Габдрәшид) 33
Романовлар 241, 243

Сабир (Галиәкбәр) 62, 104, 105, 234
Сабирҗанов Ахун 11
Садретдин 11
Садретдинов Зәкәрия 247
Садретдинов Ш. 151, 173, 177
Саҗидә (кара: Хәбибуллина Бибисаҗидә Зиннәтулла кызы) 6, 10, 20, 79
Саинова Гайшә 203
Саинова Мәрьям 203
Сакаев Н. 129
Салихов Сәгъдетдин Шәмсетдин улы (кара: Сәгъди) 22
Саллави Фоат 203
Сафа әфәнде (кара: Баязитов Сафа) 219
Сафый абзый (кара: Алты-биш Сапый) 41
Сафин Д. 85
Сәгыйть Кәрим (кара: Сәгыйтов К.) 32, 234, 235
Сәгыйтов Габделкәрим (Кәрим) 216, 218, 220
Сәгыйтова Э. 233, 236
Сәгыйть (кара: Рәмиев С.) 181
Сәгъди 10, 11, 12, 14, 22
Сәетзадә Закир 97

Сәйдәшев Әхмәтҗан 44, 46, 50, 52, 85, 113, 125, 147
Сәйдәшев Мөхәммәтҗан 113, 157
Сәйфетдинов Г. 168
Сәйфи-Казанлы Фатыйх 4, 126, 129, 134, 143, 190, 252
Сергеев-Ценский 163
Сипаев Мәхмүт 218
Сиражетдинов Әхмәтша 13
Сиражи 62
Созонович 71
Соловьев Тимершаһ 115, 147
Солтанов Зәйни 185
Солтанов Мөхәммәдъяр 60, 160
Степанов 95
Сүнчәләй С. (Сәгыйть) 143, 161, 165, 169, 171, 172, 173, 179, 181, 193, 196, 199, 200, 201, 228

Тажетдинов Н. 94, 95
Терегулова Әминә 203
Терегулова Мәдинә 203
Трейтер Г.А. 94
Толстой Л.Н. 41, 50, 53, 69, 79, 132, 157, 158, 189, 198, 240, 243, 248, 249
Төхфәтуллин Камил (кара: Мотыйгый К.) 22, 30, 33, 56, 67, 75, 76
Төхфәтуллин Х. 16
Туктаров Ф. 79
Тулбаев Габдерәкыйп 50
Туликов 182
Туприев Гайнетдин 121
Тухфатуллин Камиль Мотыйгуллович (кара: Мотыйгый К.) 76

Укмасый М. 6, 9, 10, 79, 84, 143
Уралец Касыйм 98, 99, 100
Урманчиев Әхмәт 142, 143, 145, 180, 195, 206, 208, 213, 216, 221, 223, 225, 238, 252
Ушинский К.Д. 136
Утабалиев Габдерәхим 180, 185
Үмәров Латыйп 180

Файзи А (Фәйзи Ә.) 27
Файзә 6, 79
Фатыйма 41
Фатыйх (кара: Әмирхан Ф.) 206, 247
Фәйзуллин-Болгарский 103

Фәйзуллин Мөхәмматшакир 7
Фәйзуллин М. 242
Фәтхерахман (кара: Гобәев Фәтхерахман Гатаулла улы) 10, 11
Фәхретдинов Р. 24, 59, 167
Фәхретдинов Харис 126, 129
Федоров А.М. 144
Фикъррәт Тәүфыйк 146
Франклин Джон 102

Хаҗи-Теләши М. 199, 206
Халит Г. 124, 201
Харитонов И.Н. 210, 223
Харис Габдулла 251
Хафизов С.Х. 108
Хәбибуллина Бибисаҗидә Зиннәтулла кызы 6, 10, 20, 79
Хәдичә (Ямашева Х.) 203
Хәйруллин Миңлебай (кара: Кариев Г.) 23
Хәйруллин Рәхмәтулла 19, 62
Хәлим ахун 49
Хәмидуллин Вәлиулла 24
Хәнәфи (кара: Гайфетдинов Х.) 183
Хәсән бай (кара: Акчурин Хәсән) 130
Хәсәни Әхмәтгәрәй (Хәсәнов Гәрәй) 113, 226, 230, 231, 248, 249, 253
Хәсәни Зәйнәп 203, 250
Хәсәнов Барый 226
Хәсәнов Г. (Гәрәй) (кара: Хәсәни Әхмәтгәрәй) 168, 226
Хәсәнов Кәлимулла 71
Хикмәтуллин Гали 17,18
Хисаметдинов Камалетдин 158
Ходаяров Галәэтдин 191
Хөсәенов Вәли 229
Хөсәенов Гомәр 25
Хөсәенов Хәсәнҗан 45, 63
Хөсәенов Хөсәен 233

Һади Закир 71, 156, 167
Һейне Һ. 103, 243
Һилалов И. 223, 224
Һинди Минһаҗ 108

Чайковский П.И. 219
Чәләби Мөхәммәд 101, 102

Чернышевский 243
Чертков В.Г. 198
Чулпаный Мирхәйдәр 15
Чыгтай (Галиәсгар Гафуров) 49, 111, 142, 144, 151

Шакирҗан 6
Шакиров З. 112, 152
Шамил Касыйм 97, 103, 112
Шаляпин 111
Шәрәф Борһан 78, 103, 115, 117, 130, 138, 203
Шәрәф Гыйльметдин 71, 72, 73, 77, 80, 82, 86, 93, 102, 103, 104, 107, 111, 170, 203, 207, 208, 225, 228, 228, 254
Шәрәф Шәһер 33, 86, 115, 116, 147, 167
Шәрипов Фатыйх 52, 53
Шәриф Азиз 104, 105
Шәрифә 7
Шәһидуллин Шәрәф 226, 238
Шәһит (кара: Гайфи Шәһит) 192
Шинаси Ибраһим 178
Ширвани Мөхәммәтһади 84, 91

Юлдашев Габдерәшит 178

Якобсон И. 229, 252
Якупов Р. 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 13
Ямашев Хөсәен 83, 168, 203, 212, 213, 217
Ямашева Хәдичә (кара: Хәдичә) 203
Яраева Мәүсәфә 179
Ярулла мәзин 17
Яушев Муллагали 223
Яфаров Бәкер 55, 101, 102

Яхин Ф. 20, 27, 28, 29, 40, 84

# ЭЧТӘЛЕК

Редколлегиядән . . . 3
1886 . . . 6
1888 . . . 7
1889 . . . 7
1890 . . . 8
1891 . . . 9
1892 . . . 10
1893 . . . 11
1894 . . . 12
1895 . . . 13
1896 . . . 13
1898 . . . 14
1899 . . . 14
1900 . . . 15
1901 . . . 15
1902 . . . 16
1903 . . . 20
1904 . . . 21
1905 . . . 26
1906 . . . 33
1907 . . . 62
1908 . . . 88
1909 . . . 112
1910 . . . 140
1911 . . . 168
1912 . . . 205
1913 . . . 236
Исемнәр күрсәткәче . . . 257

Научно-популярное издание

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙ**

**Летопись жизни и творчества**

(на татарском языке)

Мөхәррирләре *Р.Ф.Рахмани, Р.М.Касыймова*
Рәссамы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *М.Ш.Хәйруллина, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.12.2003. Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Антиква» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 14,28.
Шартлы буяу-оттиск 14,49. Нәшер-хисап табагы 13,08. Тиражы 2000. Заказ Я-756.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.